# казан утлары

6

ИЮНЬ • 1978

## 1978 ел өчен республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләрен бирү турында



Р. А. ФӘЙЗУЛЛИН



С. О. ЛЫВИН

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләре Комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң, 1978 ел өчен республиканың Габдулла Тукай исемендәге премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:*

*Шагыйрь РАВИЛ АБДРАХМАНОВИЧ ФӘЙЗУЛЛИНГА — «Шигырьләр һәм поэмалар» китабы (1976) өчен;*

*Художник СЕРГЕЙ ОСИПОВИЧ ЛЫВИНГА — «Татарстанда Ленин булган урыннар буйлап» картиналары сериясе һәм Г. Тукайга багышланган эшләр циклы өчен.*

# Казан утлары




АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**
ИЮНЬ
1978

## БУ САНДА

**Б. КАМАЛОВ.** Ярсөяр әрәмәсе. Повесть . . . 3
**Н. АРСЛАНОВ.** Бакча юлы. Шигырьләр . . . . 34
**Ф. САФИН.** Казан гомере. Шигырьләр . . . . 42
**Ә. СӘЙФЕТДИНОВ.** Җырла, иркәм! Повесть . . 44
**Ф. ЯРУЛЛИН.** Бер сүз әзлим. Шигырьләр . . . 79
**З. МАНСУРОВ.** Кояш чыгышы. Шигырьләр . . 83

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

**С. ХАФИЗОВ.** Согданелла. Хикәя . . . . . . . 87

ӘДӘБИ МИРАС

**Г. ХУҖИЕВ.** Ярата идем мин сезне... Героик драма . . . . . . . . . . . . . . . . 94

ОЧЕРКЛАР

**А. РЕМАКЛЬ.** КамАЗ турында легенда . . . . 117
**Д. ШӘРӘФЕТДИНОВ.** Сабан туе — халык яшьлеге . . . . . . . . . . . . . . . 126
**Г. ХӘБИБУЛЛИН.** Галим, җәмәгать эшлеклесе . . 134
**Г. ВОЛКОВ.** Казан — мәхәббәтем минем . . . . 140

СӘНГАТЬ

**Ш. РАХМАНКУЛОВ.** Бию — егет һөнәре . . . . 146

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ү. ГЫЙМАДИЕВ.** Тукай мирасы турында «Ялт-йолт» . . . . . . . . . . . . . . . . 154

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Ф. МУСИН.** Хәзерге авыл һәм әдәбият . . . . 160

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.** Тарихыбызның яңа сәхифәсе 168

**А. ӘХМӘДУЛЛИН.** Әдәбиятның яшәү көче турында . . . . . . . . . . . . . . . . 170

**М. МӨЛЕКОВ.** Бердәм гаиләдә . . . . . . . . 173

ТӨРЛЕСЕННӘН

**А. МИХЕЕВ.** Шершель көндәлеге . . . . . . 176

Әбелфәрәҗнең «Кызыклы вакыйгалар китабын»нан . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Р. ГАРИПОВ.** Сер бирмәү. Нәни хикәяләр . . . 184

**И. ТУКТАР.** Җөмләләр . . . . . . . . . . . 186

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНГА 50 яшь** . . . . . . . . . 187

Рәшит Ваһапов . . . . . . . . . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

**Редколлегия:** **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 20/II-1978 ел. Басарга кул куелды 3/V-1978 ел. ПФ 09001. Кәгазь форматы $70\times108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000 экз. Заказ В-69. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

**Барлас Камалов**

# ЯРСӨЯР ӘРӘМӘСЕ

ПОВЕСТЬ



Госман бәгыренә ут кабасын белми дә, сизми дә иде әле. Басу карап йөргәндә гомерлек механизаторның күңеле шатлык белән тулы иде. Яз шатлыгы белән.

Әйе, җир ябага койды.

Табигать кыш белән саубуллашты.

Бозлы елгасы читләрендә, ерым буйларында, үзәнлекләрдә үскән кызыл талда йөнтәс песиләр кабарынды. Чикләвек куаклары өстендә сары тузан күтәрелгәндәй булды. Зирек тә чәчәк ата. Юл кырыйларындагы үги ана яфрагы чәчәкләрендә алтын ут кабынды. Каен суының бөреләргә мул йөгергәне сизелеп тора. Хәер, куакларның бүтәннәре дә бик әрсезләнеп бөре тутыра инде.

Шөпшәләр, бал кортлары безелди башлады, күбәләкләр канат җилпенде. Кырмыскалар, соңгардык лабаса дигәндәй кабаланып, җир өстенә чыкты. Аларның чүмәлә-«крепостьлары» мыж килә.

Карга оялары тирәсендәге шау-шуга исең китәр. Елтыр канатлар иске йортларын сипли, яңаларын кора. Әлегәчә боек-ятим торган сыерчык ояларында да җанлылык. Апрель башларында ук көтү-көтү кайтып төшкән сыерчык егетләре, бикәчләре килүгә йорт-җирне хәстәрләп, канат кага-кага, дәртләнеп сайрарга тотынды. Көннән-көн мулрак сибелгән кояш нурларына кинәнеп җәйрәгән басулар өстендә, күзгә күренер-күренмәс кенә нокта булып, тургай моң тарата. Күк зәңгәрлеген иңләп, җиңел җилкәнле көймәчекләр теземедәй, кыр казлары, торналар кайта. Күк гөмбәзенә реактив самолет сузып калдырган ак ефәк тасма гүя аларны котлап тирбәлә. Диңгезләр кичеп кайтып җиткән киек казлар: «Ярсөяр әрәмәләре шушы! Ярсөяр күлләре шушы! Кыйгак-кыйгак! Чынлап-чынлап! Саумы, кадерле туган як!» — диләр төсле. Торналар, билгеле инде, тавышны бөердәнрәк алалар: «Торыйк-торыйк-торыйк! Җиргә төшик, оя корыйк!» — дип киңәшәләр кебек.

Барча җан иясе кояшка — җылыга, яктыга тартыла, язгы дәрт белән яңа тормыш башлый. Шуңа күрә апрель кеше йөрәген дә үзенә бер төрле җилкетәдер. Адәм баласының күге биегәя, сыны турая, йөзе көләчләнә, сүзендә тапкырлык, җорлык арта.

Госман Галиев, илле өченче язын каршылаган ир, басу кочагыннан шәп кәеф белән кайтты. Ярсөяр кулләренә кыйгачлап килеп төшкән киек кошларның үз телләрендә сөйләшеп, шөкранә итә-итә канат кагынулары аның күңелендә бөтенләйгә тынып калгандай булган нечкә кылларны өр-яңадан яшьлектәгечә тибрәтеп җибәрде. Саз түмгәкләренең берсенә утырып, кошларны күзәтте ул. «Сезгә дә шул тикле якынмыни соң туган төбәкләр, асылларым?» Аның иреннәре шулай пышылдады. Юктан-бардан гына мәлҗерәп төшә белми торган кешенең дә күңеле моң белән тулды. Моң дигәч тә, моңаю, бәгырь күмерләнүе, өметсезләнеп иңрәү түгел иде бу. Юк, һич юк! Тыштан чакматаштай күренсә дә, йөрәгенә нечкәлек ят булмаган игенченең — җир кешесенең — сулаган һавасына, эчкән суына, учына алган ашлык бөртегенә, бар булдыгын рәхәттә сугарган туган табигатенә гашыйклыгы иде. Ә гашыйклар көчле-кодрәтле булалар, үз күңелләрен көр дә, хөр дә итеп кенә калмыйлар, сүнек-сүлпәннәргә дә рух өстиләр.

Госманның җыр остасы дигән зур даны юк, гармун-скрипка уйнап та телгә кергәне булмады. Шулай да җанының иң эчкәресендә җырчы иде ул. Бүтәнчә булуы да мөмкин түгелдер кебек. Бозлы суы буенда, Ярсөяр әрәмәлегенә сыенып утырган Яртуган авылында туып үскән кешенең кайсын кем һәм кайчан җырга үги иткән?!

Ни сәбәпледер, күзен-кашын сыпырып куйгач, Госман, уйлап-сайлап тормастан, үзенә генә ишетелерлек итеп җыр башлады.

Айлар аяз туса иде,
Еллар имин булса иде;
Еллар урынына ел туар,
Гомер озын булса иде.

Кошлар исеменнән итеп әйтүе идеме соң әллә бу сүзләрне? Үзенең язны сагынуын аңлатуы идеме? Кем генә өзеп җавап бирсен инде моңа? Җанның мөлдерәмә тулып ташуы дисәң, дөресрәк булмасмы?

Тәненә суык үтә башлаганын тойгач кына торып басты ул. Киек казларга кул болгады да авылга таба кузгалды. Читтән берәрсе карап торса, «машина белән җенләнгән бу адәмнең акылына ят җил кагылдымы икән әллә?» дияр иде, мөгаен.

Ләкин бернинди дә ят җил кагыла алмаслык хәлдә көчле, саф, шат, самими иде бу минутларда Госман Галиев. Яз кояшының яктысы аның күңелен балкыта, җылысы тәненең һәр күзәнәген назлап җылыта иде.

— Әниләрен ияртеп килермен әле. Чәчүгә чыкканчы ирек ачуыбыз шул булыр, — дип күңеленә беркетеп куйды ул. — Күл-су хуҗаларын, күк асылларын күреп кайту Галимәгә дә кызык булыр аннан ары... Сәерсенер инде, канишны. «Олыгайган саен акылың саега барамы соң әллә, этиләре?» — дип әйтүе дә бар. Ничава диярмен, бер яшьлектә, Галимәкәй, бер картлыкта...

Мәгәр аның нияте чынга ашмады. Иртән торуына җир өсте ап-ак булган, җилләп-җилләп юеш кар ява иде. Кышның бу якларда нindидер йомышы калган, күрәсең, борылып килгән. Тәрәзә төбендә чәчәк атарга өлгергән яран гөл чәчкәләре әйтерсең лә: «Бу ниткән тоташ аклык?» — диешәләр иде.

Язга көйләнеп, җиңеләеп калган күңелләргә шыксызлык бәрде, тәнгә — суык, җанга пыскак рух кагылды. Алай да улының туган көнен уздыру мәшәкате Госманга сукрап-сыктап торырга җай калдырмады. Галимәсе аны ике кат кибеткә җибәрде дә, тегесен кушты, монысын гозерләде. Кунак килә — ит кирәк, ит булмаса, бит кирәк дигәннәр. Аталы-уллы механизаторлар йортында ит бар инде ул барын. Өстәл заманча булсын дисәң, бүтәне аз кирәкмени?! Өлфәтнең кордашлары канәгать китсеннәр.

Аннары шунысы да хәтер почмагыннан ычкынмаска тиеш: килен буласы кыз бала да мәҗлес түрендә утырачак. Госман йортына аның беренче килүе түгел түгелен, әмма бәйрәм табынында булганы юк әле. Бик акыллы, ипле, җайлы бала күренә. Төскә-биткә дә карап кына тормалы. Казагыстаннан килеп укыган да, Казанда медучилище тәмамлагач, Ташбуа районына җибәргәннәр. Райүзәктән монда, Яртуганга. Авылда медпункт мөдире. Сәвия исемле.

Өлфәт сиздереп куйды, сабан туена никахлашмакчылар. Яз тиз үтә ул. Халыкның мәйданга төшәр көне җиткәнен сизми дә каласың. Чәчүгә чыккан сәгатьтән башлап кара көзгә чаклы тракторчы, комбайнчы, шофер өчен көн белән төн аермасы җуела дисәң дә, шагыйрьләрчә бизәкләү генә булмаячак. Ризык булдыруны тикмәгә генә «ашлык өчен көрәш» димәгәннәр. Ә көрәшнең җиңеле буламыни?! Менә шул уттай эш арасына туй да килеп керәчәк, димәк...

Шундый-шундый хәлләр.

Туган көн тантанасы хәстәрен күреп, көн узганын тоймадылар да. Әдәплелек билгесе — иелеп сәлам биргәне, якын иту билгесе — кичектерми килгәне дигәндәй, өндәүле яшьләр бик төгәл халык булып чыкты. Шаулап-гөрләп, һәммәсе диярлек бергә килеп керделәр. Сәгать җиде тулганда, кунаклар зур яктагы өстәл янында иделәр инде. Чәчәккә тиңләрдәй кызлар, егетләр. Чибәрләр, ыспай, нәзакәтлеләр.

Ашның тәме ипи-тоз белән, мәҗлес яны дусларча сүз белән. Кинәнеп китеп сөйләштеләр, көлештеләр, бәхәсләшеп алдылар. Өлфәтне котлау сүзе дә аз булмады.

— Гомер чаның егерме өчне сукты. Солдат боткасын ашап карадың. Күн итек чистарта беләсең, билкаеш тимеренең көзгедәй булырга тиешлеге мәгълүм...

— Тракторист та син, комбайнер да, токарь да, слесарь да, гармунчы гына түгел. Шулай да тагын йөз ел яшәргә рөхсәт...

— Госман абый орденнарына күз яндырып кына торырга рөхсәт юк ләкин. Үзеңә алырга вакыт. Ике-өч ел срок сиңа!

— Дуадак каздай йөрүең дә җитте. Даешь кызыл туенны!..

Беравыктан мәҗлестәгеләргә җыр дәрте керде. Һәр буынның үз җыры. Татарча да әйттерделәр, русча да җырлап алдылар. Ни әйтәсең, солдаттан җырламый гына кайтмаган егетләр! Ә кызлар, кызлар үзләре җыр чишмәсе ич инде алар.

Сәвиянең тавышы әйтүле икән. «Рәйхан»ны шул тикле матур итеп җырлады, көйнең һәр бормасы йөрәккә май булып ятты. Җырны бик ошатып кәефләнгән Госман хатынына ым кагып, күз кысып алды: «Ишетәмсең, Галимәкәй?! Өлфәтебез сандугачның ниндие белән оя корасы».

Җыр кытыгы көчәеп киткәч, бәйләнә калдылар бит Госманның үзенә. Улының туган көне хакына җырла да, вәссәлам! Бик кыстагач, бәйрәм сые да кымыржкытып торгач, гармунчыны борчымый-хафаламый гына сузып җибәрмәсенме йорт башы!

Тузгын чәчләреңне ашкын җилгә тиңлим,
Бит уртаңны багалманың пешкәне дим;
Елмаюың — нур чишмәсе — корымасын,
Йөзләреңне гел балкытсын, сулдырмасын.

— Чистайда авыл хуҗалыгы техникумында укып йөргән елларында өйрәнеп кайткан җыры,— диде Галимәсе. Әллә бик риза-бәхил иде ул иренең җырлавына, әллә тартынып куюы иде. Госман исә башлаганын бетерми ташлаучылардан түгел, тирән итеп тын алды да җырында булды.

Көмеш кыңгырау чыңына тиң көлүең,
Аккош күлдә йөзгән кебектер йөрүең;

Тәнгә — сихәт, җанга — шифадыр сүзләрең,
Күзләрең ки — мәхәббәтнең үз күзләре...

Мондый очракларда була торганча, рәхмәт дия-дия, мактап кул чаптылар. Аннары яшьләр, өстәл артыннан кубып, биешеп алды.

Мәҗлеснең тәнәфесләре дә булмый калмый. Андый чакларда күмәк сөйләшүдән аерым-аерым гәпләшүгә күчәләр. Яшьләр шулайрак тын алган минутларның берсендә Госман да Сәвия белән сөйләшеп китте. Күңелендә борынлап барган сорауларын биреп бакты. Булачак килен сүзгә саран түгел, өлкәннәр белән әдәпле итеп сөйләшә белә иде.

Тумышлары белән Нократ ягыныкы икәннәр. Чирәм җирләр күтәрә башлагач, әтисе, семьясын алып, яткын дала якларына киткән. Гаиләдә өч бала үскәннәр. Сәвия уртанчысы. Әтисе хәзер совхозда бүлек управляющие, күчеп барган елларда тракторда эшләгән, аннары механизаторлар бригадиры иткәннәр. Әнисе исәп-хисап эшендә икән.

— Әтиегез ничә яшьтә инде? — дип тә сорады Госман.— Сугышта булганмы?

— Әткәй егерме дүртенче елгы, Госман абый,— дип җавап бирде кыз.— Өч ел чамасы йөргән сугышта. Германиягә җиткәч, Көнчыгыш Пруссиядә яраланган. Сул кулы бик үк таза түгел.

— Алаймыни?..— Госман авыр сулап куйды.

Ил өстенә яу ябырылган көннәр хатирәсе бастымы, булачак кайната тынып калды. Шулай да Сәвия аның яныннан кинәт кенә торып китәргә базмады. Олы кешенең сүзе бетмәгән булуы бар дип уйлады. Ялгышмаган икән, Госман янә сүз башлады.

— Әти-әниең ни атлылар, Сәвия сеңелем?

— Әнкәй Гөлниса исемле. Әткәй — Әхмәт. Тулы исеме Миңнәхмәт инде аның. Кыскартып әйтәләр.— Сәвия елмаеп куйды. Аның мәрҗәндәй тезелешеп киткән ак тешләре ялтырады. Ташкүмер карасыдай күзләрендә нур очкынланып алды.— Руслар Ахмет Гафарович дип тә, дядя Миша дип тә йөртәләр.

— Ничек, ничек? — Госман әсәрләнеп китте. Чаларган кашлары җыерылып, бергә тоташкан шикелле булды. Йөзе үтә җитдиләнде.— Синең фамилиягә бәйләп карасак, сеңелем, фамилиясе Сөнгатуллин бит инде?

— Әйе, Госман абый. Миңнәхмәт Гафарович Сөнгатуллин.

— Һы-ы...

Госманның йөрәгенә пәке белән сызып җибәрделәрмени! Ул утырган төштән чайкалып китә язды. Чырае агарып калды. Тулы түгәрәк йөзенә пудра яктылар диярсең. Шулай да ул үзен бик тиз кулга алырга өлгерде. Сәвия аның рухи халәтендәге бу кискен үзгәрешне абайламый да калды шикелле. Һәрхәлдә, телләнеп берни дә әйтмәде. Госман исә, батканда саламга ябышкан төсле, кире җавап өметләнеп, сорау бирде.

— Вятка буеннан дисең? Миңнәхмәт Гафарович Сөнгатуллин дисең? Уң битендә зур гына миңе дә бармы әллә, гафу ит, сеңелем?

— Бар, Госман абый, бар. Шул миң аркасында исемен дә Миңнәхмәт кушканнар аның. Әллә танышыгызмы? Фронтта бергә булган идегезме?

Госман үзен бозлы суга салган шикелле хис итте. Тәне чымырдады, ә сулышы кайнар иде, бугазын көйдерде. Тик сынатмаска, Сәвиягә сиздермәскә кирәк иде, тешен кысып чыдады.

— Шунысын да сорыйм әле, сеңелем, аннан ары,— диде ул, үз-үзен җинеп.— «Батырлык өчен» медале бармы әтиеңнең?

— Бар, әйе. Димәк, танышыгыз? — Сәвия күзләрен зур ачып, Госманга текәлде һәм торып басты.— Кызык!

— Кызык шул!.. Алай... Бик ихтимал... Көтмәгәндә нинди яңалык!— диде Госман.— Я, ярый, тоткарламыйм...

Сәвия, яшьлегенә бирелеп, әле генә ачылган яңалыкны Өлфәткә, иптәшләренә ирештерергә ашыкты. Ә Госман, йөрәгенең котырынып тибүенә тәкатьсез калып, аш-су ягында чәй хәстәрләү белән мәшгуль Галимәсе янына чыкты. Хатыны аның кәефсезлеген күз сирпеп алу белән аңлады.

— Нәрсә? Йөрәгең шаярамы? Кирәкмәс иде шул рюмкага кагылырга... Ятып торамсың?

Госманның йөзендәге яра җөе шәмәхәләнеп чыккан иде. Хәерле фал түгел!

— Юк, ятмыйм, Галимәкәй, ятмыйм... Һавага чыгып керим әле, тыным кысыла...

Госман киенеп урамга чыкты. Болдырдан төшеп җиткәнче үк манма су булып тирләде, хәле бетте. Капка төбендәге эскәмиягә чыгып утырды.

«Миңнәхмәт белән кода булу насыйпмыни соң миңа?» дигән сорау миен бораулады аның. «Язмышның нинди каһәре төшеп, шундый очраклыкка дучар булдым мин? Кабергәчә уңалмас бер җәрәхәт ләбаса бу минем күңелгә. Ничек туйга чакырырмын мин аны аннан ары? Чакыргач, ни рәвешле каршыларммын? Ничек итеп күрешергә кул сузармын? Ничекләр итеп кенә тел тибрәтеп «Кода!» диярмен? Ни җаным белән туганлашырмын?»

Госманның күз алдына кырык дүртенче елгы хәлләр килде.

...Июнь азагы. Кырык сигезенче армиянең көчле һөҗүмгә күчәргә җыенган көннәре. Полк разведчикларына эшнең нык арткан чагы. Заданиеләргә аларның иң кыюларын җибәрә тордылар. Бобруйск тирәсенә баручы төркемгә дүртәү билгеләнделәр. Госман бүгенге кебек истә тота: башлыклары — Чиләбе егете Краснов, Тбилисидән Леван Урушадзе, Вятка буеннан Миңнәхмәт Сөнгатуллин һәм ул. Бурычлары тел алып кайту, гитлерчы офицерны эләктерү.

Мең бәла, мең дә бер газап белән максатларына ирешеп, кайту юлына кузгалгач (җәйге төн саплам буе гына бит, яктыра башлаган иде), аларны сизеп алдылар һәм пулеметлардан рәхимсез ут ачтылар. Сазлыклы урманга кереп өлгерә алмый калган разведчикларның хәле мөшкелгә әйләнде. Башта Урушадзе яраланды. Пуля аның беләгенә тиде. Аннары Госман аяктан егылды. Уң аягына кусәк белән китереп суккандай булды, кан китте. Ул да түгел, сул яңагыннан кергән пуля аскы теш казнасын җимереп чыкты.

Бер генә минутка да тукталырга җай юк иде. Краснов мизгел эчендә карар кабул итте: «Минем белән Урушадзе китә. Бу «әфәнде»не тиз кайтарып җиткерергә кирәк. Сөнгатуллин, син Галиев белән каласың. Куа кузгалсалар, фрицларны тоткарлау да синең өстә»,— диде.

Фашистлар атудан тиз генә туктамадылар, ләкин ни гаҗәп! — куа чыгучы булмады. Ату тавышлары тынгач, Миңнәхмәт Госманны урманнан ерак түгел генә уйдыкка, ямь-яшел түмгәкләр суланып, лычкылдап торган урынга өстерәп килде. Шактый вакыт яраларын бәйләп азапланды.

Госманның хәле авырайганнан-авырая барды. Ул бөтенләй сөйләшә алмый, торып-торып ыңгыраша гына иде. Әледән-әле һушын җуйды. Исенә килгән минутларның берсендә ап-ачык итеп Миңнәхмәтнең «Бетте егет!» дигәнен ишетте. Шул сүзләрнең коточкыч мәгънәсе аңына барып җиткәч, йөрәгенә хәнҗәр кадагандай булды. «Юк! Үлмим әле мин, үлмим!» — дип кычкырасы килде, тик авызыннан ярты сүз дә чыкмады. Җаны барлыкка ышандырырга теләп, ыңгырашты. Миңнәхмәт моны колагына алмады. Ул ялгызы гына урманга таба шуыша иде инде...

Юк, Галиев үлмәде. Дөнья көтү насыйп икән әле аңа. Гомере барга сәбәп: Бобруйск шәһәрен азат итү өчен һөҗүмгә кузгалган күрше дивизия сугышчылары, яраланып авуына ярты тәүлек авышты дигәндә, үз яралылары белән бергә, Госманны кыр госпиталенә озаттылар. Аннары тыл. Аны Уфада дәваладылар. Госпиталь көннәрендәге газапларын үзе генә белә. «Егерме яшемнән күз көегенә әйләнәммени соң?»— дип кайгырды ул. Аяк сөяге тизрәк төзәлде. Егет бәгырен биттә шаран ярып торган яра эзе кимерде. Госман көзгедән бизде. Ә кырына башлагач, үз шәүләсенә күз салган саен тәмуг газаплары кичерде.

Алай да вакыт дигәнең иң яхшы дәва. Госпитальдән ул кырык биленче елның апрелендә кайтты. Әнисе вафат иде инде. Әтисе, Яртуган колхозына беренче тракторны алып кайткан Фәйзерахман карт, сугыш газаплары кичергән улын бик бетерешкән хәлдә каршылады. Сугыш елларында ярым җимерек машиналар белән интегүләр, МТС-ның җил уйнап торган мастерскойларында туң җиргә ятып ремонт ясаулар эзсез калмагандыр, күрәсең: озак тормады, ул да дөнья куйды.

Ир-ат дигәнең бик исәптә чак иде. Госманны беркавым бригадирлыкта йөрттеләр дә, Тәтеш ягына, Монастырскидагы тракторчылар курсына җибәрделәр. «Машинаны белүен болай да беләсең, сабагын укып, катыргысын да алып кайт та, иярлә инде корыч айгырны! Атаң һөнәре хур итмәс»,— диделәр. Икенче кышны, үзе гариза язып сорап, Куйбышев район үзәгенә комбайнчылар хәзерли торган механизация мәктәбенә китте. Анда да укуын тел-теш тидермәслек башкарып чыкты.

Шул рәвешле, утыз ел инде менә механизаторлыкта Госман. Тракторында да эшли, комбайнда да урдыра. Ремонт эшләрендә дә кешегә ялынычы төшми.

Басу машиналарында эшләү ир-егеттән ат көче даулый. Колхоз пешекчесе сые гына җитмәгәнен Госман бик тиз тойды. Дөрес, җизнәсе йортына кергәләп, апасы пешергән ашларын да аз ашамады ул. Тик хикмәт тамак туклыгында гына да түгел иде. Җан көрлеге бик кирәк бит кешегә, рух көрлеге. Утны-суны кичеп кайтканнан соң да салкын түшәккә сыенып йоклау шәп түгел иде ләбаса! Кыскасы, башлы-күзле булырга карар итте егет. Кыз сайлау мәшәкатеннән арынган иде инде ул. Күз атып йөргән Галимәсен бала чактан белә иде. Мәктәптә җиде ел бергә укыдылар. Бөтерчек малайга, тракторчы Фәйзерахман абзыйның төпчегенә Сәлимулла абыйсының иң өлкән кызы — тыйнак та, чибәр дә Галимәсе ошый иде. Галимәнең үзеннән дә битәр, аның әтисен — Сәлимулла абыйсын ярата иде бугай ла ул баштарак. Ник дигәндә, ул абый тирә-юньдә дан тоткан көрәшче, сабан туйларының йөзек кашы иде. Арысландай бик күп егетләрне аркаларына салды. Көрәшеп алган сөлгеләре һәм истәлек бүләкләре әле дә саклана, әмма баһадир Сәлимулла үзе күптән юк инде. Ул Бөек Ватан сугышы кырында, Днепрны кичкәндә һәлак булды.

Бер авылда яшәгән ике яшь кешенең очрашып күрешүенә комачау юк. Ара ерак, яна йөрәк дип зарланасы түгел, юлга читән үрмәгән. Хәер, түшен орден-медаль белән бизәп кайткан Госмандай егетләр читән аша сикерүдән генә өркеп торалар идемени?! Сугыш тынып, ике ел үтте дигәндә, Госман буй җиткән, җир җиләктәй пешеп өлгергән сылу кызны тормыш юлдашы итте. Еллар үткәч, үз өйләрендәге мәҗлесләрнең берсендә йорт башының хатынына төбәп җырлаганы да булды:

> Кем уйлаган ул чагында
> Яр булырсың дип,
> Тормышка бергә керерлек
> Пар булырсың дип...

Тирәннәнрәк фикерләсәң, ул чакта гомер сездерми узар дип тә уйланмаган. Юк, кая ул! Инде менә уртанчы малай өйләнергә җыена. Бер елдан кечесе дөбердәп солдаттан кайтып килер. Өлкән малай — үзе ата кеше. Оныкка алтынчы яше китте...

Туйлар якынлаша. Мондый чакта «Әүвәле-ахыры хәерле булсын!» диләр. Тик сизенә Госман, хәлләр бик үк хәерле булып бетәр микән?..

Өйгә әйләнеп кергәч, Галимәсе әчке якка аңа урын салды.

— Тынычрак утырыгыз дип әйтимме соң әллә яшьләргә? — диде ул Госманга.— Кызып алдыларны шунда...

Госман уң кулының имән бармагын иренենә аркылы куйды.

— Т-с-с-с! Ләм-мим, Галимәкәй! Ирек ачсыннар. Шуңа дип чакырдык бит. Кызып алсалар ни гаеп? Ашагач түймасаң, авыз иткәч кәефләнмәсәң, бирән булырга кирәк... Кил әле, утыр янымa...

Ул хатынының аркасыннан сөеп куйды. Тегесенә әллә ничек җайсыз булып китте, әмма бер сүз дә әйтмәде, иренең кулын җай гына читкә этәрү белән чикләнде.

Госман исә теле белән әйтә алмаганын кул кагылышы белән аңлатырга теләгән хәлдә иде. Миңнәхмәт Сөнгатуллин белән кода буласылар бар икән диген! Әтисе кылганнарга Сәвиянең катнашы да, бәйләнеше дә юк, билгеле. Шулай да Сәвия — Миңнәхмәт кызы. Аның йөрәген атасының да каны сугара. Өлфәт язмышы кыл өстендә калса, ул да йөз чөермәсме? Гомере буена бар булдыгы белән аңа тугры булып кала алырмы?

Ялгызың уйлансаң, эчеңә кату чыгар, диләр. Бу очракта әллә ни булса да чыдарга туры килә. Өлфәт белән Галимәгә авыз ачарга ярамый. Серне чишсәң, егет күңелендә өермә кубуы бар. Галимә сизенә калса да бик яман. Бернигә карамыйча, туй итүдән баш тартачак. Сәвияне килен дип танымаячак. Тузан бөртеге кадәр ялганын да, кечкенә генә гаделсезлекне дә кичерә алмый торган зат...

Өлфәт йөрәгендә дә давыл купмасын иде, купмасын. Егетнең чыгырдан чыгуы мөмкин. Авылдан баш алып качар. Әле бит менәтерәк җирне кочардай булып, ятып үбәрдәй булып йөри. Районда бер диярлек тырыш механизатор... Килер көне матур...

Газапның газабы Миңнәхмәтнең үзе белән күрешү булачак. Үткәннәр өчен рәнҗү-нәфрәтне ничек тыеп торырга? Ул нишләр? Солдат антын бозган кеше Госманның күзенә карый алырмы? Ни әйтер? Ничек боргаланыр? Гафу сорап багармы? Кичереп буламы соң мондый эшләрне?..

*

* *

Сырхап егылуы шул булдымыни соң? Иртәнге чәйгә Госман тора алмады. Төнне дә бөтенләй диярлек йокысыз кичерде. Галимәсе торып, өй белән тыш арасында кыштырдый башлаганда, Госман катлы-катлы уйлардан ничә килəп салырга өлгергән иде икән инде?! Йөрәге шаярды, йөрәге! Йокы да бирмәде, торыр хәле дә юк. Читлектәге кош сыман талпыныпмы-талпына шул йодрыктай гына ит кисәге... Иртүк, күзне тырнап ачуга димәсәң, Сәвияне чакыртыргамыни соң инде? Укол кадәр, дару каптырыр, җылы сүзен әйтер, киңәш бирер, юатыр... Алай да ул бит Миңнәхмәт кызы...

«Юк, борчымыйк әле ул баланы...» — Уйлана торгач, Госман үз-үзенә шулай диде.— «Сөтле чәй генә эчеп карыйм да беравык ятыйм. Бераз гына... Мәлҗерәргә ярамый! Болай сыгылып төшү — килешкән эш түгел. Галимәнең имәнеп калуы бар. Юк, сискәнмәсен әле, сискәнмәсен Сәлимулла абыйсының өлкән кызы, Госманны чирек сүздән аңлый торган тугрылыклы хатын... Аңа йорт-җир мәшәкате дә җитеп ашкан. Яз килде, колхозның җиләк-җимеш бакчасы-

на эшкә йөри башлар. Аннары инде кар төшкәнче шунда булыр. Җаны кыйналмасын әле Сәлимулла абый кызының!..»

Уй йомгагы сүтелә башлагач, ул нилектәндер үткәннәргә тәгәрәүчән. Гүя киләчәк ягына юл аркылы багана салганнар, гүя язмыш орчыгын әйләндергән көчле җил аны алга җибәрми.

...Сугыш чыкканчы иде. Мең тугыз йөз кырыгынчы ел шикелле. Колхозда төрле эштә булышкалап йөргән Госманны лобогрейкадагы атларны алмаштыручы итеп куйдылар. Эше бик гади иде: эшләп арган атларны ялга куясы, ашаган, ял иткәннәрен алмашка китерәсе.

Кем белсен, әтисе янында әвәрәләнеп, борынына машина исе кергән Госманның зур мәгънәдә хезмәт сукмагына басуына шул лобогрейкага кагылышлы сәбәп булгандыр? Кичә генә булган кебек хәтерендә: лобогрейкада бодай урдыручы Сәлимулла абыйсы аңа:

— Утырып карыйсыңмы әллә, Госман энекәш? — дигән иде.

Гап-гади шушы сүзләр аның өчен матур җыр төсле булып тоелган иде. Аңа ышанып машина бирәләр түгелме соң?

Тәвәккәлләде бит тәки! Атларны җиңел генә әйдәп, алга кузгалдылар. Малкайлар да, яшүсмернең дәртен абайлап алгандай, елдам булды.

Кишәрлекнең буе ике чакрым чамасы иде. Аргы очка барып җиткәнче тракторчы Фәйзерахманның төпчек улы арыды, куллары тыңламас булды, иңнәрен күтәрә алмас төсле сизде. Шулай да туктап калырга ярамый иде. Сынатсаң, Сәлимулла абый күзеңне ачырмас, бүтән вакытта машинага якын да китермәс...

Бирге очка әйләнеп кайтканда, Госманның күзләре әлҗе-мөлҗе килеп, күлмәгеннән тир сыгарлык булса да, күңелендә сабан туй иде. Ни генә димә, пар ат җигелгән урак машинасы белән кырны әйләнеп чыкты ич! Күпме бодай урдырды! Хәзер ул үзган эзгә үнган апалары көлтә бәйләргә төшәчәк. Аннары чүмәлә куярлар, аннан соң эскерт. Эскерттәге ашлыкны катлаулы сугу машинасы сугып бирер. Көшелгә Госман уфдырган иген бөртекләре дә кушылыр...

Шул көннән башлап үз буразнасын яручан булып китте ул. Тормышта аның үз теземе, үз көлтәсе, үз эскерте, кушучка алып сокланырлык үз бөртеге булды. Шул теземнәрне, шул басуларны комсыз-кансыз илбасарларга бирмәс өчен яу кырында кан түкте. Ил күген кара сөрем басмасын дип, килер буын кояш яктысыннан мәхрүм калмасын өченгә, гомерен дә бирергә әзер иде. Колхозга әтисе алып кайткан беренче трактор — «Фордзон путиловский» эз салган кырларда, Яртуганның гөл туфрагыдай туфраклы басуларында утыз ел иген игә. Сөрә, чәчә, ура һәм суга. Уртанчы улы үз юлыннан китте, кечесенең дә авылда төпләнәсенә өмет бик бөтен. Оныклары да ризык үстерер. Өлкән улы бүтәнрәк һөнәр сайлаган икән, ул тиклесенә дә сөенергә генә кирәк. Зөлфәт тә халыкка ризык бирә. Әйе, әйе, чыны шул. Газетчарак әйтсәң, рухи ризык, рухи җим. Ул — художник кеше, рәссам. Атказанган эшлекле. Татарстан Верховный Советы депутаты. Казанда гына түгел, Мәскәүдә беләләр үзен. Әнә язган бит әле: Октябрь юбилеена багышлап картинамны өлгертә алсам, зур максатыма ирешкән булырмын, дигән. Уңышлы барып чыкса, бу хезмәтем бабамның хатирәсе алдында баш июем дә, синең гомерлек хезмәтеңә мактау сүзе дә булыр иде, әткәй, дигән. Гомумән, игенче-механизаторларның тау чаклы изге хезмәтләренә багышлыйм мин бу әсәрне, дигән. Картинаның исеме табылды — «Беренче корыч карлыгач» дип атарга булдым, дигән.

Молодец, Зөлфәт, молодец! Ата-баба кадерен белүең, нәсел-нәсәбә хакын хаклавың белән бер молодец булсаң, игенче фидакарьлеген аңлавың, зурлавың белән янә дә бер молодец! Сабан туена Яртуганга кайтырсың, улым. Хатының, балаң белән. Оныкны сагындым. Сез-

нең үзегез өчен генә Газиз түгел бит ул, мина да, әбисенә дә газиз бала... Мин аны быел ат атланып йөрергә өйрәтәм әле, әбәзәтельне өйрәтәм. Башы күккә тиясе аның аннан ары... Машиналар чутсыз булса да, ир канаты — ат дигәнне оныту ярамый...

Бергә-бергә Ярсөяр әрәмәсенә чыгарбыз. Һай, ямьле дә була инде ул әрәмәлек июнь айларында! Изге кешенең күңеле төсле матур була. Яшел кочагын җәеп торачак. Елмаеп-көлеп. Әби-бабаларыбыздан башлап шунда күңел ачканнар. Эч серләрен шунда уртаклашканнар. Гашыйкларның яраткан аулак почмагы булганга, Ярсөяр әрәмәсе дигәннәр дә аны. Күпме яшь йөрәкнең серен тыңлаган инде андагы куаклар! Газизне ияртеп барасы да барасы әле анда. Сабый күңеленә ата-бабасы төбәгенең матурлыгын шунда да салмасаң, кайда гына салырсың?!

Зөлфәт Мәскәүгә барып кайткан. Әткәйнең күңеле нидән эрегәнен белгәнгә языйм әле дигәндер инде, Революция музеена кергәнен язган. Сталинград заводы чыгарган беренче номерлы трактор шунда тора икән, дигән. Аның паспортындагы сүзләрне хатка да язып җибәргән:

**«Атамасы: «Интернационал» тракторы.**
**Туган вакыты: 1930 елның 17 июне.**
**Кайсы милләткә каравы: интернационалчы.**
**Профессиясе — механизатор.**
**Хезмәт стажы: 23 ел.**
**Хезмәт өлеше: 12 880 гектар.**
**Җәмәгать эшчәнлеге: авылда социалистик уклад өчен агитатор.**
**Даими пропискасы: СССР.**
**Чит илләрдә туган-кардәшләре бармы: бертуган энеләре дөньяның 25 илендә...»**

Кызык бит, билләһи! Мәскәүгә бара калса, Госман кереп үз күзләре белән дә күрәчәк әле аны. Әткәсе Яртуган урамының каз үләне баскан туфрагына шул трактордан да алдарак кызыл Питерның кызыл путиловчылары ясаган машина белән беренче киртләч эзләрне салган бит... Тракторлар тарихы аның өчен әллә нинди кызыкларыңнан да битәр мавыктыргыч... Урамдагы трактор эзләрен шул елгы яңгырлар юк югандыр, колхоздашлар йөрәгеннән гасыр да җуя алмас. Җуймас!, Зөлфәт картинасы да озак еллар буена сөйләр әле аны... Зөлфәт Газизгә төшендерер, Газиз аңлап калыр...

Юк, түшәк җылысын үлчәп ятарга ярамый әле Госман Галиевкә. Әнә Казан иртәнге концертын башлады. Радиода да яз сулышы. Колакны иркәли торган моңга бай тавышлы җырчы җанны кинәндерә, ләззәт, ямь бирә.

Тамчылар тамар чаклар,
Ташулар агар чаклар;
Кадерен белгән кешегә
Минутлар санар чаклар...

Әйе, ел туйдырыр көннәр җитә. Минутлар санау гашыйклар эше генә түгел, җир кешеләре шөгыле дә. Механизатор моны теләсә кемгә караганда да яхшырак белә.

Торды Госман. Үзен-үзе җиңеп торды. Юынды-таранды, рәвешкә килсен дигәндәй генә тамагына да капкан булды (һич югы, Галимәнең күңеле булсын), киенеп-җыенып механика мастерскоена китте.

Кичә төшкән җепшек кар, «соңлап яудым ла!» дип оялган төсле, эреп юкка чыккан, аяк астын шактый пычраткан иде. Шулай инде, ел фасылы үзенекен итә дә итә, ныклап торып көне килгәч, кар суыгы

китә, китми хәле юк. Аңардан котылып була. Котып салкынына да үлмиләр. Җанны шыкырдатып туңдырган суыктан ничек арынырга менә?

*
* *

Машиналар паркында һәм мастерскойда аның кәефендәге үзгәрешне сизмәделәр дә шикелле. Үзе дә көндәгечә көр тавыш белән сәлам бирергә тырышты, гадәтенчә хәл-әхвәл сорашты. Җанына җылы өстәгән хәбәрне тәэминатчы Рәфгать ирештерде.

— Булды бит комбайнга запчастьлар, Госман абый! — дип елмайды.

— Авызыңа бал да май! Ничек әле ул бер барудан?

— Серен әйтимме?

— Итәк астыннан кул йөрттегезме? — Госман тәэминатчы авылдашы яныннан кул селтәп китүдән чак тыелып калды.— Берәр йомшак бәндәнең өлешенә кергәнсездер әле...

— Йомшак снабженец булмый, Госман абый. Булса да тормый,— дип һаваланып куйды Рәфгать. Шулай да сүзне кыска тоту ягын карады, белә бит, югыйсә: Фәйзерахман Госманының холкында күкерт тә бар. Запчастьлар дигәнең аңа ашый торган икмәге, эчә торган сөте кебек кирәк, әмма чын тәэминатчы икәнсең, син аны бүтән хакына кермичә тап, дип уйлый ул; көйлим-чөйлим дип, колхоз акчасы белән дә юмартланма!..— Барып төшкән көнне үк Зөлфәт абыйны күрдем.— Рәфгатьнең йөзе җитдиләнде.— Авылны сорашты, синең хәлләрне... Йомышың ни, диде. Әйттем. Төпсез чиләк белән су ташырга килдем әле, мәйтәм. Аңлап бетермәде, конкретлап сөйләдем. Запчасть дип зар елавыбызны әйттем. Пүчтәктән генә «Нива» белән «Колос» комбайннары иннек ягынып бетермәгән кыз төсле утыралар, мәйтәм. Өс-баш яхшы, аякта елтыр туфли, чәч таралган, кулда балдак, бар да бар. Ирен кызартырга иннек юк... Шуның күк безнең хәлләр, мәйтәм, бүген басуга чыгарлык комбайннар вак-төяк аркасында хәзер түгел, дим...

— Шуннан? Базага җитәкләп алып киттеме сине? — Госман тагын өнәми генә сорап куйды.— Капчыгың кайда диме?

Рәфгать чын-чынлап рәнҗи калды. Йөзенә канәгатьсезлек чыкты. Хәтта тавышында үпкә сизелде.

— Юк ла инде, Госман абый! Син бигрәк. Күкәй урлап тотылган малай урынына кыерсытасың. Тукта әле, диде Зөлфәт абый, республика «Сельхозтехника»сында минем бер белешем бар бит, башлык урынбасары. Солдатта бергә булган иптәш. Син аны баксаң үзең дә беләсеңдер. Безнең районда эшләде ул. Шахмат шаукымы кагылган егет...

— Аның янына киттегезме?

— Бардык. Ул районнар буенча разнарядканы карады. Безнең районга звонить итте, сөйләште. Аннары рөхсәт бирде. И мин алып кайттым. Зөлфәт абыйга рәхмәт яз дип сүз башлавым иде.

— Үзем барып кайтмаммы әле мин аның янына...— Монысын әйткәндә, Госманда запчастьларга кагылышлы сүзләрдән битәр, башына төшкән катлаулы уйларны өлкән улы белән уртаклашмаска микән дигән фикер уянып килә иде.

Хезмәттәшләре белән сүзләшә торгач, ул фикер янә каядыр югалып торган кебек булды. Комбайннарга запас часть юнәтү куанычы яңарды: «Шәп булган!» Шуларга кытлык — күптәнге хәсрәт. Соңгы елларда әле ничава. Кыен булса да юнәтеп булмый түгел. Бар иде заманалар!..— Госман сугыштан соңгы беренче елларны хәтерләде.

Иөрәккә төшкән теш сызлавы иде ул чакта, МТСлар заманында, техниканы ремонтлап сафка бастыруы.

...Госман комбайнда эшли иде. Уттай урак өсте. Беренче карашка әллә ни дә түгел, шестерня сафтан чыкты. Комбайн да җан көеге булып басып тора, аны тартып йөрүче трактор да эшсез. Урдырыр хәл юк. Ул заманда колхоз механигы дигән төшенчә тумаган да иде әле. Ярдәмгә килерлек бердәнбер кеше — завхоз. МТСта аңа ни бирсеннәр?! Запчасть дигәнең көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба торган хәзинә түгел... Китте Госман бригадир янына.

— Ярар,— ди тегесе,— тырышып карарбыз. Тульке рәт чыгарына гарантия юк. Әнә күрше колхозныкылар да күпме зар еладылар...

МТСка кадәр ара әллә ни ерак түгел иде, өстәвенә, бригадирның аты да яхшы (ул елларда мотоцикллар хыялда гына иде әле), икеөч сәгать дигәндә әйләнеп кайтты бу. Әйтергә генә ансат — өч сәгать! Урак өстендә басу түрендә шул гомер тораташтай басып тор әле!

— Берни дә корып булмады,— диде бригадир уфтанып.— Юк бит безгә кирәк шестерня. Көн тудымы — нужа туа, кытлык биетә башлый. Гаҗиз булдык бит инде бу запчастьлар белән. Хет утка кер!

— Утка керсәң, янып бетәрсең. Җаен табарга кирәк! — Госман кәефсезләнеп шулай җаваплашты.

Бригадир үзенчә аңлатуында булды.

— Юк бит, юк! Пустяк аркасында гомер заяга уза, ашлык коела. Хет барып якалаш складтагылар белән...

— Алай итсәң, статья алырсың, шул булыр... Анысы сиңа кирәкмидер дип беләм. Шулай да үзем барып карыйм әле МТСка...

Бригадир Галиевкә кистереп карады. Аның күзләреннән: «Мин булып мин майтара алмаганны син юлламакчы итәсеңме? Һай, бу яшьлек!» дигәнне укып була иде.

— Кемгә барып егылмакчы буласың да, нәрсә димәкче буласың? Сөйләштем бит инде, директорын да, урынбасарын да күрдем...

— Алай да барып кайтыйм әле,— диде Госман, гадәтенчә сабыр гына, ләкин сүзен сүз итеп.— МТС җире диңгез артында түгел. Кул кушырып торсак, берәү дә китереп бирмәс безгә кирәкне...

Китте. Гозерен сөйләүне склад мөдиреннән башлаган иде, тегесе, бу комбайнчы белән уртак тел табып булудан өмет өзепме, кырт кисте.

— Юк, брат, юк. Бригадирыгыз килеп китте бит инде. Таштан юкә суялмыйм.

Әллә күзенә генә күренде, әллә чынында шулай иде, склад эшчеләренең берсе сагаеп кына Госманга күз кыскандай булды. Моны үзенчә юрап, Госман складтан читкәрәк китте һәм мөдирнең бүтән берәр шөгыль белән мавыгуын көтә башлады. Ә эчендә ялкын телләре биешә иде. Кадерле сәгатьләр җилгә оча лабаса! Ул арада мөдирне МТС конторасына дәшеп алдылар. Шул чак бая күз кыскан агай әйтә куйды:

— Син нәрсә төнлә туган шикелле йөрисең? Завсклад бит инде сиңа «минем фәлән-фәлән шартларым бар» дип әйтмәс... Сиңа кирәк әйбер аңа киштәдә, ал да тәгәрә. Хакы...— Ул өч-дүрт тапкыр кыйбатрак бәя әйтте.— Өстәвенә, туганкай, ни... бер савыт та бер тавык...

Ничарадан бичара, Госман теге агайның шартларына күнде, тик савытын да, тавыгын да уртаклашып тора алмады, комбайны янына элдертте.

Ат юырткан җайга уйлап кайтты. Менә бит ул якаларыннан алып селкисе җаннар! Үз кесәләренә артык сумнар керер булса, табалар... Сыйланмый каласылары да килми. Үзләре ясаган детальмени?!

Мәгълүм инде, запчастька, мөгәричкә тоткан акчаны Галиевкә берәү дә түләмәде. Мәгәр Госманны әле яна тернәкләнеп кенә килгән

семья кесәсеннән исраф булган сумнарга караганда бердәнбер юл булып запчастьларны комсызлардан алу ысулы калганлыгы борчыды. «Кешегә һәрчак намуслы булып калуы кыен шул,— дип уй йөртте Госман,— спекулянтны, алып сатарны үзең үк сыйларга мәҗбүрсең. Әшме инде бу?! Сыйламас идем бер дә, артыгын да түләмәс идем, кырда иген әрәм була».

Үткәнгә кагылышлы уйларын мастерской бусагасында күренгән колхоз председателенең сәлам бирүе бүлдерде.

— Исәннәрмесез, дөнья тоткалары!

— Һу-у, Габделәхәт кайткан! Бик исәнбез, иптәш председатель. Үзең имин әйләнеп кайттыңмы? — диештеләр комбайннар ремонтына нокта куйыйк дип килгән механизаторлар.

— Ял шәп булдымы?

Председатель Габделәхәт Гайнуллин тазарып, чистарып кайткан иде. Болай да кырыкка да җитмәгән әле ул, каны-сүле эчендә. Шулай да ял бик килешкәнгә охшый. Киң җилкәләр тагын да шәбәя төшкән төсле. Иң күркәме — җаны елмаеп тора, күңелендә яз.

— Ял начар буламыни, агай-энеләр,— дип көлемсерәде ул.— Кавказда булсын да, начар булсынмы? Соңгы көннәрне генә кычу төште...

— Нәрсә килешмәде икән? — Госман булып Госман беркатлылык күрсәтеп куйды.

— Телевизор карый торабыз бит, Госман абый, радио тыңлый торабыз. Урта Иделдәге температураны да әйтә торалар.

— Ә аны әйтәмсең...— диде Госман, нинди кычу хакында сүз барганын чамалап алгач.— Как раз кайтып җиттең, Габделәхәт энем, как раз... Өч-дүрт көнсез җир өстенә кереп булмас әле...

— Чамаладым. Агроном да шулай ди. Ягез, кайсыгыз көйрәтә? Кавказ сигаретлары...

Кәҗәсе түгел, мәзәге дигән кебек, ремонтчыларның берничәсе сигарет кабына үрелде. Өлфәт кенә базмады. Күз кырые белән әтисенә карап куйды да, читтәрәк торуында булды. Ара-тирә тарткалаган була ул, ләкин әтисенә күрсәткәне юк.

Утырыштылар. Председатель янәшәсендә урын алган Госман туфрак торышы хакындагы фикерен тагын бер әйтеп куюны кирәк санады.

— Мин дә кичә Ярсөяр әрәмәсе артындагы басуга чыгып кердем,— диде ул.— Бик юеш әле. Бу кар яумаса да бер хәл булыр иде...

Механизаторлардан берсе:

— Кем белә, мужыт, хәерле кардыр ул,— дип куйды.

— Язгы дымның артыгы булмас булуын.— Госман аның сүзе белән килеште.— Алай да чәчүгә вакыты бик җитте дия торган.

Сигарет көйрәткән арада колхоз башлыгы һәммәсенең хәлен белешеп чыгарга өлгерде. Басу батырларының кәефләре бер дигән иде. Шул кирәк, шул тансык. Төпкә җигелеп тартучылар «Булдырабыз!» дип торсалар, булмый калган эш юк ул.

— Комбайннарның да һәммәсен хәзерлек сызыгына куябыз, алайса?

Габделәхәт бу сорауны барысына уртак биргән иде, җавабын Госман кайтарды.

— Эшләре беткән диярлек бит аларның, Габделәхәт. Запчасть алып кайтканнар.

— Әйе. Рәфгать иртүк әйтте.

— Бүген, иртәгә и вәссәлам! Уракка әзер дип әйтә алачакбыз.

— Соңгы елларда, әйтсәң-әйтмәсәң дә, ремонт белән артыгын биртелми башладык бит, җәмәгать, ә? — диде председатель сөенеп.— Аякны алдан киенергә өйрәндекме? — Габделәхәт йөзенә игенчегә хас

шөкер итә белү галәмәте чыкты. Масаю, күкрәк киерү билгесе түгел, авыр еллар кичеп яуланган урдә туа торган хис чагылышы...

— Тормыш бик үзгәрде бит, Габделәхәт энем.

Арада өлкәннәре булгангадыр, колхоз башлыгы белән әңгәмәдә күбрәк сүзне Госман әйтте. Башкалар аңа куәт өстәп торды.

— Техниканың өр-яңасын күпме алабыз, запчастька да элгәрегечә үк тилмерү юк бит чүтеки... Хакы колхоз кассасын кашый әле кашуын, ну шулай да... Технический обслуживание пункты дигәне белән бик оттык. Машинаның кайда ни җимерегә бар дип, механизатор казынып ятмый бит. Диагноз машинасы, суга караган кебек, тракторыннын да, комбайныннын да чирен әйтеп бирә. Галәмәт зур эш!.. Аннан ары машина белән генә дә түгел, общий подъем. Ашламасыннан нихәтле өлеш чыгаралар. Самолетлары килеп күпме булыша. И вәт уныш! Келәтең тулы булса, аякны киенә беләсең ул... Хәлле кеше гомер-гомергә күп йокламаган...

— Шулай бит!

— Шулай! — диештеләр мастерскойдагылар һәм тәмәке төпчекләрен комлы әрҗәгә илтеп сүндерделәр дә үз урыннарына таралдылар. Госман председатель янында калды. Аның әйтер сүзләре барын Гайнуллин да сизеп тора иде.

— Бер киңәш димме, Габделәхәт энем, гозерем бар иде сиңа.

— Әйт, Госман абый. Син ни дип әле оялчан кызлар кебек...

— Сәерсенерсең дим...— Алай да сөйләп китте.— Кичә Ярсөяр күлләренә кыр казлары кайтты...

Гайнуллин бу хәбәр артында ни ятканын төшенеп өлгермәде.

— Шул менә... Төштән соң, син кайтып житмәгән булсаң диюем, Риза янына бармакчы идем, парткомга...

— Әйт инде йомышыңны!

— Бик өшәнеп, прәме-тәки ябыгып, хәлсезләнеп кайтканнар месkенкәйләрем.

— Шуннан, Госман абый?

— Җилгә каршы күп очканнардыр, күрәсең. Төн кичәргә төшкән җирләрендә ризык-җим такы-токы гына булгандыр.

Габделәхәт артык ашыктырып мәгънә чыкмасын аңлады. Күреп тора, әйләнечен әйләнеп бетерми торып, чикләвеген ватмас бу, төшен күрсәтмәс.

— Уйладым, уйладым да, Габделәхәт энем, бераз бөртек сибәргә кирәк үзләренә дигән фикергә килдем. Сибик, тукландыннар...

— Фураж фондыннан киек каз ашатырга кушуыңмы, Госман абый?

— Ничек аңлатыйм икән? — Госман янә шомарып беткән эскәмиягә барып утырды, аннары, син дә утыр дигән шикелле, үз янәшәсендә эскәмия тактасын сыйпап-сыпырып куйды.— Бүгенгә гозер шулайрак килеп чыга, Габделәхәт энем. Точно шулай. Бер-ике капчык отходны кызганмыйк. Аннан ары мәктәп директорын күрерсез. Ул үзенең комсомолларын, пионерларын оештырыр. Хуҗалыктан җыярбыз. Мин үз чутымнан бүген бер капчык бирәм... Хет ике-өч кат туендырсак та, гөнаһсыз кошлар исән калыр, хәл алыр дигәнем...

Председатель каш җыера язып калды, ләкин үз-үзен тезгенли белә торган кеше ул, эшне йөз чытуга житкермәде. Шулай да чырае бик җитдиләнде.

— Әкәмәт кеше син дияр идем, Госман абый, үпкәләсән, үпкән тиз язылмый. Аптыравымны да әйтми кала алмыйм. Әллә ниләр килә бит башыңа.

Госманның күкерте кыза башлады.

— Үземә ипи сыныгы теләмим бит, Габделәхәт энем. Табигать балаларын ачтан коткарыйк дим. Гел кайта торган булсыннар Ярсөяр күлләренә!

— Мәңге бакый үз карыннарын үзләре туйдырганнар алар. Шуңа киек кошлар диләр аларны, Госман абый.
— Әүвәл шулай булганын мин дә беләм. Хәзер кимеп калдылар. Сазларын бетердек, күлләрен. Химикат белән агуладык. Калган кадәрен сакларга кирәк.
— Ниятең изге, Госман абый, сүз дә юк.— Габделәхәт тагын тәмәке кабызды, тирән итеп суырды һәм башын читкә борып, төтенен бер якка бөркеде.— Шунысын да уйла, «Кыр казлары фермасы» дигән фельетон язып чыгулары бар.
— Шундый ук аңсыз бәндә табылыр дисеңме?
— Бик мөмкин. Ни генә димә, фураж фондыннан тотабыз булып чыга. Әрәм-шәрәм итү дип бәяләсәләр, ничек кире кагасың? Әле мал-туар көтүгә чыкканчы ни гомер барын үзең беләсең.
— Язмаслар!— Госман, председательнең әлеге фикерен урталай чабып өзәргә карар кылган төсле, кулын кылычка охшатып бутады.— Язмаслар! Әрәм-шәрәм дигәнең мондый формада булмый ул аннан ары...
— Колач киң булгач, масштаблар зур дип, без кайчак артыгын юмартланып китмибезме, Госман абый, ә? Вак-төяк, янәсе...
Госман сүзгә нокта куяр чак җиткәнен тоемлап алды.
— Мин үзем дә, Габделәхәт энем, колхоз хисабына юмартланырга хиреслärдән түгел. Әлеге дә баягы, гөнаһсыз кошлар хакы дип әрсезләнүем генә иде. Гомер-гомергә язларыбызны, җәйләребезне ямьләгән җан ияләре аннан ары... Җылы якка киткәндә дә, күзләрен дигәнем, «Ярсөяр күлләренең кадерен белегез!» дип китәләр бит алар...
— Барысы дөрес, Госман абый...
— Алайса, менә болай...— Госман, командага буйсынгандай, аяк өсте басты. Председатель дә, аңа ияреп, урыныннан купты.— Менә болай...— Механизатор Габделәхәт Гайнуллинның сак караш белән өртелгән күзләренә тутырып карады, ун кулын аның җилкәсенә салды.— Өйдә маза куптарып йөрисем килми. Миңа, гомерен буразна санап үткәргән механизаторыгызга, колхоз амбарыннан тугыз-ун пот бодай сатып алырга рөхсәт кәгазе бир. Ашарыма алырга хакым бар икәнен беләсең...
Бу тәкъдим Габделәхәт өчен бик кулай иде, югыйсә. Бер яктан. Әмма, икенчеләй уйлап карагач, Госман абыйсының әлеге сүзләре аны, миллионнан артык сум саф кереме булган күмәк хуҗалык башлыгын рәнҗетте дә. Вакчыл, каты бәгырьле кешегә саный түгелме соң? Җирдә һәммә гүзәллекнең дошманына тиңләргә җыена түгелме?
— Ярар, синеңчә булыр. Отход бөртек бирербез.— Председатель икеләнүләрен бер читкә селтәп аткан иде инде.— Мәктәптәге иптәшләр белән дә сөйләшербез. Шуннан... Киек каз фермасында эшләргә кемне ялларга кушарсың?
Госман тирән тын алды да саран гына елмаеп куйды.
— Анысы өчен хәсрәтләнәсе түгел, Габделәхәт энем. Үзем башкарам. Мастерскойдан кайткач, кичкырын. Резин көпчәкле арбага ат җигәм дә... Анда көтү-көтү булып, дөнья күтәреп йөрү ярамый да ...Мондый хәлләр турында «Уральский следопыт» журналыннан укыганым бар.
— Теләгең түгәрәкләнә, алайса?
— Рәхмәт, Габделәхәт энем. Кая кузгалуың әле?
— Фермаларны әйләнеп чыгыйм дим. Идарәгә шуннан соң кайтам. Хафаланма, онытмам.
— Хафаланудан түгел...

*
* *

Кояш баерга әллә ни күп вакыт калмаган иде инде. Шулай да Госман каударланмады, кыбырсымады. Атны җай гына атлатып барды.

Көндез председатель белән сөйләшкәннәр хәтеренә кат-кат әйләнеп кайтты. «Ул да хаклы инде, хаклы!— дип сөйләнде Госман авыз эченнән генә.— Фуражның һәр килосы исәптә. Шунсыз ярамый да. Сөт муллыгы дибез, симертүдәге терлекләрнең көнлек артымы дибез, боларның берсе дә курмысыз булмый ла!»

Табигать ярату дигәндә, әрәмәгә, күлләргә ихласы дигәндә, мөкиббән киткән кеше Габделәхәт. Бер тарактан тарап, бөтен тирә-юньдәге сазлыкларны сукаларга, киптерергә йөргән кайнарбашлар табылганда да үз сүзен итте. Сөрердәен сөрдек, киптерердәен киптердек. Ярсөяр әрәмәсенә кул якмыйбыз, дип кырт кисте. Бөртекле ашлык мәйданын арттыруга йөз тотуыбызны әйтеп тә басымчаклык күрсәтеп бактылар. Юк, диде Габделәхәт, ерымнарны бетерү чарасын күрәбез, тугайларны хуҗаларча янә бер күздән кичерербез, елга ярларын ныгытырбыз, Ярсөяр әрәмәлегенә кагылмабыз. Тимибез аңа. Андагы сазлыкны киптерсәк, күлләр корыячак. Бозлының суы кимиячәк. Канишны, халык бер җан, бер тән булып яклады үзен... Иген уңышын бүтән гектарлар кодрәтен арттыру бәрабәренә ишәйтербез, дигәне дә рас килеп бара. Елгалар саекмасын өчен күз карасыдай сакларга кирәк сазлыклар да була икән бит...

Иң әүвәле Госман атны күлләрнең Олы күл дигәне янына туктатты. Кеше буе диярлек зур капчыкны ыңкылдап күтәреп алды да җиргә утыртты. Капчык авызы җебе нечкәрәк нәмәрсәкәй булып чыкты бугай ла! Госманның буынтыкланып торган юан бармакларына очы эләкми аптыратты.

Авызын чишеп җибәргәч, капчыктан механизатор борынына бөртек исе бәрелде. Алай да күзгә көшелдән аңкып торган тәмле ис түгел, күксегән ис тә кушылган иде. Госман түбәләмә итеп беренче соскычны алды да су буена атлады.

— Хәерле сәгатьтә!— Бөртекне сөзәк ярга, дулкын яламастай ара калдырып салды.— Карынызга аш булсын, канатыгызга көч бирсен, матуркайларым.— Ике-өч адым ара белән соскыч-соскыч бөртек яр буена сибелде.

Кече күл янында да эшен бетергәч, Госман капчыкларны берсе эченә тутырып, Кашканы авыл ягына борды. Бахбайның дилбегәсен тартып, чөңгереп куйды һәм ат юыртып киткән уңайга арбага сикереп утырды. Кече күлдән ераклаша барган саен Госман артына ешрак борылып карады. Тойдыларммы кыр казлары аның сый китергәнен? Әллә аргы як камышлыгында үз телләрендә гәп куертып абайламый калдылармы? Ә, ю-у-ук! Әнә бер төркеме разведкага килде. Күзәтчеләр! Ни майтарып китте микән бу болгар токымы татар димсез? Яртуган күчтәнәчен авыз иткәч, канат кага-кага рәхмәт укырсыз әле, матуркайларым! Госманның йөзе якын дусты, хатыны, балары белән сөйләшкәндәгечә яктырып балкый иде. Кинәт...

Кинәт... тирә-якны яңгыратып мылтык шартлады. Язгы буш басулар тынлыгы югалып калды.

Госман дилбегәне шундый итеп тартты, Кашка, туктап кына калмастан, берничә адым артка чикте.

Ниткән хәл? Кем булыр бу? Яз башында тилмереп кайткан гөнаһсыз кошларга төбәп кайсы бәдбәхете мылтык чакмасын тартты икән? Үз башына бүлгыры сунарчы күренми иде. Госман арбага менеп басты. Карашын бөртек сипкән ярдан камышлыкка күчерде. Юк кына! Җан кыючы бәндә күренмәде. Күз бәйләнеп килә иде шул инде. Әнгерменгер... Ялгыш ишетмәде ич инде ул ату тавышын! Кошлар да куркынып күккә күтәрелде. Анысын тәгаен күрде бит инде, ап-ачык.

Кайнарланып, аскы иренен тешли-тешли, Госман атын кире борды да чаптырып китте. Янгынчы да болай ашыкмыйдыр — канатланып очар дәрәҗәгә җиткән иде. «Барырга, тотарга, тәртәгә бәйләп, авыл советы-

на алып кайтырга хәшәрәтне! Ә ялгызы гынамы ул? Булмаса тагын! Фашист белән бугазлашырга курыкмаган Госман Галиев браконьер корткычлардан өркеп калсынмы? Анысы булмас! Атсалар? Һе! Бик мөмкин. Шулай да бармыйча ярамый. Ярамый!

Кече күлнең бая үзе орлык сипкән җиренә җитәрәк абайлады Госман: берәү суга кереп бара. Бот төбенә чаклы резин итекләр кигән дигән сүз.

— Әйдәле, Кашка, әйдәле, малкай!

Госманның каты кулын тоеп өлгергән ат куаклыкларны әйләнеп-әйләнеп боргаланган юлдан тагын алга ыргылды.

Саклана-саклана гына су ерып баручы кеше турысына җиткәч, механизатор атны шып туктатты һәм җиргә сикереп төште. Суга таба берничә адым атлаган иде, ни күрсен: җирдә кушкөпшә ау мылтыгы ята. Госман аны кулына алды, мондый коралны гомерендә беренче күргән шикелле, кат-кат карады. Көпшәнең берсе корулы иде әле. Икенчесеннән дары төтененең әчкелтем исе китеп бетмәгән.

— Кем икән бу? — дип кымырҗыды Госман күңеле.— Ә-ә-әй! Чык әле монда, тизрәк чык!

Сунарчы әйләнеп караган сыман күренде. Мәгәр ул кире борылмады, юлында булды.

— Чыгарсың, суда куна алмассың.

Госман байтак көтте. Кош атучының гәүдәсе җиргә сылана баручы караңгылык эчендә эрегәндәй булды. Шунда, катгый карарга килеп, Госман һавага атып җибәрде. Кашка сискәнеп китте. Аткан тавыш таралып тынгач, күлдән аваз килде.

— Кем анда-а-а? Куй мылтыкны!

Тавыш Госман колагына бик таныш тоелды, тик барыбер күл суын еручының кемлеген өзеп әйтер хәлдә түгел иде әле ул.

— Чык тизрәк, диләр сиңа, аннары сөйләшербез! — дип кычкырды Госман.

Көткәнгә озак дип рас әйткәннәр, теге бәндә юри чыкмыйдыр кебек тоела башлаган иде инде. Ниһаять, аяныйчының зурысына, механизатор каршында танышлыкның аръягына узган адәм пәйда булды. Кадим карт! Галимәнең үги этисе, Госманга бабай тиеш кеше.

Чыннан да, өскә таба киңәя барган куныйчлы резин итекләр кигән. Сырган чалбардан. Өстендә йоннан бәйләгән җылы свитер, тышлап теккән җиңсез күкрәкчә, телогрейка. Башында күн тышлы колакчын бүрек. Туңасы килми картлачның! Калын ырмаулы күзлек пыялалары аша яшькелт-соры күзләре чокырларыннан тәгәрәп төшәргә киткән кебек карый. Алардагы өркү билгеләре яшерерлек кенә түгел. Шулай да Кадим карт, сабан туенда очрашкан сыман, елмаерга азапланып сүз башлый.

— Һу-у-у, кияү, син икәнсең! Ятлармы әллә дигән идем. Исәнме, саумы, сәламәтме!

Әгәр яраса, Госман бу карт корткычны мылтык түтәсе белән сугып әйләндерер генә иде. Сәлам биреп, тел әрәм итәсе түгел һич тә. Барып төшсен иде итләч зур гәүдәсе су читенә. Капласын иде сула белмәгән алсу-кызыл йөзе белән сазга. Көн саен пәке-кайчы уйнатып, кырыптөзәтеп торган сакал-мыегын ләм сарсын иде. Тау ягы халыкларыныкы төсле бөкреле озын борыны белән җир сөрү чак буласы аңа! Ләкин самосуд заманы түгел, үз белдегең белән башбаштакланырга рөхсәт юк. Моны акылына гына түгел, холкына-канына сеңдергән Госман тешен кысып булса да чыдады. Сукмады, сүгенмәде, тик иягендәге яра эзенең кызышып бүртенүеннән үзенең халәтен ачык чамалады.

— Мин исән, мин сау...— Аның тавышы үз колагына да ят иде. Сөйләме, үкерә кебек.— Ә бичара кош синең корбаның булды.— Госман, баш кагып, Кадимнең уңягында кан саркытып яткан киек казга

ишарәләде.— Мин аларга җим өләшеп йөрим, ә син, комсыз, ит ашарга нәфселәнгәнсең... Болай да санаулы гына бит алар безнең якларда.

— Сабыр, кияү, сабыр. Артык олыдан кубма. Ят кешеләр түгел без. Сөйләшик, аңлашыйк. Бер кыр казы өчен якалашмыйк, кияү. Үрчергә яралган җан иясләре алар, берсе урынына унысы үсәр...

Әнә ничек сайрый Кадим карт! Шул тикле тыныч, шул дәрәҗәдә салкын канлы, тыңлап торсаң, оеп китәрлек, ә? Җинаять кылам дигән гаме юк. Юлбасарлыкның әллә ниндиен күтәргә була бу миһербансыздан.

— Сал табышыңны арбага илтеп! — Госманның әмере үтә кырыс иде. Кадим карт малайларча буйсынды.— Авыл советына үз кулың белән тапшырырсың. Мылтыкка кагыласы булма. Анысын участковый милициягә үзем бирәм. Хәрам сиңа корал тоту. Ауны билетың да юк бит синең. Взнос түләргә кан калтырыйсың. Ә табыш кирәк!..

Госман Кашканы авылга борып, юлга төшерде дә арбага аягын салындырып утырды. Картка «утыр!» димәде, теле тыңламады. Кадим үзе дә арба артыннан тәпиләүне хәерлерәккә чутлый иде шикелле. Аягында йон оекбашлар өстеннән җылы йомшак чолгаулар булса да, язгы су салкыны үтми калмаган иде.

Берара сөйләшмәделәр. Аннары Кадим сүз башлады.

— Син, кияү, әйткәнемчә, тәртәгә типмә әле, сүзләшик. Кияү — бабай канынннан яралган, диләр бит...

— Чайкама сана авызыңны шул «кияү» дигәнең белән! Ниткән кияү мин сиңа? Күпер башында кул сугышкан туганнар без. Вәт шул!..

Кадимгә фикерен җаергә жай гына булсын, сүз эзләп, янчыгын капшамас.

— Алай димә сәнә! Кызың кемне сөйсә, киявең шул булыр, дигәннәр. Мәхтүмәттән кем сиңа? ХатыныңГалимәнең газиз анасы булгач, әби буламы? Әби! Закун-но! Әбиеннең ире кем сиңа? Ба-бай! Менә шулай, кияү. Туганнарча сүзләшик, эрегә сырт кабартма.

Госман торган саен ныграк үртәлде. Сүз әрәм итмим, сөйләшмим дип тә караган иде, түзмәде. Теш арасыннан:

— Какой чурт бабай син миңа?! — дип сыгып чыгарды.— Кеше булсаң, бер хәл иде, аннан ары... Минем чын бабай комсыз фашистларны тукмаганда гомерен бирде...

— Анысы мәгълүм хәл бит инде, кияү. Үлгән артыннан үлеп булмый. Икенче иргә чыгу, икенче хатынга өйләнү дигән нәрсә дөньяда булмаган эш түгел. Язмыш мине әбиеннең ире иткән икән, чуртлап-гүртләп маташуың шәп түгел, кияү.

— Әйтсәм әйтим инде, аннан ары...— Госманның эчкәредә, бик тирәндә төенләп куйганнары да чишелә башлады.— Әби дә, син дә ике чабата бер киемгә әйләнеп беттегез... Берегез — указсыз мулла, икенчегез — аның остабикәсе, им-томчы. Өстәвенә каруның карунысын. Комсызлыгыңа булышып, яз башында киек кош җаны кыеп йөрисең. Утыртырга кирәк сине аннан ары!

Кадим карт, адымнарын кызулата төшеп, арба артына килеп тотынды. Гадәттә бала-чага шулай тагылучан була.

— Сунарчылык өчен утыртмаслар, кияү. Күпертмә. Аннан соң мине мулла дип битәрләмә. Ярамый алай. Авылда мәетне кем җыештырыр иде? Кем юар, кем гүргә индерер? Әҗәлен сизеп, берәү баш очына чакыртып китертә икән, белгәнеңне ничек укымыйсың? Ни нәрсәсе закон бозу моның? Ә, кияү? Икенчеләй килеп, кыр казы ите газиз әбиеңә кирәк. Казанга баргач, атаклы имче үзе әйткән, яз башында киек ите ашасаң, сырхавың кул белән сыпырып алгандай юкка чыгар, дигән... Хәләл хатыныңны тудырып үстергән, синең кулыңа тапшырган карчыкның сихәтләнүе сиңа да куаныч булырга тиеш.

Госман бәхәсләшүнең мәгънәсезлеген аңлап барды. Сизеп торды чөнки, Казан имчесе сүзләрен хәзер, кайта-кайтышка уйлап чыгарды карт азман. Шома да шома, тагын бер кат шома, коры кул белән тотармын димә! Артыгын сүз озайтмаска булып әйтте:

— Таш астыннан чыккан хәйләкәр син, ә? Газиз әбиең хакына дип... Минем йомарлап кесәгә тыгар чакларым узган. Туп-туры авыл советына кайтабыз, — диде.

Урам буйлап совет йортына кадәр барганда, Госман, үзе дә теләмәстән, Кадим карт турында белгәннәрен, кешедән ишеткәннәрен бер җепкә тезде.

...Яртуганга әйләнеп кайтып тора башлаганына алты-җиде ел гына әле аның. Истә-коста югында кайтып төшкән иде.

Яшьләр генә түгел, Госман кордашлары да юньләп белмиләр иде аны. Картлар исә белә. Заманында тирә-юньдә атаклы булган Зариф мулла малае икән ул. Әтисе диннең дәүләттән аерылуын аңлый алмаган, аңларга да теләмәгән үзсүзле диндар булган. Революция казанышларына тел озайтудан, каршы торудан да тартынмаган. Азагы шул: сөргәннәр моны.

Кадим кайдадыр Себер ягында көн күргән. Акны ак дию хак: күп йөргән, күп аралашкан, грамотасы әйтүле, русчасы нык. Өстәвенә балта эшенә осталыгы. Аннан тыш белгәне байтак. Гаҗәбрәк шул, сәгатьтер, йозактыр гына төзәтеп калмый, радио ремонтлый, хәтта телевизор көйләргә дә кулы ята. Әүвәлрәк авылдашларын шул булдыклылыгы белән җәлеп итте, аннары көтмәгәндә-уйламаганда хәзрәт-самозванец булып китте.

Үз сүзенә ышансаң, өйләнгән булган, яратышып торганнар. Ир бала туган. Тик хафалы дөньяның күчәр башы болар тормышына каты бәрелгән. Күз нурым дип кенә торган хатыны йөрәк чиреннән үлеп киткән. Кадим, улын балалар йортына биреп, Себердән Урта Азиягә юнәлгән. Һөнәрле үлми, ачлык-ялангачлыкны белмәгән, тиенгә тилмермәгән. Шулай да анда яңадан өйләнә алмаган. Буйдак килеш көннәрнең берендә Яртуганга кайтып төште. «Картлыгымда туган туфрак магниттан артык тарта башлады»,— диде ул авыл халкына. Мәхтүмәнең кече өендә яшәде. Күп тә үтмәде, Кадим абзаң Галимәнең үги әтисе булып китте. Ни әйтерсең, бер-берсенә күңелләре беректе, серләре килеште, күрәсең. Яшьрәкләрнең мәхәббәте бер якта торсын!

Кайтканда ул алтмышын тутырган иде. Кулында шытырдап торган пенсия кенәгәсе. Эшләгән елларында тал төбендә йокы симертмәгән булса кирәк, айлык тияре зар еларлык түгел иде.

Күзлек кисә кигән, мылтыктан аерылмаган. Куллары калтырау белми. Эш эшләгәндә дә... эш хакын каерып алганда да. Сәдака йомганда да, мылтык чакмасын тартканда да. Мал җыя, акча яткызмый. «Акча — кәгазь ул, тәти кәгазь. Әз кап, май кап димәктән, кечкенә булса да алтын алка, алтын балдак булсын, хрусталь-бәллүр дә ярый, келәм бик йомшак була...»

Мәхтүмә абыстаң им-том шөгыленә дип сөлек тота. Тәнгә сарышучан шул кан ерткыч суалчаннар, кан эчеп, ярты сәгать-өч чирек дигәндә, шартлардай булып күбенәләр. Сырхау кешенең хәле дә җиңеләя төшәдер.

Кадим дә — ике аяклы сөлек. Кемнеңдер гозерен үтәп, хәленә керсә, күзе туйганчы каерырга тырыша. Тырнагын батырса, төбенә тикле батыра. Алыйм дигәнен кулы белән генә түгел, күзе белән ала... Совет власте милекчелеккә табыну дигәнне крестьян рухыннан алтмыш ел куып килде. Колхозлашу крестьяндагы шул ыргылуның җирлеген бетерде. Китапчарак әйтсәң, хезмәт кешесе милекчене җиңде. Ә шулай да көрәш бетми әле, һай, бетми. Ил күләмендә җиңү күз алдында булган кебек, мал бабасыры чыгып җитмәгәннәр дә янәшәбездә...

Авыл советына кайтып җитәрәк, Кадим карт, ярга чыгарып аткан балыкны хәтерләтеп, тагын бер тыпырдап караган иде, максатына ирешә алмады.

* * *

Борчуы басылмаса да, Госман өлкән улы янына язгы чәчүне ерып чыкмый торып бара алмады. Казанга май урталарында гына кузгалды. Ташбуа белән ике арада йөри торган дизель-поезд аны башкалага кичке ун тулганда китереп төшерде. Чемоданы авыр булмагач, Госман такси-мазар эзләнәсе итмәде, платформадан туп-туры тугызынчы трамвайның тукталышына чыкты.

Шимбә киче булса да, килене өйдә юк иде. Хезмәте шундый инде аның, шимбә-якшәмбедә, бәйрәм көннәрендә ял итүле түгел. Артистка бит Фидәлия килен...

Зөлфәт этисе килүгә бик шат булды, күтәреп алырдай каршылады. Ә оныгы Газиз куанычын әйтеп бетерер хәл юк. Бабасының керфегенә кунардай булып йөрде ул һәм, балаларның һәммәсенә котылгысыз хас булганча, бик күп эшне берьюлы башкарасы итте. Укырга өйрәнгәнен исбатлады, «Әлифба»ның ике битен «су кебек эчеп» ыргытты. Үзе ясаган бер кочак рәсемнәрне күрсәтте. Фортепьянода бер бармак белән «Там, там, тамчы, там!»ны уйнап алды. Уенчык космик корабле белән мактанды (әлбәттә инде, «Үскәч, мин космонавт булам»,— диярга дә онытмады). Бабасын бик тәмле ризык белән сыйлады. Юмартлык кылганда, сый-хөрмәт күрсәткәндә, Газиз өчен иң мәзәге шул булды — бабасы тәмле нәрсәнең исемен белмәде.

— Үзең дәү, үзең шуны да белмисең!— диде онык.

— Белмим дип, без мондыйларны ашап үсмәдек бит, улым,— дигән булды Госман.— Балга катырган чикләвек төше инде ул болай...

— Түгел! Түгел! Белмәдең, белмәдең!..— Газиз бабасы каршында кушаяклап сикерде, кулларын чәбәкләде.

— Үзең әйтеп җибәр инде булмаса...— Госман аны алдына тартып китерде һәм назлап кочаклады.— Үзең дә белмисеңдер әле аннан ары...— дигән булды.

— Бел-ә-әм! Беләм!— Газиз башын артка җибәреп, күзләрен түшәмгә төбәде.— Козинак, бабакай, ко-зи-нак.— Онык шулай тантана итте.

— Казаяк дисеңме?

— Алай түгел, ко-зи-нак!— Газиз бабасының колагына иҗекләп пышылдады.

— Аңладым хәзер, аңладым, улым. Тәмле дә нәрсә икән, әй! Бик рәхмәт сиңа. Инде минем күчтәнәчне дә карап кара, эшләр болайга киткәч.

Госман ишек буендагы чемоданы белән янәшәдәге сеткадан чытырдавык кәгазьгә төреп салган күчтәнәч алып килде.

— Әйтеп кара әле, Газиз улым, мена бу нәмәрсәкәй икән?

Малай үрелеп карады да бик тиз:

— Тавык! Аны суйганнар,— дип җавап бирде.

— Юк, улым, белмәдең.

— Үрдәк алайса. Утка!

— Тагын белмәдең. Эх, сине, почык борын!..

— Каз!

— Дөрес әйттең аннан ары... Саный торгач, таптың тәки. Нинди каз икәнен сорамыйм инде. Ул тиклесен син түгел, шәһәрнең дәү-дәү апалары да белеп бетерми кайчак.

— Ә нинди каз, бабакай?— Газизгә төпченергә генә булсын, җитә калды.

— Каклаган каз, улым.

— Ә нәрсә ул «каклаган»?

— Анысын менә этиең аңлатсын инде. Ул авылда үскән егет. Аңардан сора, яме.

Зөлфәт русчалап-татарчалап улына «каклаган»ны төшендерде дә ике сөйләшер урын калдырмыйча, аңа йокларга вакыт җиткәнен әйтте. Госман юыну бүлмәсенә үтте.

Кичке чәй янында бәйнә-бәйнә хәл-әхвәл сораштылар. Зөлфәтне авыл хәбәрләре кызыксындырды, әтисенә рәссам белән актриса тормышындагы яңалыклар тансык иде.

— Минем хәзер, эткәй, шөгылем бар. Үземне уптым илаһи бер чоңгыл бөтереп алган чак. Ул да булса — «Беренче корыч карлыгач»,— диде Зөлфәт.— Ничек дип әйтим, иҗатым да шул, газабым да... Иҗат җимеше илгә булыр, газаплары җилгә очар, диләрме? Тәмамлап куйсам, ләззәте кала, газабы онытыла аның, эткәй...

— Һәр эштә шулай...— Госман өлкән улының сүзен җуплап барды.— Без дә шулай бит. Менә чәчтек. Сизми дә калырбыз, урак житәр... Киленнең кәефе әйбәтме?

— Рәхмәт, эткәй. Фидәлия әлегә бик рухланып йөри. Иртәгә баш рольдә уйнаячак. «Вөҗдан»ны куялар. Барырбыз дип беләм.

— Барып караганда, бик ярар иде, кана. Безгә сирәк киләләр бит. Игеннәр өлгергәч булса, анысын да күрми каласың аннан ары... Һәр бирмеш көнне төнен эшләү киленне алҗытадыр, мин әйтәм.

Зөлфәт көлемсерәп куйды. Әтисе белән килешәсе килми иде аның.

— Гомеремне иҗатка бирәм дип адарынган кеше армый, эткәй. Бигрәк тә артист халкы.

— Соң артист дигәч тә адәм балалары лабаса алар да!

— Үзләренә бер төрлеләр. Аена утыз мәртәбә уйнат син аларны, көн саен төрле-төрле рольдә булсын, эһ тә итми, риза-бәхил. Югыйсә хезмәт хакы шул ук, аена өч уйнаса да шуны ук ала. Рольдән генә мәхрүм итә күрмә... Әгәр бөтен һөнәр ияләре дә бер ук хакка дүртбиш норма үтәргә ашкынып торсалар, ә?

— Шулай шул, әй! Хикмәт нәрсәдә?

— Иҗатка шашып гашыйк булуда, минемчә.

* * *

Спектакльнең беренче пәрдәсе азагындарак сәхнәгә Зәйтүнә — Фидәлия килеп керә. Ул әле бер сүз дә әйтергә өлгермәде, нинди дер мәгънә аңлатырлык бер хәрәкәт тә ясамады, ә зал гөрләтеп кул чапты. Тамашачы ихтирамын казанып өлгергән актрисаны тәбрикләү иде бу.

Грим, сәхнә утлары да булыша бугай, Фидәлия бик чибәр иде. Партердагыларның аңа сокланып куюларын Зөлфәт тә, Госман да сизеп утырдылар.

Тормышта Фидәлия өзелеп чыккан гүзәл дия торган түгел, әмма аңардан да сөйкемле йөзле кешене күз алдына китереп булмастыр кебек. Нәфис ак маңгаенда акыл нуры чагыла, күзләрендә җанлы фикер очкынлана, тавышында зирәклек яңгырый, ул бик-бик самими. Аны тыйнак дип, кыюсыз дип кенә атар хәл юк. Бу ике сүз аңа йокмас иде. Күз алдында чын мәгънәсендә әдәпле-итәгатьле, әчке матурлыгы булган бер зат...

Спектакльдән соң Зөлфәт белән Госман Фидәлияне көтеп алдылар. Артистларны Ленин районына илтүче автобуста кайттылар. Өйдә, төнге чәй янында, спектакль турында сүз куерды.

— Ошаттыңмы, эткәй? — диде Фидәлия. Мактау сүзе өметләнүдән түгел (ул байтак мәдхия тыңлады инде), кайнатасының фикерен ихластан беләсе килеп сорады.

Госман, биш бармакка куеп эчкән чынаягын өстәлгә куеп, авыз тирә-сен салфетка белән сөртте дә, сүз башлады.
— Ошады дип бер сүз белән генә әйтү аз, кызым, бик аз. Әмма да ләкин мин матурлап сөйли белмим бит. Без өйрәнмәгән аңар. Чынын күрсәтәсез, менә шул... йөрәкне телем-телем телгән хәлләрне. «Вөждан» дип дөрес кушкансыз. Өч кешенең вөжданын сөйлисез бит. Ул өч кеше генә дә димәгән аннан ары. Дөнья киң, мондыйрак язмышлар да аз түгел. Не әбәзәтелни ир белән хатын арасында гына... Вөждан һәр җирдә сынала.
— Рәхмәт, әткәй. Каяле, чәеңне яңартыйм.— Фидалия тагын чүкердәп сөйләшә башлады. Кайнатаның театр хәлләре белән кызыксынуы аның күңелен үстереп җибәргән иде. Югыйсә артистларга өстән караучы тәкәббер мокытлар да бетмәгән бит әле...
Дүшәмбедә Фидалиянең ял көне иде. Ул, Газиз белән әвәрәләнеп, өй эчендә мәшәкатьләнә калды, Зөлфәт әтисен үзенең мастерскоена алып китте.
Госманның әлегә кадәр дә монда булганы бар иде инде. Рәссам хезмәтенә бәйле тәртипсезлек хөкем сөргәнне күргәне бар. Бу килүендә исә ул мастерскойның нурланып китүен искәрде. Баксаң-торсаң, ул җылы яктылык түрдәге зур полотнодан бөркелә икән. Бәрәкәт! Ярсөяр әрәмәсе буйлары Казанның Зур Кызыл урамындагы йортка күчеп килгән ләбаса!
...Әнә «Фордзон-путиловский» тракторының рулен Госманның әтисе — Фәйзерахман тоткан. Ул аерым хуҗалыкларның корама юргандай кишәрлекләрендәге ызаннарны сөрергә, әрәмәлек артындагы җирләрне колхозчыларның уртак басуы итәргә бара.
Авылның яше-карты тракторга ияргән. Бала-чага, борылгалап артка карый-карый, машинаның алдыннан ук элдертә. Җиде-сигез яшьлек малайлар арасыннан Госман үзен танып алды. Кара син бу йөздәге куаныч-мактанычны! Күр син бу күкрәкләрнең ни рәвеш киерелеп торуын! Киндер ыштан балагы тездән әллә ни узмаган булса да, кәефе әсыл кош токтандагыдай малайның. Әй кәк же! Әтиең авылга беренче тракторны алып кайтсын әле!
Корыч айгырны басуга озата баручылар арасында ил агасы картлар да, ир уртасы кешеләр дә бар. Егетләрне, кыз-кыркынны әйткән дә юк. Тракторның эзенә үк басып баручы кызларны Госман шундук таныды. Гәҗилә белән Сөембикә. Соңыннан, сугыш елларында, үзләре тракторчы булган кызлар.
Өлгереп килә торган картинаны озаклап, тәмләп карагач, Госман үз янәшәсендә сүзсез генә басып торган Зөлфәткә эндәште.
— Әрәмәгә бик якын итеп ясагансың дип әйтимме, улым? Ул елларны басуга юл арырактан төшә иде бит...
Зөлфәт көлемсерәп куйды.
— Дөрес әйтәсең, әткәй. Ул елларны басу юлы арырак булган. Мин хәзерге юл тирәләре итеп алдым. Картина дигән нәрсә фотосурәт түгел бит ул. Тормышта булганны тиенгә-тиен күрсәтергә димәгән. Сәнгать әсәрендә авторның хыялы да була. Әйтергә теләгәнен тулырак итәр өчен ул шартлылыкларга да бара. Авылга кайткан беренче трактор, аны тәзгенләгән беренче тракторчы Фәйзерахман, озата баручы авылдашлар — һәммәсе яңа тормышны чагылдыручылар, әткәй. Аларны Ярсөяр әрәмәсенә якынрак итүдән максатым ни иде диярсең. Әйтим: Ярсөяр әрәмәсе — табигатьнең матур бер почмагы — апрель азагында, май башында яңару кичерә, яшәрә, ямьләнә. Күмәк хуҗалык юлына баскан игенченең тормышы да әрәмәлек матурайган кебек матурлана барачагына ишарә монда. Шуна ым кагу. Күрәсең ич, әрәмәне нурга күмгән кояш авылдашларга да елмая.
— Алай икән! — диде Госман һәм бер-ике адым арткарак чигеп,

картинаны янә җентекләп карый башлады.— Алай икән. Шәп әйттең бит әле син монысын, улым. Мин үзем дә әрәмәлекне һушларым китеп яратам. Тормышыбыз матурлыгына тиң китереп әйбәт әйттең аннан ары.

— Тарихи чынлык шулай бит, эткәй... Менә Октябрь юбилеена өлгертеп, күргәзмәгә куя алсам, шәп буласы. Күргәзмә ачыласы көнгә авылның аксакалларыннан берничә агайны чакырам әле. Карарлар, сүз әйтерләр. Бер уңайдан кунак булып та китәрләр.

Сүз җае чыкты Госманга. Улы «кунак» сүзен әйтүгә, эләктереп алды.

— Октябрь бәйрәменнән алдарак, сабан туй тирәләренә үзеңә кайтырга туры килер әле, ахры, улым, кунакка. Өлфәт өйләнергә җыена,— диде.

Зөлфәт бу хәбәрне хуп күрде.

— Бик вакыт, вакыт... Киленебез кем булачак инде? Казанга килгәч, энекәшнең үзеннән сораштырып баккан идем, шаярып котылды. «Кызлар беткәнмени?!» дигән була.

Госман мастерскойның аргы башындагы өстәл янына барып утырды. Зөлфәт аның янына килде.

— Килен, улым, күрер күзгә бер дигән. Авылда фельдшер. Сүзгә дә бик ипле күренә. Тәрбияле бала. Эшләп үскәнгә охшый. Олыларга мәрхәмәтле булыр төсле. Өлфәтне бик ярата булса кирәк, күзенә генә карап тора. Хәзергә аны шундый итеп беләбез. Бергә көн итә башласалар, нишләп китәр тагын?!.

— Нишләсен, әйбәт хатын, менә дигән килен булыр.

— Шулай булсын иде инде, шулай. Югыйсә бит тормышның яметәме калмый аннан ары. Атың начар булса, сатып котылырсың, күршең начар булса, качып котылырсың, хатының начар булса, ничек котылырсың дигәннәр бит.

— Хатынның яхшылыгы-начарлыгы ирләрдән дә күп бәйле, эткәй. Үзегезнең яныгызда торасы кешеләр, җаегызга өйрәтерсез. Безнең энкәй белән нинди килennең дә сере килер дип беләм.

— Әнкәң хакында анысы шулай. Шула-а-ай... Тик бәгырьне тырнап торган бер нәрсә бар. Театрдан кайткач ук та сөйләргә дип калкынып карадым да, килен алдында кирәксенмәдем. Үзең белән киңәшим дидем башта.

— Тыңлыйм, эткәй.

Госман, ничегрәк башлап китәргә дип, беркадәр тын торды. Аннары «Өлфәтнең туган көн мәҗлесендә мәгълүм булды бу өйгә да килмәгән яңалык» дип сөйли башлады. Җеген җеккә китереп, барча ваклыклары белән, озак итеп сөйләде. Күңел җәрәхәтенең сулкылдап-сулкылдап куюын Зөлфәт сизеп торды, бүлдермәде.

— Инде ни кылырга да белгән юк. Акылым җитми аннан ары,—дип сүзен тәмамлагач та, рәссам улы эндәшми торды. Бүрек чөеп кенә җавап бирә торган хәл түгел. Ниһаять, Зөлфәт уң кулы белән ботына шапылдатып сукты да креслодан торып йөренә башлады. Арлы-бирле узгач сүзгә кереште.

— Киңәшим диден, эткәй. Тотар булсаң, тыңлап кара минем киңәшне.— Зөлфәт кулларын чалбар кесәсенә тыккан килеш, аяк бармакларына бер күтәрелеп, бер төшеп, дәвам итте.— Беренчедән, эткәй, син бу хакта энкәйгә дә, яшьләрнең үзләренә дә бер сүз дә әйтмә. Сугышны бергә узган кодалар и вәссәлам! Монысы әнкәй күңеленә суык төшермәс өчен дә, Зөлфәт белән Сәвия мәхәббәтенә көя булмас өчен дә кирәк. Икенчедән, монысы инде иң мөһиме, үчләнмәскә тырыш, эткәй.

Госман нидер әйтергә теләп урыннан күтәрелгән иде, улы, гафу сорагандай, аны туктатты.

— Аңлыйм. Рәнҗемәслек тә, онытылырлык та түгел. Шулай да

узган эшләргә салават дип карарлык дәрәҗәдә булу хәерлерәктер бу очракта. Язмыш кыл өстендә чагында кеше куркаклык күрсәткән, үз гомерен генә саклауны уйлаган. Ләкин шуннан соң посып ятмаган, сугышкан, кан түккән. Әле дә булса хезмәттә. Мин боларны, бу дөньяда барлык гөнаһларны ярлыкап торырга кирәк дигәннән әйтмим, аерым хәлләрдә кичерә дә белү ярый дип сөйлим. Миңнәхмәт абзыйның үзе белән ирләрчә, фронтовикларча аңлашмый калмассыз дип беләм.

— Үзем дә мең төрле уйлап карадым инде мин аны,— диде азактан Госман.— Берәүгә дә авыз ачып сүз әйткәнем юк бу хакта. Беренче киңәшкәнем син.

Аның өлкән улы киңәшен тотасы ачык иде.

*

* *

Иртә килгән яз галәмәте: Май бәйрәме алдыннан ук тирә-юнь күзне иркәли, җанга иң ләззәтле хисләр өсти торган гыйффәтле бер яшеллек хакимлегендә иде инде. Хәер, алай гына да түгел. Ал төскә ни әйтерсең?! Алмагач чибәрләре, чия кызлары, шомырт гүзәлләре ак ефәк күлмәк кигәннәр. Җете-яшел яфраклар исә, үзара лепердәшеп, тыгыз бөреләр карынында кичергән хәлләрен сөйләшәләрдер төсле. Бар гомерен күктә сәяхәт кылып уздыручы җил һәр тарафка язгы урман-кырларның хуш исен тарата. Елгаларда, күлләрдә су мөлдерәве рухны киңәйтә. Кошлар моңын әйткән дә юк. Таң сызылганда, кояш әле тәүге нурларын гына күк гөмбәзенә сирпегәндә, алар авазы аерата саф, самими була. Иртүк басуга кузгалган игенче күңеле тоя, ишетә: басулар иркен сулый, киңәнә. Бу — тормыш сүлененң хәрәкәте.

Җир өлгергәч үк чәчкән игеннәр матур булып тишелеп чыктылар да буй тарта башладылар. Һәр кыяк кояшка үрелә.

Беренче Май бәйрәменнән соң бер атна үткәч, эшкә килүенә, Сәвияне күрше бинага урнашкан элемтә бүлегенә телефонга чакырдылар. Район үзәге Ташбуадан шылтыратканнар.

Сәвиянең кәефе язгы иртә кебек иде. Халатын да салып тормастан, яз җырын көйли-көйли почтага кереп китте.

Сайра син, тургай,
Шауласын тугай,
Күкрәп үссен
Кырларда бодай...

Элемтә бүлегендә эшләүче ханым нидер язып утырган җиреннән баш кагып исәнләште дә кабинага ымлады.

Сәвия шунда керде, трубканы алды.

— Яртуганнан Сөнгатуллина тыңлый,— диде ул.

Аның гаҗәбенә каршы трубкадан бик тә таныш, бик тә якын тавыш килде.

— Исәнме, кызым! Бу — мин, әтиең. Кичтән район үзәгегезгә килеп төшкән идем, төнлә борчыйсы итмәдем. Исәнме!

— Әткә-ә-әй!— Сәвия нәни балаларча куанып кычкырып куйды. Ярый әле кабинада, югыйсә, элемтәче апаң: «Нишләве бу Сәвиянең?» дияр иде, мөгаен.— Исән генә килдеңме, әткәй? Өйдәгеләр сау-сәламәт калдыларамы? Әнкәй авырмыймы? Ярар, барысын да килгәч сөйләшербез. Безгә рейсовый автобус йөри йөрүен дә, аны беравык көтәсе була. Мин, әткәй, хәзер Габделәхәт абыйдан, председательдән дигәнем, җиңел машинасын сорап торам да үзем барып алам. Кырык минутта Ташбуада булабыз. Син гостиница янында гына тор, яме, әткәй!

Миңнәхмәт бу сүзләргә каршы үтә сабыр җавап кайтарды.

— Тукта әле, кызым, бик үк кабынып төшмә. Син үзең кил. Килүең кирәк тә кирәк. Мин, гел сине күрер өчен генә дип, өч көнгә эштән со-

ралдым. Соңгы хатында язганнарыңа кагылып сөйләшәсе сүзләр бар. Авылыгызга бармаска дигән карарда мин. Һәм сәбәпсез түгел. Сөйләшербез, бик тиз кил. Кичләтеп мин Казанга китәм, Целиноградка кадәр самолет билеты кулымда.

Сәвиягә галәмәт күңелсез булып китте. Ул боегып калды. Гүя кояшны соры болыт юрганы сарды, көзге шыксыз яңгыр коярга кереште, җилеккә үтәрдәй салкын җил исте. Сәвия тулышып-мөлдерәнеп әтисенә ялына-ялвара башлады, үпкәсен сиздереп, еларга җитеште.

— Булмаганны сөйләмә инде, әткәй. Меңәр чакрым җирдән килеп, кызыңның ничек яшәгәнен дә күрми китәргә син теге... Меңен килгәч, утыз чакрымында терәлеп калмыйлар инде, язмаганны! Хәзер алып кайтам үзеңне, бер кич булса да кунып, кунак булып китәрсең.

Миңнәхмәт сүзне озакка сузудан мәгънә югын аңлап, әйтте шунда:

— Ярар, кил әле хәзер үк, рөхсәт ал да кил. Калган ягын монда килгәч тә хәл итә алабыз,— диде.— Шулай да әти килгән, аның янына барам дип сүзләнмә. Аңладыңмы? Үз кирәгем белән барам диген. Медикаментлар алырга...

— Мине гостиница янында көт, яме.

Телефон трубкасын элгәндә, аның йөзеннән нур качкан, күзләренә монсу уйчанлык кереп оялаган иде. Әллә ниткән сәер сүзләр сөйләде ич әтисе! «Авылыгызга бармаска дигән карарда мин», «Әти килгән, аның янына барам дип сүзләнмә!» Ничек аңларга боларны? Үтерәм дисәләр дә, төшенер хәле юк Сәвиянең. Ә барырга кирәк инде. Монысы — котылгысыз, мәҗбүри!

Сәвия колхоз идарәсенә китте.

Юлда барганда, шофер егет Сәвиягә карап сәерсенсә дә, баштарак сорарга базмады. Ярты юлны узгач, түзмәде, телләнеп сорады.

— Врачыбызның балтасы суга төшкәнме әллә бүген? — диде.— Әллә булмаса Өлфәт абый кичтән хәтерен калдырганмы? Сәвия дигән медичкабызны сөмсере коелганда күргәнебез юк иде.

Тел шомартырга бер генә дә теләге юк иде шул Сәвиянең. Уен-көлкегә, җиңел-җилбәзәк сүзгә урын калдырмаска тырышып җавап бирде.

— Исәнлегем китеп тора. Башым бик сызлый, йөрәгем уйнаклый,— диде. Шулай дигәч, шофер да теш агартмады, «Медиклар да авырый мыни соң?» дию белән чикләнде.

Шоферга партия райкомына ниндидер кәгазьләр тапшырырга кушканнар иде, ул шунда калды. Сәвия гостиницага юнәлде. Көтеп тормаска кушты, рейсовый белән кайтырмын диде.

Миңнәхмәт кызын кунак йорты бакчасында көтә иде. Елдан артык күрешмәгән әтисен Сәвия кочаклап алды. Бала чагындагыча итеп. Кызның күзләре тулы яшь. Әтисе аны юатырга итте, ләкин булдыра алмады, чөнки үзе дә тетрәнгән бер хәлдә иде.

Бүлмәгә керделәр. Миңнәхмәт ике кешелек номерда ялгызы гына иде.

Сәвия әтисенә текәлеп карады. Сулып калган ата кеше. Гәүдәсе дә чүккән сыман. Ябыкканлыктан битендәге миңе зурая төшкән кебек. Борын төбеннән ике яклап тирән җыерчыклар сузылган. Йонлач беләкләрендәге төкләр суыктан чиркәнеч алгандагыча тырпаешканнар. Чәчендә чал ишәйгән.

— Сәяхәтең сәер синең, әткәй. Мин ни уйларга да белмәдем, башым катты,— диде Сәвия өйдә калганнар хакында бәйнә-бәйнә сораштыргач.— Нәрсә бар, ни булды сиңа? Кызың эшләгән авылга бармаслык нинди сәбәп килеп чыкты? Аңлата күр, әткәй, тынычланыйм ичмаса.

Госман Галиев белән сугышта аерылышкан көнге хәлләрне бик газапланып сөйләде Миңнәхмәт. Үткәннәрне хикәя кылган сәгатьтән артык вакыт эчендә аның җаны көекте.

— Мин аны исән калыр дип һич кенә дә уйламаган идем. Гомере барга сәбәп: аны табып алганнар, значит. Яшәсен, көн күрсен, дөнья иркен. Ну мин хәзер, утыз өч елдан соң, фани дөнья тәмугында янам. Яна торам, яна ит үсә тора. Сүндереп булмый ул ялкынны. Үзем генә булсам, яна торгач, бер янып бетәр идем дә, дөнья куяр идем. Язмыш җәзалап көлә диярсең, синең тормышың да Госманнар гаиләсенә уралырга тора икән. Бетереп вагъдәләштегез мени соң? Чигенер җай юкмы? Барлык күперләр янганмы артта? Һич югы, туегызны кичектереп торып булмыймы? Тора-бара бәлки өйләнешмәү дигәнгә дә риза булыр идегез. Аптырагач әйтүем, мәхәббәтегезгә бер дә тыкшынмас идем дә...

Сәвия телсез калды. Әтисе койкасы каршындагы икенче караватка барып утырды да, кульяулыгын күзләренә каплап, үкседе дә үкседе. Миңнәхмәтнең аскы иренен тешләштергәләп, кара уйга батып утырудан гайре чарасы юк иде.

Сүзсез манзара мәңге дәвам итә алмый иде.

Тынлыкны Миңнәхмәт бозды.

— Я, Сәвия кызым, ни кылабыз, нишлибез? — диде.

Нишләргә икәнен Сәвия белә идемени инде, я? Дөньяда үзе өчен иң газиз кешеләрнең берсе булган әтисеннән ул бүген җан тундырырлык сүз ишетте. Яу ярасына дучар булган, сугыштан соң алны-ялны белми эшләрлек куәт тапкан әзмәвердәй ир, авыр сынау килгәндә, үлем белән тартышып яткан иптәшен япан кырда ташлап китсен әле! Аның хәзер үкенүеннән, вөҗдан газабы кичерүеннән ни файда? Фронтовик иптәшенең күзенә ни йөзе белән күренә ала ул? Бүген бармады, ди, Яртуганга, бер ел килмәде, ди. Моның белән генә эш бетәмени? Юк бит, юк! Кыңгыр эш кырык елдан соң да калкып чыга. Без капчыкта ята алмый. Әгәр дә Сәвиянең тормыш юлы Өлфәт язмышы белән бәйләнергә тиеш булмаса, үзенең куркаклыгы, сугышчан дустына карата эшләгән эшәкелеге турындагы серне әтисе кабергә алып китәр идеме икәнни? Соңгы сулышында да берәүгә дә чишмәс идеме икән?

Җан ярасына тоз сипкән шушы төндәй кара, кургаштай авыр уйлар җәзалый Сәвияне. Торып-торып әтисеннән сагая башлый ул, кул бирми китәргә җыена. Җирәнү тойгысы бугандай була аны.

Аннары икенче бер уй дулкыны күңел ярын кага башлый. Күрәсең, сугышта төрлесе була торгандыр. Аның әтисе: «Госман чыннан да җан бирде инде, котылу ягын карыйм, үләргә артыннан үлеп булмый», дип исәпләгәндер. Әтисенә карата шул тикле каты бәгырьле, таш йөрәкле булуы белән тулысынча хаклымы Сәвия? Теләсәң генә ни диген, ул бит аның газиз атасы! Аңа тормыш биргән кешеләрнең берсе. Сәвиянең, Сәвия кебек меңнәрнең бүгенгесен яклап сугышкан, фашист белән бугазга-бугаз килеп сугышкан кеше. Бүген дә ул ил өстәленә мул итеп ризык кую өчен көннәрне төнгә ялгый.

Шундый хәл килеп туды: бер якта әтисе, икенче якта Өлфәткә булган мәхәббәте. Кайсын сайларга? Өченче юл юкмы? Һәрхәлдә, урта юл күренми.

Миңнәхмәт соравын кабатларга мәҗбүр булды. Дәшми калу мөмкин түгел иде.

— Теләсәң нәрсә диген, әткәй, мин Өлфәт белән кайтып киңәшәм. Ул хәл итсен. Миннән йөз чөерә икән, аңа үпкәләмәм. Күрәчәгем шулдыр диярмен... Ул чагында мин Яртуганнан китәм. Бөтенләйгә, башымны алып,— диде Сәвия катлы-катлы көрсенеп. Ул китәргә җыенды.

— Тукта, кызым, аз гына сабыр ит,— дип кулларын Сәвиягә сузган Миңнәхмәт тә торып басты.— Сабыр ит. Әтиең хакындагы авыр сүзне яратып йөргән кешенә сәгате-минуты белән ачып салу кирәкме икән?

Атаның бу соравы кызны ярсытты гына.

— Ичмаса, хәзер, утыз өч ел үткәч, калтырамаска иде сиңа, әткәй,— дигәнен тоймый да калды.— Җинаятьләрнең моннан да зурракларын кичерәләр күп гомер үткәч. Гөнаһыңны таный белергә кирәк, гафу сорарга, кичерү гозерләргә, тезләнергә... хуш.

Сәвия китеп барды. Миңнәхмәт, дөньялардан үткән кебек, торatаштай басып калды.

*
* *

Июнь башы Госман гаиләсенә сирәк була торган куаныч китерде.

Ташбуада язгы чәчү алдынгыларының район слеты булды. Шунда аталы-уллы Галиевларны шәһәр бакчасы буендагы трибуна алдына куелган хөрмәт пьедесталына менгерделәр. Госман — беренче урынга, Өлфәт икенче урынга басты. Өченче урынны «Октябрь бүләге» егете яулады. Кыр баһадирларының өчесенә дә иңнәре аша киң кызыл тасма тактылар. Тасмаларга «Чәчү батыры» дип язылган иде.

Аннары алдынгыларга бүләкләр тапшырылды. Басу фидакарьләрен тәбрикләгәндә, партия райкомының беренче секретаре Госманны механизатор-ветеран итеп, Өлфәтне аталар эстафетасын кабул иткән буын вәкиле буларак бик җылы котлады. «Госман иптәш Галиев — авыр яраланып кайткан фронтовик. Тыныч хезмәттә дә тынгы белми генә түгел, һәрчак уң флангта атлый. Ял итим дияргә дә, һич югында, җиңелрәк эш бирегез дип әйтергә дә хакы бар аның. Әмма фашистларга каршы аяусыз сугыш елларында коммунист билеты алган Госман Фәйзерахманович андыйлардан түгел!» диде.

Бүләкләнүчеләр исеменнән җавап сүзе сөйләргә кирәк булгач, Госман артыгын дулкынланды бугай. Үзенә сүзенең рәте-чуты булмагандай тоелды. Чынында исә хикмәтле сүз әйтте ул. «Кеше яшәвенең өч чыганагы бар. Ул яшәр өчен ашый-эчә, яшәр өчен йоклый, ял итә, яшәр өчен эшли. Мине, зинһар, өченче чыганактан аера күрмәгез. Киләчәктә дә йөземә кызыллык китермәслек итеп яшәргә тырышырмын. Рәхмәт сезгә»,— диде.

Өлфәтнең сөенече үз йөрәгенә генә сыярлык түгел, коңгырт күзләреннән ташый, һәр хәрәкәтендә сизелә, чайпалып түгелә иде.

Киенеп-ясанып, гомердә булмаганны күзгә каршына кабат килеп төзәтенә-төзәтенә җыенып, культура сараена китте. Сүз куешмасалар да, Сәвия анда иде инде. Ярты минуттан артмаган ике кешелек киңәшмә «кинога кермәскә, җәйге төн һавасын урамда суларга!» дигән карар чыгарды. Тиздән алар эңгер-меңгер эченә кереп югалдылар. Кай якка барабыз дип берсе дә сорамады. Ике яшь йөрәкне Бозлы буе, Ярсөяр әрәмәсе чакырып тора иде шикелле.

Басу капкасын чыккач, Өлфәт Сәвияне култыклап алды, аннары гел көтмәгәндә үрелеп үпте. Кызның чытыклануы идеме, әллә чыннан да уңайсызланып калдымы, ул читкә тайпылды. Тәмсезләнмәде, үпкәләмәде, әлбәттә. Бары тик:

— Район слетыннан сөйдергеч биреп җибәрделәрме соң әллә үзеңә? — дип кенә усалланды. Өлфәт рәхәтләнеп көлде. Аннары Сәвияне тагын култыклады.

— Слеттан, Сәвиям, гарәпчәләп әйтсәк, эль-иксир, «яшәү эликсиры» биреп җибәрделәр. Медикларга да бу сүз бик таныштыр дип беләм. Мәңгелек яшьлек бирә торган эчемлек. Мин шуны эчтем. Районда әтисеннән кала икенче урынны яулаган чәчү батырына хәрам булмас дидем...— Ул тагын, башын артка атып, шыркылдап көлде. Сәвия дә кушылып көлми булдыра алмады.

— Син дә мактана беләсеңмени соң, ходаем?— диде кыз соңыннан.— Бүген чыннан да бераз кабып алдыңмы әллә?

— Шатлыктан исердем, Сәвия, шатлыктан. Хезмәтемне күрә белгәннәренә сөенүдән... Трибунага басып сөйләмәдем, инемә тасма таккан Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй агага рәхмәт диюдән узмадым, ну күңелемнән ант эчтем, моннан ары икеләтә дәрт белән эшләрмен дидем... Икеләтә дәрт белән! Җир җимертеп, Сәвия!— Шулай сөйләнә-сөйләнә ул тәмам ярсынып китте һәм Сәвияне биленнән тотып өскә күтәрде дә әйләндерә башлады. Кыз чәбәләнде, куллары белән Өлфәтнең ияген этәрде һәм чырылдавык тавышын кызганмастан:

— Җибәр, дим, җибәр. Аю! Кысып сытасың лабаса! Өлфәт дим, җибәр!— дип ялынды. Аны тып иттереп җиргә бастырып куйгач, сулышы ешайган Өлфәт сөйләнеп алды:

— Сытыла торганнардан түгел син, Сәвия. Балык кебек шомасың. Кулдан ычкынырга гына торасың сыман. Алай да белеп тор, минем кулда көн бияләй булыр. Читкә-чатка җибәрмәм, йомарлап тотармын.

— Синнән китәргә җыенган кеше юктыр бит әле, ни дип сөйләнгән буласың, эль-иксир шаукымымы һаман?

— Чынын әйтимме, Сәвия? Әйтәм. Мин кайчак уйлап-уйлап торам да курка башлыйм. Кемдер көннәрнең берендә сине миннән тартып алып китәр төсле тоела. Чынлап, чынлап. Каян килә мондый уйлар, ник килә — үтер, әйтә алмыйм, ә киләләр. Ярату шулай итәме?

— Анысын инде мин дә белмим, Өлфәт.

Мәхәббәт фәлсәфәсе юлны кыска итә. Алар Ярсөяр әрәмәсенә якынлаштылар.

— Ярый, шикле уйлар ник килүен белмисең дә, ди, монысы шулай да булсын, ә үзең нигә уйчанландың? Сәбәп нәрсәдә? Ай буе диярлек күз кырыем белән генә күзәтеп йөрим, сүлпәнләнден син, Сәвия. ЗАГСка гариза биргәч, уйга калуыңмы, кире уйларга исәп итүеңме? Әйт әле дөресен генә, ни булды сиңа?

— Бер ни дә булганы юк.

— Алдашма. Сиңа ялганлау килешми. Ялганлый белмисең.

Әрәмәнең бирге башында җиргә ике бүкән утыртып, аркылы такта сузган озын эскәмия бар. Авылның диванага сапкан карты — Мөхәммәтвәли бабай ясаган аны. Ул савап җыеп йөри шулай. Чишмәкизләүләрне чистарта, юлдагы чокыр-чакырны тигезли, күгәрченнәр ашата, зират коймаларын төзәткәләп тора.

Яшьләр Мөхәммәтвәли бабай эскәмиясенә утырдылар.

Ай калыкты, офык читеннән әкрен генә күтәрелә барды. Торабара әрәмә өсте көмеш суы сипкән сыман булып калды. Куак яфраклары тоныкялтырау белән ялтыраштыЯрау һаваны ярып, ниндидер кош телгә килде. Өздереп чыркылдавына караганда, ай нурына сөенә иде булса кирәк.

— Сандугач ашыкмый әле,— диде Сәвия телен йоткан кебек утырмастан. Уенда исә бөтенләй башка нәрсә иде. Ай үтте, әтисе белән очрашуы хакында Өлфәткә әйткәне юк әле. Булдыра алмый. Әтиең кадәр әтиең хакында яман хәбәрне сөйләп китәсе ансат түгел икән шул.

— Сандугач үз кадерен белә ул, таңны көтә. Таң сызылгач кына чутылдый башлый. Әйдә бүген таңны шушында аттырабыз, Сәвия. Өшемисеңме? — Ул пинжәген салып кызның җилкәсенә бөркәндерде.

Сәвия Өлфәтнең сандугач хакындагы сүзләренә дә бөртек тә игътибар итмәде, иннәренә пинжәк салуын да дикъкатеннән читтә уздырып җибәрде һәм ничектер капыл гына:

— Әремле ипи ашаганың бармы синең, Өлфәт?— дигән сорау бирде.

— Юк, нигә сорадың? Тиктомалдан.

— Әнкәйнең сөйләгәне бар.— Сәвия сүзне шулай башларга булды.— Сугыштан соңгы елларда, ачлыктан, мохтаҗлыктан арыга

башлап, мич тутырып ипи салганнар болар. Яңа уңыш онынннан. Ипиләр шундый матур булып пешкәннәр, авызга су китерәләр икән. Мичтән алып, өстенә ашъяулык-тастымаллар каплап бермәл суытканнар да, кукрәккә терәп, телем-телем кискәннәр. Авыз тутырып чәйни башласалар, һәммәсе чәйнәгән ризыкларын йотарга да, йотмаска да белми туктап калганнар. Арыш арасында әрем үскән. Урдырган бөртек арасына эләккән. Җилгәргәндә дә очмаган. Тегермәндә арыш белән бергә ташка эләккән, онны пычраткан. Ашый алмаслык ипигә мөлдерәп карап торган әбекәй — әнинең әнисе — әйткән шунда: «Сугыш ачысы бу. Ләгънәт фашист явының ачысы. Сугыш булмаса, басулар ир-егет кулы белән сөрелсә, әрем үсәр идемени арыш арасында?!» — дигән.

Өлфәт Сәвияне бүлдермәде, бер сүзен дә ычкындырмаска тырышып тыңлады. Ниндидер киная ятканын чамалый иде ул бу сүзләрдә, тик ни нәрсә икәнен һич кенә дә чамалый алмый.

— Бу мәсьәлнең төбенә тоз койсак, ни килеп чыга инде? — диде ул алай уйлап баккач, болай үлчәп карагач.

Сәвия үз алдына сөйләнгән шикелле генә җавап кайтарды.

— Безнең хәлләр дә, Өлфәт, әремле ипине хәтерләтергә тора бит әле,— диде.

— Ничек? Монысы тагын нәрсә? Иске авыздан яңа сүз димәсән.

Егет урыныннан торды да, Сәвия каршына басып, аны иңнәреннән тотты.

— Урау юллардан йөреп маташмый гына әйт әле, нәрсә бар?

— Безнең мәхәббәтебез дә әремле ипи төсле. Бер-беребезне үз иттек, вәгъдәләштек. ЗАГСка гариза бирдек. Авылдашлар хуплый, сизелеп тора. Көнләшүчеләр дә бардыр бәлки. Матур дуслык хөсетле кешеләргә тынгы бирми. Тик... гамәлгә ашмас бугай безнең бергә булабыз дип ашкынуларыбыз.

— Ни сөйләвең бу? — Өлфәт кулларын Сәвиянең иңнәреннән алды да артка чикте, сәерсенү белән кызга карады. Ай нуры шулай күрсәттеме, әллә чыннан да Сәвиянең чырае ак бәзгә охшап калган иде-ме, егет куркынып сорады:

— Акылыңа зыян килмәгәндер ич? Тузга язмаганнарны сөйлисең,— диде.

— Акылымда мин, Өлфәт. Утыр әле, кызма, тыңла. Шуннан ни дисәң дә ихтыярың.

Һәм Сәвия барысын-барысын түкми-чәчми сөйләп бирде.

*

* *

Кич иде. Көтү керде. Мал-туар төркеме артыннан бөркелеп күтәрелгән тузан, сөт исе, терлек исе белән аралашып, янә җиргә ятты, өйләрнең бүрәнә сыртларына, тәрәз йөзлекләренә сыланды, агач яфракларына кунды.

Мастерскойда эшен түгәрәкләп кайткач, Госман озаклап, тәм табып юынды-таранды, өс-баш алыштырды, аннары гына аргы башында электр самавары пар чыгарып утырган өстәл янына килде. Галимәсе, чынаякларга чәй коя-коя, колхоз бакчасындагы хәлләрне сөйләп алды. Шау чәчәктәге җимеш куакларына соклануы чиксез иде аның.

Шул чак кече капканы киң ачып, йортка Кадим карт килеп керде. Бер генә дә житмешне куып баручы кеше димәссең, болдырга да җил-җил менеп китте, аннары өй ишеген шакыды.

— Рөхсәт микән бу гурничәләргә керергә?

— Әйдүк, Кадим агай! — диде Госман. Үз бусагасына килгән кешегә гомере бакый караңгы чырай күрсәткәне юк аның.

— Мактап йөрисең икән, әйдүк, Кадим абзый,— диде Галимә дә урыныннан торып. (Ул Кадим картка «әти» дип әйтергә күнегә алмады. Кирәксенмәде дә, тырышмады да дию хак булыр.)

— Мактамый ни, минем гомеремдә дә кеше хурлаганым булмады...— Кадим сүз җае чыгуга канәгать иде.— Рас бит, кеше кимсеткәнгә наград бирмиләр, языклы гына буласың. Килеп китим әле дидем менә. Сез оныткагыз да безне, без онытмыйбыз сезне диләрме җыруда? Шуның кебек, әйе. Язгы рәнҗетүләренне дә оныттым инде, кияү. Дүрт аяклы ат та сөрлегә, әйе.

Чәйгә утырмады Кадим. Кабар җирем дә юк, йотар урыным да юк, рәхмәт кыставыгызга дип, баш тартты. Өстәл янынннан торып килүем генә әле, диде. Хәл-әхвәл сораштырды.

— Карт башымны яшь итеп килүемнең сәбәбен төшенәмсең микән, кем, Госман кияү? — диде ул байтак гәпләшкәннән соң.

— Өзеп әйтә алмыйм шул, Кадим абзый.— Госман әллә ни ачылып китә алмый иде.— Нинди йомышың төште икән, синең дөньяң дүрт аякта инде болай...

— Гозер белән килмәдем мин, кияү, тәбрик сүзе белән килдем. Почтальон гәҗитләр китергәч, карыйм, «Социалистик Татарстан»да сезнең сурәтләр. Өлфәт белән икегез дан тавының киртләч кыяларына менеп басkансыз, әйе. Иң биектә ата булыр, аның эзенә басып улы торыр. Аннары кем, Янавыл егете... Бикләр куандым, бикләр сөендем. Киявебез, димен, районда бер диган, улы үзенә тиң димен.

— Рәхмәт, Кадим абзый, яхшы сүзеңә. Әйтәсе дә юк, олыладылар.

— Сурәтегезнең өстенә үк язган — «Хезмәтенә күрә хөрмәте» дигән. Сез бит, кияү, аталы-уллы ил туйдыручы гвардиннар. Икмәктән олы нәрсә юк. Ипи — иман, ипи югы яман дигәннәр. Сез, кем, Госман кияү, шул яманы булмас өчен тырышып-тырмашасыз. Сезгә пачут булмый кемгә булырга тиеш!

Галимә бер читтәрәк кенә кул аркаларын уыштыргалап торды, сүзгә кушылмады. Госман исә, күз алдында кычкыртып мактаганны җаны-тәне белән кире какса да, өенә килеп кергән өлкән адәмгә кырысланмас өчен, ара-тирә сүз кыстыргалап котылырга җыена иде.

— Өлфәтегез — бик булдыклы егет, бик уңган. Акылы-фигыле дә күз тимәсен дия торган. Олыга кечелекле, кечегә мнһербанлы. Шуны да авызыгыздан ишетим дигән идем, башлы-күзле булырга җыенамыни инде улыгыз?

— Шулай. Сабан туйда язылышырга вәгъдәләштеләр.— Госман моны төксерәк итеп әйтте. Кадим картның бу хакта инде күптән хәбәрдар була торып та, белер-белмәс булып суфилануына ачуы чыкты.

— Килен булачагыгыз нинди бала инде? Кем нәселеннән?

— Алар яшереп сөешмиләр, Кадим абзый. Килен буласы кешене бөтен авыл белә,— диде, ниһаять, әңгәмәгә кушылмый булдыра алмаган Галимә.— Син дә беләсеңдер — медпункт башлыгы Сәвияне.

Кадим карт үги кызының тел төбе төрткеле икәнен чамалап алды.

— Беләм дип, беләм инде болай, әйе. Күз күргән бала. Йомышым төшкәне юк, алар халкына төшә дә күрмәсен. Ходай биргән кадәр гомерне дүрт ягым сау-сәламәт булып, кабар әүкатем барында аякта булсам икән дә, аннары биргән аллам үзе җиңел әҗәл белән алса да икән. Больниска йөри калсаң, юк чиреңне бар итәләр анда. Иллә дә мәгәр бер генә дә җан тәслим кыласы килми әле. Дөньялар бик түгәрәкләнде бит, әйе. Менә туйлар көтәбез. Туй димәктән, кем, Госман кияү, син, Галимә кызым, син дә колагыгызга салып куегыз. Өлфәт белән Сәвиягә никахны үзем укырмын, боерган булса. Җиде ятны чакырасы булмагыз бу эшкә.

Галимә эндәшмәде. Дөресен әйткәндә, ире ризалашырдай булса, ул никах укытырга бик тә күнәр иде. Тик...

Госман көлемсерәп куйды. Аның елмаюында Кадим картка өстән карау чагылып китте. Хәер, ул моны сүзендә дә кистереп әйтте.

— Син мине кемгә саныйсың, Кадим абзый? Синең кармакка ук эләгерлек ахмакка чутлыйсыңмы?— диде.— Хаталанма берүк. Ике комсомол өйләнешкәндә, коммунист ата өендә никах укып утырыр идеңме? Шуңа рөхсәт бирерләр дип уйлыйсыңмы?— Госман торып йөренә башлады.— Аннары мин ил-көн каршында кем булып калам инде?

Кадим урындыгына ипләбрәк утырды. Җиләне кесәсеннән зур кулъяулыгы чыгарып, битен сөртеп алды. Каршы сыңар сүз дә ишетмәгән кыяфәттә сөйләп китте. Вәкарь белән сөйләргә тырышты.

— Син, кем, Госман кияү, кылычны бер селтәү белән эшне бетермә әле. Алай түгел. Сәвит никахына сүзем юк, бик кирәк ул. Документ. Хөкем каршында да таяныч. Иллә мәгәр анысы аның — көнең өчен. Дин кушканчасы инде мәнә денең өчен. Гомере буе күңелең тыныч, рухың бөтен булып яшәүгә ни җитә. Никахсыз кавышканнарның күңеле китек була, кем, Госман кияү...

— Әлеге мәсьәләдә минем карарым нык, Кадим абзый. Булмас нәрсә белән кыстама, әрсезләнеп маташма. Шом салып та йөрисе түгел. Менә шул...— Госман кырт кисте.

Тәмсезләнергә дә күп калмаган иде, алдан хәсләнеп торган кебек, Өлфәт кайтып керде.

— Хәерле кич,— диде ул, бусаганың чолан ягында торып кына, ике кулы белән ишек яңакларына тотынган иде. Комбинезонын салмый торып, өйгә уза торган гадәте юк.

Кадим купмас кебек утырган җиреннән торды да саубуллашып чыгып китте. Әтисе белән әрепләшә бирсә, Өлфәтнең каһәренә эләгәсен белә иде.

Өлфәткә дә кичке чәйне эчергәч, Галимә капка төбенә кайтып чүмешкән казларны лапаска ябарга дип чыкты. Аулактан файдаланып, Өлфәт әтисенә сүзе барын әйтте.

— Өйләнүдән дә җитдирәк сүзмени?— дип уенга алмак булды Госман. Шул чак улының йөзенә күтәрелеп карагач, аңлады: Өлфәт тә үтә җитди иде, димәк, сүзе дә килде-китте хакында гына түгел.

Алар алма бакчасына чыктылар, аяклары җиргә казып утыртылган өстәл янына уздылар.

Улының беренче җөмләсен тыңлагач ук, Госман түзмәде, кәефе җимерелеп сорады:

— Абыеңнан хат алдыңмы? Ул берәр нәрсә язганмы?

— Юк,— диде Өлфәт.— Абыйның миңа хат язганы юк. Боларны миңа Сәвия сөйләде. Айдан артык сүз башларга аптырап йөргән, соңыннан барыбер сөйләми булдыра алмады.

Улының сүзләрен Госман авырлык белән тыңлады. Әле үзем генә беләм дип йөргәннәрнең хәзер улы һәм булачак килененә дә мәгълүм икәнлеге аны бусарындыра, хафага сала иде. Ул һич кенә дә килен булfavorasы кешенең әтисе хакында хәбәрнең Яртуганга таралуын теләми иде.

«Ташбуага килеп җиткәч, Яртуганга сугыла алмаган. Гөнаһсын тою аягын атлатмаган дигән сүз... Миңнәхмәт кайчандыр яраксыз эш кылган дип, яшьләр юлына таш булып ятаргамыни соң инде? Монысы да бит аның яраксыз эш булачак. Өлфәт үз дигәнемне таптым дип канатланып йөри. Канатын сындырганны ул кичермәячәк. Аннан соң аны әмер биреп буйсындырыр чак узган. Хәзер ата-ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр фәкать үзара киңәшеп, аңлашып, уртак карарга килеп кенә күркәм саклана ала.

Миңнәхмәт белән минем араны икебез генә төбенә тикле ачыклый алабыз. Бары тик икебез генә! Җиңүчеләр бит без. Ә җиңүчеләрнең хокукы зур — җәзалый да, кичерә дә алалар. Еракракарак карасаң, тирәнгә төшеп исәпләсәң, үзләрен җиһангир сынаган фашист-башлыкларга буйсынып, безгә каршы корал күтәргән халыкларны кичермәдемени безнең халык?»

Ишерелеп-ишерелеп килгән уйлар өермәсе эчендә утыручы ата — өстәлнең бер ягында, ул — икенче якта. Тоташтырамы бу өстәл аларны, әллә аерып торамы? Икесе дә сүзсез.

Аларны көтә-көтә зарыккан Галимә тавышына уянып киткәндәй булдылар.

— Әтиләре! Өлфәт улым! Һәмишә бакчада утырасызмы? Суык төште ләбаса.

Командага буйсынган кебек, аталы-уллы урыннарыннан күтәрелделәр.

— Туй көне үзгәрми.— Госман моны аермачык әйтте. — Син аны бәхетле итә алсаң, ул сине бәхеткә тиендерсә, без дә бәхетле булырбыз. Аның әти-әнисе дә. Сиңа бер киңәш: әнкәңә әлегә икегезнең бере ләм-мим. Кайчан, ничек, нәрсә эшләргә кирәгер, анысын минем белдеккә калдырыгыз, яме. Сәвиянең әтисенә туйга чакырып үзем хат язармын. Иртәгә үк...

— Рәхмәт, әткәй!— Өлфәтнең бүтән сүзе юк иде.

Бер сукмактан икәүләп алга таба атладылар.

Ярсөяр әрәмәсе артыннан тулган ай калыкты. Әйләнә-тирә аның көмеш нурларына чумып, ямьле дә, серле дә булып калды. Госман күңеле шунда тартылды. Өйгә кереп тормыйча, әрәмәгә китсә, ә? Шунда, аяз күктән агылган ай нурлары астында күңеле болытлардан тизрәк арынмас идеме икән?

Юк, килешми. Галимәсеннән дә, улыннан да яхшы түгел. «Ниткән сәерлек инде бу?» диярләр. Газиз кунакка кайткач, оныгы кайткач... Төнлә түгел, икәүләшеп көндез барырлар. Кояш нурларының куак яфраклары арасыннан үтеп җирдә челтәр бәйләвен, кошларның чутылдашып моң түгүләрен, Олы күл камышларының серле кыштырдавын тыңларлар. Оныгы шуларны җанына сеңдерер. Аның саф, керсез рухында киләчәген Ярсөяр әрәмәседәй матур итеп күрү теләге уяныр. Ә тормышта теләк кенә булсын. Теләк булса, Кеше якты barган юлында туктап калмас!

1977

## Нури Арсланов

# БАКЧА ЮЛЫ

ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Телендә

Менгән атым баткан ак күбеккә,
Белмим, һаман кая чабамдыр?
Привал кирәк иде инде күптән.
Әйтерсең лә
Егет чагым белән чамам бер:

Уемда да юк җан суыклары,
Каян соң бу хәят шатлыгым?
И дивана!
Күргәч кенә үскән оныкларны
Исләремә төшә картлыгым.

Телдә генә «чамаң» диган булып
Кайберәүләр бәлки көләр дә.
Белми алар!—
Шагыйрь сүзе чыга җанда туып,
Бөтен рухы аның — телендә!

1977

### Асау атлар

Асау атлар иярләде язмыш,—
Без атландык, өркеп тормадык.
Аермасыз иде безгә яз, кыш,
Юлларны һич читкә бормадык.

Бөек көрәшләрне кичәр юлда
Гел асаулар булды иярле.
Ялтардылар атлар уңга, сулга,
Егып китәр өчен ирләрне.

Бер тибенсә селтәп арт аягын,
Бер күтәрде тарпып алгысын,—
Мондый чакта холкы шук чаяның—
Кабул итми егет ялгышын.

Һай, сынады язмыш халык көчен,
Кыл өстендә калды ирекләр...
Халкыбызның җанын саклар өчен
Җан бирделәр күпме егетләр!

Без таптаган җирдә эзләр кала —
Эзләр ята бөек мазарга.
Сөякләрдән күпер сала-сала,
Без чыгабыз яңа заманга.

Асау атның холкы гел үзгәчә,
Ышанма син асау атларга.
Ат уйнатып, халкым, горур яшә,
Иелмичә яман-ятларга!

1978

## Төшенкелек

Чара бармы, әгәр соры томан кебек
Кинәт сарып алса сине төшенкелек?

Чара бар, бар котылгы һәр бәладән дә,
Каушама тик төшенкелек көчен күреп.

Концертларда дәртлән яңа җырлар тыңлап,—
Сылу Ротаруларның ак тешен күреп.

Ишет Райкин мәзәкләрен,— сүрелә ул
Төшенкелек, бер җибәрсә кеше көлеп.

Шатлан тавыштан да җитез бу заманда
Вакыттан да алдынгылар эшен күреп.

Төшенкелек бер төшенчә генә бит ул,
Йөрмә зинһар кайгы йоткан кеше кебек!

Килсә килсен төшенкелек ишегеңә,
Тик басмасын бусагаңнан эчкә кереп.

Төшенкелек янсын шәраб ялкынында,
Туса мәҗлес, яныңа дус-ишең килеп.

Дөнья фани, үтәр-китәр кыска гомер,
Йоклаганда күргән матур төшең кебек.

Күтәрел, әй, күңел, таңда кояш булып!
Сулган айга охшап батсын төшенкелек.

1978

## Шулай да

Ни кадәрле теләсәң дә,
Гомерның язы кыска,
Бу хәлне белә һәр бәндә:
Көздән соң нәүбәт — кышка.

Шулай да, күңел имәсме![1]—
Могҗиза көтәм әле:
Көз артыннан яз килмәсме
Дип өмет итәм әле...

Диярсез:— Аннан ни файда,
Көтеп ни юкны-барны?!
Мин өмет итәм шулай да:
Өмет гомерне озайта,
Эретә салкын карны!

1977

## Камытымны сагынам

Туарылган аттай бушап калдым,
Улагымда җимем барын бар!—
Кирәк түгелдер дә далаларың,
Шулай да бит миңа аран тар.

Мин еш кына камытымны сагынам,
Күпме тарттым, көчем бар чакта.
И ул чаклар, йөккә тулы арбам...
Исәпләнгән барысы ансатка.

Кайда ул көч хәзер, илһам кайда
Рухландырып мине әйдәгән?!
Моңсу караш ташлыйм: конан[2], тайга,
Колыннарга тулган әйләнәм.

«Ат яманы тайга өер»мени?
Шулайдыр шул,— ярсый бит күңел.
Далаларда тайлар утлап йөри,—
Улак кимерү минем эш түгел.

Йокымсырап торган ялдан арынам,
Һич күнекми җаным шуңарга,
Чыгам җимле, җайлы аранымнан
Далаларга, иркен суларга!

1977

---

[1] Имәсме — түгелме, нишлисең, күңел бит мәгънәсендә.
[2] Конан — өч яшьлек ат.

•

Гомер дә узмый әкеренләп,—
Заманча чабуында.
Калышмыйм. Тик нинди имгәк
Тотынган чабуыма?!

Картлыгым икән, имансыз,
Ябышкан, өстерәлә.
Инде шул киртәме, сансыз,
Шуңамы эш тераләә?

И җиләнне йолкып алып,
Иңнәрдән салырга бер!
Чабудагы йөктән арынып,
Җиңеләеп калырга бер!..

1977

## Йокысыз төндә

Төн караңгы кайгы төсле,
Төн — зая үткән гомер.
Һич кенә килми йоклыйсы...
И хыялга комар күңел,
Төннәрем көнгә дүндер.

Ракетадай менсәң иде
Йолдызлар арасына,
Бер батмас ай элсәң иде
Күкнең зәңгәр гөмбәзенә,
Төннәрнең карасында.

Яки кояш белән баеп,
Җирләр әйләнсәң иде,—
Аннан таңнарга ялганып,
Кояш кебек мәңге сүнмәс
Иргә әйләнсәң иде.

Я Кыш бабай күк, илләргә
Еллар яңартсаң иде,
Җирдәге барлык өйләргә
Имин көннәр бүләк итеп,
Бәхет таратсаң иде...

Йоклый гүя бөтен дөнья...
Йокламый акыл гына,—
Мин тынып ятам урнымда,
Уйлар ерак хыялларны
Уята, якын кыла.

1977—1978.

## Устиния бәете

«Бичара Устя — тарихи хәрәкәт давылына эләккән гүзәл бер күбәләк һәм... императрица... кем аларны хөкем итәр, әгәр кем дә булса хөкем итә калса, Екатеринаның явызлыгы — гөнаһсыз казачканың бәхетсез язмышы үлчәү табагына нинди авырлык белән басачак».

В. Г. Короленко.

Гади генә бер йорт тора
Җаек буенда:
Узган манзаралар туа
Кинәт уемда.

Шунда өйләнгән атаман
Матур, яшь кызга:
Шунда Устиния баглаган
Гомерен «башсыз»га.

Әйе, «башсыз» булган ире —
Емельян казак:
Дауга чыккан, коллар илен
Итәм, дип, азат.

Дәһшәтеннән дөнья купкан,
Купкан башкала.
Хәбәр яшен булып суккан
Әби патшага[1].

Петр патша[2] булып Пугач
Тараткан фәрман.
Халыкларны үзенә юлдаш
Иткән каһарман.

Очкандай көзге җилләрдә
Яфрак калтырап,
Устя кергән өермәгә,
Алҗып, аптырап...

Яулар тузып, төшкәч кулга
Ирек баласы,
Сөргән кызын озак юлга
Җаек каласы.

Тол тик ике атна торган
Ир белән бергә,
Соңра урыны төрмә булган
Гомер гомергә...

Устя патша хатыны булып
Ашмый тәхеткә,
Утыз ел тоткында сулып,
Кергән ләхеткә.

---

[1] Әби патша — Екатерина II.

[2] Петр III — Екатерина тарафыннан тәхеттән төшерелгән, аннан үтерелгән ире. Пугачев, баш күтәргәндә, аның исеме белән файдалана.

Харап булган газиз башы
Унсигез яшьтә,—
Тәэсирсез булган күз яше
«Бөек көндәш»кә [1].

Дер селкеткән дау тәхеттә
Әби патшаны,
Пугачевның толы хәтта
Каушаткан аны.

Истәлек Җаек ярлары
Ил язмышыннан.
Гүя Устиния зарлары
Ишетелә шуннан.

Гади генә бер йорт тора
Җаек ярында —
Никтер моңсу, сагыш кына
Сыкрый җанында...

1977

## Контраст

Моннан унбиш мең еллар элек Азиядән Австралиягә күченгән Таш дәвере кешеләре хәзер дә элекке хәлләрендә яшиләр. Вәхшилекнең авыр шартларында алар һаман кими баралар...

Газеталардан.

Күккә карап, Җир хәлләрен
Айдан сорыйсы килә.
Айларга менсәк тә, Җирдән
Вәхши чор исе килә...

Дөнья гариплеген айкап,
Ачып йөрисе килә.
Кыштай салкын күңелләрнең
Карын көрисе килә.

Космоска Таш дәверен сөйрәп
Адәм баласы менә!..
Җирдә вәхши калдырмауга
Чара табасы килә.

Анадан тума ди алар.
Шунда китәсе килә:
Таш дәверенең кешеләрен
Кеше итәсе килә.

Бер аяк күктә, ә берсе
Вәхшиләр торган Җирдә:
Бер макта син кешелекне,
Бер әрни-әрни тиргә!..

1974

---

[1] «Бөек көндәш» — Екатерина II гә ымлау.

## Кырмыскадай көчле

Җилкәсенә Җирне Атлант[1] алган көннән
Ай аерылган, имеш, ди, җир-әнкәсеннән.

Атлант әйткән: — Авыр миңа Аең!— дигән.
Җир елаган: — Сау бул, балакаем...— дигән.

Олактырган Атлант, күп тормаган уйлап,
Ай тәгәрәп киткән зәңгәр гөмбәз буйлап...

Бәлки бу — чын, бәлки — ялган, кем белә ди...
Ләкин хәзер шунысы хак,— Ай көлә ди:

— Авырсындың мине Атлант була торып,
Ә нишләде кеше ракеталар корып!

Комар уйный отыш — анык отмак була,
Җилкәсендә бар Галәмне тотмак була.

Кая инде сиңа, Атлант,— җитми көчең,
Синең алда Кырмыскадай көчле К е ш е ң !

Шулай дип Ай гел Атлантка бәйләнә ди,
Җир тирәли әйләнә дә әйләнә ди...

1977

## Йөзек кашы

Бармагымда минем алтын йөзек,
Йөзекнең дә җәүһәр кашлысы!
Бәгырьләрне нидер ала өзеп,—
Килә җырны синнән башлыйсы:

Туймам төсле хәтта һәр иҗектә
Әйтәлсәм дә исмең, азсынам:
Син бит кирәк миңа, шул йөзеккә
Кирәк булган җәүһәр каш сыман!

1978

## Дисеннәр

Космонавтлар күккә менеп
Йолдызлар алып төште.
Мин дә менәр идем кебек
Һөнәр итсәм бу эшне.

Булалмадым шул космонавт,—
Җирдән күккә күз атам,

[1] А т л а н т — борынгы юнаннарда тиңсез батыр-гигант. Ул Җир шарын җилкәсендә тотып тора, имеш.

Шагыйрь булып, күк аралап
Үз йолдызым күзәтәм.

Космонавтлар, мактау сезгә,
Буй җитмәслек эшегез!
Күккә исән менегез дә,
Исән генә төшегез.

Оч, шагыйрь, сиңа да анда
Йолдызлар баш исеннәр.
Күр, космонавт булмаса да,
Күккә ашкан! — дисеннәр.

1977—1978

## Бакча юлы

Борынгыда алтын тәңкәләрне
Җиңүчеләр юлына сипкәннәр.
Алтыннарны таптап, шөһрәт юлын
Горур атлап үткән Искәндәр[1].

Мин Искәндәр түгел. Ә шаян көз
Тәңкәләрен чәчкән миңа да:
Шигырьләрдә, хәер, мактап яздым —
Үпкә белдермәдем мин аңа.

Сират күпере түгел, салават күпере
Без үтәсе сулар аркылы.
Аста — күрфәз[2], өстә — алтын кояш,
Шул түгелме бәхет балкуы!

Менә ачам сары йортның ишеген,
Хуҗа сыман элек-электән!..
Кай җирем ким Дарий[3] сарайларын
Ачып кергән Сәйфелмөлектән?![4]

1970

[1] Искәндәр — Александр Македонский.
[2] Күрфәз — диңгез яки елга култыгы.
[3] Дарий — Иран патшасы.
[4] Сәйфелмөлек — Искәндәрнең кушаматы.

## Фәннур Сафин

### Казан гомере

Кайда минем шәҗәрәм — нәсел агачы?
Кайсы бабам кулында
затлы мәрмәр сыман иләп шомартылган
беренче Казан ташы?
Мин сине эзлим, бабакаем!
Әйтер рәхмәтләрем, сорауларым бар.
Барын да беләсем килә:
кайда батырлар, кайда Алыплар?
Ә кайда хыянәтче, мең языклы гайбәтче?!
Бар уйларым, хисем синдә.
Ничәмә җир катламы синең иңдә?
Изге эшләреңнең барын да беләсем килә.
Күрсәтәсем килә шуны бөтен җиргә!
Бүләк булып безгә
сөңге очлары белән дары исе генә
калмаган сезнең заманнан.
Җулмас мирас булып
шәһәрләр калган!
Калган олы мирас — яшәү үзе.
Карый!..
Җанга карап тора кебек
гомер күзе!..
Кеше гомере...
Озын итсәң — озын,
кыска итсәң — кыска —
бармак арасыннан аккан сары ком сыман
сыя хәтта учка!..
Я җыр кебек — ул мәңгелек!
Кадерлисе бар әле гомерләрне!
Йолдызларга чаклы күтәрәсе бар шул мирасны!..
Моның өчен Максат кирәк! —
Олы Максат.
(Максатсызлар күпме әле,
уйлап баксак?)
Моның өчен аяз күк кирәк очарга.
Һава кирәк — хисләргә, уйларга,
хыялга!

•

Кеше яши-яши дә
хатирәгә әверелә...
Бары Җир белә:
Сөю өчен, Бәхет өчен
күпме улларының
гомере киселгәнен.
Яттан саный ала
җырга күчкән исемнәрен.
Бу данлы исемнәр —
бу шанлы исемнәр —
киселгән гомерләр —
яшәү дәвамы!..
Чордан-чорга күчеп,
җырдан-җырга күчеп,
яңарып, үсеп,
яши алар кичеп
диңгезләрне,
утлы даланы.
Яна-яна яши алар —
гүя Кешелек җаны!..

Һәм мин, һич югында,
Казан гомере телим,
якташларым, сезгә,
җирдәшләрем, сезгә —
бөек эшегезгә!

Әхмәт Сәйфетдинов

# ҖЫРЛА, ИРКӘМ!

Повесть

## 1

Март төне караңгы да, шыксыз да. Тәрәзәгә бәреп яуган карлы-бозлы яңгыр, юлбасарларча сызгырган җил Алмазның кәефен кырды. Яңгыр пәрдәсе аша сизелер-сизелмәс кенә елмайган урам утлары да аның күңеленә якты өсти алмый иде. Ул, тәрәзә яныннан китеп, бүлек коридорына чыкты.

Палаталарда авырулар йоклый. Тынлык, берәү дә күренми. Бу хәлгә кинәнеп куйды ул. Димәк, артык борчылган авырулар юк. Биш яшьлек Зифа гына йокыга китә алмый бимазалана икән. Моннан бер ай элек Алмаз ул сабыйга операция ясаган иде. Бугазындагы шешне алганнан бирле бала трахотомик көпшә аша гына сулый. Сөйләшкәндә әлеге көпшәне бармак томалап торырга, ә сулыш алганда ачарга кирәк. Әмма Зифа әле дә булса моны хәтереннән чыгара, я аны капларга онытып, тавышсыз гына сөйли, я озак каплап, тыны кысылганча онытылып йөри. Менә ул әле дә, йокларга яткач, ялгышып сулыш юлын томалаган да, тыны житми башлагач, елап уянган. Әнә палатадан ук чыгып килә. Шәфкать туташы Әлфия, аны күреп, каршысына йөгерде, баланың болай соңарып йөрүе өчен Алмаздан шелтә эләгер дип уйлады. Тик врач үзе дә елмаеп бала янына атлады. Моны күреп, Әлфия дә тынычланды, палатадагыларга ишетелмәслек итеп кенә:

— Лимонад эчәсеңме, Зифа? Әйдә, матурым, эч тә, йокларга ят! Йокламыйча терелеп тә, дәү үсеп тә булмый, — дип пышылдады.

Бала, муенындагы сулыш көпшәсен нәни бармаклары белән каплады да:

— Әнием дә лимонад китергән иде. Мин аны кичә үк эчеп бетердем, — диде.

Алмаз аны күтәреп алды, өстәл янына ук китереп утыртты. Әлфия лимонад шешәсе чыгарды. Стаканга салганда су күбекләнеп хуш ис таратты, мәгәр Зифа сабырсызланып эчәргә сузылмады, киресенчә, өлкәннәрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап нидер әйтмәкче булды. Аннары, стакандагы лимонадны бераз авыз иткәч:

— Житте,— дип стаканны Әлфия апасына сузды.— Йокы алдыннан күп эчәргә ярамый.

Алмаз, аның сүзләренә дикъкать итеп, гажәпсенеп куйды. Киң кашлар астындагы соры күзләрен ача төшеп, Зифага назлы елмайды да сөеп алды.

— Сине болай кем өйрәтте соң, Зифа?

— Әнием! — Зифа урындыктан төште дә палатага юнәлде. Аны озата барган Әлфия озак тоткарланмады, әйләнеп килде.

Алмаз дежур врач кабинетына юнәлде. Әлфияне ул шунда көтәргә булды. Кичке процедураларның үтәлешен тикшерәселәре, иртән смена тапшыруга хастәрлек күрәселәре бар иде.

Әлфия озакламады, авырулар тарихын күтәреп, врач янына килеп үк керде. Ак җәймәле өстәл янына утырып, әлеге кәгазьләрне тәртипкә салырга кереште. Тик Алмаз сүзне авырулар тарихыннан башламады.

— Зифаны әйтәм, — диде ул, — күңелне әллә ни рәвешле били, нарасый.

— Бик сөйкемле бала. Әти-әнисе сагына булыр.

— Сагынмыймы соң!.. Наилә апаң белән без дә эшкә килгәндә тәмам сагынып беткән булабыз.

— Сезгә дә бала тансык шул. Үзегезнеке булгач, сусавыгыз басылыр әле...

— Гаилә күрке — бала. Мәхәббәт җимеше — бала... Аның мәшәкатьләре үзе бер бәхет диләр. Әмма дөньяда газиз балаларыннан качып йөрүчеләр дә бар, — диде Алмаз.

— Уйлый китсәң, нинди генә язмышлар очрамас,— дип, Әлфия җитдиләнеп калды.

— Димәк, кешеләр гаилә бәхетен төрлечә бәяли.— Алмаз шулай диде дә уйга калды, ак кәгазьгә сызгалап сын ясагандай итте. — Ничек кенә булмасын, гаилә өчен мәхәббәт тә, бала да бик кирәк.

— Әмма мәхәббәт акылны исертмәсә генә, — диде Әлфия.

— Сезнеңчә, акыл өстенлек алырга тиешмени?

— Шулайдыр кебек. Тик акыл белән тойгыны бизмәнгә салып була микән?

— Яшьлектә бигрәк тә...

— Ә сез Наилә Рәхимовна белән ничек яшисез? — Әлфия бу соравын капыл гына бирде дә, үзе шундук уңайсызланып куйды.

Алмаз моңсу итеп елмайды гына.

... Таң беленде. Яңгыр томаны таралган саен, яктылык ишәя, көчәя барды. Дежур врач белән шәфкать туташы Әлфия Зифага бәйле сүзләрне куеп, иртәнге сменаны каршылау хастәренә керештеләр. Әлфия шприцларны кабат карап чыкты. Алмаз исә авыруларның хәле язылган кәгазьләрне җыеп, аларны тагын бер кат күздән кичерде.

Бүлектә иртәнге җанлылык башланды.

## 2

Наилә бүген эшкә иртәрәк барырга, Алмазны ничек тә «биш минутлык»ка кадәр күрергә, хәлләрен сорашырга уйлады. Соңгы вакытта катлаулы операцияләр Алмаздан башка ясалмады диярлек. Ә инде бүлеккә кечкенә Зифа кергәч, аның мәшәкатьләре бермә-бер артты. Яшь бала Алмаз өчен дә, аның хатыны Наилә өчен дә якын бер пациентка әверелде. Җитмәсә, бүген операция көне. Иртән күрешмәсәләр, иркенләп сөйләшү аларга тагын кичкәчә тимәс.

Көн аяз булыр төсле. Анда-санда гына кысыр болытлар йөзә. Үлән кыякларындагы чык бөртекләре көмештәй җемелди. Юл буендагы чәчәкләрдән бал исе аңкый. Күбәләкләр бер-берен куышып уйный. Өрән-

геләр тәмам купшыланган, коелган чәчәкләре урынына көмеш таңкә орлык тәлгәшләре тагылган. «Шаулы яз да үтте. Моңлы җәй дә житте», — дип уйлады Наилә. Ул җәйнең иртәнге матурлыгына хозурланып атлады. Уйласаң исең китәр... Еллар агыла да агыла...

Алар Алмаз белән шушы бакчада танышканнар иде. Нәкъ хәзергечә шаулы яз үтеп, чәчәкле җәй башланганда. Бакча яшеллеккә күмелгән иде. Алар бергәләп лекцияләргә йөрделәр, җыелышларда утырдылар. Аннары икесе дә бер клиникага туры килеп, бер бүлектә практика үттеләр. Операцияләргә, төнге дежурларга да икәү йөрделәр. Әйтерсең лә бу практика аларның күңелләрен якынайту өчен махсус оештырылган иде. Биш ел түгел, ә менә шушы бер ай вакыт аларны чын-чынлап дуслаштырды.

Практикалары танылган хирург, профессор Дәүләт Закирович Вахитов кул астында үтте. Институтның ректоры булу белән беррәттән, студентларның хөрмәтле остазы да иде ул. Наилә аның белән әлегәчә таныш булмаган икән, уку дәверендә эше төшеп кабинетына да кермәгән. Алмаз исә профессорны икенче курстан бирле яхшы белә. Операцияләрнең дә беренчесен Дәүләт Закирович ясаганда күрде. Йомшак күңелле, тыйнак, тәҗрибәсе дә, белеме дә башкаларга үрнәк булырлык профессор үзе дә Алмазга башта ук игътибарлы булды кебек. Шуңа да мөстәкыйль операцияне — сукыр эчәкне алып ташлау кебек гадиен генә булса да, ул үз курсташларыннан элегрәк башкарды. Кемнәрдер мондый мөстәкыйльлеккә гаҗәпсенде, әлбәттә. Әмма Дәүләт Закирович ашыгучылардан да, эксперимент шаукымына бирелүчеләрдән дә түгел. Алмаз Сафин аның үз сайлаганы, үз шәкерте. Аңа өметнең дә зурын баглады. Чынлыкта Алмаз аңа үзенең хирургиягә, медицинага бирелгәнлеге белән ошады. Алмаз хакында башкалардан берәр фикер ишетергә туры килгәндә дә, ул тикмәгә генә:

— Аңа ышанырга була, — димәгәндер.

Наиләнең Дәүләт Закирович белән ныклап танышып, сөйләшеп китүе дә шул практика көннәрендә булды.

Алар Алмаз белән төп уку бинасыннан чыгып, клиникага таба җәяү генә барганда, аларга кемдер эндәште. Баксаң, Дәүләт Закирович! Клиникага баруы икән.

— Сез, Наилә, ялгышмасам, Казан кызы бит? — дип сорады ул. Ничәмә йөз студентлар арасында ректор кешенең үзен белүенә Наилә гаҗәпсенеп тә, куанып та куйды. — Идел суында коенып үскән сылу кызларга тел тидерүем түгел. Шулай да теңкәгә тигән яклары бар. Диплом алгач, шәһәрдән җибәреп булмый кайберәүләрен.

Дәүләт Закировичның бу хакта сүзләре тикмәгә түгел иде. Бу көннәрдә чыгарылыш курс студентларын билгеләү бара иде бит. Аның әлеге сүзләренә Наиләнең хәтере калмады. Ник дигәндә, беренчедән, бу үпкә сүзе әле аңа турыдан-туры кагылмый. Икенчедән, шәһәр кызларының Дәүләт Закирович әйткән сыйфаты, чыннан да, эшкә билгеләү комиссиясе канына тозны аз салмый.

— Диплом алуга ерак бит әле, Дәүләт Закирович,— диде Наилә, нәзакәтле елмаеп. — Аннан соң әти белән әнигә без бишәү. Шәһәрдә калырга да, авылга китәргә дә җитәрлек.

Дәүләт Закирович бу фикерен сүз җаеннан гына әйткән иде бугай, озакка сузарга теләмәде. Сорауның бүтәнен бирде:

— Димәк, Наилә дә хирург булачак?

Профессорның бу сүзләрен Алмаз үзенчәрәк кабул итте. Янәсе, аның хирург булачагы профессорга ачык, ә менә Наилә Алмаз юлыннан барырмы?

— Әйе, миңа хирургия ошый,— дип, сабыр гына раслап куйды Наилә.

— Ошагач, әйбәт! Калганын Алмаз белән бергәләп... Ул булышыр, шулай бит, Алмаз? — Профессорның шулай түгәрәкләп куюы аларның икесенә дә кагыла иде. Бер-берсенә якыная баручы егет белән кыз моны мөхтәрәм, күренекле кешенең хәер-фатихасы дип кабул иттеләр һәм ялгышмадылар.

Алмазның Дәүләт Закировичны үз атасыдай якын күрүен Наилә һәрчак тоеп торды. Алмаз әйтүенчә, профессорның тормыш юлы шактый катлаулы булган...

Гомер буе медицинада яңалык эзләп, шуларның иң мөһимнәрен тормышка ашыру өчен янып яшәгән бу галим үзенең шәкертләрендә дә тормыш дәрте, хезмәт ялкыны булуын теләгән. Профессор үз кул астында эшләргә студентларның шундыен сайлый. Яраткан шәкертләренең берсе Алмаз булуына Наиләнең шиге юк иде... Тик май азагындагы бу сөйләшү соңгысы булган икән. Августта ректорлыкның мең төрле мәшәкатен профессорның авыру йөрәге күтәрә алмаган... Ә бит йөрәге хакында ул әле дә Алмазга әйткән һәм бу алар арасында сер шикелле булып калган иде. Студентлар өчен салынган яңа тулай торакны кабул итеп, кайтырга чыккач, инфаркт үзенекен иткән...

Клиникага кергәч тә, Наилә Алмазны күрергә ашыкты. Ире кечкенә Зифага операция ясаячак. Ә ул бала хакында алар бергәләп уйлыйлар, бергәләп борчылалар. Хәзер менә, операция алдында торгангамы, Наилә сабый өчен аерата борчылып куйды. Дөрес, Алмаз бу операциягә җентекләп әзерләнде, барысы да әйбәт булырга тиеш. Врач этикасыннан читкә тайпылмас, баланың физик хәлен һич тә күздән югалтмас. Авырлыклары, ваклыклары белән бергә сайлады бит ул хирургияне. Аның бүгенге эше пациент өчен дә, үзе өчен дә мөһим. Клиникада сулыш юлын, тамакны дәвалаганда үз ысулын кертә ул. Бигрәк тә тавыш җепселләрен саклау өчен аның ысулы нәтиҗәлерәк булырга тиеш. Әлеге тавыш җепселләре нечкә, бик тиз зарарланалар. Аларга скальпель белән кагылу да, дәвалау үткәрү дә четрекле. Шуңа күрә ул хирург та, терапевт та булып эш итәргә тиеш. Сандугачның үзәк өзеп сайравы да, кеше тавышының сафлыгы да шул җепселләргә бәйле. Әлегәчә аларны операция белән дәвалыйлар, аннары физиотерапия — нурлар белән тәэсир итәләр. Бу ысулны начар дип булмый. Шулай да кайчак нурларның тискәре йогынтысы аркасында авыруның тавышын әүвәлге хәленәчә кайтара алмаган чаклар да була. Димәк, дәвалауга нинди дер өстәмә кертергә кирәк. Ә өстәмә уйламыйча, эзләмичә генә табылмый. Моны Алмаз яхшы белә. Ул тамак шешен дәвалауга цидифос кулланырга булды. Хәзер инде операция дә, цидифос терапиясе дә эшләнде. Хәзер бала тамагына пластик операция — кисеп алынган шеш урынына исән тукыма күчереп куярга кирәк. Моны Алмаз бүген башкарырга тиеш.

Шунысы гаҗәп, балалар тормышта әле куркуларны азрак кичергәнгәме, өлкәннәргә караганда тәвәккәлрәк булалар икән. Зифа бүгенге операция хакында сорашып торды. Әнә ул Әлфия апасы итәгеннән төште дә, җәһәт кенә каядыр китәргә талпынды. Каршы яктан Наиләнең килүен күреп кенә тукталып калды. Аннары:

— Әйдә инде, Әлфия апа, Алмаз абый янына барыйк!.. — диде.

Наилә аны иркәләп:

— Зифа акыллым, Алмаз абыең сиңа бик кирәкме соң? — дип сорады. Врач апасының йомшак тавышында күңел җылысы сизелеп тора иде. Сабыйга, бигрәк тә авыру сабыйга, шуннан да тансык нәрсә бармы икән?!

— Кирәк шул, Наилә апа, ул миңа бүген операция ясый...

Аның шулай батыраеп сөйләвеннән Наилә тәэсирләнеп куйды. Зифаны ул итәгенә алды, сулыш көпшәсен марля белән сөртте дә:

— Зифаның тизрәк терелəсе, зур үсәсе килә, димәк? — диде.

— Бусы соңгы операция... Аннары, өйгә.

— Хушлашабыз, дисең?! — Наилә тотырып баланың елтыр кара күзләренә карады. — Ә үскәч кем булырсың икән соң син?

— Минме? Минем җырчы да, врач та буласым килә.

— Икесе дәме?

— Нигә? Әллә алай булмыймы? — Зифа зур кара күзләрен Наиләгә төбәде.

— Нишләп булмасын ди! Бик теләсәң җырчы да, врач та булырсың. Наилә аның башыннан сыйпады, аркасыннан сөйде.

— Минем Ләлә апам кебек җырчы буласым килә, Алмаз абыем кебек врач буласым килә. Савыккач... Зур үскәч... укыгач...

— Әлбәттә, Зифакай! — Наилә аны тагын бер кат күкрәгенә кысып сөйде дә, Әлфия янында калдырып, ары китәргә теләде. Тик бала аннан калмады, Әлфия апасына әйткән үтенечен янә кабатлады.

Алар җитәкләшеп, кабинетка килеп кергәндә, Алмаз ординатор кыз Луиза белән сөйләшеп утыра иде. Наилә сүзнең Зифага ясалачак операция хакында булуын шунда ук шәйләп алды. Баланы бирегә алып керүе өчен уңайсызланып та куйды. Җитмәсә тегеләр дә, Зифаны күреп, сүздән туктадылар. Зифа исә Наилә кулыннан ычкынды да, Алмаз янына килде.

— Алмаз абый, нигә инде операция ясамыйсыз? Көтә-көтә арып беттем.— Аның бу сүзләре өчесенә дә гаҗәбрәк тоелды. Алмаз иелде дә, ышандырырлык итеп, үз кешеләрчә:

— Без сине әле йоклый дип торабыз бит. Карасана, ялгышканбыз икән?! — диде. Аннары хатынына карап:— Наилә, Роберт Салихович бүлмәсендәме икән, күз салчы, — дип үтенде.

Зифага ясалачак пластик операция хакында бүлек мөдире белән сөйләшергә кирәк иде. Кафедра галимнәренең, шеф-доцент Зәйнәп Вахитовнаның операцияне ахырынача Алмаз ясар дигән карарга килүе эшне тулысынча аңа тапшыру иде. Әмма кайбер каршылыклар да чыкты. Бу фикерне Роберт Салихович якламады.

Кафедра мөдире Зәйнәп Вахитовна һәр мәсьәләгә үз карашын әйтсә дә, яшьләр фикерен бүлдерми тыңлый, аларга юл бирергә тырыша. Каршылыклар туа икән, ике якның кайсысын да булса кырт кисеп, кемне дә булса ашыгып яклап булмый. Хакыйкать бәхәстә туа диләр бит. Әйтик, бүлек мөдире, яшь галим, медицина фәннәре кандидаты Роберт Салихович белән Алмаз Әхәтович арасында бәхәс бар икән, нигә аны туктатырга? Беренчесе дәвалауны әлегә операция һәм физиотерапия ярдәме белән генә дә канәгатьләнерлек дип саный икән, боларга тагын ни дә булса өстәргә дип тапмый икән, бу урында аның фикеренә каршы килеп тә булмый бит әле. Икенчесе физиотерапияне химиотерапиягә алыштыру ягында. Әмма бу карашны бөтен бүлеккә тарату иртәрәк. Алмаз бу юнәлештә эзләнүләрен дәвам иттерергә тиеш... Кафедра мөдиренең мондый карашын Алмаз да яхшы сизә. Сизә дию генә аз, аның белән килешә дә. Шулай да аның ысулы өметле.

Алмаз Робертның әле килеп җитмәвен ишеткәч, Зәйнәп Вахитовна белән сөйләшергә булды.

Кафедра мөдире кемнеңдер диссертациясе белән танышып утыра иде. Ишек шакуга ул бары: «Рәхим итегез!» диде дә, укуын дәвам итте. Алмаз кергәч тә, диссертациядән тиз генә аерылмады. Бераздан башын күтәреп, Алмазга карады:

— Сез икәнсез! Рәхим итегез, утырыгыз!

Хирург уңайсызлана калды.

— Мин бер генә минутка кергән идем. Бүген Зифага соңгы операция ясалачак. Шуның өчен, Зәйнәп Вахитовна, сезнең белән кайбер мәсьәләне ачыклыйсым килгән иде.

Тулырак гәүдәле кырык биш-илле яшьләрендәге бу ханым шактый сөйкемле иде. Саф тавышы, бөдрәләре алга төшеп торган чем-кара чәчләре аны шактый яшь күрсәтә иде.

Ул, бөтен игътибарын Алмазга төбәгән килеш, ягымлы гына елмайды:

— Тыңлыйм сезне...

— Мин Роберт Салиховичка да сугылган идем, ләкин ул юк икән, инде сезне борчырга булдым.

— Ул министрлыктадыр, — диде Зәйнәп Вахитовна.

— Соңгы рентген рәсемнәре Зифаның операция җәрәхәте төзәлүен күрсәтә. Кан составының да беркадәр яхшыра төшүе билгеле.

— Ә баланың тавышы, каефе ничек?

— Зифа сабыр бала, ул беркайчан да зарланмый. Әмма аның белән генә операциянең уңышлы чыгуын билгеләве кыен. Тавышына килгәндә, әлегә үзгәреш юк кебек. Ләкин...

— Әйтеп бетерегез.

— Тулы нәтиҗә пластик операциядән соң ачыкланачак, Зәйнәп Вахитовна.

Доцент кулларын өстәлгә куйды, бармакларын җиңел генә биетеп алды, аннары:

— Шулай да беренче нәтиҗәләрне ачыклый төшәргә кирәк. Хәер, каны әйбәтләнеп килә дисез. Тавышның үзгәрүе сизелмәү алай ук куркыныч түгел. Пластик операцияне ясарга туры килә. — Ул Алмаз кулындагы рентген кәгазен алды, ут яктысына килеп, аны карарга тотынды.— Бирелә хәл ачык, операция эзе тәмам бирчәйгән, сезнең соңгы сүзегез кирәк.

Алмаз доцентның үзенә ышануын тойды. Әмма бу ышаныч бер Зифа язмышы мисалында гына түгелме? Хирург бер кешегә ясалган операция белән генә бөтен мәгълүматлар тупланган дип әйтә аламы? Күңелендә туган әлеге сорауларны кафедра җитәкчесенә дә әйтмәкче иде Алмаз, ләкин тыелып калды. Чынлап та, төп мәсьәлә сабыйның сулыш юлын дәвалау, тавышын камил саклау иде бит.

Китәргә теләп, ул урыныннан күтәрелде. Зәйнәп Вахитовна Зифа турындагы кәгазьләрне бергә җыеп, Алмазга сузды.

— Алмаз Әхәтович, сезнең ысулыгыз вакытлы мавыгу гына булып калмаска тиеш. Фәнни нигезгә таянып, практик ачыклау тәртибендә алып барырга кирәк аны. Хәер, бу хакта аерым сөйләшербез. Шулай да материалыгызның протоколларын саклагыз, сөйләшкәндә уңайлырак булыр.

Операциягә әзерлек төгәлләнеп бара. Алмазга Луиза булышачак икән. Бу яшь ординаторның ярдәменнән Алмаз һәрчак канәгать. Сәбәбе бер генә: Луиза бик тырыш кыз. Институтны бетергәч тә, башта ул дәвалаучы врач булып эшләгән, ә менә хәзер, колак-тамак-борын куышлыгы хирургиясенең серләренә төшенү өчен, ординатурага кергән. Терапияне хирургиягә алыштыру күпләргә аңлашылып бетмәсә дә, Алмаз күреп тора, Луиза хирургия белән чын-чынлап кызыксына, операцияләргә бик теләп катнаша, кирәк икән еш кына үзе теләп ассистентлык итә иде. Алмаз ясаган операцияләрнең серенә төшенергә тырыша. Бу хакта Алмазның үзенә сиздермәсә дә, Наиләгә ул берничә тапкыр әйтте. Тик Луизаның Робертны да мактап куюы гына Наиләне ирексез турындагы мактау сүзләрен юкка чыгаргандай итә иде. Ярый, Наиләгә Алмаз хакында сөйләсен дә ди, ә Робертны нигә кыстырырга? Бүлек мөдире булгангамы? Әллә?.. Җитмәсә, Алмаз белән бүлек мөдире арасында аерым бәхәс тә бар бит әле...

Төшлеккә күтәрелгән кояш операция бүлмәсенә нур бөрки. Тәрәзәләр ныклап ябылганга бүлмә эче бөркү. Әмма хирург күңелендә — озакламый өстәлгә ятачак Зифа.

Әнә ул кызу-кызу атлап, бирегә килә. Наилә белән шәфкать туташы китерә үзен. Бүлмә ишегенә җиткәч, ул кереп китмәде, туктап:

— Алмаз абый андамы соң? — дип сорап куйды.

— Анда, анда... Сине көтә.

— Сез биредә генә торыгыз, яме! — диде ул апаларына.

— Ярый, ярый, үскәнем, Әлфия апаң белән икәүләп кәтәрбез,— дип, Наилә аны аркасыннан сөеп калды.

## 3

Операциядән соң дүртенче көн дигәндә, Зифаның хәле кинәт авыраеп китте. Җөй урыны җилсенеп, температурасы күтәрелде. Ә кичә ул үзен әйбәт хис иткән иде. Бу соңгы операциядән соң аның сулыш юлында калдырылган тишек тә томаланды.

Зифаның өзлегүе Алмаз белән Наиләне янган утка салгандай итте. Бу хакта алар өйгә кайткач, телефоннан сорашып белделәр.

— Бәлки вакытлы кризис кынадыр? — дип, Наилә ирен тынычландырып карады.

— Бәлки... — Хатыны тагы нидер әйтергә теләгән иде. Алмаз аны күз карашы белән үк бүлдерде. Аның эчкә батып калган соры күзләре Наиләгә сораулы төбәлде, мускуллары тартышып алды.

— Фараз итү, Наилә, конкрет ачыклау түгел бит әле.

— Уйланмый гына конкрет ачыклап та булмый шул, — диде Наилә. Тик бу сүзләр аның ирен генә түгел, үзен дә канәгатьләндермәде. — Менә хәзер Роберт Салихович өчен козырь...

Алмаз дәшмәде. Бүлмә буйлап йөренә башлады. Ул җитди уйлана иде. Кыска итеп кыркылган, хәзер тырпая төшкән чәчләре аның башын тагын да зурайтып күрсәтә. Ул хатыны янына килде, нидәндер сагая төшкәндәй, кыяр-кыймас кына янәшәсенә утырды.

— Шулай да ике кат операцияләү яшь баланы мораль һәм физик яктан йончыта. Зифа арыган, организмының каршы тору сәләте кимегән. Мәсьәләнең бу ягын алданрак уйлап җиткермәгәнбез...

— Гадәти кризис кына булырга тиеш,— диде Наилә.

— Әйе, әгәр алдан комплекслы дәвалау билгеләнгән булса, җилсенүгә юл калмаган булыр иде. Пациентыбыз сабый. Ә яшь организмнан төрлесен көтәргә мөмкин.

Иртәнге чәй янында да, больница юлында да алар артык сүз сөйләшмәделәр.

Бүлеккә кергәч, хирург палатага ашыкты. Зифа иртәнге йокысыннан арыныр-арынмас хәлдә ята иде. Алмаз абыйсын күргәч, ул күзләрен ача төште. Врач аның нәни кулларын учына алды, башыннан сөйде. Шулай да ни дә булса әйтә алмый торды. Алмазның тынып калуын әле йоклаган авыруларны борчырга теләмәве дип тә, Зифадан сорыйсы сорауларның кайсысыннан башларга икәнен белә алмавы дип тә санарга мөмкин иде. Зифа Алмаз абыйсының иркәләвенә канәгатьләнеп, елмайды. Шатлыклы, өметле елмаю иде бу. Ул врач теленә гүя ачкыч та булды.

— Хәлең бик авыр идемени, Зифа? — Алмаз беренче соравын бирде.

— Тамагым сулкылдады... — ул акрынлап сөйләшә-сөйләшә, куллары белән врач абыйсының битен капшады.

Бүлектә балаларның күбесенә операцияне ул ясый. Шуңадырмы, Алмаз һәр баланың холык-фигылен яхшы белә. Укол, операция, ачы дару кебек нәрсәләрне балалар аның исеме белән бәйләсәләр дә, үзләренә ягымлы булсаң, ышандырырга, күңелләрен тиз яуларга була. Кирәк икән, ул бала белән балача сөйләшә, әллә кайдан кызыклы сүзләрен табып, күңелен күтәрә. Шулай да Зифа башкачарак, бер баланың

да Алмазга аның кебек сарылганы юк иде әле. Әнә бит ничек сагынган, ничек үз итә!..

— Зифа, матурым, озакламый хәлең әйбәтләнер. Савыкканда шулай кыен була ул.

Алар янына Наилә килеп керде. Ул иренең йөзендә борчылудан бигрәк, ир-атларның сирәгендә генә була торган наз, игътибар, баланы ярату хисен күрде, һәм бер балага, бер Алмазга карап, сүзсез калды...

Наилә иренә бүлек мөдире Роберт Салиховичның озакламый палаталарда йөриячәген әйтте.

— Бәлки Зифаның хәлен тикшерүне бүгенгә кичектерергә кирәктер? — диде Алмаз.

— Бүлек мөдиренә күрсәтмә биреп булмас бит?..

Алмаз кызның чәчләреннән янә сыйпады да, урыныннан торды.

— Алай икән... без Зифа беләп беркемнән дә качмаган. Күрсеннәр, күрсеннәр.

Сүз дә юк, Робертны Зифа яныннан читләтеп үткәрү мөмкин түгел иде. Беренчедән, бүлек мөдире буларак, ул һәр авыру белән танышып торырга тиеш, икенчедән, Зифа — бәхәсле мәсьәлә. Җитмәсә, менә хәле дә авыраеп китте.

Күп тә үтмәде, берничә врач ияртеп, палатага Роберт килеп керде. Озынча буйлы, саргылт чәчләрен иплән артка тараган, алтын кысалы күзлек кигән, утыз яшьлек бүлек мөдире тышкы кыяфәте белән һич кенә дә артык таләпчән кешегә охшамаган. Ул туп-туры Зифа янына килде. Алмаз да, Наилә дә Роберт Салиховичны һәм аның белән кергән коллегаларны аяк үрә каршы алдылар. Алмазның да, палата врачы Наиләнең дә теләге бер: авыруны коллегалар кузгатыр сүзләр тәэсиреннән саклау иде. Шуңа күрә Наилә ашыгып:

— Бик сизгер, тәэсирләнүчән бала,— дип кисәтеп куйды. Шуннан соң ул дәвалаучы врач буларак авыруның хәле белән таныштыра башлады.

Роберт, артык берни дә әйтмичә, Зифа муенындагы җөйне, йокы артериялэренең ритмын тикшерде.

— Алмаз Әхәтович, бу пациент хакындагы фикерегезне ишетергә кирәк булыр, — дип, палатадагы бүтән авыруларга юнәлде.

Палатадан чыкканда Алмаз башта Наиләгә, аннары Зифага карап алды, мөмкин кадәр тыныч күренергә тырышты, чынлыкта исә Зифаның хәлен әйбәт дип булмый. Ә бүлек мөдире аңардан фикер көтә. Нинди фикер? Алмаз эшенең нәтиҗәсе хакында, әлбәттә. Ә шул нәтиҗә әлегә ничегрәк соң? Көенерлек үкме? Шул хәлдә ул Зифаның зур ачылган күзләренә карады, сабыйның самими карашы белән очрашты.

Димәк, Зифа Алмазга, хирургка ышана, аның карашы шуны сөйли. Врач моны ачык сизде. Бу аны бала каршында тагын да җаваплы, тагын да бурычлы итә кебек иде.

Кафедраның бүлек врачлары катнашындагы җыелышы икенче көнне сәгать тугызда башланды. Гадәттәгечә, башта кафедра мөдире Зәйнәп Вахитовна сүз алды. Ул нигездә операцияләргә тукталды.

— Яхшы хирурглар булып та, начар дәвалаучы булсак, эштә уңышка ирешү мөмкин түгел, — диде ул. — Хирург скальпель белән генә түгел, терапия белән дә коралланырга тиеш.

Алмаз аның бу сүзләре мәгънәсенә башта төшенә алмады, «күрәсең, Зифаны күздә тотадыр», — дип уйлады. Ләкин шефның сүзләре Алмазга да, пациентка да турыдан-туры кагылмый иде. Ул соңгы вакытта операцияләрдә әллә ни катлаулылык килеп чыкмавын сөйләп үтте. Әллә яңа материал булганга, әллә ниндидер башка исәп белән, ул Зифа мәсьәләсен бөтенләй читләп үтте. Бу хәл барлык коллегаларны, бигрәк тә Робертны, гаҗәпсендерә калды. Алмазны да борчып куйды. Тик шефның мәсьәләгә үз карашы булуга берәү дә шикләнми иде.

Зәйнәп Вахитовнадан соң сүзне Роберт алды. Ул иң әүвәл кафедра мөдиренең фикерен яклап куйды.

— Техник термин кулланып әйтәбез икән, безнең беребезнең дә стандарттан түбән төшәргә хакыбыз юк, иптәшләр. Уртак максат турында сөйлибез икән, димәк, бездә уртак фикер, килешүчәнлек сакланырга тиеш. Әмма иҗади яңалык дип һәркайсыбыз үзебезнең тәкъдимнәребез белән генә яши башласак, уртак максат буш булып калачак. Ә безгә йөкне бер юнәлештә тарту җитенкерәми. Аның тавышында да үз дәрәҗәсенә ишарә, башкаларны үзен тыңлатырга тырышу сизелә иде. Ул чәчләрен төзәткәләп алды, ялтыравыклы күзлеген этебрәк, үз урынына иплән утыртты. Күңел күзе булган кеше сизәрлек: Роберт үзен тыныч тотарга, урыныннан кузгалмыйча, тавышын бер агымда сакларга тырышып сөйли.

— Алмаз Әхәтович та шәхси максатка ашкынучыны хәтерләтә. Яңа ысул — тышкы яктан ялтыравыклы, әмма яңгырамый. Нәтиҗәсе, ялгышмасам, әлегә берәүне дә канәгатьләндерерлек түгел. Аннан соң, — бүлек мөдире янә күзлеген төзәтеп куйды, — мин Зифа Халитованың хәле кискенләшүен искә төшерер идем. Кеше — тәҗрибәгә куела алмый... Бала организмының икешәр операцияне күтәрә алмавы да кирәгенчә уйланылмаган...

Зифа исемен ишеткәч, Алмаз урыныннан кузгалып куйды. Аның хафалы хәрәкәтен дә, йөзенә бәреп чыккан әчке ярсынуын да иң әлек Наилә белән Луиза абайлады. Наилә иреннән күзен алмый гына аның күңелендәге уйларын аңларга теләде. Ә Луиза утырышта Зифа мәсьәләсе төп мәсьәләгә әйләнеп китүенә борчыла иде.

Башта Алмаз:

— Сабый алдында мораль җаваплылыкны мин тулысы белән үз өстемә алам, — дип, реплика белән генә чикләнергә теләгән иде, әмма аңа сүз алып сөйләргә куштылар.— Без тәкъдимебез тәмам тулы дип әйтергә җыенмыйбыз. Аны бергәләп карарга, уйларга тиешбез. Ләкин мин үзем сайлаган ысулны дөрес саныйм, тик бераз сабыр итәргә кирәк. Менә цидифос та безнең өметне аклады. Бер нәрсә дә кинәт кенә барлыкка килми.

— Әйе, сабыр итәргә кирәк. Тик нинди мәгънәдә бит? Бөтен бүлек мәнфәгатен яклапмы, әллә берәүнең мавыгуына риза булыпмы?

Бүлек мөдиренең турыдан-туры аңа төрттереп сөйләве Алмазны чак кына чыгырыннан чыгармады.

— Хемотерапия безгә күктән төшмәде. Элек аңа әһәмият биреп җиткермәгәнгә күрә генә яңа ул. Ә эффекты?! Озакламый күрербез. Дәвалау курсы бер кадәр озыная икән, бер нишләп тә булмый.

— Күрше республикалардан да авыруларның безгә мөрәҗәгать итүләрен истән чыгармыйк, — дип кыстырды шул чак бүлек мөдире.

— Шундый кыенлык алдында калдык дип, сезнеңчә, яңа тәкъдимне ташларга, операцияләүне конвейерга әйләндерергә киңәш итәсезме, Роберт Салихович?

Роберт әдәп саклавына үтә басым ясап, Алмаз сүзләренә саран гына көлемсерәп җавап кайтарды һәм янә сөйләп китте:

— Шунысы гаҗәп, иртәгә майтарасы эшне бүгенгесе бәрабәренә башкарырга җыенасыз, Алмаз Әхәтович. Килер бер көн, ихтимал, без сезнең ысулга чын-чынлап игътибар итәрбез. Тик әлегә... — ул кулларын як-якка җәеп җибәрде. Бу хәрәкәте аның яңа ысулны вакытсыз дип исәпләвен аңлатырга тиеш иде.— Вакыт җитми чәчәк атмый бакчадагы гөлләр дә, дигәннәр. Вакыты җитми җимеш тә пешми, ә инде бала туа икән — артык газап-мәшәкать белән туа... Шуны да истән чыгармаска кирәк, күп кенә яңалыклар үзләренең «яңа» дип аталуларыннан узмый онытылалар...

Алмаз, бер мәл ачуы килеп: «Яңаны нәкъ менә яңа булуы өчен дә

өйрәнәләр, тикшереп карыйлар, ә нәтиҗәсен соңыннан гына ачыклыйлар», — дип бүлдермәкче иде дә, тыелып калды. Уйлаганнарын әйтсә, үзенең дә ысулга ышанычы сыек дип уйлалар кебек тоелды. Асылда исә, ул үзе күтәргән проблемага, яңа ысулга чын күңелдән ышана. Айһай, аны бу юлда кем дә булса туктата, яки кире бора алырмы икән?

Сүз дә юк, кафедра утырышы Алмаз белән Робертның бәхәсенә әйләнеп китте. Моны утырыштагылар бик яхшы чамалады. Ә мөдир нигә чик куймый? Зәйнәп Вахитовна кара кашларын өскә тартып, бераз уйланып калды.

— Без кеше саулыгы дип, кеше бәхете дип җан атабыз. Бурычыбыз кешеләрне бәхетле итү булганга, без, врачлар, үтә анык белеп эш итәргә тиешбез. — Аның йөзендә җиңелчә елмаю чагылды. Ул бер Алмазга, бер Робертка караш салды. — Минемчә, һәр якта да дөреслек бар. Роберт Салихович бүлектәге дәвалау ысулын канәгатьләндерерлек дип санаса да, авыруларның үтенечен тизрәк канәгатьләндерү ягында. Алмаз Әхәтович исә, аңлашылганча, хемотерапия тылсымына игътибар итүне хуп күрә. Минемчә, аның тәкъдимендә перспектива бар, цидифосның эффектын ачыклау да кызыклы. Аннан соң, Алмаз Әхәтович әйтүенчә, нур терапеясын чыннан да индивидуаль рәвештә тәкъдим итәргә кирәктер. Ни дисәң дә нурлар, нәфис тукымаларны дәвалаудан тыш, бер кадәр зәгыйфьләндерә дә бит. Дозасын белеп кулланмасаң бигрәк тә... Тавышның сафлыгын саклау өчен көрәш барган очракта моны истә тотмау күрәләтә сукырлык булыр иде. Алмаз Зифаны дәвалаганда үз алымын сайлады, нур терапеясын цидифос белән алыштырды... Минемчә, аның юлына «кытай стенасы» кору урынсыз.

Кафедра мөдире үз-үзенә ышаныч, коллегалар арасында беренче дә бәхәс булмагандай, салкын кан белән сөйләде. Әйткәннәре бик мөһим булуга карамастан, аны башкаларга ишеттерү өчен көч куймады, иркенләп, фикерен ачык итеп белдерде. Ул гына да түгел, кара туткыллы бу хатын хәзер аерата сөйкемле, аерата эшлекле иде. Аның гадәти елмаюы да, ямь өстенә ямь дигәндәй, самими балкыды.

Кафедра мөдире белән парторг яшь ягыннан бер тирә. Икесе дә — күренекле хирург, мәрхүм Н. Н. Лозанов укучылары. Профессор вафат булгач, институт коллективы кафедрага житәкчелек итәрдәй кешене әллә кайдан эзләмәде, бер тавыштан бу эшне әлеге хатыннарның берсенә тапшырырга дигән нәтиҗәгә килде. Һәм бу хакта аларның үзләреннән ишетергә теләде.

— Зәйнәп Вахитовна докторлык эшен тәмамлады, хәзер яклау алдында торучы галим, — дип кырт кисте ул чакта Галия Рифкатовна. Ә үз кандидатурасы турында: «Минем эшләр әлегә йомгаклау алдында гына, вакытны бик күп сорый торган чагым», — диде.

Шулай итеп, кафедраны Зәйнәп Вахитовнага тапшырдылар.

Бу ике ханым тыштан караганда бер-беренә бөтенләй охшамаганнар; Зәйнәп Вахитовна уртача буйлы, шат йөзле кеше булса, Галия Рифкатовна озын һәм какча гәүдәле, сөйләгәндә ашыкмый, әйтәсе һәр фикерен алдан бизмәнгә салып әйтүчән. Табигый матурлыгы сирпелеп тормый. Әмма коллективта аны Зәйнәп Вахитовнага тиң саныйлар, икесен дә ихтирам итәләр иде. Ватан сугышында Зәйнәп Вахитовна — полк врачы, ә Галия Рифкатовна шул полкта шәфкать туташы булган. Сугыш тәмамлангач, Казанга кайтканнар.

Кафедра мөдиреннән соң сүз алган парторг Галия Рифкатовна башта бүлмәдәгеләрнең һәммәсен күздән кичерде, аннары өстәл өстендәге кәгазьләрне бер өемгә җыеп салды. Фикер туплый иде, күрәсең.

— Әгәр дәвалауның яңа ысулы үзен аклый икән, минем уемча, безгә Казан хирургия мәктәбендә генә түгел, союз күләмендә игътибар итәчәкләр. Роберт Салихович, без сезнең белән бер коллектив кешеләре, бер үк вакытта коммунистлар да. Сез — бүлек җитәкчесе. Инициатива-

ны сүндерү ансат, әллә бу мәсьәләне төптәнрәк уйлыйкмы? — Ул текәлеп Робертка карады. — Койкалар аз дибез, бу хакта берничә ел сөйләп киләбез. Сез килгәнче үк башланган сүз бу. Нигә безгә бүлекнең мәйданын киңәйтүгә эшлекле төстә керешмәскә? Җиң сызганып, изүне чишеп... Мин бинага ялгап, өстәмә мәйдан төзүне күздә тотам. Югары органнар алдына мәсьәләне кабыргасы белән куйсак — ә безнең аргументларыбыз җитәрлек — дикъкать итми калмаслар дип ышанам. Еламаган балага мәми бирмиләр.

Наилә үз янәшәсендәге иренең кулына кагылып куйды. Ул үзенең канәгать икәнлеген сиздерергә тели иде. Хатынын аңласа да, «ашыгып төшмә!» — дип куйды Алмаз. Робертка килгәндә, ул артыгын сиздерүчәләрдән түгел, бая ничек тыныч утырса, хәзер дә шул ук халәттә иде.

4

Әлфия дежур өстәле янына килеп, авыруларның шәхси карточкаларын алып, төнгә һәм иртәнгелеккә кемгә нәрсә билгеләнгәнне тикшерде. Шулай җай гына утырганда, үзара сөйләшә-сөйләшә Наилә белән Зифа килеп чыкты. Әлфия аларга игътибар итмәгәндәй, эшендә булды. Зифаның куллары аның ачык, йомры тезләренә килеп тигәч, инде дәшми мөмкин түгел иде.

— Зифа түгелме соң? Ә мин сине өйгә кайтып киткән дип торам тагын,— дип шаярта башлады.

— Юк әле, өйгә иртәрәк. — Зифа аның муенына сарылды. Баланың Әлфия апасын нинди сагынганлыгын Наилә елмаеп карап торды. Тормыш тәҗрибәсе булган, ана булу бәхетен татыган, хисләргә бай бирәр ханым күзәтсә, Наиләнең бу карашында тасвирлап бетергесез назны, хатын-кызларда бөркелеп торган балага сусау тойгысын чамалар иде.

Шулай икесе дә бала белән юанган арада, кайдандыр бер моң ишетелде. Бу — аларның күңелен бик тиз үзенә җәлеп итте. Зифа жырга бирелде, тынып калды. Кулларын акрынлап Әлфия апасының муеныннан алды, аның итәгеннән идәнгә төште һәм онытылып тыңлап торды. Күзләре зур ачылган, йөзләрендә әсәрләнү галәмәте иде. «Ләлә апа җырлый. Ләлә Нуриева апа... Аның җырлавын әбием дә, әнием дә ярата», — диде дә, бар дөньясын онытып, җыр яңгыраган палатага ашыкты.

Казан радиосы кечке концерт тапшыра иде. Палаталарда, коридорларда сөйләшкән авазлар тынды. Бөтен бүлекне күңелләрне айкап ала торган җыр биләде. Нинди тылсымга, нинди көч-кодрәткә ия син, җыр!

Кар сулары бетте,
Ярсулары үтте,
Ташлар тәгәрәми ташкында.
Минем генә йөрәк,
Сагынудан йөдәп,
Бәйгедәге аттай ашкына.

— Абау, матур җырлый! — Әлфия тәмам җыр иркенә бирелгән иде.

— Әйе, Ләлә матур җырлый, күз тимәсен...— Наилә онытылып, үзүзе белән сөйләшә иде. Җыр күңелнең иң нечкә кылларына чиртә иде.— Алмаз абыеңның студент чагындагы танышы ул...

— Шулаймыни?

Кичке концерт әле тәмамланмаса да, Ләлә Нуриеваны тыңлаган авырулар сөйләшә, җыр турында фикер алыша башладылар. Җыр һәркемне җилкендереп җибәрде. Кайсысының йөрәгенә дәва, күңеленә бәлзәм булып ятты җыр. Кемнәрдер уйга калды, сагышына бирелде...

— Чынлап та сәнгатьнең искиткеч дәвалау көче бар.

— Шулай шул, Наилә Рәхимовна. Тормышның шатлыгын да, кайгысын да җыр әйтә. Җыр җырламый күңел басылмый, диләр бит...

Дежур врачның күзләре уйчан, вак сипкел кунган озынча йөзе кичерешле иде. Гадәттә ягымлы, аз сүзле, кешене зур игътибар белән тыңлый белүче ханым хәзер моңаеп, ничектер онытылып калган кебек иде. Керфекләре яшькә чыланды. Наилә кулъяулыгын алып яшьле күзләрен сөрткәләп куйды. Ул ничек кенә булмасын, күңелендә кайнаган кичерешләрне тышка чыгармаска тырышты.

— Әлфия, зинһар гаеп итмә, иң зур серемне сиңа әйтәм. Ул — мине читләтеп үткән шатлык, безнең гаиләнең газабы. Менә Зифаны очраткан саен әлеге газап көчәя генә. Күңел ярасы күрер күзгә күренмәсә дә, бик әрнеткеч икән. Сабыйның савыгуына шик юк, әлбәттә. Озакламый аны өенә озатырбыз. Зур итеп. Тик безнең бәхет кенә китек булып калыр.

Әлфия Наиләгә теләктәшлек хисе тулы күзләре белән томырылып карады.

— Бу дөньяда берәүнең дә бәхете мөлдерәмә түгел, Наилә апа, — дип куйды.

— Юк, Әлфия, бер тулмаса, бер тулырга тиештер ул кеше куанычы. Наиләнең үткәннәре аңа үтә борчулы, сызланулы булып ишетелде. Өметен өзми кеше дигәнең, ышанычы юк түгел.

— Менә Алмаз абыең белән бергә кушылганга инде алты ел. Зифа кебек, туптай тәгәрәп йөрер балабыз булырга бик вакыт... Тик... без ул бәхеттән мәхрүм.

Әлфия ни дияргә аптырап калса да, аны юатырга теләде:

— Булыр әле, Наилә апа, сабыр итегез.

— Юк шул инде. Биологик яктан ялгыш кушылганбыз. Бала ярала алмый. Генетика... Алмаз абыең белән, шөкер, дус яшибез. Балабыз булмауда кайберәүләр Алмазны, кемнәрдер мине гаепли. Чынында, Әлфия, нинди гаеп ди ул. Моны исбат итү, беләсеңме, безнең аерылышуны таләп итә. Әйтергә генә җиңел... күңелләр береккән, ә борчу сүнми дә, сүрелми дә...

Наилә сулкылдап куйды. Аның күзләрен тагын яшь күмде.

— Бүгенге фән казанышы ярдәм итми булмас, Наилә апа. Әби әйтмешли, шайтан гына өметсез... — дигән булды Әлфия.

— Ә шайтан юк шул, — Наилә яшьле күзләрен сөртә-сөртә көлемсерәп куйды. Янып сүнгән кебек, сабырлана төште.— Алмаз абыеның Зифаны нинди иркәләвен син, Әлфия, үзең үк күреп торасың. Өйләнгән елларны ул: «Безнең ике кызыбыз, бер улыбыз булачак», — дип хыяллана торган иде...

Бу әңгәмә катлаулы һәм күңелгә авыр иде. Шулай да төн тиз үтте.

Больницада таң аеруча көтеп алына. Авырулар өчен генә түгел, врачлар, шәфкать туташлары өчен дә таң күңелләргә җиңеллек бирә. Кояшның тәрәзәгә төшкән иртәнге нурлары да, кошларның дәртле черкелдәүләре дә сагыңдырган була. Наилә белән Әлфиянең дә хәзер кәефләре әйбәтләнгән төсле күренә.

Авырулардан иң беренче булып коридорга Зифа килеп чыкты. Кай арада йокыдан арынган диген!

— Алмаз абый килмәдеме әле? — дип сорады ул.

## 5

Медиклар бәйрәме бигрәк матур көнгә туры килде. Һава саф. Күк чалт аяз. Алмаз белән Наилә кебек табигать күрке тансык булганнарга бүгенге көн аерата сокланырлык. Ниһаять, алар бергәләп ял итәрләр. Паркка барырлар, гөлләрнең, чәчәкләрнең хуш исен татырлар. Шуңа да Наилә бүген һәммәки мәшәкатьләрен күеп торырга булды. Матур итеп киенү, бизәнү иде аның теләге. Ул аксыл-сары чәчләрен толымнарга үрмичә генә матур итеп иңбашларына таратып салды. Болай да

сөйкемле яшь ханым үзенең бизәнүеннән яңа бер төсмер тапкандай булды һәм бу хәлгә эченнән генә сөенеп тә куйды шикелле. Зәңгәр күзләрендә шаян очкыннар уйнаклашты, кабарынкы иреннәре дымлы иде. Ак җирлеккә зәңгәр бизәкләр төшкән озын күлмәге дә сынына ятып тора. Гәүдәсе бераз тыгызланырга өлгергән. Иякне аз гына алга чөеп, башны горур тотканда, ул аеруча мәһабәт күренә. Үзе яраткан ярым платформалы ак туфлиен киеп алгач, бүлмә түрендәге зур көзге алдына басты. Үзенең буй-сынын күздән кичерде, канәгать иде.

— Мин нәрсә киим икән соң, Наиләм? — диде Алмаз.

— Синме? — Хатыны аңа нәзакәтле караш ташлады. — Син актан киен. Җәйгечә. Ак чалбар, тенниска, ак сандали.

— Башка ак эшләпәме? — Алмаз «ак» сүзен кат-кат кабатлаган хатынын шаярта иде бугай. Наилә исә җитди сөйләште.

— Юк, юк, башыңа берни дә кимисең...

Үзәк ял паркы. Бирегә аларның бик күптән, бергә яши башлаганнан бирле килеп чыга алганнары юк иде. Парк та шактый үзгәргән, яңарган. Асфальт юллар да, тар сукмаклар да элеккечә түгел, киңәйгән, матурланганнар. Хәер, студент чагында да алар бергә еш йөрмәделәр. Ә институт тәмамлап, гаилә коргач, паркны тәмам оныткандай булдылар. Тулган ай, хуш исле чәчәкләр романтикасын гап-гади тормыш прозасының чыбылдыгы урап алды төсле.

Алар башта Казан елгасы буена карап, тау битеннән бардылар. Моннан шәһәрне күзәтү үзе бер кызык, үзе бер мавыктыргыч иде!

— Мин туып-үскән Сабин авылы бетеп бара икән. Без җуага йөргән болынлык та юк инде, — диде Наилә.

Бераздан тау сыртыннан урманлыкка атладылар, андагы сукмаклар белән парк үзәгенә, уен мәйданчыгына килеп чыктылар.

Шул чак ачык эстрададан таныш моң яңгырады.

— Ләлә үзе җырлый түгелме? — диде Наилә. — Әллә магнитофон гынамы?

— Чынлап та!.. — Алмаз гаҗәпсенеп тә, сөенеп тә шулай диде.

— Әйдә барыйк әле шул якка.

— Безнең үз планыбыз бар, Наиләм. — Алмаз үзенең сабыйларча кабынып китүеннән җайсызланып, сабыр-салмак булырга тырышты. — Киттек «Шайтан тәгәрмәче»ндә әйләнергә! — Ул хатынын култыклап алды.

Менә тәгәрмәч аларны утыртып, әйләнә дә башлады. Бу хәтәр биеклектән шәһәр, бигрәк тә яңа районнар әйбәт күренә. Казан елгасы һәм аның тугайлары ялтырап ята.

Әлеге матурлыкны Наилә дә күрәме икән дип, Алмаз хатынына борылды. Юк, Наиләсенең күзләре бер ноктага төбәлгән, ул тирән уйга калган иде. Ире аны үзенә тартты, иңнәреннән сыйпады, хатыны имән бармагын иреннәренә китерде дә «ти-иш!» дип кисәтте.

— Ләлә җырлый ич! Әллә тыңламыйсың да инде? — диде. Аның күңеле, чынлап та, җырда иде. Алмаз да тыңлады, әлбәттә, тик хатынкыз тәэсиргә тизрәк бирелә. Наилә үзенә хас нечкә сизгерлек белән һәммәсен аңлап торды.

Ә җиргә төшеп өс-башларын төзәткәләгән арада, алар янына танышлары килеп чыкты.

— Күрче, алар кай тирәдә йөриләр! Адашканнар! — диде әлеге парларның берсе булган Роберт шаярып.

Аңа җавап итеп Наилә ихтыярсыздан:

— Ир белән хатын нишләп адашсыннар? — дип куйды.

— Ә без эстрада концерты тыңладык... — дип, сүзгә Луиза кушылып китте.

— Әйе, безнең эстрада да үзен сиздерә башлаган икән. Әмма пентатоника бу цивилизация заманында шуннан да көчлерәк яңгырый

алырмы? Юкса, әйбәт кенә башкаручылар да күренә... — Роберт милли музыка хакында сөйли иде.

— Сез, Роберт Салихович, Ләлә Нуриеваны күздә тотып сөйлисез шикелле? — диде Луиза. Ләкин Наилә Роберттан алда сүз башлады:

— Музыканың чын таянычы — халык көйләрендә, халык җырында. Ә һәр халыкның үзенчәлекле моңы, тарихи музыка нигезе бар. Безгә дә пентатоникадан качмаска, аның белән исәпләшергә кирәктер. Табигатьтә дә гөлләр-чәчәкләр бихисап төрле, әмма һәркайсының үз яме бар.

— Күренә ки, безнең Наилә Рәхимовна музыка дигәндә үтә дә үз фикерле.

Бәхәс-бәхәс инде ул, күңелгә дәва түгел. Алай да Алмаз бу очрашуга шат иде. Ни әйтсәң дә алар — коллегалар. Җитмәсә, бүген аларның уртак бәйрәмнәре.

Алар студент елларыннан ук таныш. Роберт өч курска өлкәнрәк иде. Ул травматология һәм кыр хирургиясе, ә Алмаз гомуми хирургия фәнни түгәрәгенә йөрде. Алмаз түгәрәккә беренче кат килгәндә, Роберт инде институт күләмендәге студентлар фәнни оешмасы председателе иде. Оешманың конференцияләрендә ул профессорлар белән янәшә президиумда утыра, утырышларда председательлек итә иде.

Роберт студент чакта ук башкалардан аерылып торды. Үзен эрерәк тота, башкалардан өстенрәк хис итә кебекме шунда... Берәүләр моны үз сәләтенә артык ышану, масаю дип санасалар, икенчеләр хирургия доценты булган әтисенә аркалану дип карый иде. Әмма ул чакта аның холык-фигыле Алмазны бөтенләй кызыксындырмады. Мавыкканы өлкән курс студентының тирән эчтәлекле докладлары булды. Чөнки алардан фәнни яңалык та, докладчының эрудициясе дә ачык чагыла. Шулар тәэсиредерме, күңеленең кай җирендәдер Робертка карата ихтирам әле дә булса саклана килә. Шулай да кафедрада яңа проблема туып, бүлек мөдиренең аңа каршы төшүе әлеге хөрмәтне торган саен киметә, зәгыйфьләндерә төсле иде. Җитәкче булгач та, үз фикере белән генә яшәргә ярый дип уйлый, күрәсең. Принципиальлыкның чамасын белми... Югыйсә, үз кул астындагыларның бүрегенә шулай сукмас иде. Алмаз да бүген генә диплом алган яшь врач түгел ләбаса. Дәрәҗә югарылыгыннан торып, кул астындагылар фикерен ишетә, аңа колак сала алмаган җитәкчене нәрсә дисең?

Музыка турында нигездә Наилә белән Роберт арасындагы шаяру катыш бәхәсне Луиза түгәрәкләп куярга җыенды.

— Музыканы кешенең рухи халәте итеп карау тикмәгә генә түгелдер. Хисләр, тойгылардыр аның тукымасы. Музыканы да өйрәнергә, күбрәк тыңларга кирәк. Ә сезнең, Роберт, татар концертларына, ялгышмасам, барганыгыз да юк төсле.

— Дөрес, аз йөрим. Ләкин безнең өйдә татар сәнгате, татар музыкасы аз яңгырамый. Менә бүген тыңлаган Ләлә Нуриеваның язмалары да бездә бар.— Роберт үзенең бу сүзләре белән милли музыкага бөтенләй битараф булмавын күрсәтә иде. — Нуриева сәхнәдә сокландыргыч, эффектлы икән.

— Аның лирик җырларында аеруча тирән хис бар...— дип өстәде Луиза.

Җырчы хакында сүз әйтүдән Алмаз гына тыелып калды.

— Булмаса, кафега кереп, мороженое ашар идек, — диде ул сүзне икенчегә борырга теләп. Ә хатыны:

— Һава болай да сүрәнләнеп китте, туңуыбыз бар, — дип көлеп куйды.

— Алайса, башка берәр нәрсә, бәйрәм көн бит, — диде Луиза.

— Кафега керсәк? Чынлап та... Әйдәгез, утырып чыгыйк! — диде

Роберт чын күңелдән кыстап. — Шампан шәрабе, Наилә Рәхимовна, сезне дә җылытып җибәрер.

Кире кагу һич урынсыз иде. Үзе бәйрәм, үзе көтелмәгән очрашу! Алмаз да, Наилә дә моның белән килеште.

6

Ике сөенеч берьюлы булды. Көтмәгәндә Зифадан, дөресрәге, аның әнкәсеннән хат килеп төште. Икенче шатлык та хат. Мәскәүдә чыга торган журнал редакциясеннән иде. Алмаз аларның кайсын да башлап укырга белмәде. Зифаныкын беренче итеп ачты. Хирург үз пациентының хәле турында язылган юлларны дулкынланып укыды. «Зифаның хәле тәмам яхшырды... Җырларга бик ярата». Алмазны шатлык тойгылары биләде. Димәк, өметнең бу өлеше акланды. Ул икенче хатны алды, конвертны ачар алдыннан шөбһәләнеп куйды. «Мәкаләне кире каккannармы?» Мәгәр куркуы юкка гына икән, Зәйнәп Вахитовна белән язган мәкаләне журналга кабул иткәннәр.

Кафедра мөдире үзе дә аны күрергә теләгән иде.

— Керүең әйбәт булган, сөйләшәсе сүз дә бар иде. Бүген утырыш икәнен беләсеңдер бит? — Ул каршысындагы барлык кәгазьләрне дә тәртипләп, як-ягына өеп куйды, өстәл өстендә ике-өч битлек язу гына торып калды. — Алмаз Әхәтович, менә мин сезнең диссертация планын шулайрак күз алдына китерәм. Нинди өстәмәләр, үзгәртүләр кертү кадәресен карарбыз. Бергә утырып уйланыр вакыт таба алмаганга, фикеремне бирегә яздым. Танышыгыз. — Ул әлеге кәгазьне Алмазга сузды. Алмаз язуларны игътибар белән карап чыкса да, Зәйнәп Вахитовна әйткән диссертация планына тәмам төшенеп җитмәде. «Ничек инде диссертация?» — дип, әлеге планның чынлап та аның өчен көтелмәгән булуын шефка чак кына әйтмәде.

— Минемчә, шеш тукымаларының гистохимик анализын күздә тотарга кирәктер, — диде ул.

— Әлбәттә. Хәзергә бу планны тикшермибез, сез аны һәр яклап өйрәнегез. Вакыт табып, соңыннан бергәләп карарбыз. Бүген кафедра утырышы... Анда да сезнең нәтиҗәләр турында сүз булыр. Әзер торыгыз.

Кафедра мөдире сүзен кыска тотарга тырышты. Моны сизеп, Алмаз:

— Зәйнәп Вахитовна, ике хат килеп төште бит әле, — дип конвертларны шефына сузды.

Доцент хатларны игътибар белән укып чыкты да, гадәттәгечә сөйкемле елмаеп:

— Котлыйм, Алмаз Әхәтович. Димәк, эшләр шәп, — диде. Ул Алмазның менә хәзер үзе янына керүеннән, әлеге хәерле хәбәрләрне ишетүеннән бик канәгать иде.

Соңгы вакытта дәвалаучы врачлар да кафедра утырышларына теләп йөриләр. Моңа һәр операцияне фәнни нигездә анализлау, аларга йомгак ясау гадәткә кереп китүе сәбәптер. Шулай да бүген күбесе хирург Алмаз тәкъдим иткән дәвалау ысулы хакында ишетер өчен килгән булса кирәк. Чөнки бу ысулны тикшергән утырышларга алар аерата актив катнашалар.

Утырыш мөдир кабинетында булачак иде. Алмаз килеп кергәндә, халык әле җыелып бетмәгән, ләкин буш урыннар да аз иде. Аңа урынны соңгы рәтләрнең берсендә Наилә белән Әлфия алып калган булып чыкты.

Фәнни эзләнүләрнең нәтиҗәләлеге һәм бүлектә дәвалау шартларын яхшырту кебек мәсьәләне бер утырышта тикшерү партоешма тарафыннан билгеләнгән иде.

— Тыштан караганда кафедра һәм бүлек мөстәкыйль булып күренсәләр дә, безнең максатлар уртак, — диде Галия Рифкатовна, болай җыелуның сәбәбен ачыклап.

Парторгның кереш сүзеннән соң Зәйнәп Вахитовна чыгышы башланды. Ул башта бүлекне кинәйтү җәһәтеннән башланып киткән төзелеш өчен соңгы вакытта материаллар житешмәвен әйтеп үтте. Кафедрада фәнни эшләрнең торышы хакында сөйләгәндә дә төзелешне тиз арада хәл итәргә кирәклегенә кат-кат басым ясады.

— Дәвалауда хемотерапиягә зур игътибар бирү, шул юнәлештә эзләнүләр инде матур нәтиҗәләрен бирә дә башлады. Болар Алмаз Әхәтовичның тырышлыгы хакында сөйли. Минә үзәк журналдан шатлыклы хәбәр килде: аның эзләнүләре союз күләмендә игътибарга лаеклы дип табылган. Шуның белән бергә, безне борчырлык икенче мәсьәлә бар. Ул да булса, яңа ысулны үзләштерүдә Алмаз Әхәтовичның ялгызлыгы. Башта бу эштә зур активлык күрсәткән Луиза Хәмитовна да нигәдер читкә тайпылды, — традицион ысулны хуп күрә. Сәбәп нәрсәдәдер, кистереп кенә әйтергә читенсенәм...

Әлеге сүзләр Луиза Хәмитовнаны сискәндергәндәй итте. Аның кара тутлы озынча йөзе агарып китте, сөйкемле кара күзләрендә борчылу сизелде. Ул дулкынланып, җилкәсен томалаган калын чәчләрен бер якка кайтарды, йомры түше еш-еш калкып куйды. Бары Робертның үзенә төбәлгән карашын күргәч кенә тынычлангандай булды. Ул караш гүя: «Борчылма, синнән җавап көтелми, ә инде ни дә булса әйтергә икән, бирергә мин бар», — дию иде. Шулай да ординатор бөтенләйгә тынычланып житә алмады. Бераздан урыннан торды. Ул күзләрен Зәйнәп Вахитовнага төбәде.

— Мин яңа ысулдан качмадым. Тик яңалыкка күчү өчен, минемчә, әлегә иртәрәк, бүлектә шартлар җитәрлек түгел кебек. — Ординатор фикерен ачык һәм тулы итеп әйтә алмады. Тел төбеннән сизелә, Луиза бүлек хуҗасы фикеренә нәреп сөйли иде.

Ниһаять, Роберт сүз алды. Ул үзен иркен, тыныч тота, фикерен нык-лы логика белән бәян итәргә тырыша иде.

— Нинди тармакта эшләсәк тә, безнең, медикларның, максаты уртак — кешенең саулыгын-сәламәтлеген саклау. Бу юлда уңышларыбыз бар икән, димәк, барыбызга да сөенеч. Безнең эштә уңышны берәүнең генә иҗат җимеше итеп карау ялгыш булыр иде. Хәтта... Зәйнәп Вахитовна безгә Алмаз Әхәтовичның беренче нәтиҗәләре үзәк журналда басылу алдында торуын хәбәр итте. Бик хуп! Моны, коллегалар, котларга кирәк. Тик, әйтәләр бит, таңканың икенче ягы да бар. Минә без ул мәкалә белән таныш түгел. Безнең бүлектә тупланган нәтиҗәләрдән без үк хәбәрдар түгел... Минемчә, мәкаләне журналга җибәргәнче без аның белән танышырга тиеш идек. Аннан соң, хөрмәтле коллегалар, үзегез беләсез, ординатор Луиза Хәмитовна да башта Алмаз Әхәтович белән бергәләп эшләгән иде. — Робертның сүзе кай тарафка баруы һәркем өчен ачык иде инде. Аның сөйләгәннәрен игътибар белән тыңлаган Әлфия түзмәде, үз-үзен онытып: «Бүлек мөдиренең үз хирургының эшен белмәве — гаҗәп!» — дип куйды. Аның әйткәнен барыннан да элек Роберт белән Луиза ишетте, Әлфия аларның үзенә төбәлгән карашын башкаларга караганда алда күрде һәм оялу катыш сагаеп калды. Аннары бер ягында Алмаз, икенче ягында Наилә утыруын сизеп, тынычланган кебек тә булды.

Роберт сөйләвен дәвам иттерде.

— Минемчә, Луиза Хәмитовна сүзендә хаклык бар. Яңа ысулга тотынганда тәҗрибәне дә, мөмкинлекләрне дә исәпләү зарури. Бинаны зурайту тукталып тора, димәк, объектив сәбәп бар. Ул, ни дисәң дә, алдан планлаштырылган объект түгел. Ярый әле министрлык, җәмәгатьчелек ярдәм кулын сузып, башлап җибәрергә мөмкинлек тудырды.

Шулай да төзелешне тиз генә башкарып чыгарбыз дию реаль булмас. Мөмкинлекләр, үзегез күрәсез, чамалы. Түшәгеңә күрә аягың суз дигәндәй, үзәк журналда мәкалә бастыру белән генә мәсьәләне хәл ителгән дип булмый.

Бүлек мөдирен тыңлап утырган Алмаз йөзендә гарьләнү, күзгә бәреп әйтү теләге, ачу — һәммәсе бергә кайный иде. Күренеп, аңлашылып тора лабаса, төзелештә эш аксауга бәйләп, Роберт Алмаз тырышлыгына шик ташламакчы... Аның күңелен бер сорау борчыды: «Әгәр Зәйнәп Вахитовна әлеге мәкалә хакында әйтеп өлгермәгән булса, Роберт тагын ниләр сөйләгән булыр иде икән?»

Бүлек мөдиреннән соң Зәйнәп Вахитовна сөйләми булдыра алмый иде.

— Сез шахмат уйнаганны хәтерләтәсез бит әле, иптәшләр! — дип сабыр гына сөйләп китте ул. — Анда ат йөреше бар. Үзәк журналга мәкалә язган ике авторның берсе буларак, мин әйтә алам — без үзебезнең эзләнүләребездә тәвәккәллек кылдык, «ат йөреше» ясадык. Шул ук вакытта өметебез акланууы белән сезне дә сөендерергә уйлаган идек.— Ул тагын нидер өстәргә теләп, коллегаларының күңеленә разведка ясагандай, каршыдагыларга карап алды. Ләкин әйткән дә җитәр, аңлаганга аңларлык дипме, туктады. Кемгәдер кискен күрсәтмә ясап, үз принцибын алга сөрергә теләми иде ул. Чөнки Алмаз да, Роберт та яшьләр. Өметле яшьләр. Роберт беркадәр субъективлык белән «чирли» икән, бу озакка сузылмас. Бүлек мөдиренең атасы күркәм кеше. Республикабызда медицина хезмәтен оештыручы, бай тәҗрибәле хирург, галим-доцент. Алмагачтан алма еракка тәгәрәмәс, бәлки Робертта атасының сыйфатлары өстенлек алыр... Ә Алмаз — авыл егете, эчкерсез. Көндәлек тормыш дипломатиясе җитенкерәми яшь хирургка. Сәләтле, эзләнүчән, үз фикере бар.

Партоешма җитәкчесе Галия Рифкатовнаның какча һәм ара-тирә вак җыерчыклар күренгән йөзе гадәттәгечә сабыр. Бүген аның соры күзләрендә җитдилек.

— Һәр яңалык башлангыч чорда шулай бәхәсле була. Сәбәбе ачык — яңалык авыр туа, дәррәү ачылып китә алмый. Вакыт кирәк, тир түгү кирәк. Ә без ничек итәбез? Үзәктәге журнал, андагы галимнәр Алмазыбызның беренче ачышларын хуплаганнар икән, димәк, кафедра яшь хирургка игътибарлы булган. Автор өчен дә, коллектив өчен дә мактаулы эш эшләгән. Инде шартларга килик, — парторг бүлек мөдире ягына борыла төште. — Әйе, Роберт Салихович, сез министрлыкта булгансыз. Тик...

— Мин ул хакта сезгә әйтергә өлгермәгән идем әле,— диде Роберт. Гүя ул шүрләп калды, акланырга ашыга иде.

— Кафедра һәм бүлек арасындагы мөнәсәбәтне дә кабарта төшкәнсез... — Галия Рифкатовна сүзен озынга сузмады, бигрәк тә алдан әйтелгән фикерләрне кабатлаудан сагайды.

Парторг сүзләре барыбер үзенекен итте. Эссе, бөркү көндә искән яраулы җил кебек. Роберт кына тынычлана, ярсынуын баса алмый, озын бармакларын тез өстендә биетә. Утырышның кинәт кенә шундый борылыш алуын көтмәгән иде ул. Җитмәсә, үзәк журнал... Димәк, җиңүче ул түгел... Шулай да көрәшергә кирәктер. Шахматтагыча. Ә ул алай ук начар шахматчы түгел. Короле дә исән, атлары да үз урынында... Зәйнәп Вахитовна әйткән «ат йөрешен» нигә аңа да ясамаска?

Утырыштан соң парторг, кафедра һәм бүлек мөдире өчәүләп җыелышта каралган мәсьәләләрне тагын бер кат уйларга, алар хакында киңәшергә кирәк таптылар.

Луиза коридор буйлап барганда Әлфияне куып җитте һәм бер кулы белән аның иңбашына кагылды. Әлфия өчен көтелмәгән хәл иде бу. «Утырышта Роберт Салиховичка реплика ясавым өчен тиргәргә кил-

гән», — дигән уй йөгереп үтте. Ничек итеп акланырга да белмәде. Күңеленә яшерә алмаган, инде башкаларга билгеле булган фикерен якларга да әзер түгел иде шул ул. Ә чынлыкта алар арасында бәхәс менә-менә кузгалыр кебек күренсә дә, әңгәмә бөтенләй башка юнәлеш алды:

— Зифадан хат килгән дип ишеткән идем, хакмы, Әлфия? — дип сорап куйды ординатор.

— Әйе, әйе, Луиза Хәмитовна, Алмаз Әхәтовичка да, миңа да,— дип, ашыгып җавап кайтарды ул.

— Безгә сәлам дә юктыр әле, — дип, үпкәләгәндәй булды Луиза.— Ике операциядә дә Алмаз Әхәтовичның ассистенты мин идем бит...

— Теләсәгез, танышa аласыз... — Әлфия хатны аңа сузды.

Тәрәзә янынарак авышып, Луиза әлеге хатны укый башлады. Бала сүзләрен кертеп язылган юллар аның күңелен күтәргәне ачык иде. Ул инде сәлам язмаган өчен хәтере калуны онытып җибәргән. Шулай да азактан:

— Зифа күңелендә сакланырлык эш майтармаганмын, күрәсең,— дип, китеп барды.

Луизаның әйбәт врач, кече күңелле кеше икәнен Әлфия күптән белә. «Ә кафедра утырышында нигә дөреслекне якламады соң? — дип куйды ул үз-үзенә.— Роберт Салиховичка каршы килә алмагангамы?» Шунда аның очына чыга алмаган уйларын Алмаз тавышы бүлдерде.

— Әлфиякәй, ялгышмасам, сез бүген дежурда түгел бит? — Шаярган минутларында ул гел «Әлфиякәй!» дип эндәшә. — Наилә апаңның да ялы бүген. Әллә бергәләп театрга барабызмы?

— Әллә билет бармы?

— Алып куйган идек шул. Сезнең өчен дә табылыр.

Әлфия башта Алмазны шаярта гына дип уйлаган иде, инде чын күңелдән дәшүен белгәч, рәхмәт әйтергә ашыкты.

— Бүген бара алмыйм шул, Алмаз абый.

— Димәк, очрашасы кешең бар? Егетеңме?

— Ю-ю-к, ул авылда иң. — Кыз уенын-чынын бергә кушып җавап кайтарды. — Укыйсым күп, Алмаз абый.

Алмаз киткәч, Әлфия аңын җуйгандай басып торды. Бүлек мөдиренә теге репликасы белән тѳрттереп куюы ничек килеп чыкты соң әле? Алмаз абыйсына теләктәшлек күрсәтергә теләпме, хакыйкатьне яклапмы? Луиза белән аңлашып өлгергән булса, аңа җиңелрәк булыр, ничәмә-ничә сораудан арыныр иде. Тик сүз башкага кереп китте. Шуңа да ул күңелсез генә кайтырга чыкты.

## 7

Кичә үзенә чакырып, Робертның әйткәннәреннән Алмаз әле дә булса арына алмый. Кая ул?!. Менә хәзер, иртән эшкә килгәндә дә, клиникага якынлаша барган саен шул хактагы уйлары куера, ярсый. Роберт аңа башка больницага, травматологиягә китәргә куша. Шул хакта сүз бүген дә булачак. «Ярый, иртәгә кадәр уйлагыз», — дигән иде бүлек мөдире. Нәрсәсен уйлыйсың инде аның? Уйласаң да бәхәс өчен генә. Менә алар утырып килгән трамвай көтмәгәндә рельсларны шыгырдатып, тукталып калды. Пассажирлар сөртенеп, чайкалып алдылар. Алмаз да баягы уйларыннан бер мәлгә айнып киткәндәй булды. Баксаң, чак кына авария килеп чыкмаган икән. Пөк машинасы алды белән трамвайга килеп бәрелгән. Үзенең бер як фарасы чәлпәрәмә килгән...

Чыннан да Алмаз ялгышмаган икән. Роберт аны үзе янына дәштерде. Кичәге мәсьәләгә кабат кайту өчен, соңгы сүз өчен. Юк, ул травматологиягә хәтта вакытлыча гына булса да китә алмаячак. Ничек

башлаган эшне ташлыйсың ди? Дөрес, клиникадан бер хирургны травматологиягә күчерүне министрлык үзе сораган, үтенеч белән мөрәҗәгать иткән. Ә ул «бер хирург» нигә Алмаз булсын ди? Бүлек мөдире шулай санагангамы? Ул, әлеге уйларының очына чыгарга өметләнеп, Роберт кабинетының ишеген шакыды.

Бүлек мөдире рәсми каршылады. Әмма, сизелә, күңеле тыныч түгел. Буран кузгалуны күргән юлчы кебек. Алмаз белән исәнләшеп, урын тәкъдим иткәннән соң саран гына сүз башлап җибәрде.

— Мәсьәләне иртәнге акыл белән хәл итү нияте белән дәшүем,— диде ул, Алмаз йөзенә туры карарга кыймыйча.

— Минем акыл бер төн эчендә генә үзгәрми шул, Роберт Салихович,— Алмаз да шактый төксе җавап бирде.

— Сүз министрлык таләбе турында бара. Ә аның таләбе катгый. Мин исә югары органны тыңламый булдыра алмыйм, — дип, Роберт утырган җиреннән күтәрелергә генә теләгән иде, Алмазның кинәт биргән соравын ишеткәч, янә урынында калды.

— Ә мин килешмәсәм?

Роберт саран елмайды. Әйтерсең ул үзенең шушы елмаюы белән хирургның мәгънәсез карышуын кисәтә иде.

— Сез гариза белән кермәгәнсез ич? — Роберт һаман салкын канлылык сакларга тырышты.— Алмаз Әхәтович, әйдәгез таякны бөгеп җибәрми генә сөйләшик. Ирләрчә. Коллегаларча. Травматологиягә җибәрү өчен сездән дә кулайрак кандидатура таба алмыйм. Ихлас менә. Аннан соң, әйткәнемчә, вакытлыча гына бит. Күп булса бер елга.

— Гади генә белгеч булсагыз бер хәл, Роберт Салихович. Сез гыйльми дәрәҗәле. Башланган эзләнүләрнең беренче нәтиҗәләре галимгә нинди кыйммәтле булса, алдагылары, хыялдагылары да шулай ук. Бүлектән бер елга китү — башланган проблеманы бер елга ташлау. Күрәләтә ничек килешим?

— Бәлки берәр тәкъдимегез бардыр? — Роберт тагын үтә житди кыяфәт алды.

— Тәкъдимем шул, травматологиягә җибәрү өчен коллегадан башка берәүне сайларга мөмкин. Миңа эшемне дәвам иттерергә ирек бирегез.

— Әлеге берәү дигәндә, кемне күз алдына тотасыз? — Бүлек мөдиренең тавышында тимер суыгы сизелде. Үзе ярсыну алдында тора иде.

— Сез — мөдир, коллективны сез житәклисез...

— Алмаз Әхәтович бәлки үз кандидатурасын Луиза Хәмитовна белән алыштырырга мөмкин дип саныйдыр?

— Нигә, Луиза Хәмитовнага йөкләнгән проблема әлегә юк кебек. Аңа бер ел соң тотынса да мөмкиндер. Ялгышмасам, ординатура срогы да бетеп килә бугай.

— Юк, мөмкин түгел. Кафедра мөдире тәкъдиме буенча, ул да яңа ысулны үзләштерәчәк. Аннан соң Зәйнәп Вахитовна Луиза Хәмитовнаны аспирантурага алырга ният кыла. Без сезне борчуга кадәр барысын да бергәләп уйлаштык.

Бүлек мөдире сүзне алай ук озынга сузарга җыенмады. Хәзер үзеннән җитәкче таләпчәнлеге белән чигенүсез генә эш итү сорала дип уйлый иде ул.

— Сез, Алмаз Әхәтович, үз кыйблагызга каерасыз. Газетча димәгез, җәмгыять интереслары бар бит әле... Мин тагы сезне чакырып маташам. Уртага салып сөйләшик диюем, янәсе. Югарыдан кушалар икән, буйсынмаска беребезнең дә хакы юк. — Роберт кызып китте, ләкин чамаңы югалтмаска кирәген күңеленә киртләп куйган, күрәсең.

— Буйсыну бар, аңлыйм анысын. Ләкин пешка була алмыйм,— Алмаз бил бирмәсен тагын искәреп куйды.

Сүз көрәштерү икесен дә ярсытты, үртәде, үчектерде генә. Бүлек мөдире янында үзен кая куярга белмәс дәрәҗәдә ачулы чыкты Алмаз. «Аңлы рәвештә миңа аяк чала. Димәк, Луиза аспирантурага керәчәк, аның өчен тема да әзер. Ул да Алмаз күтәргән проблема белән шөгыльләнәчәк». Алмаз бүлек мөдиренең тел төбендә ни ятканын чамалады. Ә Зәйнәп Вахитовна? Нигә шеф аспирантура хакында аңа бернәрсә дә әйтми? Нигә Алмазга да аспирантура юлын сайламаска? Алмаз әлеге сорауларга җавап таба алмады, бары күңелсез нәтиҗәгә генә килде: «Күрәсең, Зәйнәп Вахитовнага да Луиза кирәктер». Шул чак аның Наилә белән сөйләшәсе, барысын да уртаклашасы килде.

Алар дежур врачның бушап калган бүлмәсенә керделәр.

— Роберт Салихович травматологиягә күчеп торырга куша. Әмер бирә диярлек. Министрлыктан килгән кәгазьне сылтау итеп ала,— диде ул.

— Министрлык сине атап сораганмы?

— Анысын Роберт Салихович белә. Миннән котылуны ул кулай саный, күрәсең.

— Ә Зәйнәп Вахитовна ничек уйлый икән? — Гадәттә сабыр холыклы, йомшак тавышлы Наилә хәзер аеруча борчылып сорады.

— Мин бит кафедра кешесе түгел, бүлек работнигы.

— Роберт Салихович аның белән килешми эшләмәс.

Алар бераз сүзсез утырдылар. Тынлыкны Наилә бозды. Аның башлап ни дә булса әйтүен Алмаз да көткән иде.

— Нигә нәкъ мине сине?

— Аңа да кирәкмимдер...

Наилә үзенең зәңгәр күзләрен иреннә төбәде. Гаҗәпләнүдән зур ачылган бу күзләрдә бик күп сорау чагыла иде.

— Алмаз, нигә шулай дисең әле? Зәйнәп Вахитовна сиңа карата бик ихтирамлы бит.

— Шулай да аспирантурага Луиза Хәмитовнаны ала ди.

Наилә өчен болар чынлап та иске авыздан яңа сүз булып яңгырады. Тик ул сабыр булырга, болай да кәефе кырылган ирен тынычландырырга омтылды.

— Син аспирантура хакында беркайчан да уйламаган идең ич, Алмаз. Аннан соң аспирантура сиңа нәрсәгә? Диссертация өчен материалың шактый, кандидатлык минимумын, имтиханнарны гына бирәсең калып бара. Минемчә, Луиза Хәмитовнага көнчелек кылу дөрес булмас.

— Юк ла, Луиза булдыклы доктор. Аннан күпне өмет итәргә була. Аның үзенә сиздермәстән, Роберт Салиховичның Луизаны миңа каршы куярга җыенуын гына аңламыйм.

— Кафедра мөдиренә кер, парторг белән киңәш. Инде алар да булышмасалар....

— Алар белән сөйләшү нәрсәне дә булса үзгәртер дисеңме? — Әлеге сорауны Алмаз текәлеп караган килеш бирде.

— Шулай да ятып калганчы...

Кафедра мөдирен дә, партогны да берьюлы очратуына ул сөенеп куйды, аның эченә җылы керде. Тик кыяфәте бик йомыкый иде. Зәйнәп Вахитовна да, Галия Рифкатовна да аны игътибар белән тыңладылар. Әмма, сизелеп тора, алар Алмаз мәсьәләсе белән таныш, аңа ярдәм итәргә ашыкмыйлар. Шул ук вакытта битараф та түгелләр шикелле иде.

— Әйе, Роберт Салихович әле яңа гына бу хакта безне таныштырды,— диде Зәйнәп Вахитовна. Күренеп тора, аның да кәефе ал да гөл түгел. Соң, булса ни?! Кеше гел елмаеп кына яшимени? Менә бераздан Зәйнәп Вахитовнаның йөзе ачыла төште.

— Алмаз Әхәтович, бездән, өлкәннәрдән, яшьләр фикер көтә, ярдәм сорый. Без андый ярдәмне кичектерми күрсәтергә тиешбез. Роберт

Салихович та безгә мөрәҗәгать итте. Җитәкче булса да, тәҗрибәсе аз әле аның. Кай ара бик теләп, кайчак үзен көчләп дигәндәй, ул безнең киңәшне тота. Алай да бу «мәҗбүр»нең чиге булырга тиеш. «Мәҗбүр» иттерү озак дәвам итсә, яшь җитәкче үзендә нинди мөстәкыйльлек тәрбияләр?

— Менә мин аның белән килешә алмыйм, Зәйнәп Вахитовна.

— Аңлыйм. Анысы сезнең эш. Әмма сабыр төбе сары алтын дип тикмәгә генә әйтмиләрдер.

— Бераз искермәдеме икән ул әйтем? Хаклыгыңны белә торып, тел тешләп яшәргә өндәү түгелме ул?

— Дөрес, бүлек мөдиренең холкында да үзсүзлелек сыйфатлары юк түгел, әмма конкрет бу очракта ул үз таләбен куярга хаклы. Бәлки безгә сезнең белән башка мөмкинлекләр эзләп карарга кирәктер. Травматология клиникасына китеп торган очракта да эшегезне туктатмаслык итеп булмасмы?..

Кафедра мөдиренең сүзләрен парторг та баш селкеп, җөпләп торды. Күрәсең, Алмаз мәсьәләсен алар тикшерергә өлгергәннәр иде.

Робертка ачу һәм рәнҗү белән тулы иде Алмазның күңеле. Шуңа да кафедра мөдире һәм парторг үгете белән генә тынычлану кая?! Җитмәсә, аларның ниятләре дә аның файдасына түгел, киресенчә, яңа конфликт туура сәбәп кенә булып күренде. Хаксызлыкны тоеп рәнҗегән күңеленә әлеге сөйләшү сизелерлек дәва була алмады.

## 8

Базык гәүдәле, чәчләренә, калын кашларына чал йөгергән, яше алтмыш ягындагы министр урынбасары Алмазны ачык чырай белән каршылады. Гүя яшь врач аның күптәнге танышы иде. Институтны тәмамлап эшләү дәверендә әлеге кешенең алар клиникасына килгәне, ә Алмазның министрлыкка аяк басканы юк иде. Алмаз аңа текәлеп карады, әйтерсең озак елларга хәтерләп калырга тели. Аның тышкы кыяфәте чыннан да Алмаз күптән белгән кешене хәтерләткәндәй тоелды.

— Я, коллега, ни йомыш? Тыңлыйм сезне! — диде урынбасар. Аның тавышы да таныш кебек иде. Алмаз янә аңа текәлде, ни дә булса әйтергә белми сүзсез торды. Һәм ихтыярсыздан: «Карасана, Дәүләт Закировичка шул кадәр охшаган булса да булыр икән», — дип уйлады.

— Мин сезгә үзем өчен мөһим булган бер мәсьәлә белән килгән идем.

— Хуш, сөйләгез!

Кызганычка каршы, Алмаз тиз генә ачылып китә алмады. Бу җитәкче кешенең мәрхүм профессорга охшамавы аның фикерен чуалта язган иде.

— Гафу итегез, гадәти булмаган бер сорау бирер идем. Сез мәрхүм профессор Дәүләт Закировичка бик тә охшагансыз. Әллә аның туганы буласызмы?

— Әйе, Дәүләт ага минем бертуган абыем. Ә сез аның шәкерте, димәк.... Я, алайса, таныш булыйк.

— Дәүләт Закирович — минем остазым. Шәһәрнең колак-тамак-борын клиникасыннан, Алмаз Сафин булам.

— Шулаймыни? Әйе, сезнең хакта ишеткәнем бар. — Ул яшь хирургны зур игътибар белән тыңларга әзер иде. — Галия Рифкатовна биредә булды. Дәвалауда яңа ысул үзләштерәсез икән. Бик әйбәт. Инде килеп, бүлек мөдирегез, Роберт Салихович бит әле.

Алмаз хөрмәтле профессорының энесен күрүдән туган тәэсир белән тулган иде. Охшаса да охшар икән! Нәкъ абыйсы. Агасыныкы-

дай калын кашлар, мөлдерәп торган соры күзләр, киң маңгаенда еллар сызган сырлар. Алмазның бу өлкән кешегә бик үз итеп эндәшәсе килде. Аны ул әллә кайчан белә, холкы да, башкаларга мөнәсәбәте дә аның өчен инде бик таныш кебек иде.

— Таһир Закирович, коллективта аңлашылмаучылык килеп чыкты. Миңе кирәгенчә аңлап җиткермәүләр бар... Роберт Салихович белән килешеп булмый.

Боларны сөйләгәндә Алмазның күзләрендә хафалану билгеләре чагылды, күңел китеклеге сизелде. Юк, сукранып-сыктап рәхим теләнми. Малай чактан авырлыкларны кичерергә күнеккән кешегә мәлҗерәп калу, гомумән ят нәрсә булса да, хөрмәтле профессорның энесе Таһир Закирович алдында ничектер йомшап китте. Нервлары туарыла язды.

— Мәгълүм бит, приказ тикшереп тормый гына үтәлергә тиешле очракта да, солдаттан да аңлы фикерләү сорала. Врачтан бигрәк тә...— дип, Таһир ага Алмазның фикеренә теләктәшлек сиздерде. Ул соры күзләрен тулырак ача төште, сынаулы итеп Алмазга карады.

— Үзәк журналда үз методыбызны язып чыккач, безнең ысул белән күп кенә галимнәр кызыксына башлады. Хатлар килә. Күпләр операцияне бездә ясатырга телиләр. Болар безнең файдага сөйли дип беләм. Яңа ысулны үзләштерә башлавыбыз тыштан гына иртәрәк кебек. Тормыш, практика үзе ашыктыра. Тик без дигәнчә генә түгел шул... Роберт Салихович турында гайбәт җыеп килү түгел.

— Без алай уйламыйбыз да.— Таһир ага хирургның хәлен җиңеләйтергә, тамагына килеп бөялгән төенне йомшартырга ашыкты, күрәсең. Аеруча җылы итеп елмаеп куйды.

— Бер нәрсә гаҗәпсендерә: сезнең таләпкә тотты да минем кандидатурамны күрсәтте.— Алмаз ара-тирә сүзләреннән тукталып калды, аңгәмәдәшенең аны ничек тыңлавына игътибар итте. Ә инде Таһир аганың игътибарлы карашы белән очрашкач, тынычлана төшкәндәй булды.— Башка вакыт булса бер хәл... Операциянең мөһим өлешен, тукыма күчерүне төгәлләргә кирәк. Шуны гына эшләп өлгергән булсак та ярар иде.

Мәсьәлә ачыкланды министр урынбасарына. Хәзер үз позициясен төшендерү кирәк иде.

— Роберт Салиховичны хаксыз дисезме?— Бая гына теләктәшлек сиздереп утырган Таһир ага кырт кистереп сорады. Бу хәл Алмазны сагайта калды; өлкәннәрдән монысы да ярдәм кулы сузарга җыенмый, ахрысы. Аның шулай баш ватулары тикмәгә генә микәнни?

— Башкача уйларга чара юк ич, Таһир Закирович.— Алмазда югалып калмас көч бар икән әле. Сүзләре калтыравыклы ишетелсә дә, үз фикерендә калуын ачык белдерде.

— Анда Зәйнәп Вахитовна белән Галия Рифкатовна да бар бит әле. Кафедра җитәкчеләре булып саналсалар да, бүлектә аларның роле зур,— диде Таһир ага.— Сезнең мәсьәләгә килгәндә, минемчә, эшегезне дәвам иттерергә кирәк. Шулай да мине дөрес аңлагыз, травматологиягә күчегез. Тәкъдимемә кәефегез кырылмасын. Эшегезне дәвам иттерер өчен вакыт калдырырга тырышырбыз. Моны минем вәгъдәм итеп кабул итә аласыз. Беләм, икегә бүленү җиңел булмас. Әмма нишләмәк кирәк.

Алмазның йөзенә нур йөгерде, сулышы иркенәя төшкәндәй булды. Рухына җылы өрер кеше бар икән ләбаса!

— Авырлыкны җиңү безнең өстә, Таһир Закирович! Тик беркадәр шартлар, ярдәм генә булсын...

— Борчылмагыз, нык булыгыз, барысы да җайга салыныр. Киләсе елга Ленинградтан ординатура тәмамлаган белгечләребез кайтып

житәчәк. Аннары сезне төп эшегездә генә калдырырбыз. Бу кадәресен дә минем вәгъдәм итеп санагыз...

Күмере сүнмәгән учакны яңадан кабызу әллә ни кыен булмаган кебек, хәерлене өмет иткән күңелгә дәрт өстәргә дә күп кирәкми икән. Җылы, ягымлы сүз җан азыгы булды да куйды. Яхшылыкны зурга да, кечкенәгә бүлеп ялгышалар кебек. Яхшылык яхшылык инде ул... Таһир Закирович яныннан чыккач та Алмаз үзендә рухи җиңеллек сизде. «Травматологиягә күчкәч тә бер-ике ай байтак нәрсәгә өйрәнергә туры киләчәк. Бүлеккә аннары гына йөри башлармын. Таһир ага әйткәнчә, Роберт белән бәхәсне куертмаска кирәк», дип уйлады ул. Тик бүлеккә кайтып кергәч кенә аны бер яман уй биләмәсме? Министрлыкка барганы өчен Алмаз үзен гаепле саный башлады. Дөрес, Таһир Закирович аның килүен, сөйләгәннәрен гаепкә алмады булса кирәк, танышуларына да канәгать күренде кебек. Зәйнәп Вахитовна гына аның бу адымына ничек карар? Соң бит аның бүтән чарасы юк иде. Бу минутта ул Робертны да күз алдына китерде, мәгәр бүлек мөдире алдында үзен гаепле саный алмады. «Әгәр ул мәҗбүр итмәсә, министрлык бусагасын атлар идемме?»

Кыскасы, Алмаз җиде кат үлчәгәннән соң бер кат кисәргә булды — травматологиягә китәргә ризалык бирергә дигән карарга килде. Шул хактагы теләген ишеттерү өчен мөдир кабинетына юнәлде.

Ул килеп кергәндә, Роберт өстәл өстендәге кәгазьләре белән мәшгуль иде. Алмазны күргәч тә мөдир, аңа урындык күрсәтеп, ым какты. Кәгазьләре белән эшен бетергәндәй иткәч, өстәл яныннан ук чыгып, Алмаз янына килеп утырды. Тавышы йомшарган, килешүчәнлек үзен сиздерә иде. Әллә соң Алмазга гына шулай тоелдымы?

— Бу мәшәкатьле дөньяда дәгъвәләшәбез, бер-беребезгә каршы төшәбез. Конфликтлар чыгарабыз, хәтерләр калган чаклар да була,— диде ул.— Күрәсең, тормыш үзе шундый тынгысыз нәрсәдер...

Алмаз Робертны аңламады. Хәтта, турысын әйткәндә, тагын да сагая, шикләнә калды. Тозак түгелме икән? Мөдир исә уйланып торды. Ул фикерен туплый, әңгәмәгә әзерләнә иде.

— Беләсезме, Алмаз Әхәтович, иртәнге якта миңа приемга кем керде? — Сорау биргәч тә, коңгырт күзләрен Алмазга төбәде. — Җырчы Ләлә Нуриева!..

— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

— Әйтергә теләгәнем хәвефле хәбәр. Җырчыбыз тавышын югалту алдында. Фаҗига яный, аңлыйсыздыр. Аңа операция кирәк.

— Мондый мәсьәләне мөдир хәл итә.

— Нигә алай дисез? Ягез, чыгымчыланмыйча гына сөйләшик әле. Алмаз Әхәтович, хирург буларак бәлки ... сез?

— Атна башыннан мин травматологиягә күчәсе кеше. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Министрлыкта да миңа шулай диделәр.

— Димәк, сез анда да булдыгыз?

— Булдым, шуны сезгә әйтергә дип керүем. Минем китүем ике арабызда чи төен калдырмасын...

— Алаймы?! — Бу сүзләр Роберт күңеленә хуш килде, күрәсең, чырае яктырып китте.— Без уртак фикер табарга тиешбез.

— Килешүемне уртак фикергә килү дип исәпли аласыз,— диде Алмаз.

— Димәк, Ләлә Нуриева хакында да бергәләп уйлашабыз.

— Сез нәрсә, Роберт Салихович? Бала кебек.. Мине курчак дип саныйсыз мәллә?

— Мин сезне киңәшкә чакырырга җыенган идем. — Ул Алмазга сынаулы караш ташлады. Сизелеп тора, психик атака ясавы.— Сез кайчандыр бик якын танышлар да булгансыз бит. Алай гына микән?.. Яшьлегебездән качу беребезгә дә килешми.

Яшьлектә калган сернең шулай көтмәгәндә ачыклануыннанмы, әллә инде Робертның тагын аны үз принцибына буйсындыру өчен әрсезләнүеннәнме Алмаз тетрәп китте.

— Роберт Салихович, сезнең буйдаклыгыгызда берәүнең дә эше булмаган кебек, минем үткәнемә дә һичкем тыгыла алмый...

Алмазның йөзе чытылды. Моны күреп торган Роберт сүреләә төште, хәзер ул ачулы да, таләпчән дә түгел иде.

— Ә ул сезгә ышана тагын...— диде мөдир, утырган җиреннән торып, һәм кабинеты буйлап йөренә башлады. — Ул чын күңелдән өмет баглый. Сез мине дөрес төшенергә тырышыгыз әле, Алмаз Әхәтович. Аннары мөнәсәбәтләрне гел кирегә генә кору кайсыбызга файда китерер икән?..

— Миңа пешка булырга, алайса?!

— Сез әллә бер дә компромисс ясый алмассызмы? Реаль тормыш таләп итсә дә.— Робертның тавышы кечелекле яңгырады. Әмер бирер кеше түгел иде ул хәзер. Шома таралган озынча саргылт чәчләрен еш-еш бармаклары белән төзәткәләп куюы аның чынлап та дулкынлануын күрсәтә иде. Мәгәр үзе ничек тә Алмаз күңеленә ачкыч яратырга омтылуын куймады:

— Аңласагыз иде?! — Ул тагын коллегасының янәшәсенә килеп утырды.— Ләлә Нуриева үзенең сәнгате, җырлавы белән халыкка билгеле шәхес. Аңа ясалган операция бары тавышы камил саклап калынган очракта гына уңышлы дип санала ала. Бу искиткеч җаваплы. Операцияне мин үзем дә ясар идем. Такташ әйткәндәй, «ләкин» бар шул. Операциянең нәтиҗәсен гарантияләп булмый. Шулай да аны сез ясасагыз, бәлки...

— Миңа барысы да ачык.

Алмаз хушлашып ишеккә атлады. Ә Роберт һаман да сөйли, үтенеченә тулы җавап алырга тели иде.

— Ләлә Нуриева иртәгә тагын килә... Үтенәм сездән, кире какмагыз, сүз бирегез үзенә. Таләп итмим, шулай да үтенәм. Ул бары сезгә генә ышана...

## 9

Көн кичкә авышты. Җир өстенә суык төште. Лимон сарысы йоккан яфраклар салкын җилдә арлы-бирле оча, тукталырга җай таба алмый аптырыйлар. Алмаз күңелендә Роберт белән сөйләшүдән туган ярсыну янәшәсендә Ләлә Нуриевага ничек тә ярдәм итү хисе калыкты. Җырчының рухи халәтен аңларга кирәк иде. Яшьлек дустыңа да ярдәм кулы сузмасаң... Алмаз әлегә кадәр аны искә төшерергә дә батырчылык итми. Хәзер Ләләгә аның булышлыгы, дөресрәге, аның хирург кулы кирәк. Шулай гына микән? Бүлектә аңардан башка да тәҗрибәле врачлар бар ич. Әйтик, Роберт Салихович. Үзе хакында бүлек мөдире әйтте инде. Ә килешмәгән хәлдә? Ничек инде? Ул иртәгә Ләләгә вәгъдә бирерме, операцияне үзем ясармын дип аны ышандырырмы? Алмаз алай да, болай да уйлап карады. Тик җавапны күңеленә килгән бер сорау: «Ничек карышасың?» дигән сорау таптырды. Юк, юк! Шушы җавап икеләнүләрне читкә этәрде. Кинәт аңа җиңел булып китте, Ләлә белән дуслыкта узган еллары, беренче танышу көннәре татлы истәлекләр булып күңелендә кузгалды.

...Алмаз медицина институтының дәвалау факультетында, Ләлә консерваториянең вокал бүлегендә укый иде. Икесенең дә яңа гына урта мәктәпне тәмамлап, студент булу бәхетенә ирешкән чаклары. Алар беренче курс студентларына багышланган опера һәм балет театрында булган кичәдә таныштылар. Шуннан сөенечле дә, көенечле

дә үткән вуз тормышының һәр көне хакында бер-берenә сөйли тордылар. Икесе дә үзләренең Казанда кунак кына икәнлекләрен тоялар иде; шәһәр белән бергәләп таныштылар, кино-театрларга икәү йөрделәр. Ләлә Алмазның үзе сайлаган һөнәрен яратуын күреп сөенсә, Алмаз аның җырчы булу теләген чын күңелдән хуп күрә иде. Ә очрашуларның берсендә, хискә бирелеп, Ләлә үзенең озын керфекле зур кара күзләрен аңа төбәде дә:

— Минем яратып башкара торган җырым бар, — диде һәм, җырлыйммы дип, Алмаздан рухландыргыч сүз көтте.

— Җырла, иркәм! — дип пышылдады аңа Алмаз. Әмма Ләлә җырламады, нурлар сирпеп елмайды да алга атлады. Алмаз әлеге җыр хакында түземсезләнеп сораша башлады:

— Ул нинди җыр, Ләлә? Ничек атала?

Ләлә янә көлде, иркәләнеп баруын дәвам итте. Аннары сабырлана төште дә:

— Җырның исеме? Син әйткәнчә, «Җырла, иркәм!» Ләкин ул җырның сүзләре дә, музыкасы да язылмаган әле,— диде.

— Ничек инде, дөньяда юк җырга исем куеп була димени?

— Бөтенләй үк юк түгел. Бар. Музыкасы да, сүзләре дә колагыма ишетелә. Тик азаккача ачыклап кына җиткерә алмыйм.

— Нәрсә турында соң ул?

— Улмы? Ул... безнең мәхәббәтебез турында. Ике йөрәкнең кайнар хисләрен бер-беренә бәян итәрлек җыр тиз генә табылмады... Ә беренче мәхәббәт хакындагы ул җыр туганда алар очрашмыйлар иде инде. Әмма Ләлә үзенең концертларында шул җырны башкармый калмады. Гомумән, аларның мәхәббәте турындагы җыр Ләлә өчен иҗади ачышка, тыңлаучыларның күңелен әсир итәр моңга әверелде.

Алмаз бер сөенеп, бер көенеп хәтерләде ул елларны. Ә алар арасын өзгән сәбәп хакында уйлыйсы да килмәде. Тик уйлар аның ихтыярына буйсынмадылар.

Югары курста укый барган саен вакытның кадерен үзен ныграк сиздерә. Ләлә дә, Алмаз да — тырыш студентлар. Вакыт җитмәвен искәрүләре бер-берсенең мәшәкатьләрен аңлаудан булды. Шулай да Алмаз вакытны санаучанрак иде, ахры. Ләләнең моңа һич тә хәтере калмый, ул Алмазның ничек тырышуын, китапларга ябышып ятуын яхшы белә. Ләлә егетнең вакытын саклау өчен Алмаз яши торган тулай торакка үзе килә башлады. Ә кайчакта, консерватория студентлары белән авылларга концерт куярга чыккан арада, Ләлә көн саен аңа хат яза торган иде. Еш кына авылдан язган хатларын Казанга кайтып, Алмаз бүлмәсендә утырганда үзе ала иде. Әмма хатларны Алмаз үзе генә калгач укырга куша. Аларның кайсысы күбрәк сагына иде икән? Күрешми торып очрашкач та Ләлә аеруча бер сусау белән күргән-белгәннәрен, җырлаган җырларын, уңышларын шатланып сөйли, күрешә алмый үткән көннәре өчен дә яратасы, иркәләнәсе килә. Алмаз аның кебек үк ялкынланып ашкынмаса да, Ләлә аны аңлый, аның мәхәббәтен тоя килде. Алмаз аның иңенә тикле калдырып киселгән чәчләреннән иркәләгәндә, Ләлә бөтен дөньясын онытып, татлы хыял эчендә кала, мәңге шулай назланып яшәү теләгендә яна иде.

Әмма тора-бара Алмаз күңелендә шикләр туды. Акрынлап, берсе артистлыкка, икенчесе врачлыкка ирешә барган саен, әлеге шик Алмазга үзен ныграк сиздерде. Мәхәббәткә үч иткәндәй, бу хакта еш уйланды. Сәнгать кешесен, җырчыны, янында тотып торып булмас шул, дип кабатлаган саен аның күңеленә яшерен шом көчлерәк үрмәләде. Җитмәсә, башкалардан да: «Артист халкы белән гаилә кору — янган утка керү түгелме, Алмаз? Җырчы хатының илнең бер читендә йөрер, ә син каңгырап больница палатасында утырырсың. Ярый ла, мәхәббәткә тугры булып кала алса», кебек әллә нинди сүзләр өстәлде.

Байтак ара ул Ләләгә бу хакта әйтергә кыймады, теле бармады. Мәгәр ахырда ничек тә сиздереп карарга булды. Ай, җан газабы иде сөйләшүгә әзерләнүе: аңы таралды, дәрестә укыганнар башына кермәде.

Ул кичне алар бик озак йөрделәр. Казан елгасы буйлап та, парк аша да үттеләр. Ләлә шат иде, хыялга чумып, ашкынып-талпынып сөйләде. Алмаз да аны бирелеп тыңларга тырыша иде.

— Тормыш гел шулай шатлыктан гына гыйбарәт булса икән...— диде Алмаз сүлпән генә.

— Ә нигә? Без бергә булганда, дөнья гел шатлык кына булачак,— диде Ләлә.

— Белмим шул...

— Әллә икеләнәсеңме?

— Әйе...

Алмаз уендагын, мәхәббәткә үзенең карашын мөмкин кадәр сабырлык белән сөйләп аңлатты. Ләлә әүвәле, аның сөйләгәннәрен чынга алмагандай, шаяртып тыңлады. Ә аннары бераз сагаеп уйланды да, үзен тыя алмыйча, еларга кереште. Алай да китеп бармады, ике кулын Алмаз иңбашына куеп, башын күкрәгенә салды, кайнар яшен түгә-түгә сулкылдады. Әйтерсең лә аның йөрәгенең тибешен тыңларга, егет күңелендәге тойгыларның чынын ишетергә тели иде. Алмаз сүзләренә ышанып җитмәүдән иде бу. Ул аның калтыранган иңбашына куллары белән орынды, кызны тынычландырырга теләде. Ул гына да түгел, Алмаз: «Шаярдым гына бит»,— дип әйтеп ташлардай булды. Тик ул аны әйтмәде, һәм шул әйтми калдыра алуы өчен сөенә кебек иде.

10

Ләлә Нуриевага ике операцияне дә Алмаз үзе ясады. Шуңа күрә, травматологиягә күчүе бөтенләйгә китү булып чыкмады. Операциядән соң авыруны дәвалау гына да ике айдан артыкка сузылды.

Хәзер пациентның хәле әйбәтләнеп килә, зарланмый. Ул палатаның дәвалау врачы Наилә. Пациент белән врач дуслар дип, авыз тутырып әйтергә мөмкин. Ә бүген иртән Наилә аның тумбочкасына гладиолуслар куйды.

— Сәнгатегез алдында баш иючеләрдән. Тизрәк савыгуыгызны телиләр, — дип елмайды врач.

Больницада шундый чәчәкләрне кабул итеп алу рәхәт тә, сөенеч тә иде Ләләгә. Айлар буе ятканда аны кем шулай олылап искә төшерде икән? Кем аның рухына канат куярга теләде икән? Концертлардан соң аңа чәчәк бәйләмнәрен еш бүләк итәләр иде. Ә менә бүген букет китерүләре гаҗәп! Нигә соң ул нәкъ менә бүген? Наилә Рәхимовнаның да күңеле күтәренке күренә. Әйтерсең лә Ләлә Нуриеваны да, аны дәвалаучы врач Наилә Рәхимовнаны да бүген бер үк шатлык биләгән.

Алмазның да эше хәзер иҗат дәрәҗәсенә күтәрелде. Башка больницага күчеп тә, бирегә шундый катлаулы операциягә «җигелә» алуы белән ул тагын бер кат хөрмәт казанды. Ни әйтсәң дә, бу операциягә бөтенләй катнашмаска да мөмкин иде аңа. Нәтиҗәдә, Алмазның травматологиягә күчүе бөтенләй башкача килеп чыкты: хәзер ике йөкне бер итеп тарта һәм аңа йөкнең авырлыгы хакында уйланырга вакыт та калмый.

Кафедра утырышы көннең беренче яртысында буласын алдан белеп, Алмаз төшкәчә бүлектә калды. Анда аның пациенты Ләлә Нуриеваның хәлен тикшерү дә булачак. Кичә ул аны үзе күрә алмады, вакыт тимәде, хәлен Наиләдән генә сорашып белгән иде. Шуңа да, бүген бүлеккә килгәч тә, Ләлә яткан палатага кереп чыгарга ашыкты. Күңеле тыныч түгел иде. Утырыш хакында авыруның үзенә дә әйтер-

гә булды... Таһир Закирович та катнашачак дигәннәр иде түгелме соң?

Ләлә яңа гына иртәнге аштан кайткан иде. Кәефе әйбәт күренә. Йөзендә көлемсерәү. Куе кара чәчләре маңгаена, чигәләренә алкалар ясап, бөдрәләнеп төшкәннәр дә, алсу йөзен чәчәкләр белән урагандай иткәннәр. Алмаз палатадагы барлык авырулар белән исәнләште, һәркайсына баш какты. Ул арада Ләлә Нуриева җыештырып куйган койкасының ары башынарак китеп утырды, хирургның нидер әйтүен көтте. Алмаз исә үзе дә аның белән сөйләшергә ашыга иде. Сүзне сулы вазадагы гладиолуслардан башлады:

— Бүген генә өзгәннәр, ахры,— диде ул һәм әлеге чәчәкләргә чак кына кагылып алды.

— Тырышканнар, рәхмәт инде,— диде Ләлә.

Алмаз пациентына сынап карады. Хәле ничек икән?

— Кәефегез әйбәт күренә, Ләлә. Чәчәкләр тәэсиреннән генә түгелдер бит?

— Терелеп киләм кебек, Алмаз Әхәтович.

— Без дә һичшиксез терeләчәксез дип ышанабыз. Шуңа күрә дә сезне бүген кафедра утырышына чакырырга булдык. Белгечләр алдында хәлегезне сөйләргә туры киләчәк.

— Анда минем булуым мәҗбүриме?

— Ничек дип әйтим... Сезгә ясалган операция һәм терапевтик дәвалау ысулы әлегә яңа санала. Шул ысулны, аның методикасын үзләштерүче буларак, миңа аның хакында күп сөйләргә туры килде. Инде пациентны да тыңлап карыйсы иде, диләр коллегалар.

— Алай икән...— Ләлә Алмазга нидер әйтмәкче иде дә тукталып калды.

— Тартынмагыз. Җырларга иртәрәк икәнен беләбез, — дип юатты Алмаз.

— Ярый, аңлашыла.— Ләлә ризалык бирде.— Минем өчен борчылмагыз.

Дәваланучының күңелгә ятышлы сүзләреннән дә кыйммәтлерәк нәрсә бар?! Алмаз инде үз пациентын теләсә нинди дәрәҗәле комиссия алдында да күрсәтеп булуына ышанды. Шушы ышану аны канатландырды, күңелендәге шик-шөбһәне юкка чыгарды. Кәефе күтәрелүгә канәгатьләнеп, Ләләгә сорауларны артык бирмәде. Чынында пациент та бу мәшәкатьләрнең мәгънәсен аңлый. Бүген аның савыгуы ачыклану белән бергә, кафедра галимнәре алдында хирургның хезмәте дә бәяләнәчәк. Менә шуны тою да пациентны беркадәр борчыды. Сүзләр үлчәнеп, уйланып сөйләнде. Ахыр чиктә уйлаганнарын әйтеп бетерә алмыйча аерылыштылар.

Алмаз хатынын коридорда очратты. Наилә иренең тамак кырып килүен ишетеп алгач та, каршысына килде.

— Я, Ләләнең хәле ничек, әйбәтме?

Алмаз хатынын кочып алудан чак кына тыелып калды, бары иңбашларыннан тотып үзенә кысу белән генә чикләнде. Наиләсе дә аңа елышты.

— Ләлә инде терелеп бара. Кемдер чәчәкләр дә бүләк иткән үзенә.

— Әйе, Ләләнең кәефе әйбәт,— дип куйды хатыны. Әлеге чәчәкләрне бүләк итүче үзе булуын чак кына әйтми калды. Ярый әле, ире ашыга иде. Аның утырышка кадәр бүлек мөдирен күрәсе бар. Ә чәчәкләр Ләләне генә сөендермичә, Алмазның да күңелен күтәреп җибәргән икән, шуннан артыгы тагын нигә?!

Бүлек мөдире Алмазны җылы каршылады. Кафедра утырышында Ләлә Нуриева буласын хуплады.

— Минемчә, бары да әйбәт булачак, Алмаз Әхәтович. Без үз бурычыбызны уңышлы үтәп киләбез, — диде Роберт. Аның бу сүзләреннән дусларча теләктәшлек сизелде.

Әлфия дә палатага кереп чыкты. Зифадан тагын хат килгән икән. Баланың бу хаты да кызык. Әнисе язса да, сүзләр баланыкы. Аларда Зифа беркатлылыгы, үткенлеге сизелә.

«...Минем, Әлфия апам, сезнең кебек врач буласым килә. Ләкин сез нигәдер операция ясамыйсыз. Ә минә Алмаз абый оста ясый. Син дә шундый булсаң иде. Ләлә Нуриева апа җырлавын тыңларга яратам. Үземнең дә шулай җырлыйсым килә...»

Үзенә билгеле булмаган баланың аның хакында язуына Ләлә бер мәлгә гаҗәпсенеп тә куйды. Сабыйның беркатлылыгы, әчкерсезлеге диген!... Җитмәсә, исеме Алмаз исеме белән бергә!

Зәйнәп Вахитовна өчен бүгенге утырыш аерата җаваплы иде. Аның шәкерте Алмазның хезмәтенә бәя биреләчәк. Дәвалау практикасына кертелгән яңа ысулда аның фикере дә бар. Ләлә Нуриеваның хәлен тикшергәндә сораулар туа икән, аларга җавапны да алар бергәләп бирергә тиешләр. Аның үзенә дә әзер торырга кирәк. Дөрес, ул Алмазга ышана. Башкарган эшенең бөтен нечкәлеген белә яшь хирург. Тик күңеле бөтенләй үк тыныч түгел. Аның чыгышы да кичергесез.

— Хирургның хезмәте коллегалары биргән бәя һәм пациентның фикере белән ачыкланырга тиеш.— Кафедра мөдире аеруча бер сөйкемлелек белән Ләлә Нуриевага карады.— Без Алмаз Әхәтовичны күккә чөеп мактамасак та, ул ирешкәннәрнең чын мәгънәсен ачык күрергә тиешбез...

Зәйнәп Вахитовнаның сүзләреннән Ләлә Нуриева тәэсирләнеп куйды. Ул аңа олылап та, сокланып та карады. Кафедра мөдире кабаланмыйча, катлаулы һәм бәхәсле булып тоелган мәсьәләне гади итеп сөйли. Ә инде пациент буларак, доцент үзе аңа сүз биргәч, ул дулкынлануын тиз җиңде. Ничектер бирелгәннәрнең барысы да аңа күптән таныш, үз булып күренде. Шуңа күрә дә операциядән соң үзен ничек сизүен сөйләү аңа әллә ни кыен булмады.

— Дөресен әйткәндә, беренче операциядән соң хәлемнең әйбәтләнүенә ышанычым алай ук нык түгел иде. Менә хәзер, сизелеп тора, хәлем яхшыра бара. Авырый башлагач, миңа тавышын җуйган артистлар хакында шактый ишетергә туры килде. Аларның күбесенә медицина ярдәм итә алмавын белгәч, мине дә шундый кара язмыш көтәдер кебек иде. Хәзер сулышым иркен, авырту сизмим. Сәнгатемә кайта алачагыма ышанып яшим.— Ул үзенең чыгышында Алмаз исемен атарга, бәхетсезлектән коткаруы өчен аңа рәхмәт әйтергә дә ният кылган иде, ләкин алай эшләмәде. Нигә барысына да көн кебек ачык нәрсәне сөйләп торырга? Ул хәтта Алмазга туры карарга да кыймады. Әйтерен әйтеп, сөйләрен сөйләп палатага кайткач та, мондый тыйнаклыгы өчен үкенгәндәй булды. Мәгәр акыл тойгыларны басты, хисләрен әчкәре яшерде.

Бүгенге утырышның гади генә булмавын Ләлә дә сизенде. Алмаз тормышында да әлеге сөйләшүләрнең вакыйга икәнен ачык абайлады ул. Шуңысы сөенечле, аның хезмәтенә бирелгән бәяне үз колаклары белән ишетергә насыйп булды. Үзенә ясалган операциянең уңышлы чыгуына икеләтә сөенеп куйды. Ничектер, аларның бәхетләре дә уртак төсле иде.

Кайта-кайта гаҗәпсенгәне шул булды: кара әле, язмыш аларны тагын ни хәлдә очраштырды?!

Рәфкать Сәлахетдинов ◆ Җырла, иркәм!

Алмазның эшен һәрьяктан тикшерү соныннан, Ләлә Нуриева чыгып киткәч булырга тиеш иде. Бигрәк тә практик врачлар фикерен ишетү кирәк иде. Әмма бүлек мөдиренең чыгышын көтеп, берәү дә сөйләргә ашыкмады. Алмазның эш нәтиҗәләре Роберт өчен ачык, сорау тудырмый иде, күрәсең. Ул сүз алмады.

Әле яңа гына аспирантурага кергән Луизага сүз бирелү утырыштагыларда зур кызыксыну уятты. Аз сүзле, бары аңа атап эндәшкәндә генә сөйләшүче егерме бишләр тирәсендәге бу кызның кыяфәте матур, ул бары тик күңеле, намусы кушканны гына сөйләячәк кебек иде.

— Алмаз Әхәтовичның яңа ысулы хакында Зәйнәп Вахитовна да, Галия Рифкатовна да тулы әйттеләр. Мин үземне Алмаз Әхәтовичның өйрәнчеге дип саныйм.— Ул керфекләрен сирпеп Алмазга карап алды, чак кына елмаеп куйды.— Бүген инде Алмаз Әхәтович тәкъдим иткән проблема буенча миңа тема бирелгәч, аның ярдәменә бигрәк тә мохтаҗмын. Теманы башкарып чыгу өчен аның фикере бик кирәк булачак. Хәер, Алмаз Әхәтович игътибарлы кеше, ул беркайчан да сорауны җавапсыз калдырмый. Бергәләп уйлаша да, киңәш тә бирә белә.

Утырышның эшлекле узуы министр урынбасарында да канәгатьләнү уятты шикелле. Зәйнәп Вахитовна ахырда сүзне аңа бирде.

— Иптәшләр,— диде урынбасар, өлкәннәргә хас сабырлык белән.— Бик күркәм коллектив бит сез. Һәр чак министрлыкның күз алдында булуыгыз да тикмәгә түгел икән. Тулы җанлы тормыш, иҗади бәхәс белән яшисез. Эшегезнең нәтиҗәсен менә бүген үз күзебез белән күрдек, үз колакларыбыз белән ишеттек. Алмазны тыңлап, аның сәләтле хирург, галим булып үсеп чыгуына инандык. Ничек шатланмыйсың! Димәк, республикабызда медицина фәне яңа үргә атлый.

Аннары министр урынбасары бүлекне киңәйтү, шартларны яхшырту өчен ярдәм итәчәген әйтте. Аның сүзләре болай да куанып утырган врачлар, ассистентлар, доцентлар өчен яңа сөенеч булып яңгырады.

## 11

Алмаз соңгарып булса да Әлфиядән гафу үтенергә теләде. Туйларына бара алмавы өчен үзен гаепле санап йөри иде. Барырбыз дигән иде. Әмма булмады...

Алмаз аны кеше азрак йөргән берәр бүлмәдә очратырга теләде. Шуңа күрә дә:

— Әлфия, минем янга кер әле,— диде дә, үзе ассистент бүлмәсенә юнәлде.

Шәфкать туташы кереп утыргач, Алмаз аңа күтәрелеп карады һәм сул кулы белән маңгаен сыпыргалады. Аның йөзенә арыганлык чыккан иде.

— Әлфия, менә үзеңә истәлек бүләгем булсын...— дип, юка гына китапчык сузды.

Бу — кандидатлык диссертациясенең авторефераты иде.

— Рәхмәт, Алмаз абый! Әйбәт булган! Булдыргансыз... Карагыз әле, мин сезне ассистент итеп билгеләнүегез белән дә котламаган идем....

— Ә, мин туегыз белән... Әлфия, бара алмавым өчен зинһар гафу итә күр. Шатлыгыгызны шул чаклы уртаклашасым килгән иде. Наилә апаң аркасында башымны югалттым. Сыңар канат килеш ничек барасың.

— Сез бергә булырсыз төсле, Алмаз абый.

— Белмим, Әлфия... Наилә хәл иткән...

— Ул сезне ярата ич! — Кыз шулай диде дә тынып калды. Кайчандыр төнге дежур вакытында икәүләп сөйләшкәннәре исенә төште.

Ул чакта Алмаз: «Бер-беребезне яратабыз»,— дип әйткән иде. Күрәсең, аның болай әйтүе ялгыш булган. Алмаз үзен алдалаган. Әлфиягә болай гына әйткән. Тирәнтен уйласаң, ничек инде болай гына? Юкса, ике ара шулай тиз өзелер идемени? Ярату мәңгелек диләр ич! Әлфия шулай уйланды, үзе хөрмәт иткән Алмаз Әхәтовичның халәтен ничек тә аңларга теләде.

Алмазның да әйтер сүзе табылмый торды. Ул бераз исәнгерәгән кыяфәт белән торганнан соң, кесәсеннән конверт чыгарып шәфкать туташына сузды.

— Менә, Наиләнең җибәргән хаты. Мин аны бары сезгә генә укытам,— диде Алмаз.

Әлфия хатны укый башлады.

«Алмаз, хәерле көн!

Үзебез бергә көн күргән йорттан киткәндә мин бер юл да яза алмадым. Инде әйтер сүзләрнең сиңа ирешүен йөрәгем тели.

Алмаз, дөнья булгач бәлки күрешербез дә. Зинһар дип әйтәм, күңелеңдә ачу төене йөртмә. Үзең беләсең, син мине, мин сине рәнҗетешеп яшәмәдек. Күрәсең, бер-беребезне хөрмәт итү өчен бездә акыл да, сабырлык та җиткәндер. Шулай да, Алмаз, икебез өчен уртак бәхет — бала була алмавын ачыклаган саен, мин иң элек сине, аннары үземне бәхетсез санадым. Дөрес, кайберәүләр үзләре тудырмасалар да, чит балага ата-ана була беләләр, аңа карап юаналар, сөенәләр. Тик, үзебезнең кыргыйлыгыбыздандыр бәлки, без андый була алмадык. Кем тапкан — шул үстерсен, дигән сүз искә төшә торган иде. Янәсе, безнең кан, күкрәгеңдә безнең сулыш түгел икән, ул балага ничек ата-ана буласың ди. Бер нәрсә ачык: без икебез дә бала яратабыз. Синең Зифага булган мөнәсәбәтеңнән мин шуны күрәм.

Алмаз! Үләрдәй гашыйклар булып кавышмасак та, без кабергәчә бергә яши алыр идек. Ләкин моның өчен дә уртак бәхет — гаилә яме — бала кирәк иде. Әйе, без ата белән ана була алмадык. Белмим, бәлки минем фикер йөртүем, язган сүзләрем бары аклану булып кына тоеладыр. Тик мин башкача уйлый алмадым һәм алмам да.

Синнән киткәндә, миндә кемне дә булса эзләү уе юк иде... Кем дә булса мине көтәдер дип күңелемә дә китергәнем юк иде. Андый кеше булган икән. Яшьлектә мин аның хисләрен бөтенләй санга сукмаган идем. Яшьлектә, килер мәхәббәтеңне көтеп яшәгәндә күңел андыйларга урын бирмәгән, күрәсең. Ә тормыш менә безне яңа очраштырды... Инде ана булу теләге белән яшим.

Алмаз, зинһар, үзеңне ялгыз итә күрмә. Наилә мине ташлады дип курланма. Син көчле, намуслы. Юлларыбыз үзебезнең бәхетебезне табу өчен аерылды. Күңелең теләгәнне тап, аның белән бик-бик бәхетле бул!

Аерылышканнан соң, Ләләнең җырлавы миңа аерым бер мәгънәгә ия кебек. Син яраткан җыр бигрәк тә... Ләлә аны искиткеч матур җырлый. Моңы саф, үзәкләрне өзгеч. Син дә тыңлыйсыңдыр. Аны тыңламый мөмкинме соң?! Аның җыры, аның тавышы мәшәкатьләремне, булган борчуларымны оныттырып җибәрә. Шушы җыр киләчәккә бару юлыбызны яктырта кебек...

Хуш, Алмаз! Сиңа кыюлык, батырлык, бәхет, яңа уңышлар телим.

Наилә.»

Ярасына ничәнче кат инде тоз сибә-сибә, Алмаз Әлфиянең укып чыгуын көтте. Кичерешләре аны изә, сыта кебек иде. Тәмам исәнгерәгән, таралып калган. Ул күзләрен тутырып Әлфиягә карап алды, юату сүзе өмет итте.

Әлфия дә аның газаплануын бөтен тирәнлеге белән тоя, ләкин хәс-

рəттəн шифа булырдай сүзне каян табасың? Ул хатны конвертына салып кире бирде.

Алмазның борчулардан йончыган йөзендə саран гына елмаю чагылды. Бу бəлки күңел газабын җиңə-җиңə тапкан өметнең беренче зəгыйфь нуры булгандыр. Ул сүзне янə Əлфиягə күчерде, туйның ничек узуын, анда кемнəрнең катнашуын сорашты.

— Ниһаять, сөйгəнең белəн кавыштыгыз. Молодец, Əлфия!

— Күңел гел ышанып бетми əле,— диде Əлфия беркатлылык белəн.

— Чын ярату шулай ул. Җитмəсə, үзең биредə, ə киявең авылда.

— Институт тəмамлыйсы бар бит...

Алмаз яшь киленнең киявеннəн читтə яшəвен башка телгə алмады.

— Димəк, Луиза Хəмитовна белəн Роберт Салиховичның туегызда булуы хак? Яхшы иткəннəр!

— Үзебез дə сөендек. Мəҗлестə дə бик күңелле кешелəр икəн,— диде Əлфия.

Алар сөйлəшеп байтак утырдылар. Алмазның йөзендə шатлык чагылгандай булды. Кəефе күтəрелеп китте, ахры. Ул хатны янə күкрəк кесəсенə салып куйды да, Əлфияне озатып, кабинет ишегенə килде. Тик ишек ябылып, бүлмəдə тəмам ялгызы гына торып калгач, җəберлəнү тойгысына яңадан уралды. Аптырап, тəрəзə янына басты.

Урамда җил ыжгыра, буранлап тора. Əнə кар өермəсе тəрəзəгə килеп бəрелə дə, бермəлгə урамны күмə. Аннан тагын җир өсте ачылып куя. Тик озакка бармый, буран яңадан көчəя, янə ярсынып тəрəзəгə ябырыла. Эш сəгатьлəрен тəмамлап, инде ассистентлар да кайтып киткəннəр. Ялгызы гына калган Алмазга дөнья шыксыз иде, əйтерсең кыш суыгы, тыш ямьсезлеге менə бу бүлмəгə үтеп кергəн дə, аның тəнен генə түгел, җанын ук өшетə башлаган. Əле генə Əлфия белəн сөйлəшүдəн сызылып куйган күтəренкелек тойгылары да əллə кая китеп югалды. Суык җил, котырынган буран улавы аны торган саен сагышка батыра кебек иде. Ул тын, җанны кыса торган бүлмəдəн чыгып китəргə ашыкты. Ялгызлык белəн икəүдəн-икəү калу шомлы икəн. Берəрсен эзлəп, күңел ярасына шифа эзлəп карарга кирəктер. Əмма кемне табасың? Шундый күңелсез хəлгə дучар кешене дус-ишлəр көтмидер төсле.

Ул боегып, нурсызланып калган өенə кайтты. Монсу хуҗасының кəефен бүлмəсе дə күтəрə алмады. Кая карама — Наилəне искə төшерə торган əйберлəр... Түгəрəк өстəл уртасындагы ваза да буш. Наилə булганда анда чəчəклəр бетеп тормый иде.

Гөллəр... Лəлə Нуриева тумбочкасында да матур гөллəр тора иде. Ул хатирə Алмазның күңелен бермəлгə генə булса да җылыткандай итте. Лəкин юк... шыксыз уйларны чыбыркылап куарга да мөмкин түгел. Алмаз бүлмə уртасындагы буш өстəл янына килеп утырды. Аннары Наилə хатын күкрəк кесəсеннəн өстəлгə алып салды, лəкин ачып кабат укымады. Чөнки андагы язылганнар болай да колагында яңгырый, күңелен телгəли иде. Əмма конверттан күзен ала алмады, гүя ул хат түгел, ə Наилəнең үзе иде. Нишлəргə? Ачуланыргамы, əллə кичерергəме аны? Ташлап китүен дə, шушы хатын да исəпкə алып бер фикергə килергə кирəк иде. Чынлап та... Хаттагы сүзлəр тикмəгə генə түгел. Шулай да сүзлəр белəн генə йөрəк ярасын төзəтергə мөмкинме соң? «Хəзер юллар аерылды. Моны үзебезнең бəхетебезне табу өчен дип кабул итик». Əллə соң бу тормыш юллары гел бер кушылып, бер аерылып кына торамы икəн? Шунысы гаҗəп, теге чакта Лəлə белəн ике арасы кырт кискəндəй өзелеп киткəн иде. Хатлар язышып та аңлашып маташмадылар. Хəер, андый аңлашуларга вакыт бар идеме соң? Алар Наилə белəн туй ясап куйдылар бит. Ашыгып, əмма уртак килешеп. «Күңелең телəгəнне тап, имеш, аның

белән бик-бик бәхетле бул!» Ләләне күздә тота Наилә. Тик исемен генә атамаган... Әнә күз алдында пациенты — җырчы кыз. Чак кына елмая. Йөзендә туган яктылыкны, матурлыкны яшерергә ашыккандай аннан ераклаша, койкасының теге башына ук күчеп утыра... Алмаз ул чакта аңа алай ук текәлеп карамаган шикелле иде. Әмма каралган, күрелгән икән. Җитмәсә, Наилә дә үзенең хаты белән аның күңелен Ләләгә бора.

Ул күз ачылмас буранлы урамга чыкты. Мәгәр үзенең кая баруын, кемне күрергә теләвен һич белми иде. Төнге урамда гына түгел, аның күңелендә дә гүя буран иде. Бу халәтеннән котылырга теләп, ул алга атлады, бары тик адымнар гына аңа җиңеллек бирә кебек. Ләкин шул чак аның каршына Луиза белән Роберт килеп чыкты. Алар тукталып сәлам бирделәр. Сәлам Алмазны аңына китергәндәй итте. Җитмәсә, йөзләреннән чын шатлану сизелеп тора. Әнә, алар ике яклап аны култыклап ук алдылар. Роберт кырт кистереп:

— Буран каравыллап йөргәнче, әйдә миңа киттек. Сөйләшеп утырырбыз. «Абу-сөмбел»ем бар...— диде.

Алмаз бермәл карышмаска булган иде, мәгәр шунда ук:

— Рәхмәт, барган чаклар булыр әле,— дип, аларның кыстауларыннан котылырга ашыкты.

Ә инде алар хушлашып күздән югалгач, Алмазга рәхәт булып китте. Үз итеп сөйләшүдән, хәтта кунакка дәшүдән иде булса кирәк. Әгәр барган булса, утырырлар иде, сөйләшерләр иде.

Алмаз өенә кайтып кергәндә ялгызлык борчуларыннан беркадәр арынган кебек сизде үзен. Киемнәрен салып элгәч тә кухняга чыкты. Чәй куйды. Исәбе — соңарып булса да, ашап-эчеп алу иде. Ә чәйниккә «җан кереп», чыжлау авазы килә башлагач, аңа да күңеллерәк булып китте. Әйтерсең ул борчуларны куа, үз-үзенне юатырлык тойгыларга әйләнеп кайтырга өнди. Ә юатыр тойгылар — Ләлә Нуриева. Ләлә!.. Кайда соң ул? Элек шәһәр урамнарындагы афишаларда аның рәсеме еш күренә торган иде. Ә хәзер менә күренми. Клиент буларак больницага да килеп чыкмады. Башкалар больницадан савыгып чыккач та, үзен дәвалаган врачка күренеп китәләр, сәламәтлекләре хакында сөйләп, шатландыралар. Ләлә исә больницадан чыкты да югалды. Аның тавышы ни хәлдә икән?.. Алмазны әледән-әле яңа сораулар биләде. Алдагы мәшәкатьләр, озакламый якланырга тиешле диссертация турында уйларга, тормышны шулар исәбенә тулыландырырга теләде Алмаз.

## 12

Тамак-колак-борын хирургларының Мәскәү конференциясеннән кайткач, Алмаз, иң беренче эш итеп, Зәйнәп Вахитовнаны күрергә, анда алган тәэсирләрен шефка ишеттерергә, конференциядә булган докладлар җыентыгын тапшырырга ниятләде. Әмма кафедра мөдире бүлмәсенә таба барганда, каршысына Луиза килеп чыкты. Аның йөзе борчулы иде. Исәнлек-саулык сораштылар. Луиза каядыр ашыга кебек тоелды Алмазга.

— Алмаз Әхәтович, бер авыруым операциядән соң нигәдер рәтләнеп китә алмый. Беренче көннәрдә ярыйсы гына иде дә, хәзер тагы...

— Ничә көн үтте?

— Бүген тугызынчы.

Алмаз сүзсез калып, фикер җыйды. Больницага кайтып керү белән — мәсьәлә. Үз карамагындагы авыру түгел түгелен дә, ләкин мондый очракта карап торып булмый. Мәсьәләне чишәргә, ярдәм итәргә

кирәк. Җитмәсә, Луиза үтенече, Алмазны остазы итеп санаучы коллегасының гозере.

— Әйдәгез, алайса, пациентыгызны карыйк. Шефка соңрак керермен.

Пациент илле яшьләр тирәсендәге ир кеше икән. Алмаз сүзен нәрсәдән башларга да белми торды. Луизаның осталыгына, сәләтенә әлегәчә һич тә шикләнгәне юк иде аның. Хәзер дә шулай. Бәлки ул Алмаз методын үзләштергәндә нәрсәнедер төшенеп җитмәгәндер. Эштә андый хәлләр дә була.

Алмаз игътибар белән авыруның тышкы кыяфәтен карап чыкты, сүзләренә ныграк колак салды. Йөзендә чагылганны тавышы яңгырашы белән чагыштырып карады. Аннары авыруның йөрәк-үпкә эшчәнлеген тикшерергә кереште.

— Рентген рәсемнәре бармы?

— Әйе, менә.

Ул Луиза кулыннан рентген язуларын алып карады. Әйе, операция урыны җилсенгән иде. Өзлегү бөтен организмда бара торган физиологик кризис түгел... Димәк, операциядән соң яра нинди дер физик яки химик тәэсир кичергән. Шундый фикергә килергә мөмкин иде. Әмма бу азаккы нәтиҗә түгел иде әле. Алмаз операция җөен кат-кат карады, бугаз куышлыгын тикшерде. Җилсенү башлангыч хәлендә генә булса да, чын-чынлап шомланырлык иде.

— Тәмәке тартасызмы? — Алмаз авырудан шактый кырыс сорап куйды.

— Тарта идем, хәзер юк...

— Бер дәме?

— Бер дә. Кая, тәмәке тарту түгел, төкерек йоту да газап бит.

— Шулай да операциядән соң тарткалагансыз бит? — дип, ышаныр-ышанмас кына янә сорады Алмаз.

— Әйе, доктор. Бишенче көн дигәндә тарттым, түзмәдем.— Алмазның бер-бер артлы бирелгән сорауларын тыңлый торгач, авыру үз гаебен танып, телгә килде. Ниһаять, аның күзләре яшьләнде.

— Бугазы операцияләнгән авыруларга тәмәке тартмаска дип без алдан ук кисәтәбез. Менә хәзер үзегез газапланасыз. Безне дә уңайсыз хәлгә куясыз.

Палатадан коридорга чыккач, Луиза Алмаз әйтер сүзләрне әйтергә ашыкты:

— Алмаз Әхәтович, мин авырудан таләп итә белмәгәнмен. Рәхмәт сезгә,— диде кыз чын күңеленнән канәгатьләнү белдереп.

Савыгып барганда гына кинәт өзлеккән шул авыру хакында сөйләшеп барганда, алар берьюлы ике җитәкче каршысына тап булдылар.

— Алмаз Әхәтович кайткан лабаса! — дип елмайды Зәйнәп Вахитовна.

— Кайту белән эшкә дә тотынганнар...— диде Роберт, шулай ук ачылып. Ул Алмазның Луиза үтенече белән әлеге палатада булуын аңлап алган иде инде.

— Менә, йөреп кайттым,— диде Алмаз.— Мин сезгә керергә җыенган идем, Зәйнәп Вахитовна. Өлгерә алмадым.

— Төштән соң, вакыт булса, Роберт Салиховичны да дәшәрбез. Конференция хәлләрен бергәләп тыңларбыз,— диде Зәйнәп Вахитовна. Шеф үзе дә мәшәкатьле күренә иде.

Алмаз ассистентлар бүлмәсендәге өстәлдә ике чакыру билеты күрде. Опера һәм балет театрында булачак эстрада концертына чакырулар иде болар. «Наилә шаяруы түгелме икән?» дигән уй сызылып үтте. Алай дисәң, аның теге хатында барысы да ачык әйтелгән иде... Наилә моңа бармас. Башка берәүдер. Кем икән? Нигә

ул бер-ике сүз булса да язмаган. Ләлә? Юк, булмас... Ләләнең шәһәрдә юклыгы билгеле ич. Аннан соң ул ничек батырчылык итсен? Төрлечә уйлап карады Алмаз. Ахырдан концертка барырга һәм билетларның серен ачыкларга дигән карарга килде.

...Җырчыны сәхнәгә чыгуын көчле алкышлар белән каршыладылар. Әлеге алкышлар музыканың беренче аккорды башлангач кына тынды. Залда җырчы тавышының көч-кодрәте, моң-аһәңе барлык төсмерләре белән ишетелерлек тынлык урнашты. Ниһаять, Ләлә җырлый башлады. Аның тавышында җир йөзенең барлык сайрар кошларының моңы, салават күперенең бөтен төсләре, болындагы бихисап чәчәкләр гүзәллеге, кояш жылысы, сөеклеңнең күз карашыннан сизелә торган иркәләү бар иде кебек. Көчәнми, кыланмый, табигый җырлавы, нур өстенә нур дигәндәй, артистканы тамашачыга якынайта, тагын да яраттыра төшә.

Алмаз ни гаҗәптәндер, халыкка кушылып кул чабарга да, чапмаска да белмәде, нидәндер шикләнгән кебек, Ләләне хупларга батырчылык итә алмый утырды. Ләлә, алкышларга рәхмәт белдереп, тамашачыларга баш иде. Алдагы рәтләргә текәлеп карады.

Ул Алмазны күрми калмагандыр! Шул хакта уйлап, Алмаз яшүсмерләчә дулкынланып алды.

Ләлә башта берничә яңа җыр башкарды. Алмазның аларны ишеткәне юк иде әле. Әлеге җырлар үзләренең яңа булулары белән генә түгел, ә бәлки артистканың аларга өстәгән бизәкләре белән ямьлерәк, дәртлерәк яңгырый кебек иде. Ул Ләләгә сокланып карады, шушы мәшһүр җырчының кайчандыр үзенең пациенты булуына, нәфис тавышын саклап калуда аңа ярдәм итә алуына сөенде. Җитмәсә, менә аны сәхнәдә күрә, аның җырлавын тыңлый! Залда да җырчының кунагы булып утыра.

Алмазның Ләләне беркайчан да болай иркенләп тыңлаганы юк иде. Вакыт-вакыт ишетергә туры килсә дә, бүгенгечә тәэсирләнгәне юк иде. Әллә Наилә булганга инде. Менә хәзер ул яшьлек дустының җырлавын бөтенләй башкача, ирекле кеше буларак тыңлый.

Бермәл Алмаз гаҗәпсенеп тә куйды: ник соң әле ул теге икесе өчен дә уртак булып яңгыраган җырны җырламый? Җырны да, җырга күчкән мәхәббәтне дә онытканмы әллә Ләлә? Ләкин ул җыр, тәнне-җанны савыктырыр моң бераздан яңгырады. Җырны халык аеруча көчле алкышлады. Тамаша залы сихри әсирлек кичерде, Алмаз исә үзен биредәге иң бәхетле кеше итеп санады.

Башкалар кебек ул да кул чапты. Башкалар җырның кабатлануын сораганда, ул да кушылды. Эченнән генә: «Җырла, иркәм! Җырла!» дип торды.

Ләлә! Ләлә! Менә бит син нинди?! Җырыбыз әле дә булса югалмаган икән! Шул җыр күңелне яңадан дулкынландырды, яшьлек хисләребез кайтаваз булып әйләнеп кайтты.

Алмаз залдан иң соңгылар белән чыкты. Урам буйлап бераз атлагач, кая барырга дип тукталып калды.

— Исәнмесез, Алмаз!

— Исәнмесез!

Эндәшүче Ләлә үзе иде.

— Наилә Рәхимовна килә алмадымы, дежурдамы?

Сорау Алмазга сәер булып ишетелде. Шуңа да бер сүз белән генә:

— Әйе,— дип кенә җавап кайтарды.

— Кызганыч, бергә килә алмагансыз...

— Сезгә зур рәхмәт, Ләлә...

Шушы очрашу минутларының кадерен һичбер нәрсәгә дә тиңләп булмый иде. Алмазның күңеле нечкәреп, рухы сафланып, сөекле кешесенә генә түгел, ә бәлки бар дөньяга мәрхәмәт һәм наз белән тулы

иде. Ләлә җырлавы биргән дәрт, ялкын өстенә менә хәзер очрашу бәхете дә кушылды.

— Мөмкин булса, сезне озата барыр идем?

— Рәхим итегез,— диде Ләлә, бу тәкъдимгә аз гына да карышмыйча.

Янәшә атлаганда Ләлә, читләтеп кенә булса да, Алмаздан хатыны һәм диссертациясе турында сорашты. Ә ул исә әйбәт дип кенә чикләнде, сорауларны күбрәк үзе бирү ягын карады.

— Сезне үзгәргәнсез димме?

— Үзгәреп торган еллар безне генә бер килеш калдырыр дисезме?..

Алар, сөйләшер сүз таба алмыйча, тынып та калгаладылар.

— Тел төбегездән сизәм: сезне минем хәлем дә кызыксындыра,— диде, ниһаять, Ләлә.

— Хак сүзгә җавап юк. Әйе.

— Һаман ялгызмын. Бердәнбер юлдашым — җыр белән яшим.

Ләлә шулай диде дә тагын сүзсез калды. Борчыла да, уңайсызлана да кебек иде. Аннары бер «сез» дип, бер «син» дип сөйләп китте.

— Алмаз, мин сезнең парлап килүегезне теләгән идем. Еллар буе югалып торуым да менә хәзергечә икәүдән-икәү калудан өркү аркасында иде. Бу курку бигрәк тә сезнең матур гаиләгез бәхете өчен иде.

Алмаз аның ачылып сөйләвеннән уңайсызланып калды.

— Минем ялгыз булуымны да, Наиләнең мине ташлап китүен дә, инде аның башка берәүгә тормышка чыгуын да син белмисең, ахры.

Ләлә әлеге сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Әйтерсең өн белән төш буталды.

— Туктагыз әле, мин берни дә аңламыйм,— диде ул, тәмам аптырап.

— Димәк, Ләлә башкаларга бәхет теләп, үзенә газаплану юлын сайлаган булып чыга?

— Якын кешенә карата усаллык кылып буламы соң...

— Сөю белән нәфрәт янәшә йөри диләр бит...

— Кемдер шулай санаса да... Нәфрәт белән яшәсәм, җырларымны алкышлап кабул итмәсләр иде. Аларга минем изге тойгыларым, саф хисләрем үрелгән. Шуңа күрә мин ялгыз да, бәхетсез дә түгелмен.

Ләләне тагын беркадәр озата баргач, Алмаз:

— Сезне кабат күрергә теләр идем... Мөмкин булса иртәгә үк,— диде.

Ләлә сүзсез калды, ә аннары йөзендә шатлык балкыды һәм ул телгә килде:

— Врач тели икән, мөмкин. Мин — аның пациенты.

Алмаз саклык белән генә Ләләнең кулын үзенекенә алды. Төн җитүне онытып, алар урам буенча атлый бирделәр.

Сөйләшер сүзләре табыла торды.

## Фәнис Яруллин

### Бер сүз эзлим

Бер сүз эзлим сиңа әйтер өчен,
Матурмы ул, әллә түгелме —
Тик беркем дә әйтмәгән сүз булсын,
Тетрәтсен ул синең күңелне.

Әгәр ул сүз кара төндә туса,
Күкне ярып, таңны уятсын.
Таратсын ул бөтен болытларны,
Офыкларга якты ут яксын.

Әгәр ул сүз салкын кышта туса,
Яз китерсен җиргә йөгертеп:
Һәрбер бөре чәчәк атып торсын
Чын икәнен язның белгертеп.

Әгәр ул сүз сары көздә туса —
Алда кышлар көтеп торганда,
Өр-яңадан сайрар кошлар кайтсын
Ятимләнеп калган урманга.

Бер сүз эзлим сиңа әйтер өчен,
Беркем әйтмәгәнне, якынны:
Тормыш кебек тирән булсын ул сүз,
Мәхәббәттәй булсын ялкынлы.

1977

●

Тауларга карап
Тау булмасаң да,
Таңнарга карап
Таң булмасаң да,
Кешегә карап
Кеше була бел,
Олы җанлының
Ише була бел.

1977

●

Сөялдем сөяннәргә,
Тирбәлдем имәннәрдә.
Бар шатлыгымны бирәмен
Кадерен белгәннәргә.

Тукталдым аланнарда,
Сокландым баланнарга.
Бар ялкынымны бирәмен
Кабына алганнарга.

Йөгердем урманнарга,
Уралдым бураннарга.
Йөрәк давылын бирәмен
Тып-тыныч булганнарга.

Ашкындым офыкларга,
Үрелдем болытларга.
Шигырьләрем канат булсын
Күңеле сыныкларга.

1977

## Тамчы мәхәббәте

Әле яз да түгел иде,
Шулай беркөнне —
Кояш нурлары дөньяга
Мулрак бөркелде.
Уянды да тамчы шунда,
Гел исе китте:
Йөрәге атылып чыгардай
Ашкынып типте.
Күктәге кайнар кояшка
Булды ул гашыйк.
Сөюдән эреп, көн буе
Тамды шып та шып.
Кич җитте, һава суынды,
Көн шул тиз уза...
Әйтелми калган сүзләре
Әйләнде бозга.

1977

●

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда чәчәкләр бәйләме.
Каядыр ашыккан җиреңнән
Карыйсың әйләнеп-әйләнеп.

Карыйсың, кулларың изисең,
Юлларга чәчәкләр коела.
Йөзеңдә ниндидер үпкәләү
Һәм сагыш бар сыман тоела.

Нәрсәдер әйтәсең каерылып,
Тик җилләр өзгәли сүзеңне.
Тирбәлә һавада бер аваз:
«Без инде... Без инде... Без инде...»

Гел шулай керәсең төшемә:
Кулыңда яшьлекнең гөлләре.
Гөлеңне йолкыйлар кулыңнан
Тормышның аяусыз җилләре.

1977

## Сулыш

Үпкәм тутырып сулыш алам да
Башым белән чумам суларга:
Кабырчыклар эзлим тирәннән —
Энҗеләре суның шуларда.

Тыннар бетә, күкрәк кысыла,
Кабырчыклар белән уч тула:
Кабыкларын ачып карасаң,
Энҗе түгел, эче буш була.

Өметемне өзмим шулай да,
Буш икәне, әйдә, буш булсын.
Үз энҗемне тапмый чыкмамын,
Җитсен генә бары сулышым.

1976

## Без, без, без идек...

Без, без, без идек,
Без алты пар күз идек:
Алтыбыз да дөньяга
Әйтелмәгән сүз идек.

Без, без, без идек,
Без алты пар кул идек:
Эшләнмәгән эш идек,
Башланмаган юл идек.

Без, без, без идек,
Без бит алты җан идек:
Тормыш дигән офыкта
Яктырмаган таң идек.

Таң булып атмасак та,
Дан булып кайтмасак та,
Без барыбер без идек,
Әнкәбезгә үз идек.

1977

●

Тау ватты, таш кисте кеше,
Арымады.
Тимер бөкте, янды-пеште,
Арымады.
Сөрде, чәчте, урды, җыйды,
Арымады.
Таш пулатлар салып куйды,
Арымады.
Сазлыкларны киптерде ул,
Арымады.
Чүлләргә су китерде ул,
Арымады.
Иртә торды, гел соң ятты,
Арымады.
Зур юлларда көн-төн чапты,
Арымады.
Ә бервакыт кинәт анық
Бетте эше.
Менә шунда бик нык ару
Сизде кеше.

1977

●

Рифмадаш сүзләр —
Маңгайдагы күзләр:
Сүзләр сүзгә охшаш.
Күзләр күзгә охшаш.

Шигырьдәге юллар —
Иңнәрдәге куллар:
Юллар юлга тигез,
Куллар кулга тигез.

Шигырьдәге фикер —
Күңелдәге хистер:
Фикер була эчтә,
Яшерен була хис тә.

1977

●

Әйттең миңа уңганым дип,
Һәм ышандырдың шуңа:
Чынлап та шул көннән башлап
Эшләрем китте уңга.

Әйттең миңа акыллым дип,
Әллә чын, әллә уйнап:
Акыллырак итеп сизәм
Үземне хәзер чынлап.

Әйттең миңа матурым дип,
Сокланып күзләремә:
Сибелде күк таң нурлары
Шул вакыт йөзләремә.

Үзгәрдем, сизәм үзем дә,
Канатлар үсте хәтта:
Мең рәхмәт шулай үзгәрткән
Тылсымчы мәхәббәткә.

1977

## Зиннур Мансуров

### Кояш чыгышы

*Бер сөйләшүдән соң уйлану*

«Быел тагын сипләтәсе бар»,— дип,
сүз кузгаттың йортың хакында.
Бу дөньяда искермичә тормый
аксакаллар биргән акыл да.
«Кич сөйләгән иртән ярамый»,— дип
әйтәсеңдер әле үзең дә.
Үткәннәрдән хәтта канатлы сүз
килеп җитми кайчак бу көнгә.
Киләчәккә очкан хатларга да
куя сынап вакыт йөз ятьмә.
Заманалар мирас булып килгән
мәкальгә дә кертә төзәтмә.

«Нигезенә таза имән салып,
өйне сиплим,— дисең,— яздан соң».
...Иманымны шулай, кайта-кайта,
кабат яңартырга язмасын.

●

Көмеш таңкәле йөгәнен
тез астына салган да,
туп кадәрле генә малай
ат тышаулый яланда.

Яшен төсле уйнаклый ат —
тоталмассың ялын да!
Ташкын туктап калганмыни
шул ут-малай алдында.

Җен атын да буйсындырыр
ирлек бар бу оланда.
Әллә хакмы: балаларны
чакмый, диләр, елан да...

Шулай аңа баш бирерме
ярсу хыял аты да?

Ул да кайчак ташлап китә,
я утырта катыга.

Иркенлеккә җибәрсәң дә,
йөгән калсын куеныңда.
Тамыр төртер җире була
башка сыймас уйның да.

Кайчак олы нияттән дә
шулай куркып куясың:
януын да белми чапкан
ат күк башны җуймасын...

Яле, күрсәт ирлегеңне —
ярсу ат бит заман да!
...Туп кадәрле генә малай
ат тышаулый яланда...

●

Таудан аска ыргый чишмә —
чишмәгә тау кирәкме?

Биеклеккә күтәрергә
кирәк миңа йөрәкне.

Җиргә китсә, кибеп бетсә —
чишмәләрне ни көтә?..

Югалмаска кирәк миңа,
югалмаска ничек тә!

## Кояш чыгышында

Саумы, янар таулар иле,
саумы, Кояш чыгышы!
Юктыр бүтән — мондагыдай
төшкә кергән чык исе.

Ярым белән китәргә дип
вәгъдәләшкән җир чите...
Синдер хәтер китабымның
иң кызыклы бер бите.

Җир ачылып бетмәс кебек
мәңге җирдә яшәп тә.
Исемеңне куштым, әнкәй,
миңа ят бер чәчәккә.

Монда хыял-кошларымның
кунаклаган кыясы.
...Иңем куеп күтәрешәм
яңа вакыт Кояшын.

## Гомер чикләре

«Кырык бернең 22 июне —
бала чактан киткән көнем...»
(Апам көндәлегеннән.)

«Кайчак вакыт миһербансыз була —
чәч агара бер көн эчендә.
Шундый катгый чикне теймый гына
яшә,— дисең,— минем өчен дә...»

Вакыт — чиксез. Тик ул алдыбызга
үз чикләрен куя һаман да.
«Бүген ир бул!»— диеп, егетлектән
дәшеп ала безне замана.

Яшьлек чиге! Азрак булды, ахры,
халык күңеленә салган җыр.
...Акыллырак булып яшәр өчен
алда еллар күбрәк калгандыр.

Вакыт билгеләгән шул чикләрне
сизмичә дә үтә кемнәрдер...
Гомер чикләренең артындагы
сынауларга һәрчак без әзер!

●

Шомыртларның чәчәк аткан чагы —
каян килгән мондый салкынлык?!
Әллә инде язның учагында
җирне җылытырлык ялкын юк...

Кар шикелле сарган бу аклыкта
котып суыклары бар мәллә?!
...Туй күлмәгең кигәч, син дә шулай
салкынаеп куйдың бер мәлгә.

Битеңне куй — баксаң, челләдә дә
салкынчарак икән ак кылган.
Без дә, ахры, чәч агарткач кына
ирешәбез салкын акылга.

Тик аксакал сүрән сөйләсә дә —
хисе салкын диеп уйлама.
...Май төненең аен күшектереп
шомыртларда салкын ут яна.

●

Хәтер — уяу. Бәлки бу халәттә
күзләремне йомып йоклыймдыр.
...Инеш тулып, ак болытлар ага —
кулларыңны суга тыкмый тор!

Бәреп кермә татлы төшләремә!
Ә син, хәтер, барсын отып кал.
...Инеш тулып ап-ак керләр ага,
кемдер дәшә миңа: «Тотып ка-ал!..»

Җуелганны инде даулап булмый,
башыбызны җиргә орсак та.
Яныбыздан шулай китеп бара
кулдан ычкындырган форсат та.

Кемдер тотар аны, кыргый ат күк,
йолкып алса да ул кул башын!
Бу тормышта югалтулар мена
дошманыңа табыш булмасын.

Кулдан ычкындырган алтын вакыт
үкендереп куя хәзер дә.
Ташудагы кызыл алмадай ул
ымсындырып ага хәтердән.

...Инеш тулып, ак болытлар ага..

# «ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Сәгыйть Хафизов

## СОГДАНЕЛЛА

хикәя



Безнең бригада апрель азакларыннан башлап ерак тайгада җиңел кулдан ике нефть скважинасы бораулап алгач, җәйге эссе бер кичтә буровой вышкасын, җиһазларны сөйрәтеп, дизель моторлары белән шаулап бер авыл янына якынлашты. Мастерыбыз — аюдай таза гәүдәле ир уртасы Кузьма Христофорович әйткәнчә, биредә без яңа скважина ачарга, димәк, берәр айлап гомеребезне уздырырга тиеш идек.

Мин тирән буразналар сызып чайкала-чайкала авыр гына шуган вышка баскычларыннан өскә үрмәләдем. Кызыксынып авыл ягына текәлдем. Гөмбәзендәге тәрәзәләре белән кояшта ялтырап иске чиркәү күзгә ташланды. Иркен чәчелеп утырган йортлар, озын урам күренде. Күзләремне дулкынланып яткан аксыл иген басулары, куе яшел болыннар иркәләп алды. Утрау-утрау үскән камышлар арасыннан күл ялтырады. Күл өстендә канатлары белән бер суга тия язып, бер һавага ыргытылып акчарлаклар оча иде.

Кешеләргә, ыгы-зыгылы тормышка якынаю күңелдә җиңеллек уятты. Эшләве дә кызык булыр монда. Караңгы тайга туйдырган иде инде...

Вышканы геологлар билгеләгән урынга, калкулыкка китереп якягыннан тpraslar белән ныгыта башлауга, тирә-юньне карга көтүедәй бала-чага каплап алды. Биек вышкага төртә-төртә нидер сөйлиләр, кычкыралар. Ә кайбер әтәч йөрәкләре якын ук килеп тимерләрне капшап карарга, егетләр белән сүз алыша башларга да өлгерделәр.

Беркетәсен беркетеп, тегесен-монысын карагач һәм мастер, «инде бүгенгә җитәр, егетләр» дигәч, бераз сулыш алырга, тәмәке көйрәтергә утырдык. Вышка күрергә бала-чага гына түгел, олылар да килгән икән... Күзләрем яшь-җилкенчәкләр төркемендәге ак күлмәкле бер кызга тукталып калды. Унбиш-уналты яшьлек иде ул. Әнә нинди гаҗәпсенеп, үтә самимилек һәм кызыксыну белән буровойга карый. Сабырсызлык белән барысын күрергә, карап калырга ашыга. Әледәнәле кулын каш өстенә куя, күзләрен кичке кояшның кызгылт нурыннан күләгәли... талгын җил иркәләп аның җилкәсенә таралган дул-

кын-дулкын сары чәчләрен, нәфис гәүдәсенә сыланган кыска күлмәк итәген селкеткәли.

Мин янымда утырган Данилның янбызына төртәм. Ләкин Данилның мондә гаме юк, бригаданың көлке капчыгы җирән Гаврошның мәзәген тыңлап эче катып көлә иде.

— Я, Данилушка, шайтан кытыкламыйдыр бит? — дим, ак күлмәкле кызга ымлап. — Күр, чибәрме?

Данил көлүеннән тыелып мин ымлаган тарафка күз сала. Йөзендәге елмаю дикъкать, кызыксыну белән алмашына. «Ничего» дип баш бармагын тырпайта. Аннан өстәп куя:

— Һәйбәт!.. Әллә шобага салабызмы? Буровоена сокланганч, егетләренә дә гашыйк булмый түзә алмас.

— Син чибәррәк, Данилушка, сиңа булсын.

— Ну, Гәрәй, шәп тә егет соң син!

Тәмәкеләр тартылып бетте. Мастер: «Цивилизациягә килеп палаткаларда аунамассыз, егетләр», диде дә, мотоциклына атланып көтелмәгән кунакларны күрергә килгән кызыл чырайлы авыл советы председателе белән безне квартиралларга урнаштыру хәстәрен күрә башлады. Фатирга Данил белән икебезне бер карт йортына төшерделәр.

— Картның өе иркен, бер генә кызы бар. Әйбәт яшәрсез, — диде председатель.

Зур кыргый алмагачларга күмелеп утырган, эче пөхтә җыештырылган өй һәм аның хуҗасы — ягымлы чырайлы тәбәнәк карт — үзебезнең күңелгә дә хуш килде. Юл капчыкларын, чемоданнарны алып урнаша башладык.

Бераздан сабын-сөлгемне алып, юынырга чыгыйм дип ишек бавына тотынган гына идем, ишек үзе ачылып китте һәм... каршыма теге, буровой янында күргән кыз килеп басты. Йөзгә-йөз бәрелә яздык. Бая төсмерли алмаган идем. Күзләре аяз күк йөзедәй зәңгәр икән. Әллә нинди серле, сирәк очрый торган күзләр...

— Саумысыз... — дидем мин уңайсызлана да, каушый да төшеп. Гаҗәп! Ничек бу кызның өенә туры килдек соң әле без?

Нәрсәдер эзләп капчыгында казынган Данил да күтәрелеп кызга карады. Куе кара бөдрәләрен селкетеп елмаеп куйды:

— Исәнмесез, чибәркәй! Сездә яшәп торырга исәп, ачуланмыйсыңмы?

Ләкин кыз безнең сүзләргә аз гына да илтифат итмәде. Кергәч, караваг тимеренә тотынды да, аптыраулы күзләрен әле мина, әле Данилга күчереп, тик торды. Берәр сүз әйтсен иде, ичмасам. Балигъ лык яшендәге кызның йомышка кереп, сүзен әйтергә оялган яшь бала кебек кылануы ничектер бик сәер иде. Яңадан сүз катарга уңайсызланып аптырашта калдык. Әллә безне өнәми, шуңа сөйләшмиме икән?

Кыен хәлдән бабай коткарды.

— Ә, кызым кайткан, — диде ул ишектән керә-керешкә. — Минем шул инде минем кыз. Таныштыгызмы әле? Юкмы, аңлашып булмадымы? Юктыр шул. Теле башка шул минем балакайның, үзенчә...

Картның сүзләре безнең өчен аяз көндә яшен сугу белән бер булды...

Бабай иркәләп кызының чәчләреннән сыйпады, ишарәләр белән нәрсәдер сөйләп алды. Кыз кинәт елмайды һәм кулы белән кызу-кызу хәрәкәтләр ясап, бабасына нәрсәдер аңлатты.

— Сезнең килүегезгә кызым бик сөенә, — диде карт.

Бабай тагын кызына нидер ымлады. Кыз баш какты, шундук җитез адымнар белән өйдән чыгып китте. Тиздән ул зур табакка салып эре-эре кыярлар, кызара башлаган помидорлар алып керде. Өстәлгә

зур түгәрәк ак май, кечкенә тәпән белән бал китереп утыртты, шкафтан ипи алып кисте.

Юынып кергәндә, самавар да кайнаган, табын да көйләнгән иде. Карт безне өстәл янына чакырды. Безгә дустанә елмаеп, ниндидер мәшәкатьләр белән ишекле-түрле йөргән кызына карап, карт:

— Нарасыем телсез шул... Бәхете китек, — дип куйды.

— Безгә дә бәхет тәтемәде, алайса, — диде Данил шыпырт кына.

*

* *

Киң күңелле, мөлаем Афанасий картка без тиз ияләштек. Ул үзе дә безгә бик шат. Эштән кайткач, кичләрен, караватка кырын ятып, аның белән еш кына фәлсәфә куертабыз. Зур, саллы трубкасын тәмләп суыра-суыра ашыкмый гына мәгънәле итеп сөйләгән сүзләрен тыңлавы күңелле безгә. Афанасий бабай — сунарчы, гомере тайгада узган. Сугышта да снайпер булган. Башыннан әллә нинди хәлләр кичергән икән.

Бабай кызы турында да сүз кузгата:

— Сез, егетләр, пешекчебезнең ни атлы икәнен дә сорамадыгыз бит әле, — ди ул бераз шелтәле төстә һәм мич янындагы табуреткага утырып безне күзәткән кызына ымлый. — Теле булмагач, әллә исеме дә юктыр дип уйлыйсызмы? Бар аның исеме, бар. Бер генә дә түгел, икәү хәтта. Колагына Серафим дьяконнан кычкыртканы Валя, Валентина була. Тик хәзер анысын телгә алмыйм, Согданелла дип йөрим. Согданелла... Матурмы? Шул-шул, матур! Дөрес, кызның үзенә нинди исем дә барыбер. Ишетми бит. Тик миңа барыбер түгел. Кешеләргә дә шулайдыр. Син, Гәрәй улым, кызыңа нишләп Согданелла куштың диярсең инде? Сорау урынлы үзе. Тик исем алмаштыру кыз игә килмәсме, теле ачылмасмы дип өметләнүдән түгел. Хорафат иясемени мин юк-барга ышанырга? Согданелла... Яратам шул исемне... Исеме җисеменә ятышлы сыман.

Карт сүнгән трубкасын кабызып җибәрә. Зәңгәр төтен алкалары очырып суыра да, сүзен дәвам иттерә:

— Сез, егетләр, йөреп шомарган таш күк инде, бәлки ишеткәнегез бардыр, дөньяда согданелла атлы чәчәк бар бит. Роза гөле сыман бик матур кызыл чәчәк икән ул. Тау якларында үсә үзе... Әмма сәер дә чәчәк инде. Сәерлеге нәрсәдәме? Син башта минә кайчан тереклек итә, кайчан чәчәк ата ул дип сора. Шул-шул менә. Хикмәте дә нәкъ шунда аның. Әле яз дигәнең, үги бала сыман, кыюсызланып, табигатьнең ишегеннән генә шакый. Әле һаман салкын, суык. Тауның төн ягында зәһәр җилләр уйный, буран туза, кояш караган якта — кайчан шыткан да, кайчан чәчәк атарга өлгергән диген — согданелла балкый... Могҗиза, чынлап могҗиза! Шулай булмыйни, кар өстендә күз явын алырдай кып-кызыл чәчәк үссен әле?! Акылга сыймаслык эш бит бу... Мөсафирлар, сунарчылар очратсалар, матур булса да, чәчәкне өзмиләр үзе. Берәүнең кулы бармый, бозлы карда шытып, яшәү даулаган гөлнең гомерен чикләргә җөрьәт итми. Икенчесе исә бу чәчәктә ниндидер сер бардыр, өзсәм, яман эш килеп чыгар дип шикләнә, тими уза. Табигатьнең шушы гөнаһсыз гөле кешегә ничек тәэсир итә...

Согданелла бик кыска гомерле. Суык белән көрәшеп, тарткалашып яшәгәнгәдер, мөгаен?! Җир кардан арына, тау битләре аллыгөлле назлы чәчәкләр белән каплана. Берсен-берсе уздырып ходаның кошлары сайрый. Тирә-якта хозурлык, ямь... Тик бу чакта теләсәң дә согданелла чәчәген очрата алмыйсың инде. Табигатьнең бәйрәмен үзенә чит тоеп, тормыш белән саубуллашкан була бу чәчәк...

«Согданелла!.. Кара, нинди серле чәчәк үсә җирдә. Нинди матур исем бар!» — дип уйлыйм мин әсәрләнеп.

Картның хикәясе Данилның да күңелен кузгаткан:

— Да, кызыңның исеме бик мәгънәле икән. Тик үзе генә белми...

Афанасий бабай кабалана-кабалана трубкасына тәмәке төя. Аны яндырып тартып җибәрә, моңсуланып уйланып тора.

— Бала чагында кызым ишетә дә, сөйли дә иде бит,— дип сүзен дәвам иттерә ул. — Улым солдаттан кайтты да, Христинага өйләнде. Үзебезнең очтагы Сәләнтәй кордаш кызы. Бик акыллы, бик игелекле булды. Ире белән чөкердәште, атай дип өзелә иде... Инде килен Согданелланы тапкач, безнең өй тагын да ямьләнеп, тулыланып китте. Малаем шофер. Бик зур машинада эшләде, ерак-ерак калаларга йөрде. Ул бик гаилә җанлы иде. Өйгә ашкынып кайта. Кайта да, өйне күчтәнәчләр белән күмеп, безнең белән гөрләшә, шау-шу күтәреп кызын сөя. Согданелла нечкә, көмеш тавыш белән өйне яңгыратып көлә.. Бервакыт улым хатынын да утыртып китте. Шәһәргә барабыз, кирәк-яраклар алып кайтырбыз дип киттеләр. Тик кайта алмадылар шул бахыркайларым... Сагынып сөйләргә сурәтләре генә калды әнә...

Афанасий карт өй түреннән безгә карап елмайган хөр рухлы яшь кенә ир һәм иренә сыеныбрак төшкән оялчанрак карашлы мөлаем хатын рәсеменә ымлады. Бездән күреп Согданелла да рәсемгә таба башын борды. Җәһәт кенә урыныннан торып түргә узды һәм бер сурәткә, бер күкрәгенә төртә-төртә, дулкынланып үзенчә нәрсәдер сөйли башлады. Билгеле, ачык төшенмәсәк тә, кызның сүзе әти-әнисе турында булуы мәгълүм иде...

— Шулай хәлләр... Согданелланың әти-әнисенә әйләнеп кайтырга насыйп булмады, — ди Афанасий бабай сабыр, хәсрәтле тавыш белән. — Ул көн бик бозлавык иде. Машиналары аварияга юлыгып, икесе дә гүр иясе булды...

Согданелланы алып һәлакәт урынына килеп җиткәндә, машина пыскып янып ята иде. Малай белән киленнең канланып, көеп беткән гәүдәсен җиргә куйганнар... Согданелла аларны күргәч, яннарына йөгереп барып «этием-энекәем» дип үзәк өзгеч тавыш белән кычкырды да, төсе китеп, һушсыз хәлдә кулларыма ауды.

Шул көннән Согданелла телдән язды. Айлар буена тәненнән эссе китмәде, саташты. Үзен зур табибларга алып бардым, профессорларга да күрсәттем. Тырышсалар да, телен ача алмадылар шул. Кызыгызның авыруы тирән психик кичереш нәтиҗәсе, бәлки терелер дип тынычландырдылар да бит, үзгәреш юк шул,— диде карт авыр сулап.

*

* *

Себер якларында җәй көннәре озын була. Кояш, кызгылт томан белән өретелеп, тайга эченә батарга өлгерми, бераздан, качышлы уйнаган малай төсле, мин монда дип чыгып та җитә. Озын булса да, хезмәт мәшәкатьләре белән көннең үткәне сизелми дә. Шуның өстенә Кузьма Христофорович та: «Бу скважинаны рекордлы срокта бораулыйсы иде, егетләр, Татарстан нефтьчеләренең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтик әле», дип, эшкә ашкындырып тора.

Вакыт узган саен без Согданеллага да ияләшә барабыз. Ул баштагы кебек сәер тоелмый. Киресенчә, сөйкемлелеге, эчкерсез мөлаемлыгы һәм тагын әллә нинди сыйфатлары белән күңелгә якын була бара.

Согданелла яшендәге кызлар, гадәттә, бала чакларындагы терелек, җитезлекләрен җуеп салмаклана, сулпәнләнә башлыйлар. Ләкин

Согданелла алай түгел. Шук бала кебек кыбырсык, тиктормас ул. Аның һич кул кушырып торганын күрмәссең. Хәтта ашны да тыныч кына утырып ашый алмый. Капыл, нәрсәдер хәтерләп, кухняга йөгерә. Я булмаса балык яки йомырка кыздырылган табаны, ипиләрне безнең алгарак шудырып куя, өсте-өстенә чәй ясап, безне кыстый.

Бер көнне мин иртә уяндым. Тәмәке кабызып өй алдына чыктым. Кояш урман өстеннән яңа гына күтәрелеп килә иде әле. Ә Согданелла инде торган булып чыкты. Өстенә бабасының пинжәген киеп, башына ак яулык бәйләгән килеш зур мүкләк сыерларын иркәли-иркәли саварга әзерләнә иде.

«Келт» итеп туган авылым, апам исемә төште. Әни авырса яки берәр җиргә китсә, сыер саву апам өстенә төшә иде. Ул исә, үз чиратында, көтү куу мәшәкатен миңа йөкли. Менә ул сыерны савып керә дә, мине түшәктән аерырга тырыша. Әни булса, таләпчән кырыс тавышы белән мине күптән сикертеп торгызыр иде. Ә апам алай итә алмый. Баш очыма килә дә, йомшак кына:

— Нәнәм, тор инде, нәнәм! Сыерыбыз көтүдән кала бит, — ди.

Апамның ялварулы тавышы да, үзе дә бик ягымлы тоела миңа. Шуңа бу мизгелне һаман-һаман сузасым, иркәләнәсем килә.

Таң белән торып сыер саварга җыенган Согданелла да ни өчендер кинәт апам кебек үз, якын булып китте миңа.

— Исәнме, Согданелла! — дим мин. Ул, әлбәттә, мине ишетми. Тик нидер сизенеп ишек ягына борыла, мине күреп ала. Җанланып киткән зәңгәр күзләрен сирпеп, кулларын яңагына куя, аннары кояшка күрсәтә. Бик иртә әле, йокла да йокла, янәсе.

Урынга кереп ятсам да, инде йоклап булмый. Ә Согданелла сыерны савып көтүгә озатты. Плитә астына ут үрләтеп, таба чыжлатырга, савыт-саба шалтыратырга кереште.

Согданелла колхоз эшенә дә йөри. Утауга, печән җыярга — азмыни авылда җәен кыр эшләре. Озын буйлы, тәмәкедән мыегы саргайган чандыр бригадир Гаврилның кызны эшкә кушуы бик кызык. Башта капка төбендә тыр-пыр килеп мотоцикл тавышы ишетелә. Аннары тәрәзә каршында Гаврилның бәрхет тавышы яңгырый:

— Һәй, өйдәләрме?

Афанасий карт, тавышны ишетеп, өстәл җыеп, бүлмәләрне тәртипкә китереп йөрүче Согданеллага ымлый да, кулын баш өстенә калкытып тәрәзәгә күрсәтә. «Бар, кызым, Озын килде».

Эшкә кушу өчен бригадирга кыз белән озын-озак сөйләшеп җәфаланасы түгел. Менә ул гәүдәсен бер кадәр бөкрәйтә төшеп, печән чапкандагы хәрәкәтләр ясый һәм кулы белән урман ягына ишарәли. Димәк, Гаврил абыйсы, кичәге кебек, бүген да Согданеллага урман буена борчак чабарга барырга куша. Согданелла ризалык белдереп баш селки. Әмма үзе дә бригадир кебек чалгы белән селтәнгәндәй итә, урман ягына күрсәтә һәм бармакларын бит алмасына төртеп, икенче кулы белән баш артында бөдрәләр ясап, Гаврилга сораулы караш ташлый. «Сипкелле, бөдрә чәчле кызны — Анфисаны да шул эшкә куштыңмы?»

Бригадир Анфисаны башка эшкә кушса, кыз чыраен сыта, уфтанып куя. Шул хәл булмасын дипме, Гаврил абыйсы быел күбесенчә Согданелланы унынчыга җүчкән сөйкемле ахирәте Анфиса белән бергә куша.

Гаврилның мотоцикл тавышы тынарга да өлгерми, чалгысын күтәреп Анфиса килеп керә һәм без бергәләп диярлек эшкә китәбез. Анфиса бик оялчан, күзләрен җирдән күтәрми дә. Ә Согданелла шаян елмаеп безне үзләре янына эшкә чакыра. Үзенчә итеп анда шәп, анда кызык, борчак та ашатабыз, ди.

Аңа каршы Данил үкенүле чырай белән кулларын җәя дә, тирә-юньне гөр китереп эшләп яткан буровойга күрсәтә:

— Барыр идек тә, кызлар, булмый шул. Әнә эшебез көтә.

Кичен, эштән кайтып ял итәргә чыккач та Согданелла өлгерлеген күрсәтә. Кыю кулларыбыздан эләктереп ала да, бәрәңге бакчаларыннан ерак түгел җәйрәп, кош-корт тавышларыннан яңгырап торган күлгә алып төшә. Клубка да өчәү чыгабыз. Тик Согданелла уенга кушылмый. Бөтерелә-бөтерелә вальс биегән яшьләрне генә күзәтә. Мин яки Данил берәр кызның биленнән алып танцыга чыксак, ул күңелсезләнеп, боегып кала. Көнләшә бугай...

Менә шулай үз кешеләр, дуслар булып киттек без Согданелла белән. Ә дуслар арасында, билгеле, шаяру, уен-көлке еш була ул.

Данил йокы ачылсын, тәндә сихәт артсын дип, һәр иртән сикеренгәли, биленә кадәр чишенеп салкын су белән юына иде. Бүген дә ул шулай гадәтенчә сикеренгәләп, күлмәген салып, юынгычка кул тидергән генә иде, өстенә шаулатып су койдылар. Кем койганын күрмәдем, сабын, сөлгеләремне урнаштырып маташа идем. Борылып карасам, буш чиләген тотып Согданелла басып тора. Үзе елмая-көлә, күзләре шуклык белән балкый, әйтерсең нәни хәйләсе белән атасын алдаган бала инде...

Салкын судан күгәреп киткән Данил ачуланган булып аңа бармак селти. Ә кыз Данилның ялангач күкрәгеннән, чалбарыннан аккан суга, йөзенә бармагын теки-теки көлә. Данилның аптыраулы-кызганыч кыяфәтенә карап мин дә шаркылдап көләм.

— Ах сине! Егетләр белән ничек шаярырга икәнне күрсәтим әле мин сиңа! — ди Данил янап һәм кулындагы буш чиләкне шалтырата-шалтырата киткән кыз артыннан ташлана.

Согданелланың зифа гәүдәсе алга омтыла, сары чәчләре җилләнеп дулкынлана. Ләкин Данил озын ботлары белән биш-алты сикереп кызны куып җитә, биленнән эләктерә. Аның ихтыярына буйсынып Согданелла туктый, кисәк кенә аңа каршы борыла. Мин бер мизгелдә генә аларның бер-берсенә текәлгән күзләрен күреп калам. Йа, хода!.. Ни кадәр дәрт, хис, наз аның күзләрендә! Ни кадәр кайнарлык аның карашында! Согданелла Данилның кулларыннан ычкына да, тагын йөгереп китә...

Аңладымы Данил кыз карашын, әллә юкмы — әйтә алмыйм. Хәер, монда күрәзәче булу да кирәкмидер. Согданелланың үз-үзен тотышы эчкерсез, табигый. Күңелендәгесе шундук йөзенә, күзләренә саркый аның. Согданелла сабыйлар соклануы белән Данилга күз ата, елмайса да, аңа карап елмая. Ул аңа артык игътибарлы...

Бер көнне киногa баргач, Данил кайдадыр югалып калды. Кайтуын да таң әтәчләре кычкыра башлагач кына кайтты. Һәрчак күңелле, шат йөри торган Согданелла иртән бик сөмсерен коеп йөрде. Тик Данил аның белән шаяра, үртәшә башлагач кына элекке халәтенә кайтты ул. Елмайды, көлде. Әмма Данил үзе һаман аның ялкынлы карашын да, назлы елмаюын да сизмәскә, күрмәскә тырыша. Күрәсең, Согданелла кебек кыз сөю-сөелү эшенә лаек түгел дип уйлый.

Тәүлек буе эшләп смена алыштыргач, йоклап алырга гына түгел, башкасына да вакыт калды. Афанасий бабайның кармакларын алдык та, күл буена киттек. Безгә Согданелла да иярде. Башта шаугөр килеп су коенып алдык. Чишенгәч Согданелла тартыныбрак торды, камышлар арасына качты. Ләкин бер суга кереп алгач, безнең янга килеп су чәчрәтергә, шаярырга кереште.

Коенып туйгач, балык тотарга керештек. Вакыт та кичке якка авышты. Кояш урман өстенә, офыкка тәгәри. Аның кыйгач кызгылт нурлары күзләрне камаштыра, күл өстендә уйный. Көнозын эссе

кояштан качып кайдадыр яшеренеп, тынып яткан кош-кортлар җиләсләнгән һавага, иркенгә чыгалар, җим эзлиләр. Аларның тавышларыннан күл өсте, тирә-юнь яңгырап тора иде. Мин транзисторның тавышын көчәйтәм һәм җиңел, ашкындыргыч көйгә кушылып сызгыра-сызгыра балык чистартырга керешәм. Ә Данил белән Согданеллага учак өчен коры-сары җыеп килергә кушам.

Мин эшемнән аерылмаган хәлдә алар ягына күз салам. Менә Согданелла кулына чыбык-чабык күтәреп күл читенә килеп баса. Йөген җиргә ташлый, ашыгып су эченә кереп китә. Сары төнбоек чәчкәләрен сайлап кулына җыя башлый. Зур букет булганчы җыя... Өйгә алып кайтыр, кувшинга утыртыр дип уйлыйм. Юк, алай түгел... Менә ул чәчәкләрне күкрәгенә кыскан хәлдә судан чыга да, тавыш-тынсыз утын әзерләп маташкан Данил каршына килеп баса. Чәчәкләрне аңа суза. Данил кызга гаҗәпсенүле караш ташлый. Согданелланың очкынлы, ялкынлы күзләре аны сихерлидер кебек. Ул акрын гына букетны ала. Битараф түгел, битараф түгел Данил бу кызга!!.

Мин яхшы күрәм. Согданелланың йөзе, күзләре балкый. Ул кулы белән акрын гына Данилның шомырт бөдрә чәчләренә кагыла, сыйпый... Ләкин Данил кисәк талпынып аның кулын этә, читкә тартыла. Чәчәкләр дә җиргә коела. Мин чиксез уңайсызланып күзләремне яшерәм. Салкын акылдан җиңелгән самими кайнар йөрәк кызганыч... Кызганыч миңа табигыйлык!.

Илереп чыккан авазга сискәнеп башымны күтәрсәм, Согданелладан җилләр искән. Зур шәүләләр сузган камыш сабаклары, таллар арасыннан чыгып, кыз үзәк өзгеч тавыш белән елый-елый иркен болынга йөгерә. Согданелланың сары чәчләре чайкалып җилдә дулкынлана.

И табигать, яса могҗиза! Бәгырь көйдергән сөю-югалту утың, ичмаса, бер шифа булып, шул баланың телен ачсын!..

Гали Хуҗиев

# ЯРАТА ИДЕМ МИН СЕЗНЕ...

## Героик драма

ТУГЫЗ КҮРЕНЕШТӘ[1]

Тормыш таҗы — батырлык.

Ф. Энгельс.

Ярата идем мин сезне,
Кешеләр, уяу булыгыз!

Юлиус Фучик.

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Прага читендәге Дейвица. Фучиклар квартирасы. Фучик хатыны Густина белән тәрәзә янында сөйләшеп торалар.

Густина. Ишетәмсең, Юлий, безнең Дейвица каштаннары язгы таң җилендә нинди күңелле, нинди дәртле шаулыйлар.

Фучик. Ишетәм, сөеклем, ишетәм, бөре ачалар, яфрак яралар алар. Моңарчы без дә шулай күңелле итеп, бер-беребезне ихлас аңлап, бер-беребезгә сыенып, матур өметләр белән яшәдек. Йөрәкләребез һәр вакыт бергә типте.

Густина. Әйе, кадерлем, онытылмас минутлар күп булды безнең тормышыбызда. Хәтерлисеңдер, моннан өч ел элек, син Советлар Союзыннан кайткач, Дейвица калкулыгында таңны бергә каршылаган идек.

Фучик.

Мин бит барысын күреп кайттым,
Шул сиңа әйтер сүзем:
Ах, бу тормыш нинди матур,
Хуҗасы булсаң үзең!..

Густина.

Аңлыйм сине, аңлыйм, иркәм,
Бик дөрес синең сүзең:
Ах, бу тормыш нинди матур,
Хуҗасы булсаң үзең!..

[1] Кыскартып басыла.

**Ф у ч и к.** Чынлап та, моңарчы шундый күңелле яшәдек без, сөеклем! Ә моннан соң?.. Өченче империя безнең илебезгә үлем куркынычы белән яный. *(Ишекле-түрле йөреп).* Бүген-иртәгә әллә нинди фаҗигале хәлләрнең башланып китүе ихтимал. Шуны уйлап, үз буыныбыз турындагы романыма кереш сүз язып калдырырга булдым. Киләчәк буын вәкиленә мөрәҗәгать итеп яздым мин аны. Сиңа да укып күрсәтимме? Син бит минем беренче укучым, беренче киңәшчем.

**Г у с т и н а.** Укы, Юлий, укы. Бик рәхәтләнеп тыңлыйм.

**Ф у ч и к** *(өстәлдән кулъязма ала һәм, ара-тирә генә караштыргалап, аны яттан укый).* «Петр, Петруша, мин ике төн буе керфек какмадым һәм хәлдән тайганчы дулкынланып эшләдем. Ә өченче төнне синең өчен борчылу миңа йокы бирмәде. Мин күзләремне йомдым һәм синең турыда уйладым. Син туарсың, үсәрсең, ир-егет булырсың... Ләкин мин, мөгаен, сине беркайчан да күрә алмам... Сиңа әйтеп калдыра торган сүзләрем бар минем...

Без — җиргә чәчкән орлыклар. «Без» дигәнем — ул безнең буын... Яз килгәч, без бәлки барыбыз да тишелеп чыкмабыз, барыбыз да үсентеләр җибәрмәбез... Тимер дагалы итекләр кигән кешеләрнең безне таптап, изеп китүләре бар. Без моны беләбез, шул тойгылар белән яшибез.

Ләкин, Петр, болар үлемнән курыкканнар икән, дип уйлама. Без барыбыз да яши алмабыз, әмма... торган саен югарырак, яктырак үрләп, башкалар шаулар. Җан әрнеткеч борчулар, кайгы-хәсрәтләр онытылыр... Ил кырыннан уңыш җыйганда Сез: «Бу — аларның җимешләре, моның өчен алар үзләренең гомерләрен биргәннәр» дип уйларсыз...

Мин бу хатымны, шешә эченә салып җибәргән хәбәрдәй, вакыт океанына ташлыйм. Бәхетле дулкын аны сиңа илтсен. Һәм син, күптән язылган сүзләрне укып, безне аңларсың, минем якын һәм таныш булмаган энем Петр!»

**Г у с т и н а** *(дулкынланып).* Йөрәк түренә үтә торган сүзләр бу, Юлий!

**Ф у ч и к** *(тәрәзәгә килеп).* Менә тагын таң атты. Нинди гүзәл безнең башкалабыз Прага! Ә бүгенге көн безгә нәрсә китерер: шатлыкмы, кайгымы? Тукта, дөньяда ниләр бар икән? *(Радиоалгычны тоташтыра).*

**Д и к т о р** *(җан әрнеткеч тавыш белән).* Прага гражданнары! Империя гаскәрләре бүген безнең башкалабызга басып керделәр... Хөкүмәтебез сезне аларга бертөрле дә каршылык күрсәтмәскә чакыра.

**Ф у ч и к** *(әрнеп).* Безнең хөкүмәт башында әнә нинди сатлык җаннар!..

**Д и к т о р.** Хөкүмәт әмерен үтәмәгән кешеләр иң каты җәзага тартылачак.

**Ф у ч и к** *(тыныч кына).* Димәк, безне иң кырыс сынаулар, иң каты бәрелешләр көтә, Густина.

**Г у с т и н а.** Аңлыйм, Юлиус, аңлыйм.

**Ф у ч и к.** Без шатлык өчен яшәдек, инде шатлык өчен сугышка керәбез.

**И к е с е б е р г ә.** Ниләр күрсәк, ниләр кичерсәк тә, соңгы сулышкача бер-беребезгә тугрылыклы булырбыз.

Ишектә звонок шалтырый. **И о з е ф** белән **М а р и я  Е л и н е к л а р** кабаланып килеп керә. Иозеф бераз аксый.

М а р и я *(тирән борчылып).* Нинди аяныч язмыш көткән икән бит безне, туганнар!.. Испания фаҗигасе, димәк, бездә дә кабатланачак.

И о з е ф *(шулай ук борчылып).* Трамвайда сөйләделәр, сез ишетмәгәнсездер әле: «Руде право»ның редакторларыннан берничәсен кулга алып та өлгергәннәр...

М а р и я. Сезгә киңәшкә килдек. Я, инде нишлибез, туганнар?

Ф у ч и к. Безгә узган ел ук, фюрер таләбе буенча Мюнхен киңәшмәсе безнең туган илебезне бүлгәләргә карар биргәнче үк, фашизм казынуларына каршы аяусыз көрәш башларга кирәк иде. Ә хәзер көрәшү икеләтә авыррак булачак.

М а р и я. Сез — коммунист кешеләр. Сезгә тагын да авыргарак туры килер.

Ф у ч и к. Без моны аңлыйбыз, пани Елинек. Кайда авыр — безнең урыныбыз шунда. Шуның өчен дә бит коммунистлар без. Бурычыбыз — дошманга аз гына да шәфкать күрсәтмәү.

И о з е ф. Мин трамвайчылар белән сөйләштем. Барысы да бер авыздан шулай диләр.

Ф у ч и к. Әйе, башлап эшчеләр сыйныфы үзенең катгый сүзен әйтер.

И о з е ф һ ә м М а р и я. Без, Елинеклар, үз бурычыбызга турылыклы булырбыз.

Ф у ч и к һ ә м Г у с т и н а *(аларның кулларын кысып).* Без сезгә ышанабыз.

М а р и я. Ә шулай да хәзер безгә нәрсә эшләргә соң?

Ф у ч и к. Подпольега күчәбез. *(Бераз уйланып йөргәч).* Мин бүгеннән Юлиус Фучик түгел, ә укытучы Горак. Иптәш Тельманның төрмәдә немец коммунистына язган хатын укыганым бар минем. *(Хәтерләп).* Ул анда болайрак ди: «Кем үз язмышына хуҗа булырга тели, кем үз халкын якты киләчәккә алып барырга тели һәм үзендә шул көчне тоя, шул кеше дошманлык, наданлык һәм алдау дөньясына каршы күтәрелә. Яшәүнең мәгънәсе бары көрәштә генә!» Без шушы хакыйкатьне һәркемнең аңына, бөтен халыкның аңына җиткерергә тиешбез. *(Елинекларга).* Бу эштә сез безнең партиябезгә ярдәм итәргә әзерме?

Е л и н е к л а р. Әйе, әзер!

Ф у ч и к. Ярый, аңлаштык. Поручение булу белән үзем хәбәр иттерермен.

Е л и н е к л а р. Көтәбез. *(Саубуллашып чыгып китәләр).*

Бераздан звонок шалтырый. Густина, сагаеп, Фучикка күрше бүлмәгә керергә ишарә ясый. Килүченең кем икәнен сорап, ишекне ача. Кабаланып, Фучикның әнисе килеп керә.

А н а *(күрешеп).* Юличек кайда?

Г у с т и н а. Өйдә, әнкәй, өйдә.

Күрше бүлмәдән Фучик чыга.

Ф у ч и к *(кочаклап).* Исәнме, әнкәем! Әткәй һәм туганнар нихәлдә?

А н а. Бездә хәзергә һәммәсе ярыйсы. Менә сезнең хәлләр генә бик хәтәрләнеп китте. Бөтен җирдә коммунистларны кулга алалар, төрмәгә утырталар. Сине алар күптән белә бит. Хәзер үк башка берәр илгә китәргә кирәк сиңа.

Ф у ч и к. Юк, әнкәй, мин үз халкымның көрәшеннән читтә кала алмыйм, башкалар яулап алган бәхет хакына яши алмыйм.

А н а *(Густинага).* Син дә үгетлә зинһар, күндер, Густина бәбкәм. Икәү бергә китегез.

Г у с т и н а. Әйе, әнкәй, без үз халкыбызның көрәшеннән читтә кала алмыйбыз.

А н а *(күзләрен сөртеп, улының муенына сарыла).* Күз яшьләрем белән сорыйм, бәбкәм... Юкса, монда хәзер эләктереп алырлар да, харап итеп ташларлар үзегезне.

Ф у ч и к. Гафу итегез, әнкәй, бу юлы сезнең киңәш буенча эш итә алмыйм.

А н а. Алайса, безнең янга, Котимерж авылына, күченеп килегез, ичмаса. Анда тынычрак, куркынычсызрак булыр.

Ф у ч и к. Менә бусы — әйбәт киңәш, әнкәй. Рәхмәт! Күченәбезме, Густина?

Г у с т и н а. Күченәбез, Юлий, күченәбез. Безнең турыда кайгыртуыгыз өчен зур рәхмәт, әнкәй!

А н а. Озакламагыз, алайса. Без көтәрбез. Сак булыгыз, балакайлар. *(Саубуллашып китә).*

Ф у ч и к. Мин хәзер тиз генә редакциягә барып килим. Мондый чакта кул кушырып утырырга ярамый, сөеклем.

Г у с т и н а. Ләкин сак бул, Юлий!

Ф у ч и к. Борчылма, миңа бернәрсә дә булмас! *(Китә).*

Г у с т и н а *(борчылып).* Китте... Партия эше дигәндә, башка бер нәрсә белән дә санашмый.

Берәздән каты итеп звонок шалтыраталар. Ишекне ачуга, бүлмәгә ике гестапочы килеп керә.

Б е р е н ч е с е. Без гестаподан!

И к е н ч е с е. Фамилиягез?

Г у с т и н а. Фучикова.

Б е р е н ч е с е. Ә бу квартирада яшәгән Барешлар кайда?

Г у с т и н а. Алар биредән күченеп киттеләр.

И к е н ч е с е. Кайчан?

Г у с т и н а. Ел башында ук.

Б е р е н ч е с е. Ә кая киттеләр?

Г у с т и н а. Һич әйтә алмыйм, адресларын калдырмадылар.

И к е н ч е с е *(боерып).* Алай-болай бирегә килеп чыксалар, шунда ук безгә хәбәр итегез!

Б е р е н ч е с е. Юкса, үзегезгә начар булачак. Аңладыгызмы?

Г у с т и н а *(тыныч кына).* Аңладым...

*(Гестапочылар чыгып китә).* Миннән Барешларны тотып бирүне таләп итәләр. Ах, кабахәтләр. Юлиус тизрәк кайтса икән. Аның эзенә төшә күрмәсеннәр тагын. Безгә тизрәк җыенып моннан китәргә кирәк. *(Көйләп).* Никтер һаман шушы җырны яратам:

Расшумелся ковыль, голубая трава,
Голубая трава-бирюза.
Ой, геройская быль не забыта, жива,
Хоть давно отгремела гроза.

Поднимался народ, атаманов кончать,
Шли казаки, забывая страх.
Шла казачка вперед, пулеметом стуча,
Помогать партизанам в боях.

Котимерж авылы. Кечкенәрәк берничә бүлмәле авыл өе. Бер почмакта балыкчы кирәк-яраклары эленеп тора. Ана аш-су әзерләп йөри.

Ана. Кичә хатларын алдык. Исән булсалар, бүген үзләре дә килеп җитәрләр.

Тышта эт өргән тавыш ишетелә.

Әнә киләләр, киләләр!

Бераздан, чемоданнарын күтәреп, Фучик һәм Густина килеп керәләр. Фучик бераз сакал-мыек үстергән.

Фучик *(күрешеп)*. Нихәл, әнкәй, исәнлекме?

Ана *(күрешеп)*. Әйдәгез, балакайларым, әйдәгез! Прагада озак тоткарландыгыз.

Фучик. Эш бит, әнкәй, эш.

Ана. Бик борчымадыларммы соң?

Густина. Булгалады инде. Йорттан-йортка, танышлардан танышларга күчеп йөрдек.

Фучик. Әткәй кайда соң? Балыкка киткән дисәм, ятьмәләре биредә.

Ана *(борчылып)*. Әткәгез туган шәһәребез Пльзенда больницада шул әле. Сеңелләрегез дә шунда. Алар, әледән-әле барып, аның хәлен белешеп торалар.

Фучик *(борчылып)*. Аңа ни булды, әнкәй?

Ана. Бер аягы авырта, тәмам теңкәсенә тиде инде.

Фучик. Иртәгә үк барып, хәлен белербез, Густина.

Ана. Хәзер борылып чыгып китәргә килгән кешеләр түгел ич сез. Ишек төбендә тормасыннар әле. *(Чемоданнарны түргә күчерә башлый)*. И, балакайларым, йөгегез дә бигрәк авыр булган икән. Нәрсә тутырдыгыз боларга шул кадәр?

Фучик *(елмаеп)*. Аларда зур байлык, әнкәй! *(Чемоданнарны ачып, өстәлләргә китаплар тезә)*.

Ана. Китап җене кагылгандыр инде сиңа, бәбкәм, китап җене...

Густина. Әйе, әнкәй, безнең Юлий китаплардан башка яши алмый.

Фучик. Беләсеңме, әнкәй, китаплар күңелне яктырта алар. Ленинның көрәштәше Феликс Дзержинский болай дигән: «Башкалар өчен якты нур булырга, үзең нур чәчеп торырга кирәк.— Кеше ирешә ала торган иң зур бәхет менә шунда».

Ана. Бик дөрес әйткән, бәбкәләрем.. Юлда арыгансыздыр. Я, бераз тамак ялгап алыгыз. Аннары бу сакал-мыегыңны кырып җибәр, улым. Синең бит әле ир уртасы гына чагың.

Фучик. Юк, кырырга ярамый, әнкәй. Мин хәзер Юлиус Фучик түгел, ә укытучы Горак.

Ана. Ә алай икән, алай икән... *(Чәй ясый да, урыныннан торып)*. Я, улым, бу хәлләр озак дәвам итәрме? Әллә Испания хәлләре бездә дә кабатланырмы?

Фучик. Әйе, хәзер көрәшү авыр булачак. *(Тәрәзәгә күз салып)*. Кошлар ачыкканнар, мескеннәр... *(Форточканы ачып, икмәк уып сибә)*.

Ана. Үз кайгың гына җитмәгән, кошлар турында да кайгыртасың тагын, бәбкәм.

Фучик. Яратам мин аларны, әнкәй. Авыр чакта юанычларым алар минем. Ашагыз, аша, кадерлеләрем!..

Тышта ярсып-ярсып эт өргәне ишетелә.

А н а *(икенче тәрәзәгә барып).* Жандарм килә. Яшеренегез, балалар!

Ф у ч и к. Минем аны күргәнем дә бар сыман. Ялгышмасам, ул бит чех?

А н а. Әйе, чех.

Ф у ч и к. Болай булгач, мин аның белән ачыктан-ачык сөйләшәм...

Пистолет тотып, ж а н д а р м килеп керә.

Ж а н д а р м *(Фучикка).* Кулларыгызны күтәрегез! Сез кулга алындыгыз!

Ф у ч и к *(урыныннан кузгалмыйча).* Аңлашыйк әле, якташ, аңлашыйк! *(Ана белән Густинага).* Без икәү генә сөйләшергә теләр идек.

А н а. Сөйләшегез, сөйләшегез. Без кухняга чыгабыз.

Ф у ч и к. Мин — чех. Ялгышмасам, сез — Иозеф Говорка, сез дә чех.

Ж а н д а р м. Әйе, чех бугай...

Ф у ч и к. Нигә бугай? Дөньяга чех булып туганыгызга үкенәсезме әллә?

Ж а н д а р м. Юк, үкенмим. Соңгарак мине белерсез әле.

Ф у ч и к. Алайса, тыңлагыз: бу килмешәкләр безнең илебездә озак тора алмаслар. Ә сез кан-кардәш туганыгызны гестапога тотып бирергә уйлыйсыз. Үсеп җиткәч, балаларыгыз нәрсә дияр? «Безнең әтиебез туган илебез дошманнарына хезмәт иткән, үз кан-кардәш туганнарының тормышын сатып яшәгән»,— диярләр бит алар. Сезгә нәләт укырлар.

Ж а н д а р м. Ә миңа нишләргә соң! Миңа да гомерем кадерле бит.

Ф у ч и к. Киңәшем шул: эзләп-эзләп тә сез мине тапмадыгыз. Сез мине, мин сезне күрмәгән.

Ж а н д а р м. Ә мин сезгә ышана аламмы?

Ф у ч и к. Тулысынча.

Ж а н д а р м. Әмма моны беркем дә белмәсен инде. Сез мине, мин сезне күрмәгән. *(Китә).*

Г у с т и н а. Көтелмәгән кунак китеп тә бардымыни?

Ф у ч и к. Без аңлаштык: эзләп-эзләп тә ул мине тапмаган. Мин аны белмим, ул мине.

Г у с т и н а *(рухланып).* Моннан соң бераз тынычлап эшләп тә булыр бәлки.

Ф у ч и к *(китаплар караштырып).* Эшлибез, сөеклем, эшлибез. Мин «Көрәшүче Божена Немцева» дигән хезмәтемне дәвам иттерәм.

Г у с т и н а. Ә миңа Карел Сабина әсәрләренең тәрҗемәсе тынгы бирми.

А н а. Сез эшләгез, балакайлар. Мин кош-кортларны караштыргалап керим әле.

Ф у ч и к *(китаплар актарып).* Әйе, Густина, һәртөрле бөек сәнгать көрәштән үсеп чыга... Иң бөек сәнгать — җиңелү ачысын татыганнар сәнгате ул. Чөнки чын әсәрләр йөрәк каны белән, көрәштә алган яралардан агып торган кан белән языла лар. Тукта, дөньяда ниләр бар икән? *(Радиоалгычны көйли).* Ах, кабахәт... Нинди оятсызлыкка барып җиткән бит.

Г у с т и н а. Кем ул? Нинди оятсызлык?

Ф у ч и к. Империя министры, фюрер попугае Геббельс бездән кайберәүләрне Берлинга чакырткан, бөтен чех интеллигенциясен үзләренә хезмәт итәргә өндәгән, төрлечә янаган.

Г у с т и н а. Димәк, безне халыктан аерырга, аңа хыянәт иттерергә уйлыйлар.

Ф у ч и к. Әйе, сез безнең кулыбызга капсагыз, бөтен чех халкы да безнең кулга эләгер, дип фикер йөртәләр алар.

Г у с т и н а. Юк, мондый эшәке тәкъдимгә җавап бирмичә калырга ярамый.

Ф у ч и к. Әйе, бөек немец драматургы Лессинг сүзләре белән әйтсәң, «бу шундый шаярту, аңа яңакка чалтырату белән җавап бирәләр». Шулай шул, бик дөрес. Шуның өчен мин чех интеллигенциясе исеменнән Геббельска шул турыда тозлап-борычлап ачык хат язарга кирәк саныйм.

Г у с т и н а. Әйе, моны бездән вөҗданыбыз, халкыбыз таләп итә.

Ф у ч и к. Хатның фикере ачык: без, чех музыкантлары, артистлары, язучылары, инженерлары, үз халкыбызның революцион көрәшенә беркайчан да хыянәт итмәбез! Караңгылык һәм коллык көчләренә беркайчан да хезмәт итмәбез! Тукта, Густина, чех интеллигенциясенең җавап хатын хәзерлим әле. *(Арлы-бирле йөреп).* Меңнәрчә туганнарыбызны төрмәләргә, концлагерьларга ябып, партиябезне, матбугатыбызны, әдәбиятыбызны, сәнгатебезне тыеп, сез безнең авызыбызны томаламакчы буласыз. Әмма белегез, мондый шаяру өчен яңакка чалтыраталар.

Г у с т и н а. Килер бер көн, аларның яңакларына халык үзе чалтыратыр.

Тышта эт өргән тавыш ишетелә.

Ф у ч и к *(тәрәзәгә барып).* Лида Плаха килә. Бер-бер хәл булды микән әллә?

Өс-башын кага-кага, чыланган Л и д а П л а х а килеп керә. Ул чандыр, яшь кыз.

О, Лидуша, әйдә, әйдә, рәхим ит! Син, Лида, җил-яңгырдан да, тегеләрдән дә курыкмыйсың икән!..

П л а х а. Хәзер бернәрсәдән дә куркып тора торган заман түгел, Горак әфәнде.

Ф у ч и к. Әйе, Лидуша!

П л а х а. Сезгә йомыш белән килгән идем... *(Густина белән күрешеп).* Җизнәм һәм апам Ваксглар әйттеләр: биредә борчый башладылар, Горак әфәнде безгә күчеп килсен, киңәшәсе нәрсәләр дә бар, диделәр.

Ф у ч и к. Ә хат-фәлән юкмы, Лида?

П л а х а. Юк шул *(йөрәгенә ишарәләп).* Барысы да биредә.

Г у с т и н а. Я, Прагада ниләр бар, сеңелкәш?

П л а х а. Дөньяның асты-өскә килә. «Руде право» редакторларының күбесен, тагын әллә никадәр кешене кулга алганнар.

Ф у ч и к һәм Г у с т и н а. Кызганыч, бик кызганыч.

Г у с т и н а. Мин хәзер. *(Чәй хәзерли башлый).*

П л а х а *(бүлдереп).* Юк, юк, кирәкми, пани Густина! Рәхмәт! Юкса, поездга соңлыйм.

Ф у ч и к. Алайса, Лидуша, Ваксларга әйт, кайчанрак баруым турында мин үзем хәбәр итәрмен.

П л а х а. Китәбез, Горак әфәнде. *(Саубуллашып китә).*

Ф у ч и к. Тагын күпме көрәшчеләр һәлак булачак икән.

Г у с т и н а. Әйе, гестапо тырнагына эләккән кеше исән котыла алмый инде ул. Ә нишләргә соң?

Ф у ч и к. Хәрәкәт итәргә, хәрәкәт итәргә, тагын бер тапкыр хәрәкәт итәргә!

Ишек шакыйлар. Ашыгып М и р е к һәм аның артыннан а н а керә.

Ф у ч и к *(күрешеп).* Ни бар, Мирек? Әткәйгә бирер нәрсә булды мәллә?

М и р е к. Пльзенда сине гестапо эзли, Юлий. Биредә эләктереп алмасыннар өчен, син моннан һич кичекми китәргә тиешсең!

Ф у ч и к. Ни булган соң?

М и р е к. Сезнекеләрдә бүген иртән гестапо булган! Сиңа яшеренергә, эзеңне югалтырга кирәк.

А н а. Ә кайчан булганнар?

М и р е к. Иртәнге сәгать бишләрдә.

Ф у ч и к. Сәгать ун тулып килә. Димәк, гестапо минем кайда икәнемне белми. Юкса, алар инде мине биредән эзләрләр иде. Поезд китәргә тагын ике сәгать вакыт бар. *(Мирекка).* Ә сине бирегә кем җибәрде?

М и р е к. Сеңелегез Вера. Ул минем квартирама килгән. Ләкин мин эштә идем. Вера миңа хуҗа хатынының малаен җибәргән һәм сине кисәтергә кушкан. Тиз генә станциягә киттем. Ә бирегә килүемне сиздермәс өчен, бакчага койма аша сикердем, аннан — йортка.

Ф у ч и к. Гаҗәп өлгерлек һәм тапкырлык күрсәткәнсең, Мирек! Сиңа да, Верага да рәхмәт!

М и р е к. Бирегә тоткарланырга ярамый. Хәбәрләшербез әле. Я, мин киттем.

А н а *(борчылып).* Сиңа, чыннан да, биредә калырга ярамыйдыр, бәбкәм.

Ф у ч и к. Әйе, бу — үзеңне-үзең гестапога тотып бирү булыр иде. *(Өстенә костюм, плащ кия. Фуражкасын кесәсенә тыга).* Я, әнкәй, мин киттем. *(Кочып үбә).* Я, Густина!..

Г у с т и н а. Юк, юк, мин сине станциягә кадәр озата барам. Ни күрсәк тә бергә күрербез.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакслар квартирасы. Гади генә итеп җыештырылган бүлмә. Стенада карта. Фучик ишекле-түрле уйланып йөри.

Ф у ч и к. Быел февраль аенда партия өстенә гаять зур бәла килде: бөтен Үзәк Комитетны диярлек кулга алдылар. Күпме көрәшчене югалттык. Саксызлыктан килеп чыктымы бу хәл? Әллә берәрсе хыянәт иттеме? Һәрхәлдә, провокациясез булмагандыр бу. Вакыты җиткәч, хөкем каршысына китереп бастырылган Прага гестапочылары сөйләп бирерләр әле моны... *(Карта янына килеп).* Иң авыр сынау көннәре килеп җитте. «Империя» кол итүчеләре хәзер Советлар Союзына ташландылар. Ләкин алар анда муеннарын сындырачак... Әйе, дөньяда хәзер илләр, халыклар язмышы, буыннар язмышы хәл ителә. Безнең алда бер генә юл: хәрәкәт итәргә, хәрәкәт итәргә, хәрәкәт итәргә! *(Сәгатенә карап).* Тукта, нигә озаклады әле бу Гонза Дика? *(Тәрәзәгә килеп).* Тышта нинди матур айлы кич, акацияләр шау чәчәктә. Гашыйклар өчен генә дигән төн. Ә без боларның барысыннан да мәхрүм. Безне адым саен эзәрлиләр. *(Кемнеңдер килүен күреп, сыный карап торгач).* Әйе, үзе, Гонза Дика. *(Барып ишек ача).* Кочаклашып күрешәләр.

Гонза Дика — түгәрәк йөзле, көләч чырайлы, ир урталарындагы кеше.

Д и к а. О, озак эзләдем мин сине, Юлий!

Ф у ч и к. Мин дә шулай ук. Камалу көннәреннән соң, кара урмандагы кебек, адашып йөрдек бит. Хәзер безгә яңадан, башлап юл ярырга кирәк.

Д и к а. Кирәк, бик кирәк. Вакыты шулай. *(Картадан СССРны күрсәтеп).* Биредәге фронт безнең илебез аша да, безнең йөрәгебез аша да үтә.

Ф у ч и к. Димәк?..

Д и к а. Димәк, хәрәкәт итәргә, хәрәкәт итәргә.

Ф у ч и к. Тагын бер тапкыр хәрәкәт итәргә.

Д и к а. Дөрес, бик урынлы өстәдең бусын. Я, ничек киңәшәбез?

Ф у ч и к. Мин, элеккечә үк, матбугат белән җитәкчелек итәм. Ә син, башлыча, оештыру эшләрен алып барачаксың. Ризадыр бит?

Д и к а. Риза, әлбәттә. Күнегелгән, таныш эш. Мин тагын бер кеше таптым.

Ф у ч и к. Кем ул?

Д и к а. Гонза Черный. Испаниядә сугышкан һәм анда үпкәсен пуля тишеп, бу сугыш башлангач кына Прагага кайткан иптәш. Мин аның белән берничә тапкыр сөйләштем. Ул урыннарда диверсияләр һәм саботаж оештыру эшләре белән җитәкчелек итәчәк.

Ф у ч и к. Чынлап та ышанырлык, булдыра алырлык иптәшме?

Д и к а. Мин кешеләрне таный беләм бит инде. Дөрес, аңарда солдат гадәтләре дә бераз бетеп җитмәгән әле. Ләкин зарар юк, мондый эштә шундый иптәш кирәк тә. Теләсәң, аның белән тиздән үзеңне дә очраштырырмын.

Ф у ч и к. Бик әйбәт булыр иде.

Д и к а. Булды, эшлибез аны.

Ф у ч и к. Климент иптәш Готвальдның күрсәтмәсе бар. Хәзер безгә Милли революцион комитетлар төзергә кирәк. Ә моның өчен, иң башлап, урыннардагы партия оешмалары белән тизрәк элемтәгә керәсе иде.

Д и к а. Әйе, бу — иң мөһиме. Мин шактый тоткарландым бугай. Бергә озак булырга ярамый. *(Фучикның кулын кысып).* Хәзергә хуш! Тиздән очрашырбыз.

Ф у ч и к. Әйе, очрашырбыз. *(Бераз уйланып йөргәч).* Үз-үзен аямаучы, кыю, партия эшендә компромиссларны белми торган иптәш бу. Кешеләрне ярата, үзен дә яраталар. Димәк, аның белән бергә чын-чынлап эшләп булачак...

Бераздан ишек шакыйлар. Л и д а П л а х а керә.

П л а х а. Булды, Горак әфәнде: сез кушкан эшне үтәдем. *(Сумкасыннан чыгарып, листовкалар суза).*

Ф у ч и к. Рәхмәт, Лида, бу юлы да булдыргансың.

П л а х а. Без биредә кулдан килгәннәрнең бөтенесен эшләрбез, ничек тә түзәрбез. *(Карта янына килеп).* Совет кешеләренең хәле бик читенләшеп китте бит менә. Сөйләгез әле, Горак әфәнде, ул илне чын-чынлап беләсем килә минем. Сез анда үзегез дә булгансыз бит.

Ф у ч и к. Әйе, Лида, ике тапкыр булдым. «Руде право»ның хәбәрчесе идем. Соңгы баруымда ике ел яшәдем. Анда азат хезмәт белән яши торган, кешене кеше җәберләми торган сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзелде, яңа чынбарлык туды. «Бу илнең кичәге көне — безнең иртәгәге көнебез»,— дип уйлый идем мин һәр вакыт. Мин аңа ияләшкән, ул илнең гражданины булган идем инде... Ләкин шуннан соң миңа тагын берничә ун елларга артка, яңа тарихтан иске чорга, иске дөньяга кире кайтырга туры килде.

П л а х а *(кызыксынып).* Ник алай иттегез соң, Горак әфәнде? Ник шунда гына рәхәтләнеп, чын кешеләрчә яшәмәдегез?

Ф у ч и к. Үз халкыбызның көрәшеннән читтә калырга теләмәдем, Лидуша, башкалар яклап алган шатлык һәм бәхет белән генә яшәргә теләмәдем. «Кем тормыш һәм ирек өчен һәр көн сугышка керә, тик шул гына яшәүгә лаек»,— дигән бит Гете!

П л а х а. Әйе, минемчә, шундый кеше генә герой була ала да.

Ф у ч и к. Кем соң ул герой?

Плаха *(уңайсызланып).* Улмы... ул... Я, сез әйтегез инде анысын.

Фучик. Герой — ул, Лида, хәлиткеч моментта гомуми эш өчен, миллионнарның бәхете өчен эшләргә кирәк булганны эшли торган кеше. Безнең заманның герое — ул пролетариат. Геройларны ул һәркайда: хезмәттә, көрәштә, кырыс сынауларда тудыра. Димитровны, Сакко һәм Ванцеттины, 1934 елда Венада фашистик диктатурага каршы героик восстаниедә катнашкан көрәшчеләрне хәтерлик. Буржуазия барыннан да элек үзе турында уйлый. Мәсәлән, 1937 елда гитлерчы агентлар фетнәсе вакытында каты яраланган канцлер Дольфусс үлә. Ул үзенең соңгы сүзендә: «Минем семьям турында кайгыртыгыз!» — ди. Ә шуннан бер генә көн элек Венада шул ук канцлерның боерыгы буенча үлем җәзасына хөкем ителгән яшь социал-демократ, эшче Иозеф Герльны асалар. «Яшәсен азатлык!» — ди ул үзенең соңгы сүзләрендә... Безнең яшерен көрәшебездә дә геройлыклар эшләп буламы? Синеңчә ничек?

Плаха. Әлбәттә, була.

Фучик. Димәк, ялгышмыйсың *(карта янына килеп).* Көнчыгыш фронттагы хәлләр белән танышып барасыңмы соң?

Плаха. Юк шул. «Прожекторат» газеталарын укырга бер дә яратмыйм мин. Ә Советлар Союзының сугышта җиңеп чыгачагына чын күңелемнән ышанам.

Фучик. Лида, үзең партиягә керү, коммунист булу турында хыялланасың. Ә үзең?.. Партия өчен нииндидер кыю, тәвәккәл эш эшләвем дә җитә, дип уйлама. Син бертуктаусыз, армый-талмый укырга тиешсең. Ышану гына җитми, ә белергә кирәк.

Плаха. Ышану гына җитми, ә белергә кирәк. Ышану гына җитми, ә белергә кирәк... *(Сәгатенә карап).* Вакыт соң инде. Мин киттем, Горак әфәнде. Берәр йомышыгыз булса, иртәгә кереп чыгармын.

Фучик. Кер әле, кер. Бик мөһим эш булачак, Лида.

Плаха. Керермен. Хәзергә хушыгыз!

Фучик *(бераз уйланып торгач).* Акрынлап үзгәрә, тормышны аңлый бара бу кызый.

Берәздан ишек шакыйлар. Фучик, паролен сорап, ишек ача. Гонза Черный керә.

Черный. Мине сезгә Гонза Дика җибәрде. *(Кул сузып).* Таныш булыйк — Гонза Черный.

Фучик. Сезнең белән очрашуыма чын күңелдән шатмын.

Черный. Испаниядә сугыштым... Хәер, минем турыда Дика сөйләгәндер инде.

Фучик. Әйе, сөйләде. Без сезгә ышанабыз.

Черный. Намусыма беркайчан да тап төшермәм.

Фучик. Без болай киңәштек: Дика оештыру эшләрен алып барачак. Ә сез урыннарда диверсияләр һәм саботажлар оештыруга җитәкчелек итәчәксез.

Черный. Әйе, без Дика белән дә шулай уйлашкан идек.

Фучик. Беләсез, немец илбасарлары хәзер Советлар Союзына ташландылар. Димәк, безгә дә һөҗүмгә күчәргә, дошманның тылында «кечкенә сугыш» алып барырга, халыкны кораллы восстаниегә хәзерләргә кирәк. *(Листовкалар сузып).* Менә болар белән танышыгыз һәм эшчеләргә җиткерергә тырышыгыз.

Черный. Барысы да ачык. Хәрәкәт итәргә генә кала. Я, мин киттем. Тиздән тагын очрашырбыз. *(Китә).*

Густина керә. Кочаклашып күрешәләр.

Ф у ч и к *(сакалын кулы белән каплап).* Ничек, ошыйммы мин сиңа?

Г у с т и н а *(елмаеп).* Карачкыга охшагансың. Хәер, зарар юк. Иң шатлыклысы — очраштык.

Ф у ч и к. Башлап шуны әйт, әткәй нихәлдә?

Г у с т и н а. Больницадан чыкты, аягы төзәлеп килә.

Ф у ч и к. Яхшы. Үзең ничек килеп җиттең?

Г у с т и н а. Төрлесе булды инде. Прагага җиткәч, башта трамвай белән, аннары җәяүләп, тагын трамвай белән, тагын җәяүләп. Шымчылар күзенә эләкмәс өчен...

Ф у ч и к. Әйе, сак йөри беләсең син, сөеклем. Утыр, әйдә, гаҗәп сагындым үзеңне!

Г у с т и н а. Мин чиксез шатмын.

Ф у ч и к. Биредә мин үземне гаять әйбәт хис иттем. Эшләү өчен вакытым күп булды. Ләкин монда бик озакладым инде. Иозеф Елинектан бүтән берәр квартира табуын үтенгән идем. Ул менә-менә килеп җитәргә тиеш.

Бераз чатанлап, И о з е ф  Е л и н е к керә.

Е л и н е к. Сезнең йомышны үтәдем, Горак әфәнде. Квартира булды. Ләкин чормада йокларга туры килер бәлки.

Ф у ч и к. Гестапода утыруга караганда, бу күп тапкыр яхшырак, Иозеф.

Е л и н е к. Тагын бер ягын әйтим: өстәге катта жандарм яши.

Ф у ч и к *(елмаеп).* Анысы да начар түгел. Сак астында булам, ичмаса.

Е л и н е к. Ә кайчан күченергә уйлыйсыз?

Ф у ч и к. Иртәгә төнлә белән.

Е л и н е к. Мин шушы вакытларда килеп җитәрмен. Башка йомышыгыз юкмы?

Ф у ч и к. Бар. Сезнең трамвайчыларыгызга сәлам хат. *(Яшергән урыныннан алып, листовкалар бирә).*

Е л и н е к. Безнең эшче халык мондый сәлам хатларга бик яхшы карый. Ә тиздән сезне үзебездә көтәбез.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Елинеклар квартирасы. Ул Ваклар квартирасына бик охшаган.

М а р и я. Байларда хезмәтче булудан да авыр эш юктыр дөньяда. Көн буе чабасың, җитмәсә, синең өстеңә әллә нинди пычрак сүзләр ыргыталар. Җир тишегенә керердәй буласың.

Бераз аксап, И о з е ф  Е л и н е к эштән кайтып керә.

И о з е ф. Уф, арыдым, карчык. Кая, ашарга-эчәргә нәрсәң бар?

М а р и я. Хәзер, картым, хәзер, барысы да булыр.

И о з е ф. Трамвайларның бер рәте дә калмады. Көне буе тәмам җәфа чигеп бетәсең.

Звонок шалтырый. М и р е к һәм ирле-хатынлы тагын ике кеше керә.

И о з е ф. Бигрәк мактап йөрисез, дуслар. Әйдәгез, чәй янына узыгыз.

М и р е к. Рәхмәт, рәхмәт! *(Утырышалар).*

И о з е ф. Карчыкка шуны сөйли башлаган идем әле: трамвайларның бер дә рәте калмады. Көн буе тәмам җәфа чигеп бетәсең.

М и р е к. Ә трамвайчыларның кәефе ничек? Безнең сәлам хатларны ничек каршылыйлар?

Иозеф. Эшче халыкны беләсез инде аны, Мирек туган...

Фучик килеп керә.

Мария. Узыгыз, уз, Горак әфәнде. Чәй янына рәхим итегез!

Фучик. Тагын саксызлык. Иптәшләр, сезне күрүемә бик шатмын. Ләкин барыгыз да берьюлы җыйналу кирәкмәс иде. Бу бит туп-туры төрмәгә, үлемгә бару дигән сүз. Конспирация кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Юкса, үзегезне дә, башкаларны да куркыныч астына куясыз.

Барысы бергә. Аңладык, аңладык, Горак әфәнде!

Фучик. Миңа нәрсәләр китердегез?

Иозеф. «Руде право»ның яңа санын.

Фучик. Бик әйбәт. Синдә нәрсә бар, Мирек?

Мирек. Болай, вак-төяк кенә. Эш әйбәт бара.

Мария *(бүлдереп)*. Бик үк әйбәт бармый шул, Мирек энем. Әле генә Лида Плаха килеп киткән иде. Кичә «Юнкерс» заводы ячейкасын тулысынча кулга алганнар, ди. *(Фучикка конверт сузып)*. Менә сезгә Лида калдырган иде.

Фучик *(хатны ачып укыгач, борчылып)*. Әйе, «Юнкерс» ячейкасын тулысынча кулга алганнар. Шул ук саксызлык харап иткәндер. Ярый, әлегә тәмам. Беренче майдан соң очрашырбыз. Үзем хәбәр итәрмен. Хушыгыз!

Мария. Тагын бер генә чынаяк.

Фучик. Юк, юк, пани Елинек, без биредә бик күбәү.

Мария. Ягез инде, тагын бер генә чынаяк. Зинһар дим.

Каты итеп ишек кагалар.

Тыштан тавыш. Ачыгыз! Полиция!

Фучик. Тәрәзәләргә, тиз булыгыз! Качарга! *(Револьверын чыгарып)*. Мин аларны биредә тоткарлап торам.

Ишек артына сыена. Барысы да тәрәзәләргә ташланалар. Ләкин «биредә дә полицейскийлар» дип кинәт кире чигенәләр. Ишекне каерып, 9 полицейский килеп керә. Алар арасында озын буйлы, чандыр чырайлы Иозеф Бем да бар.

— Һенде һох! Кулларыгызны күтәрегез!

Өйдәгеләргә 9 револьвер төзәлә. Фучик ишек артыннан атмыйча кала.

Полицейскийларның берсе. Әһә, тагын берәү... *(Бик каты итеп Фучикның йөзенә суга)*.

Фучик *(аның йөзенә төкереп)*. Тьфу, гестапо эте!..

Бем *(Фучикка ташланып)*. Әһә, башкалардан да бигрәк, менә монысы кызыксындыра иде мине!..

Берничә тапкыр Фучикның йөзенә сугалар. Бүлмә ауган мебельләр, ватылган әйбер белән тула.

Мария. *(янәшә басып торучы иренә)*. Хәзер нәрсә булачак инде?

Иозеф. Үлемгә барачакбыз, Маня!

Мария. Икебез бергә! *(Күтәрелгән кулын җиңел хәрәкәт белән төшереп иренә суза)*.

Иозеф. Әйе, бергә, Маня!

Полицейскийларның берсе. Сөйләшмәскә! *(Елинекларның йөзләренә суга)*.

Мария *(бераз текәлеп карап торгач, ярым көлемсерәп)*. Шундый чибәр егетләр... *(Тавышын көчәйтеп)*. Шундый чибәр егетләр... Ә үзләре нинди ерткычлар...

Полицейский. Эндәшмә! *(Яңадан Мариянең йөзенә суга)*.

Бем *(барысына да ишеккә күрсәтеп)*. Киттек, машина көтә.

Кулга алынучыларны эткәләп-төрткәләп өйдән алып чыга башлыйлар.

Мария *(артына борылып)*. Хуш, гомер иткән газиз оябыз! Без сиңа әйләнеп кайтырбыз әле!..

Панкрау төрмәсенең тоткыннардан сорау алу бүлмәсе. Рәт-рәт итеп тезелгән эскәмияләр. Каршыда — экранга охшаган буш стена.

Б е м. Каты чикләвеккә охшый бу сакаллы шайтан. Юк, мин аны ничек тә ватармын. *(Звонокка баса).* Вослав Дворжак керсен. *(Өстәл тартмасын актарып, газета-журналлар карый).* Бу дәлилләрем белән стенага терәрмен мин аны...

Полицай Д в о р ж а к керә.

Д в о р ж а к *(баш иеп).* Тыңлыйм сезне, пан Иозеф Бем!

Б е м. Утырыгыз.

Д в о р ж а к. Рәхмәт!

Б е м. Шулай, Дворжак, сез моңарчы безгә әйбәт хезмәт иттегез. Ярдәмегез белән «Юнкерс» ячейкасын һәм Елинеклар адресын кулга төшердек. Моннан соң да исән калырга, иректә йөрергә теләсәгез, бу юлы да дөресен генә сөйләгез.

Д в о р ж а к. Минем сезне беркайчан да алдаганым юк.

Б е м. Шуның өчен сезгә ышанабыз да. *(Өстәл тартмасыннан фото чыгарып).* Сез бу кешене таныйсызмы?

Д в о р ж а к. Әйе, таныйм.

Б е м. Кем?

Д в о р ж а к. «Руде право» редакторларыннан берсе — Юлиус Фучиков.

Б е м. Котимерж авылында качып яшәдеме?

Д в о р ж а к. Эзләп барган идем, очрата алмадым. Ләкин шунда ук тиешле җиргә хәбәр иттем.

Б е м. Соңгы вакытларда ул Вакслар квартирасында качып яшәгән. Сез бу турыда ишеттегезме?

Д в о р ж а к. Әйе, ишеттем. Әмма эзенә төшәргә соңладым.

Б е м. Алай булгач, мин сезне аның белән күзгә-күз очраштырыйм.

Д в о р ж а к. Юк-юк, кирәкми. Зинһар дип әйтәм, кирәкми. *(Бем алдына тезләнеп).* Бу турыда ул бер нәрсә дә белмәскә тиеш... Мин сезгә әле тагын кирәк булачакмын.

Б е м *(өстәл тартмасыннан фото алып).* Ә бу кешене таныйсызмы?

Д в о р ж а к. Әйе, таныйм. Гонза Дика бу. Фучиков белән бергә эшләгән кеше.

Б е м. Вакслар квартирасына килеп йөрдеме?

Д в о р ж а к. Үзем күрмәдем. Ишетүемә караганда, әйе, килеп йөргән.

Б е м *(өстәл тартмасыннан тагын фото алып).* Ә бусы кем?

Д в о р ж а к. Гонза Черный.

Б е м. «Юнкерс» заводында хуҗалык эшендә эшләгәндә сез бу кешеләрне эшчеләр арасында очратмадыгызмы?

Д в о р ж а к. Әйе, очраттым. Эшчеләр арасында да, ячейка секретаре белән бергә дә берничә тапкыр очраттым. Ишетүемә караганда, июнь аенда алар Вакслар квартирасына килеп йөргәннәр, аннары безнең күрше заводларда да берничә тапкыр очрашканнар. Шуннан соң озак та үтмәде, заводларда берничә диверсия булды, немец гаскәрләренә озатыласы сугыш припаслары шартлатылды.

Б е м. Әйе, анысын беләбез. *(Дворжакның кулын кысып).* Тырышлыгыгыз өчен зур рәхмәт! Сез хәзергә азат була аласыз. Кирәксәгез, тагын чакыртырмын.

Д в о р ж а к. Мин һәр вакыт әзер. *(Яшерен ишектән чыгып китә).*

Б е м *(звонокка басып).* Сакаллы шайтанны алып керегез! *(Газета-журналлар караштырып).* Әйе, бу дәлилләрем белән ничек тә стенага терәрмен мин аны...

Ф у ч и к н ы алып керәләр. Аның бер беләгенә кызыл чүпрәк бәйләнгән.

Б е м *(тупас кычкырып).* Алдашкансың. Хәзер барысы да билгеле булды. Син укытучы Горак түгел, ә без уйлаганча, «Руде право»ның бер редакторы... Котимержда, аннары Ваксалар квартирасында качып яткансың. Шулай итеп, син оттырдың, барыгыз да оттырдыгыз.

Ф у ч и к. Юк, мин генә оттырдым.

Б е м *(ярсып).* Ә алаймы? *(Фучикның сакал бөртекләрен йолкып алып, шаркылдап көлә).* Менә нинди көнгә калдың син, пане редактор... *(Йомшарган булып).* Нигә үзеңне бер дә якламыйсың? Йөрәгең юк синең...

Ф у ч и к *(горур).* Ә шулай да хәтта тырнак очларымнан кан тамып торганда да тез чүгәргә уйлаганым юк әле.

Б е м. Я, ярый, аңлашуны дәвам иттерик. Үзәк Комитетта синнән башка тагын кемнәр бар иде?

Ф у ч и к. Беркемне дә белмим.

Б е м. Юк, беләсең. Синең янга, Ваксалар квартирасына ике подпольщик килеп йөргән.

Ф у ч и к. Мин анда беркем белән дә очрашмадым, беркемне дә күрмәдем.

Б е м. Хәзер күрерсең. *(Звонокка басып).* Гонза Дика белән Гонза Черныйны кертегез.

Б е м *(Фучикны күрсәтеп, икесенә дә).* Сез бу кешене танысызмы?

Т о т к ы н н а р. Юк, танымыйбыз.

Б е м. Ә танымагач, Ваксалар квартирасында ничек аның белән очраштыгыз?

Т о т к ы н н а р. Без беркайда да, беркем белән дә очрашмадык.

Б е м. Ялганлыйсыз. «Юнкерс» һәм күрше заводларда кемнәр белән очрашып йөрдегез? Герман гаскәрләренә озатыласы сугыш припасларын шартлатуны ничек оештырдыгыз?

Г о н з а Ч е р н ы й. Моны исбат итәргә сезнең дәлилләрегез юк.

Г о н з а Д и к а. «Сандугачны тотканда аны җыр белән алдыйлар»,— ди халык мәкале. Ә сезнең сайравыгыз, сезнең җырыгыз дәреслеккә бер дә туры килми бит, тикшерүче әфәнде...

Б е м *(ярсып).* Җитте! Әзегезгә төшәрләр. Барысы өчен дә башларыгыз белән җавап бирерсез. *(Звонокка басып, полицейскийларга).* Камераларына озатыгыз!

Тоткыннарны алып чыгып китәләр.

Я, пане редактор, аңлашуны тагын дәвам итик.

Ф у ч и к. Мин әзер.

Б е м. Тормышыгыз кадерле булса, яшерми сөйләгез. Радиотапшыргычларыгыз, типографиягез кайда?

Ф у ч и к. Нинди типографиям булсын минем?

Б е м *(листовкалар, газета-журналлар күрсәтеп).* Ә боларны кайда бастыгыз? Синең эшнең очы, ай-һай, тирәнгә китә бит. Ике тапкыр Советлар Союзында булгансың. Аннан кайткач, шәһәрдән шәһәргә, заводтан заводка йөреп, ул ил турында докладлар сөйләгәнсең.

Ф у ч и к. Нәрсә, чынбарлык турында, хакыйкать турында сөйләү дә гаепмени бездә?

Б е м. Сабыр ит, сабыр ит, эшнең асылына хәзер җитәбез. *(Өстәл тартмасыннан «Творба» журналын чыгара).* СССРга мәхәббәтең, аның эшләренә хәйран калуың турында бу мәкаләне син яздыңмы?

Ф у ч и к. Әйе, мин яздым.

Б е м *(булеп-булеп укый).* «Мин ике елга якын СССРда яшәдем... Социализм идеяләре белән сугарылдым... Мин инде социалистик илнең гражданины булган идем...» Бу ни дигән сүз? Бу нәрсәне аңлата?

Ф у ч и к. Мин рухым, җаным белән үземне хәзер дә шулай хис итәм.

Б е м. Димәк, син ул ил файдасына эшләгәнсең һәм эшлисең.

Ф у ч и к. Моны исбат итәргә сезнең дәлилләрегез юк һәм беркайчан да булмас та.

Б е м. Син ни генә дисәң дә, мин үз фикеремдә калам. Бу — бөтен полиция идарәсе фикере. *(Папирос кабыза. Бераз ишекле-түрле йөргәч, өстәл тартмасыннан «Руде право» газетасын чыгара).* Менә тагын бер документ. 1936 елгы газетагыз. Бу рәсемнәрне танысыңмы?

Ф у ч и к. Әйе, таныйм. Мадрид пролетарийларының стадионда уйнап йөргән алтмыш баласын империя бомбалары өзгәләп ташлаган.

Б е м. Сугышта төрле хәлләр була. Ә син менә нәрсәләр язгансың. *(Укый).* «Бу коточкыч документларны алыгыз да... алар белән кешедән кешегә йөрегез, алар белән өйдән өйгә йөрегез... Хәрәкәт итегез, һич кичекмәстән хәрәкәт итегез. Бу фаҗига Испаниядә дәвам итә алмасын һәм яңадан турыдан-туры безнең күз алдыбызда кабатлана алмасын...» Димәк, син халыкны турыдан-туры хөкүмәтебезгә һәм өченче империягә каршы күтәрелергә чакыргансың.

Ф у ч и к. Испания фаҗигасының кабатланмавын теләдем мин. Ә ул хәзер бездә дә кабатлана...

Б е м. Син һаман киреләнәсең. *(Звонокка баса).* Хатынын кертегез! Уйладым-уйладым да, мәрхәмәт күрсәтеп, сезне очраштырырга булдым.

Г у с т и н а *(Фучикка таба омтылып).* Юлий, син дә исән икәнсең бит. Биредәге газаплауларга түзә алмыйча, асылынып үлгән дигән нәр иде ич сине.

Ф у ч и к. Юк, Густина, үләргә җыенмыйм әле мин. Тагын кырык еллар чамасы яшисе иде әле.

Б е м. Яшәргә кирәк, яшәргә. *(Густинага).* Үгетләгез үзен, тиргәгез, акылга утырсын бераз. Инде үзе хакында уйларга теләми икән, сезнең хакта уйласын. Әгәр дә ул һаман киреләнсә, без аны бүген үк атачакбыз. *(Густина дәшмәгәч).* Атлагыз. Бу соңгы тапкыр күрешүегез булыр.

Г у с т и н а *(Фучикка ягымлы елмаеп).* Хәзергә хуш, Юлий!

Ф у ч и к. Хуш, Густинам, хуш!

Б е м *(пистолетын чыгарып).* Атлагыз диләр сезгә!

Густинаны алып чыгып китәләр.

Ф у ч и к. Әнә шундый ул минем Густинам — мәхәббәте дә, көче дә шундый аның!

Б е м *(звонокка басып).* Әнисен кертегез!

А н а. Тыңлыйм сезне.

Б е м. Улыгыз һаман киреләнә. Үгетләгез үзен. Тормышын кызганса, сезнең турыда, хатыны турында уйласа, акылга килсен бераз.

А н а. Ул бит сабый түгел. Үзе өчен үзе җавап бирә белер.

Б е м. Соңлаганчы уйлашыгыз, уйлашыгыз. Мин икегезне генә калдырам. *(Яшерен ишектән чыгып китә).*

А н а *(стенага чәчрәгән канны күреп).* Бу соң, улым, синең канмы?

Ф у ч и к. Әйе, әнкәй, минем каным, димәк, синең каның. Анда безнең нәфрәт яна.

Б е м керә.

Б е м. Я, киңәштегезме?

А н а. Мин үз сүземне әйттем инде сезгә. Ул сабый түгел. Үзе өчен үзе җавап бирә белер!

267 нче камера. Кысан. Агач идән. Кап-кара авыр ишек. Югарыда тимер рәшәткәле кечерәк тәрәзә. Фучик салам түшәктә йөзтүбән ята. Иозеф Пешек һәм Карел Малец ашап утыралар.

Малец. Әткәй, әткәй! Үлә бит бу бичара. Ничә көн инде тамагына бер нәрсә капканы юк.

Фучик *(башын күтәреп, карлыккан тавыш белән).* Юк, үлмим әле, туганнар. Яшәргә, озак яшәргә телим әле мин. Бик сусаганмын. Бераз су юкмы шунда?

Пешек. Бар, бар. Мәгез, эчеп җибәрегез, бераз хәл кереп китмәсме.

Фучик. Рәхмәт сезгә! Сез кем буласыз, агай? *(Торып утыра).*

Пешек. Иозеф Пешек.

Фучик. Моңарчы кем идегез?

Пешек. Бөтен гомерем буе балалар укыттым, өлкән укытучы идем.

Фучик. Бу зинданга ни өчен эләктегез?

Пешек. Иректе чех мәктәбе турындагы проектны хәтерлисезме?

Фучик. Хәтерлим, хәтерлим.

Пешек. Шул уңай белән «Германия империясенә каршы заговор»да гаепләп кулга алдылар.

Фучик. Бирегә күптәнме?

Пешек. Сиксән биш көн инде.

Фучик. Алай икән, алай икән. *(Икенче тоткынга).* Ә сез кем буласыз, туган?

Малец. Карел Малец.

Фучик. Кайдан, нинди хезмәттә идегез?

Малец *(Фучикның беләгендәге кызыл чүпрәккә карап торгач).* Сез коммунистмыни?

Фучик. Әйе, коммунист. Бөтенесен дә ачыктан-ачык сөйли аласыз.

Малец. Гудлиц янындагы бер шахтада машинист булып эшли идем мин. Яшерен оешма өчен шуннан шартлаткыч матдә алып чыкканда тотылдым. Инде менә ике елдан артык бирегә газап чигәм. Бүген-иртәгә судка алып китәчәкләр. Бәлки Берлинга ук озатырлар.

Фучик. Семьягыз бармы?

Малец. Хатыным, ике балам. Их, шундый ярата идем мин аларны...

Фучик *(ягуарә басып, икесенә дә).* Аңлыйм мин сезне, туганнар, бик аңлыйм. Болай озак бармас. Хакыйкать барыбер тантана итәр.

Пешек *(рухланып).* Без дә шулай булыр дип ышанабыз.

Малец. Барыбызның да өмете шундый.

Төрмә күзәтчесе керә.

Күзәтче. Иозеф Пешек, сине допроска чакыралар. *(Малецка).* Ә сине — канцеляриягә!

Фучик *(камерада үзе генә калгач акрын йөренеп).* Ишектән тәрәзәгә җиде адым, тәрәзәдән ишеккә җиде. Беренче май демонстрациясендә полицейскийлар, резина таяк белән сугып, алгы тешләремне койган елны мин бирегә бер тапкыр утырган идем инде. Чех промышленниклары һәм сәүдәгәрләре политикасының халыкка нинди һәлакәт китергәнен бик ачык итеп күрсәтүем өчен утыртканнар иде мине бирегә. Менә хәзер минем халкымны җәзалыйлар... *(Бераз уйланып торгач).* Кешелеккә прогресс юлына чыгу өчен ничә мең төрмә камерасы аша үтәргә туры килде икән? Тагын ничә камера аша

үтәсе бар? Ахыры күренми әле. Шулай да, ничек кенә булмасын, дөнья уянды, хәзер инде ул йокламый!

Ишек ачыла. Күзәтче Карел Малецны алып керә.

Күзәтче *(Малецка)*. Тизрәк җыен, тизрәк.

Малец *(ашыга-ашыга әйберләрен җыештыра, Фучик янына килеп)*. Мине озаталар. Ах, кызганыч, сезне бик соң очраттым. Я, хушыгыз! *(Фучикны кочаклап үбә)*. Бәлки очрашырбыз әле...

Күзәтче тоткынны алып чыгып китә.

Фучик. Хушыгыз, туган, хушыгыз! *(Бераз уйланып йөргәч)*. Аны бит башка төрмәгә яки концлагерьга, җәзалау урынына алып киттеләр.

Иозеф Пешек кайтып керә.

Пешек *(гаҗәпләнеп)*. Карел кайда?

Фучик. Аны әле генә алып чыгып киттеләр.

Пешек. Димәк, озаталар. Кызганыч, саубуллаша алмый калдым. Эшче кеше, әйбәт кеше иде ул. Биредә кешеләр әнә шулай, суга төшкән кебек югалалар.

Фучик. Шулай икән шул. Карел урынына инде менә мин калдым. Мин дә сезне «әткәй» дим.

Пешек. Сезнең белән булуыма мин чын күңелемнән шатмын.

Төрмә коридорыннан Иозеф Бем үтеп китә.

Фучик. Сез бу бәндәне беләсезме, әткәй?

Пешек. Юк шул, белмим.

Фучик. Иозеф Бем дигән явыз бу. Моннан ун ел элек «Флора» кафесында официант булып эшли иде. Кафеда ашап-эчеп алгач, кулыбыздагы көмеш акча белән өстәл шакырга торганда гына, янымызга тавыш-тынсыз гына, урындыклар арасыннан йөзеп кенә килә дә, күз ачып-йомганчы санап бирә иде. Аның җитез һәм шау-шусыз хәрәкәтләре нәкъ ерткычныкы шикелле, күзләре дә ерткычныкыдай җитез, барын да күреп өлгерә иде ул.

Пешек. Алай икән. Ә шуннан соң?

Фучик. Шуннан соң ул «протекторат»ның баш министры Беран иярченнәре яшерен киңәшмә үткәрә торган «Наполеон» кафесында официант булып эшләгән. Беран яки «протектор» Гейдрих хәбәр итмәгән нәрсәләрне Гитлерга Бем үзе җиткереп торган... Менә шушы бәндәгә хәзер минем эшемне тикшерүне, язмышымны хәл итүне тапшырганнар. Ярый, көрәшеп карыйк.

Пешек. Әйе, авыр көрәш бу.

Фучик. Беләм, җиңел түгел. Аларның хәйләләреннән башка, кулларында балталары да бар... Ә без коралсызмыни, без көчсезмени?! Юк, түгел! Безнең җиңүчән идеябез, якты идеалларыбыз бар. Аларны беркем дә, беркайчан да үтерә алмас... Болгар шагыйре Никола Вапцаровның әсәрләрен укыганым бар иде минем. Үткән ел аны, биш коммунист белән бергә, София тоннеленда фашистлар атып үтергәннәр. Аның фашистларга нәфрәт белән язган бер шигыреннән шундый юллар истә калган. «Безнең идеалларыбызны, безнең ышанычыбызны үтерә ала торган пуля әле коелмаган, әле коелмаган!» — ди ул.

Пешек. Җаным белән сизеп торам, көрәштә туган шигырь бу.

Фучик. Әйе, әткәй, һәртөрле бөек сәнгать көрәштән үсеп чыга... Иң бөек сәнгать — мәхрүм ителүләр ачысын татыган кешеләр сәнгате. Мондый әсәрләр йөрәк каны белән, көрәштә алган яралардан ага торган кан белән языла. Кешеләрне көрәшкә, якты әйди

торган чын сәнгать әсәрләре бары тик шулай гына туа. Үзебезнең Иржи Волькер шигырен генә хәтерлик. Ул, үзенең тормыштагы урынын билгеләп, менә нинди юлларны яза:

Ты больше, чем сердце, свяжи его туже,
Не будь побежденным своим же оружьем.
И боль победи и не думай над болью,
Будь вечно в бою, никогда — после боя!

Пешек. Әйе, мәгънәле әйткән: «Будь вечно в бою, никогда — после боя!»

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Төрмә коридоры. Ике яклап камералар тезелеп киткән. 267 нче камера бер читтә, аның эчке ягы да күренеп тора. Төрмә күзәтчесе Адольф Колинский Фучикны камерага озата килә.

Колинский *(камера ишеге төбендә Фучикның кесәләрен тентегән булып).* Эшләрегез ничек?

Фучик. Белмим. Тиздән атачакбыз диделәр.

Колинский. Бу карар сезне куркыттымы?

Фучик. Мин аңа әзер.

Колинский *(Фучикның пиджак чабуларын капшаган булып).* Шулай итүләре бик ихтимал. Бәлки бик тиз атмаслар әле. Бераз сабыр итеп торырлар... Ә бәлки бөтенләй берни дә булмас... Шулай да мондый вакытта... әзер тору яхшырак...

Фучик. Мин дә нәкъ шулай уйлыйм.

Колинский. Бәлки... Иректәгеләргә ни дә булса тапшырасыгыз бардыр? Бәлки ни дә булса язарга телисездер?

Фучик. Әйбәт булыр иде. Хәзер булмаса, киләчәктә кирәгегез чыгар.

Колинский. Бирегә ничек эләктегез, берәрсе тотып бирде мәллә?.. Кемнәр үзләрен ничек тоттылар?.. Белгән нәрсәләрегез үзегез белән һәлак булмасын... *(Китә).*

Фучик *(уйланып).* Тукта, кем бу?! Ни дә булса язарга телимме? Ул минем иң ялкынлы теләгемне ничек сизеп алган? Тозакмы бу, әллә чынлапмы? Ышана алырлык кеше булса, искиткеч яхшы булыр иде бу...

Колинский килә.

Колинский *(яшереп кенә кәгазь һәм карандаш суза).* Сез мине белмисез, мин сезне белмим. Сак булыгыз! *(Китә).*

Фучик *(камерада кәгазь һәм карандашны яшергәч, бераз гаҗәпләнеп).* Мондый вакытта кешегә ярдәм кулы сузу өчен нинди зур ихтыяр көченә ия булу кирәк! *(Яңадан төрмә коридорына чыга).*

Шул ук коридордан Лида Плаха үтеп бара.

Плаха *(Фучикны күреп).* Биредә миңа да эш табылды бит әле, Юлиус абый!

Фучик. Шулаймы, Лида? Нинди эш?

Плаха *(елмаеп).* Коридор хезмәтчесе иттеләр бит.

Фучик. Әйбәт булган ул. *(Колагына).* Элемтәне өзмәс өчен дим.

Плаха. Әйе, әйе, элемтәне өзмәс өчен.

Фучик. Бергә озак булырга ярамый безгә. *(Камерасына кереп китә. Коридорда Мария Елинек Лида Плаха белән очраша).*

Плаха. Хәлегез ничек, пани Елинек?

Елинек. Әлегә бирешмим.

Плаха. Борчылмагыз, сез кулга алынган көнне мебельләрегезне кем урлаганын һәм аларның кайда икәнлеген белгәннәр.

Е л и н е к. Мебельләр турында уйламыйм әле мин, Лида. Аңа вакыт әрәм итеп торасы юк. Аннан мөһимрәк эшләр бар бит әле. Башта шуларны хәл итәргә кирәк, ә соңыннан, әгәр исән калсам, өйне мин үзем дә тәртипкә китерермен.

П л а х а. Бик дөрес әйтәсез, пани Елинек.

Е л и н е к. Күрәсез, биредә кешеләр бик тиз югала. Безнең белән дә әллә нинди хәлләр булуы ихтимал... Булдыра алсагыз, иректә йөрүчеләргә әйтегез, мине кызганмасыннар, үзләрен куркытуга юл куймасыннар. Мин, эшче буларак, үз бурычымны үтәдем. Һәм аңа хыянәт итмичә үләрмен дә. *(Китә).*

П л а х а. Менә нинди әйбәт кеше икән бу пани Елинек. *(Китә).*

Камерага төрмә парикмахеры белән И о з е ф  П е ш е к кайтып керә.

П е ш е к *(Фучикка).* Улым, мин биредә күптән «үз кеше» булып киттем инде. Менә, канцеляриядән сорап, синең янга чәч алучы чакырдым. Сакал-мыегыңны рәткә китерсен әле.

Ф у ч и к. Рәхмәт, әткәй, рәхмәт! *(Төрмә парикмахерына).* Сезне борчуыбыз өчен гафу итегез инде.

П а р и к м а х е р *(ул ябык, алҗыган тоткын).* Биредә минем эшем шул бит, үзем кебек тоткыннарга хезмәт күрсәтү.

Ф у ч и к. Бик әйбәт эш бу.

П а р и к м а х е р. Ягез әле, алайса, бер яшәртеп җибәрим үзегезне. *(Урындыкка утыртып, Фучикны кыра башлый. Куллары калтырый).* Бритвам бик үк үткен түгел шул. Читен булса да, түзегез инде.

Ф у ч и к. Каушамагыз, туган. Печек сараенда сорау алу вакытындагы газаплауларга түзгәнне сезнең бритвагызга гына ничек тә түзәрмен...

П а р и к м а х е р *(Фучикның сакалын кырып бетергәч).* Булды бу, туган. Ким дигәндә, ун-унбиш яшькә яшәреп киттегез.

Ф у ч и к *(кулын кысып).* Хезмәтегез өчен зур рәхмәт сезгә!

П а р и к м а х е р. Кирәк булсам, тагын чакырырсыз. *(Саубуллашып чыгып китә).*

Коридордан Лида Плаха үтеп китә.

П е ш е к. Бу коридор хезмәтчесе Лида Плаханы әйтәм әле: ул, чынлап та, акылга бераз җиңелрәк мәллә?

Ф у ч и к. Юк, әткәй, алай түгел. Сездән яшермим, болай йөрүенең сере бар аның.

П е ш е к. Төшендем, төшендем.

Ф у ч и к. Хәтеремдә әле: турыдан-туры Үзәк Комитетта партия сафларына алгач: «Хәзер мин үзем өчен яшәмим»,— дигән иде ул. Шуннан соң иң авыр эшләрдә дә сынатмады. Утлар аша үткәндә үзенең иң нык металлдан ярагылган булуын күрсәтте. Хәзер дә нәкъ шулай эш итә.

Скорепа тоткыннарга «кара кофе» һәм икмәк өләшеп йөри башлый. 267 нче камера янына туктала.

С к о р е п а *(ишекне шакып).* Иртәнге ашыгызны алыгыз.

Ф у ч и к. Хәерле иртә, Скорепа абзыкай!

С к о р е п а. Хәерле иртә, туганкай! *(Фучикка кофе һәм өч кисәк икмәк сузып).* Тизрәк терелегез!

Ф у ч и к. Рәхмәт, рәхмәт!

С к о р е п а *(тагын кофе һәм икмәк сузып).* Болары — Иозеф Пешекка *(як-ягына каранып).* Барысы да тәртиптә, *(Фучикның кулын нык итеп кыса).* Тизрәк терелегез! *(Китә).*

Ф у ч и к. Бередә гади кул кысышу да яки яшерен генә папирос бирү дә төрмә читлегенең тимерләрен каера, кешене коточкыч явызлыктан коткара... Бу туганлык канга батып үлсә үләр, ләкин җиңелмәс.

*Кулындагы әйберләрен камерага тиз генә кертеп чыга. Лида Плаха коридордан үтеп барышлый яңадан Фучикны очрата.*

П л а х а. Юлиус абый, кичә туганнарым белән очраштым. Тиздән Берлинга, судка озатылачагыбызны белгәч, әнием миңа шундый итеп карады, бөтен кайгыларым таралгандай булды. «Лидушка, — диде ул, — кайгырма, сез әйләнеп кайтырсыз. Әгәр кайтмасагыз, сез моның нәрсә хакына икәнен, нәрсә хакына үлемгә баруыгызны беләсез». Их, ничек итеп әйтте ул моны! Ә үзе бит гомере буе эштән башка бернәрсә дә күрмәгән гади хатын гына.

Ф у ч и к. Әйе, гади кешеләрдә олы йөрәк бар, Лидуша. Алар безнең киләчәгебезнең якты булачагына ышаналар. Чыннан да, сез, яшьләр, кайтырсыз. Киләчәк — сезнеке.

П л а х а. Әйе, киләчәк безнеке, Юлиус абый! *(Фучикның колагына пышылдый).* Елинекларны яңа гына каядыр, икесен ике якка алып киткәннәр... Гонза Дика белән Гонза Черныйны да җәзалап үтергәннәр... *(Китә).*

Ф у ч и к *(залдагыларга).* Бу көннәрне үткәреп, җирдә исән калган кешеләрдән мин бер генә нәрсәне үтенәм: Онытмагыз! Яхшыларны да, явызларны да онытмагыз! Бу көрәштә һәлак булган кешеләр сезгә дусларыгыз, туганнарыгыз кебек якын булсын. Бу газаплардан соң безгә яңадан очрашырга туры килсә, безнең ничек яшәвебезне сез күз алдыгызга китерә аласызмы? Ирек һәм иҗат нуры белән яктыртылган тормышта яшәү! Хыялларың, омтылышларың гамәлгә ашканнан соң яшәү! Без бит әнә шул хыялларыбыз, шул омтылышларыбыз өчен бүген үлемгә барабыз. Ләкин без үлгәннән соң да сезнең бөек бәхетегезнең бер кисәгендә яшәрбез. Шатлыгыбыз әнә шундый. Ә шулай да аерылышу авыр...

*Коридордан Пешек килә, алар камерага кереп китәләр.*

Ф у ч и к *(тәрәзәгә төбәлеп торгач).* Тышта нинди матур яз! Мин язны, чәчәкләрне, кыңлекне, кояшны ярата идем, әткәй. Фашизм безне боларның бөтенесеннән дә мәхрүм итәргә тели. Әнә безнең тимер рәшәткәле тәрәзәбез төньякка карый. Без кояш нурларын бары кич белән бик аз гына күреп калабыз. Юк, болай озакка бармас бу! Кояш булыр, әйе, ул балкыр. Һәм кешеләр аның тылсымлы нурларында коенып яшәрләр.

П е ш е к. Әйе, моның шулай булачагына ышану — зур бәхет, улым!

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Шул ук сорау алу бүлмәсе.*

Б е м *(елмаеп).* Әйе, байтактан күзәтеп йөри идем мин сине. Инде менә кулга алындың. *(Тәрәзә пәрдәләрен ача).* Күр әнә, тирә-якта нәрсә дә булса үзгәргәнме? Кешеләр һаман, элекке кебек үк, йөриләр, көләләр, мәшәкатьләнәләр. Алар арасында синең әсәрләреңне укучылар да бардыр. Менә хәзер уйла инде, сине юксынудан йөзләренә, ичмасам, бер генә җыерчык булса да өстәлгәнме соң?

Ф у ч и к. Өстәлмәсен. Кешеләр һәр вакыт яшь булсыннар.

Б е м. Мин беләм, син Праганы яратасың. Шунда яшисең килмимени соң? Нинди матур бит ул!

Ф у ч и к *(рухланып).* Әйе, җәйге төндә, якынлашып килгән көз томаны белән уратылган Прага, өлгереп килә торган виноград шикелле, күгелҗемләнеп күренә. Бу гаҗәеп матурлыкка мин гасырлар буе карап торыр идем.

Б е м. Син үлгәч тә ул шундый ук матур булып калачак.

Ф у ч и к. Сез юк ителгәч, ул тагын да матурлана төшәр!

Б е м. Әдәпсез икәнсең.

Ф у ч и к. Хакыйкатьне әйтү — әдәпсезлек түгел.

Б е м. Сез юк ителгәч, дисең, ә? Димәк, син безнең җиңүебезгә әле һаман да ышанмыйсың.

Ф у ч и к. Бу турыда күп тапкырлар әйттем бит инде. Әйе, ышанмыйм.

Б е м. Ярый, яңадан дәлилләргә күчик. *(Өстәл тартмасыннан «Творба» журналын чыгара).* Менә синең үзеңне укыткан Прага университеты галимнәренә язган хатың. *(Укый).* «Мин — коммунист. Һәм сезгә белдерү өчен шуны әйтәм: мин ярдәм итәргә сәләтле бердәнбер властьны кайдан эзләргә беләм, илебезне коткарып калырга сәләтле бердәнбер көчне кайдан табарга беләм, азатлыкка илтә торган бердәнбер юлны беләм... Мин сезгә ендәшмәгәнегез өчен мөрәҗәгать итәм. Чехословакия республикасында жандармнар нибары өч ай эчендә генә дә эшчеләргә ике тапкыр аттылар... Ә сез һаман тавышсыз-тынсыз...» *(Укуыннан туктап).* Димәк, бу юлы син чех интеллигенциясен хөкүмәтебезгә каршы куярга тырышкансың.

Ф у ч и к. Мин гаделсезлеккә каршы чыктым, кешеләргә чынбарлыкны, хакыйкатьне әйтеп бирергә теләдем.

Б е м *(өстәл тартмасыннан листовка чыгара).* Ә бусы нәрсә тагын? Өченче империягә каршы бу листовканы язу һәм бастыруны син оештырдыңмы?

Ф у ч и к. Күргәнем дә, белгәнем дә юк.

Б е м. Геббельс әфәнде чех интеллигентларын Берлинга чакыртып киңәшергә, аларга хөрмәт күрсәтергә булган. Ә сез... коммунистлар...

Ф у ч и к. Юк, без андый хөрмәткә мохтаҗ түгел.

Б е м. Мохтаҗ булмасагыз, барысы өчен башыгыз белән түләрсез.

Ф у ч и к. Менә шулай, Бем әфәнде. Сез чех коммунистларын кырасыз. Сез, аларның һәркайсы белән бергә, немец халкының киләчәккә булган өметенең бер өлешен үтерәсез...

Б е м *(бүлдереп).* Я, дәлилләрдән читкә китмик әле. *(Листовканы укып).* «Геббельс әфәнде, бу шундый шаяру, аңа яңакка чалтырату белән җавап бирәләр». Сез, коммунистлар, һай-һай, биеккә сузылырга уйлыйсыз. Ләкин буегыз җитмәс шул.

Ф у ч и к. Вакыты җиткәч, моны халык үзе эшләр.

Б е м. Ялгышмасам, шагыйрь Ян Неруда турында синең мәкаләң дә бар бугай?

Ф у ч и к. Әйе, бар. Безнең бөек шагыйребез ул.

Б е м *(күрсәтеп).* Димәк, аның бу шигыре листовкага синең аша килеп кергән.

Ф у ч и к. Ул моңарчы да күп тапкырлар басылып чыкты, аны бөтен халык белә. Мин аны хәзер дә кабатлый алам. *(Күңелдән укый).*

> Мы все, что с нами будет, ожидали.
> Мы не страшились бури и невзгод.
> Мы с чешскою судьбою себя связали,
> И с ней — вперед, и только лишь вперед!

Б е м *(тузынып).* Нәрсә син, биредә театр мәллә?

Ф у ч и к. Шулай да, укып кына бетерим инде.

> Мы родились под бури грохотанье,
> К великой цели через мрак и грязь

Проходим шаг за шагом испытанья,
Лишь перед своим народом преклонясь.

Б е м. Димәк, Ян Неруда шигырьләре листовкага синең аша килеп кергән. Димәк, листовканы язуны һәм бастыруны син оештыргансың. Менә шулай, боргаланыр урының калмады бит инде. Я, ачык итеп әйт әле, бу хәрәкәтләрең белән империя дошманына — большевиклар Россиясенә булышуыңны икърар итәсеңме?

Ф у ч и к. Әйе, хәзер ачык әйтәм: Советлар Союзына ярдәм иттем, Кызыл Армиягә ярдәм иттем. Һәм мин моны кырык еллык гомерем эчендә башкарган иң яхшы эшем дип, изге эшем дип саныйм.

Б е м *(гаҗәпсенеп)*. Синең башың да кызганыч түгел, ахры. Судта да болай сөйләнсәң, шунда ук маңгаеңа — пуля.

Ф у ч и к. Әйе, судта да шулай сөйләячәкмен. Беләм, анда мине үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ә мин сезгә хөкем карарын күптән чыгардым. Ул дөньядагы миллионнарча кешеләрнең, барлык намуслы кешеләрнең каны белән язылган. «Фашизмга — үлем! Капиталистик коллыкка — үлем!» диелә ул карарда.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шул ук 267 нче камера. Фучик белән Иозеф Пешек икәү.

Ф у ч и к. Шулай, әткәй, эшем буенча тикшерү бетте. Минем белән бергә Лида Плаха һәм Мирек гаепләнәләр. Мине дәүләткә алты тапкыр хыянәт итүдә, герман империясенә каршы заговорда, коралллы восстание хәзерләүдә гаеплиләр... Беләсез, әткәй, үз гомерем, шулай ук иптәшләремнең гомере өчен мин унөч ай буе көрәштем, кыю да булдым, хәйләкәр дә булдым. Дошманнарым мине хәйлә белән эләктерергә тырыштылар. Ләкин мин ул капкынга эләкмәдем. Бу уенда минем оттыруымның сәбәбе шунда гына: хәйләләреннән башка аларның кулларында балталары да бар.

П е ш е к. Их, улым, совет гаскәрләре тизрәк килеп җитсә, котылып та калган булыр идең бәлки.

Ф у ч и к. Әйе, әткәй, һәркайсыбыз сугыш барышына карап өметләнәбез. Үлем белән тормыш көрәшә. Кайсыбыз элегрәк үләр — фашизммы, әллә безме? Дөньядагы миллионлаган кешеләр бирә бу сорауны. Фашизм җиһанны дәһшәт белән тутырды, бу дәһшәт һәркемгә үлем белән яный.

П е ш е к. Чынлап та, нәрсә белән бетәр бу?

Ф у ч и к. Халыклар үз сүзләрен әйтерләр, әткәй. Әгәр миннән соң бер корбан да булмаячагын белсәм һәм фашизмның һәлакәтен тизләтә алсам, мин, бер минут та уйлап тормыйча, үлемгә шатлана-шатлана барыр идем, әткәй.

П е ш е к *(Фучикны кочаклап)*. Нинди олы йөрәкле кеше син, улым!

Каты итеп ишек шакыйлар.

Т ө р м ә к ү з ә т ч е с е. Иозеф Пешек, сине төрмә начальнигы чакыра.

П е ш е к. Миннән тагын нәрсә кирәк икән инде аларга? *(Чыга)*.

Ф у ч и к *(ишек артында эленеп торган каешны күрсәтеп)*. Бу — минем каешым. Димәк, мине озаталар. Бүген төнлә Берлинга хөкемгә алып китәләр... *(Бераз сүзсез йөргәч, язарга утыра)*. Тарихыбызның соңгы битен язам... *(Уйланып)*. Язасы нәрсәмнең ахырын язып бетерә алмадым. Мин аны белмим. Бу — уен түгел. Тормыш бу. Ә тормышта тамашачылар булмый... *(Торып, яңадан уйланып йөри)*.

Акрын гына ишек шакып, Колинский керә.

Колинский. Миңа тагын йомышларыгыз юкмы?

Фучик. Бар, туган, бар. *(Яшергән җирдән алып, язуны аңа суза).* Соңгысы бу.

Колинский. Тыныч булыгыз. Бусы да югалмас.

Фучик. Шулай итегез, зинһар. Без башка очраша алмабыздыр инде, туганкай. Бөтен яхшылыкларыгыз өчен зур рәхмәт! Иң авыр көннәремдә якын ярдәмчем булдыгыз.

Колинский. Мин, намусыма каршы килеп, башкача эшли алмый идем. Яңадан, иректә очрашырга насыйп булсын. *(Фучикның кулын кысып чыгып китә).*

Фучик *(озатып).* Әйе, чын кешелек хисләренә ия булып чыкты бу кеше.

Акрын гына ишек шакып, Скорепа керә.

Скорепа. Сезне бүген озатачаклар бугай.

Фучик. Әйе, Скорепа абзыкай.

Скорепа. Миңа рәнҗеп китмәгез инде. Мин, коммунист булarak, кулымнан килгәннәрнең бөтенесен эшләдем.

Фучик. Юк, юк, сез мине дә, башка берәүне дә рәнҗетмәдегез, ә, киресенчә, күп яхшылыклар эшләдегез.

Скорепа (кочаклап). Хуш, туганкай! Куркусыз, чын кеше икәнсең. Киләчәктә дә шулай бул! *(Чыгып китә).*

Фучик. Бу көрәштән исән калган иптәшләрнең, шулай ук бездән соң киләчәк кешеләрнең кулларын нык итеп кысам. Үзем өчен дә, Густинам өчен дә кысам мин аларның кулларын. Без үз бурычыбызны үтәдек. *(Бераз уйланып йөргәч).* Мин үземнең бөтен хезмәтем белән, миңа булган мәхәббәтләре, изгелекләре өчен, әткәй һәм әнкәемнең кояшлы күзләрен тәэмин итәргә тели идем. Алар янында була алмау нинди авыр! Эшләүче үлә, ләкин аның эше яши. Аларны уратып алган җылылык һәм яктылыкта мин һәр вакыт яшәрмен, алар янында булырмын.

Пешек кайтып керә.

Пешек. Тәмам теңкәгә тиделәр бит...

Фучик. Шулай, әткәй, безнең аерылышу минутларыбыз да килеп җитте, күрәсең.

Пешек. Кызганыч, бик кызганыч... *(Кочаклашалар).*

Фучик. Биредән исән-сау котылсагыз, ирекләгеләргә әйтегез, әткәй, сез дә, без дә үз бурычыбызны үтәдек... Үзем өчен дә, Густинам өчен дә кысам мин сезнең кулыгызны! Хушыгыз, әткәй, хушыгыз! Без үз бурычыбызны үтәдек.

Пешек. Халык моны онытмас.

Фучик *(залдагыларга).*

Ярата идем мин сезне,
Кешеләр, уяу булыгыз!

1954—1965.

**Андре Ремакль,**
француз язучысы

# КамАЗ ТУРЫНДА ЛЕГЕНДА

Безнең укучы француз язучысы, коммунист Андре Ремакльне яхшы белә. Ул 1976 елда Чаллыга барышлый Казанда туктады, республикабыз язучылары белән очрашты, ә «Советская Татария» һәм башка газеталар язучының тормышы һәм иҗаты турында яздылар. Ул чакта үзенең интервьюсында А. Ремакль болай дигән иде: «Чаллыга баруымның төп максаты — КамАЗ турында языласы китапка материал җыю. Китап — документаль характерда булачак. Аңа Чаллы җирендә туплаган материаллар һәм кайбер уйланулар керер. КамАЗ заводлары, шәһәр һәм кешеләр хакында бер дә бизәмичә, ничек күргән булсам, шулай язасы килә...

Бу сәфәргә хәзерләнгәндә миңа, әлбәттә, КамАЗ турында СССРда һәм Франциядә басылган күп материалларны укып чыгарга туры килде. Бездә «ирекле» дип йөртелгән информация органнары вакыты-вакыты белән дөреслектән шактый ерак торган фактлар һәм уйдырмалар тараталар — бу берәүгә дә сер түгел. Менә шуңа күрә дә мин китапта мөмкин кадәр объектив булырга тырышачакмын. КамАЗ — җитди тема. Минем алда, язучы буларак, КамАЗ комплексы кебек зур эшләр тора».

А. Ремакль безнең илдә ике ай ярым булды. Шул вакыт эчендә ул Татарстанның төрле шәһәрләрен күрде, колхоз-совхозларда, балалар бакчасында, пионер лагерендә, судта, больницада, милициядә, саклык кассасында, загста, студентлар бәйрәмендә — кыскасы, кайда теләсә, шунда булып, республикабызның тормышы һәм бик күп кешеләре белән танышып йөрде, очрашты, сөйләште. Хәзер бу китап язылып бетеп, «Чит ил язучылары СССР турында» дигән сериянең беренче карлыгачы буларак дөнья күрде. Китап совет тормышын яктырта торган бәләкәй энциклопедиягә тиз арада әверелеп тә өлгерде. Чөнки ул француз укучысына совет кешесенең хезмәте, уй-хыяллары, идеаллары турында сөйли.

Язучы очеркларын КамАЗ балаларына багышлаган. Аның исемен дә бит язучыга нәкъ алар, балалар, табып биргән иде. Журналыбызның бу санында дустыбыз Андре Ремакльнең шул китабыннан өзекләр урнаштырабыз.

Материалларны журналга А. Ремакльнең тәрҗемәчесе Лия Завьялова тәкъдим итте.



Тел очымда торган бу сорауны күптән инде берергә вакыт, чөнки Бигеш аэропортына килеп төшкән һәр кеше, шосседан иске шәһәргә килгәндә, бер якта Яңа шәһәрне, икенчесендә — яңа заводларны күреп, бу турыда сорамый калмый. Чынлан да автомобиль комплексын ник Татарстанда төзергә булганнар?

Сорауны КамАЗның генераль директоры, СССР автомобиль промышленностеның министр урынбасары Лев Васильевка бирәм.

— Заводларны, әлбәттә, башка җирдә дә төзеп булыр иде, — дип башлады ул сүзен. — Мондый мөмкинлекләр Советлар Союзының һәр республикасында диярлек бар. Бу мәсьәләдә бик күп проектлар һәм географик пунктлар тәкъдим ителде. Шулай да ахыр чиктә Татарстан сайланды. Нигә?

Татарстан илебезнең Европа өлешенең уртасында диярлек урнашкан. Йөк машиналарын төрле районнарга озату өчен бу бик уңайлы. Каманың да, табигый юл буларак, уңай яклары күп: машиналарны озату һәм төрле җиһазлар ташу су юлы белән арзанга төшә. Аннан Чаллыны техника белән тәэмин итеп торучы Ярославль, Горький, Тольятти, Димитровград шәһәрләрендә урнашкан йөк машиналары һәм автомобиль заводлары да якын. Уралның металлургия базасын да ерак дип булмый. Шулай итеп, транспорт расходлары шактый кими. Киләчәктә тимер юл челтәре һәм шосселар күбәю сәбәпле алар тагын да кимиячәкләр. Моның өчен Чаллы белән Әгерҗене тоташтырырлык утыз километр тимер юл гына кирәк. Ул Каманың эчке бассейнын Удмуртия башкаласы Ижевск белән һәм, иң мөһиме, Иделнең Куйбышев линиясен, Себернең — Сургут һәм Ульяновск — Уфа — Чиләбе — Свердловск магистрален бергә тоташтырачак. Юлларның Казан — Чаллы — Әлмәт — Казан боҗрасы исәбенә элемтә киңәячәк һәм алар Казан — Горький — Уфа автострадасына барып кушылачаклар, аннан — Уфа һәм Чиләбегә кадәр сузылачак. Яңа ГЭС плотинасы төзелеп бетүгә, су юлына шоссе һәм тимер юллар өстәләчәк. Татарстанның төньяк-көнчыгыш районы су юллары, тимер юл һәм шосселар хисабына көнбатыш һәм көнчыгыш белән зур бәйләнышларга керә, тупиклар бетә дигән сүз бу.

Тиздән төзелеп бетәсе КамАЗ өч шәһәрдән — Чаллы, Түбән Кама, Зәй — зур өчпочмак хасил итә, анда миллионга якын кеше яшәячәк.

Бу район киләчәктә энергетика, машина төзү һәм нефть промышленносте үзәгенә әверелер.

Боларга өстәп тагын шуны әйтергә мөмкин: ул да булса — резервтагы эшче куллар. Моңа кадәр Татарстанда эшчеләр резервы шактый зур иде. Төзелешнең башында республика утыз мең кеше бирә алды. Алар эшкә җитди тотындылар, барысы да һөнәр алырга ашыкты.

Инде икенче сорау: завод нигә шул кадәр зур? Илнең төрле почмакларында берничә вагран завод төзү дөресрәк түгелме?

— Түгел шул, нәкъ менә киресенчә, — дип дәвам итте Лев Васильев.— Төрле җирдә төзелгән заводлар бик күп артык чыгымнар таләп итәр иде. Мәсәлән, су белән тәэмин итү өчен берәдә без бөтен комплекска нибары бер су туплау станциясе төзедек, җылыту өчен дә шулай ук. Һәм алар арзангарак төштеләр. Ә берничәне төзи башласаң?.. Бу — канализация системасына да кагыла. Без инде утыз

процент экономия ясадык. Әлеге хуҗалыкларны эксплуатацияләү буенча да экономия якынча шундый булачак. Белгечләрнең исәпләвенә караганда, әгәр безгә тимерчелек заводы койган детальләрне ерактан китерергә туры килсә, өстәмә чыгым елга илле мең сумга кадәр җитәр иде...



## Совет кешеләре нигә бер урында гына яшәмиләр?

Совет кешеләре бер урында гына яшәргә теләмичә, күчеп йөрергә, тормышларын яңача корырга яраталар һәм бу инде әле генә башланып киткән гадәт түгел. Сәбәбе бәлки илнең зурлыгында, аның йөреп бетермәслек киңлекләрендәдер.

Поездлар, пароходлар, самолетлар һәр вакыт халык белән шыгрым тулы. Мәскәү үзе генә дә көн саен миллионнан артык транзит пассажир кабул итә.

Илдә даими төзелеш бара. Алар берсеннән-берсе зур. Күчеп йөрү дә шуннан килеп чыга.

КамАЗ — шундый төзелешләрнең зурысыдыр, мөгаен.

Әгәр башта тирә-юньнән җыелган утыз мең татарлар завод һәм шәһәрне төзүдә төп көчне тәшкил итсәләр, соңыннан аларга илнең төрле якларыннан килгән кешеләр килеп кушылды.

«КамАЗны бөтен ил төзи» дигән девиз предприятиеләрнең төзелешкә материаль ярдәме турында гына сөйләми, ул эшче кулларны исәпкә алып та әйтелгән.

Биш елда шәһәрдә халык саны утыз меңнән ике йөз илле меңгә җитте.

Чаллы хәзер миниатюрадагы Советлар Союзы дип әйтсәң дә дөрес була. Биредә җитмеш милләт вәкиле, йөздән артык шәһәр, район һәм республикалардан килгән кешеләр яши. Алар Киевтан да, Горький, Алма-Ата, Ташкент, Новосибирск, Уфа, Чиләбе, Мәскәү, Пермь, Одесса һ. б. шәһәрләрдән дә килгәннәр.

Партия оешмалары, комсомол һәм завод администрациясе биш ел эчендә илнең төрле төбәкләреннән ике йөз меңнән артык хат алды. Хатларда төзелеш турында кызыксыналар, андагы шартлар һәм эшкә керү мөмкинлекләрен сорашалар.

1975 елның ноябрена 37500 гаилә яңа квартира алу бәхетенә иреште.

Кешеләрне КамАЗга нәрсә тарта соң?

Яшь рәссам Аврик Ниязовны туган шәһәре Ивановодагы квартирын, эшен, тыныч тормышын ташлап КамАЗга килергә нәрсә мәҗбүр иткән?

Удар бригада бригадиры, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Новолодский да өен, дәрәҗәле хезмәтен һәм зур хезмәт хакын ташлап 1971 елны бирегә килә, яңа бригада төзи. Моның сере нәрсәдә?

Хәзер монда эшләгән йөз мең кеше йортлар да, магазин, кинотеатр, больница, хәтта юллар да булмаган чакта килеп яңа шәһәр төзи башлаганнар. Моны ничек аңлатырга?

Зур хезмәт хакы беләнме? Икенче зона өчен өстәмә түләүне исәпкә алмаганда, заводта берәүгә дә акчаны өеп бирмиләр.

Түләү системасы нәкъ Тольяттидагы кебек үк.

КамАЗда дүрт элементтан торган прогрессив түләү системасы кабул ителгән: 1) гадәти эш өчен, 2) продукциянең сыйфатына карап премия, 3) эш шартларына карап премия, 4) хезмәт җитештерүчәнле-

ген үстергән өчен премия. Шуңа тагын ай һәм ел азагында түләнә торган премияләр өстәлә. Ике йөз сумлык оклад монда 312—315 сумга кадәр үсә ала.

«КамАЗда берәүгә дә акча күктән яумый», — диделәр миңа.

Квартира мәсьәләседер бәлки? Мөһим момент, ләкин аның белән генә барысын да аңлатып булыр микән. Торак төзелешенең колачын Чаллыда без үз күзебез белән күрдек. Торак төзелеше монда шул кадәр кызу темплар белән бара ки, Советлар Союзының башка җирендә андый төзелеш бар микән дип уйлап куясың. Ике кешелек гаилә ярты елдан бүлмә бирүләрен өмет итә ала. Ләкин бу фактор гына да әле халыкның массовый төстә монда агылуын аңлатып бетерә алмый, чөнки күбесенең элекке урында да үз тормышы, йорт-җире булган.

Американың Ерак Көнбатышына омтылган массовый эмиграцияне анда табылган алтын, тиз арада баерга тырышу нияте белән аңлаталар. Ләкин Кама буе Клондайк түгел, ә Даусон-ситида халык саны беркайчан да ун меңнән артмаган.

Мондагы төзүчеләр, фрезерчылар, кыручылар, наладчиклар, мастерлар, тимерчеләр, бригадирлар, инженерлар, директорлар ни сөйли соң? Ачыктан-ачык сөйләшкәндә алар ни диләр? Әйдәгез, тыңлап карыйк:

«Минем төзелешне күрәсем, шушында эшлисем килде...»

«Яңа шәһәр төзешәсем килә...»

«Монда тормыш кызыграк...»

«Яшьләр белән яшәве күңеллерәк...»

«Яңа шәһәрдә тору миңа ошый...»

«Минем зур заводта эшлисем килгән иде...»

«Шәһәр төзүдә катнашасым килде... Биредә төзелештәге иң яңа ысулларны кулланалар...»

«Икмәк кенә җитми, кешегә үсәргә дә кирәк бит әле...»

«Боларны мин гомеремдә беренче күрәм... Кызык...»

«Мәскәүне нигә ташлап киттегез диярсез инде. Мин Иске Арбатның бер урамында яши идем. Нәрсә югалтуымны да, ни табуымны да мин яхшы беләм. Бер дә үкенмим, чөнки монда күп нәрсәне төшендем, тәҗрибәм артты. Хатыным да, балалар да бер дә үкенмиләр. Минем коллегаларым да шулай уйлый...»

«Үземнең министр кабинетында утырып калган булсам, мин боларның берсен дә белмәс идем. Мәскәүдә кырык биш ел яшәдем. Мин килгәндә монда ачык дала иде, бер кызык та юк. Иң авыры үтте. Без, биредә эшләүчеләр, катлаулы психологик сынаулар үттек. Кайбер нәрсәләр мине, әлбәттә, үкендерә: мәсәлән, көннәр, атналар бик тиз үтә. Менә пенсия яшенә җитәм. Бездә җаваплы пост тапшырылган кешеләр горурлана гына. КамАЗ пионерлары коммунизм төзү тарихына керәчәкләр. Инженер өчен моннан да зур бәхет бар микән...»

«Казаннан килгәч, мин монда баштанаяк пычракка чумдым. Дүрт ел буе бер генә көн дә резина итекне аягымнан салмадым, ләкин башка камазлылар кебек үк бәхетле идем...»

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк: мин монда берәүдән дә акча турында сүз ишетмәдем, ә күпме французлар акча артыннан куа-куа интегәләр. Әлбәттә, материаль яктан төшемлерәк эштән монда берәү дә баш тартмый. 1965 елны үткәрелгән экономик реформаны һәм 1970 елны Щекино химкомбинатында туып, башка предприятиеләргә таралып өлгергән тәҗрибәне искә алсак, материаль кызыксындыру үз алдына ике максат куя: производствоны үстерү һәм хезмәт ияләренең тормыш шартларын тагын да яхшырту.

Хезмәт ияләренең, бигрәк тә яшьләрнең, массовый рәвештә КамАЗга омтылуына матбугатта төзелеш турында ачыктан-ачык

сөйләү, язу бик тә ярдәм итте. Совет хөкүмәтенең Татарстанда гигант төзелеш башлап җибәрү турындагы карарын халык зур күтәренкелек белән каршылады.

КамАЗлылар үзләренең заводы, төзегән шәһәрләре белән горурланалар, чөнки алар турында бөтен ил кайгырта, алар Ватанның игътибар үзәгендә.

Кемнәр соң ул үз заводын, шәһәрен, поселогын, йортын төзергә килгән кешеләр? Килеп төшкәч, нинди һөнәр иясе булуларына карамастан, барысы да төзелештә эшләгәннәр. Мәсәлән, Яңа шәһәр поликлиникасының баш врачы хәзер үзе җитәкчелек иткән поликлиника бинасын төзешкән.

КамАЗлыларны якынча дүрт категориягә бүлеп була:

1. Яшьләр, атап әйткәндә, комсомоллар. Аларның күбесен монда төзелеш романтикасы һәм үз эшең белән илгә файда китерү теләге китергән.

2. Төзүчеләр, дөресрәге, зур төзелешләрдә — Братскида, Волгоградта, Тольяттида, Мәскәүдә — тәҗрибә туплаган белгечләр. Аларны КамАЗның искиткеч зур масштаблары кызыктырган.

3. Шәһәрдә яшәргә теләүче авыл халкы, аларның күбесе — татарлар.

4. Илнең төрле төбәкләреннән килгән гаиләләр. Аларның кагыйдә буларак, кемнәре дә булса элегрәк КамАЗга килеп урнашкан һәм монда килгәч сыенырлык кешеләре бар. Шуңа күрә алар зур ышаныч белән киләләр.

Килгәннәрдән һәр дүрт кешенең өчесе төпләнеп кала торды. КамАЗ мәктәбен үтеп башка төзелешләргә китүчеләр дә булган.

«Сезгә билгеле микән, — диде миңа бераү сөйләшеп утырганда, — хәзер Ростов тирәсендә атом электростанциясе өчен реакторлар заводы төзелә. Аның директоры да, башка җитәкчеләре дә — КамАЗлылар бит. Волгоградтагы төзелеш башлыгы да — КамАЗлы. КамАЗ ул батырлык һәм ачышлар мәктәбе, чөнки монда эшне һәм тәрбияне яңача оештыру формалары һәм методлары сынау үтә».

КамАЗ телгә кергәч үк монда килүчеләр җиңел тормыш эзләмәгәннәр. Реаль тормыш үзенекен сиздерә, бер дә аллы-гөлле романтик төсләр йөгертелмәгән мондагы тормышка.

Кайберәүләр берсен-берсе кабатласалар да, сүзне үзләренә бирик:

«Иң кыены — вакыт факторы. Бик кызу темплар белән эшләргә туры килде, чөнки бер үк вакытта заводны да, шәһәр һәм аны азык белән тәэмин итүче хуҗалыкларны да төзергә кирәк иде. Килеп төшкәннәрне вагоннарга һәм авылларга урнаштыра тордык. Крестьян халкына бу бик ошап бетмәде бетүен, ләкин вакыт үтү белән, якын дуслык урнашты һәм кечәйгәннән-кечәя барды.

Мәсәлән, кибетләр, икмәк пешерү базасы әле начар булу сәбәпле, халыкны икмәк белән тулысынча тәэмин итеп өлгерә алмадылар. Безгә бөтен ил ярдәмгә килде. Икмәкне Түбән Кама җибәреп торды. Үз мәшәкатьләре булуга карамастан, Алабуга да, Әлмәт, Лениногорск һәм башка шәһәрләр ярдәм итә тордылар...»

«Яшьләр, җәмгыятьнең иң хәрәкәтчән, бер урында гына торуны яратмый торган өлеше булуга карамастан, сынауны чыдамлы үттеләр. Тәҗрибәле төзүчеләр, төзелештәге белгечләр тирәсендә аларның үз коллективлары тупланды...»

«Ирко, түземсез, җиңел яшәеш эзләп килүчеләр китә торды. Коллективта табигый сайланыш шулай барды...»

«1971 ел азагында яңа шәһәрдән шактый кешегә квартиралар бирелде, алар уңай шартларда яши башладылар. Ләкин юллар әле начар булганга язын-көзен пычракка бата идек. Магазиннар җитеш-

ми, театрлар турында әйтеп тә торасы юк. Кайчак суы да туктап торгалады...»

«1971 елның язында бу урында ачык дала иде. Кешеләр монда ашкынып килсәләр дә, бер-берсен белмиләр, эш белән дә таныш түгелләр. Ялгышлар да шактый булды. Бу иң авыр этапны үткән кешеләр хәзер коллективның үзәген тәшкил итә. Ул көннәрдән соң байраклар да, җиңүләр дә күп булды, ләкин кыенлыклар җиңүләргә караганда күбрәкне өйрәтә икән...»

«Эш, әлбәттә, мөһим момент. Әмма эштән башка да тормыш бар бит әле. Ә анысы бик җиңелдән түгел иде. Авылларда яшәдек, йорт хуҗасы белән бәрелешкән вакытлар да булгалады. Вагоннарда, баракта тордык. Ләкин тормыш үзенекен итте. Менә бер вагонда туй ясадылар, икенчесендә бала туды. Вакытлыча гына төзелгән поселокта магазин ачылды, мунча, ашханә... һәм гинекология кабинеты. Хәзер КамАЗлылар менә дигән йортларда торалар»...

«Беренче трамвай 1973 елны гына йөри башлады... Авыр иде, әлбәттә. Ә сез Братскины төзүчеләрнең палаткада яшәгәннәрен беләсезме? Ә менә КамАЗда завод белән беррәттән торак йортлар да төзеделәр...»

1969 елны Чаллыда Беренче май демонстрациясе утыз минут, ә 1975 елны — өч сәгать дәвам иткән...

Чыннан да, нигә совет кешеләре бер урында гына яшәмиләр соң?

## Келәмле өйдә

Без «Гигант» совхозына юл тотабыз. Ике якта сөрелгән җирләр, кукуруз, бодай, арыш басулары, көтүлекләр һәм сап-сары көнбагыш кырлары чагылып кала.

«Гигант» совхозы заводлардан шактый ерак урнашкан. Берничә ел элек бу гап-гади совхоз булган, иген иккән. КамАЗ төзелә башлагач, аның масштаблары киңәйгән, ул Чаллыны азык-төлек белән тәэмин итә торган төп чыганак ителгән: яшелчә, икмәк, сөт шуннан китерелә.

Совхозда төзелеп бетеп килә торган зур ферма бар. Анда ике мең баш сыер асралачак. Бөтен процесслар механикалаштырылган. Ферма каршындагы түгәрәк сигез башняның һәрберсендә тугызар тонна сенаж саклана. Совхозның төп эше терлек асрау булуга карамастан, монда кырчылыкка да зур игътибар бирелә. Совхоз — дәүләт хуҗалыгы. Эшчеләр һәм белгечләр билгеләнгән оклад һәм премияләр ала. Һәр гаиләнең җир участогы бар. Анда үзләренә яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр.

КамАЗ тирәсендә санитар зона оештырыла. Анда торак йортлар салынмаячак. Авылларның берсе нәкъ менә шул зонага туры килгән дә, аны шуннан сигез километрда төзелгән яңа поселокка күчерергә булганнар. Поселокта хәзер ике йөздән артык йорт бар.

Татарларның бүрәнәдән салынып, тәрәзә наличниклары төрле төскә буяп-сырлап эшләнгән, зур бер бүлмәдән торган һәм бүлмәсендә сандык, карават, кисея пәрдәләр, стенасында келәмнәр эленгән өйләре инде сирәгәя бара. Авыл елдан-ел шәһәр тибындагы поселокка әверелә. Аның мәктәбе, үзәктән ягып җылыту системасы, медицина учреждениесе һәм бүтәннәре бар. Поселок элекке авыл кебек яшеллеккә бик үк бай булмаса да, яшәү өчен бик уңайлы: дүртәр бүлмәле ике катлы җылы йортлар, кышын мичкә ягар өчен утын кисәсе-ярасы, су ташыйсы юк.

Урамның буеннан-буена сузылган бу агач өйләр бик матур тәэсир калдыра. Һәркайсы бакча, түтәлләр белән уралган, өй һәм капка төрле төстәге агач орнамент белән бизәлгән, өй каршында гөлләр.

Совхоз директоры белән бергә авыл урамыннан узабыз. Бер өй янында: «Кереп карарга мөмкинме?» — дидем. «Теләсәң — рәхим ит». Хуҗа хатынга кыска гына итеп аңлатканнан соң безнең алда ишекләр киң итеп ачылды.

Беренче катта кухня. Плитәсе электр белән эшли, суыткыч... Аннары — кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе. Икенчесендә — мансарданы хәтерләтә торган түбә астында тагын бүлмәләр. Мебельләре стандарт булса да, һәр нәрсәдә — тәрәзә пәрдәсеннән алып урын өстенә баскычлап өеп куйган мендәрләргә кадәр — үз зәвыклары сизелеп тора. Ләкин иң шаккаттырганы һәм көтелмәгәне стеналар иде: бүлмә саен икешәр-өчәр келәм балкый. Бу — кечкенә булса да, үзенә күрә хәзинә!

Мөлаем йөзле кунакчыл хуҗа хатынга безнең гаҗәпләнүебез бик тә сәер тоелды. Аның өчен келәм гадәти нәрсә. Келәмнең идәнгә генә җәелмичә, стенага эленүе дә татарларга хас икән.

Аның ире мич ягучы, үзе металлолом складында эшли. Алар монда берничә ел элек Архангельскидан күчеп килгәннәр һәм авылда торып киткәннәр. Хәзер менә шушы яңа поселокта яшиләр.

Бүлмәләрне карый торгач, мин пыяла китап шкафы каршында тукталып калдым.

— Әйе, укырга бик яратам, — диде хуҗа хатын, — ләкин китап табу хәзер җиңел түгел. Кайберләрен подписка белән алдырам.

Китапханәсендә өч йөздән артык китап бар.

— Барысын да укып чыктыгызмы?

— Укыдым, кайберләрен кабат укыйм...

Шкафта рус классикасы, бүгенге заман язучылары, чит ил авторларыннан — Хемингуэй, Шарлотта Бронте һ. б. күренә.

Совхозны яңадан кору шома гына үтмәгән. Кайберәүләр моннан КамАЗга киткәннәр. Бер араны авылда бөтенләй эшче куллар җитешми башлаган. Ләкин совхозга яңа кешеләр килгән. Техника да заманчарак, камилрәк эшли башлаган. Механиклар, агрономнар саны да арткан. Хәзерге көндә белгечләрнең кырык проценты югары белемле. Завод белән элемтә җайланган. Чәчү һәм уру вакытында эшчеләр ярдәмгә килә. Заводтан кире совхозга кайтучылар да бар.

— Чын авыл кешесе һәр вакыт җиргә тартыла, аның йөрәге түземе соң? — ди совхоз директоры.

Совхозга бик күп авыл хуҗалыгы техникасы кайтарылган. Юллар яхшырган. Авыл белән шәһәр арасындагы аерма елдан-ел кими бара.

Киләчәктә «Гигант» үзенең авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүен һәм терлекчелекне тагын да үстерәчәк, чөнки КамАЗ һәм Чаллы шуны таләп итә.

## Авыл һәм театр

Культура сараеның тәрәзәсеннән бәрәңге кыры күренә. Алгы планда — түбәләр, өйләр, авыл.

Без һәвәскәр музыкантларның репетициясенә килдек.

Колхоз председателе кулына аккордеон алып бер көй уйнап җибәрә. Культура сарае мөдире — чәчләренә чал йөгергән ягымлы ханым — татар халык җырын суза, аннан үзе бии башлый. Репетициягә килгән бу ирләр һәм хатын-кызлар үзләрен бик иркен һәм горур тоталар. Исемнәре дә матур, нәфис яңгырый.

Бу — «Коммунизм» колхозының үзәге. Колхозның 7836 гектар җире бар. Шуның 7097 гектары чәчү мәйданы итеп файдаланыла икән. Культура сарае купшырак бизәлгән, ләкин ике нәрсә аны чын мәгънәсендә матурлый: тамаша залы һәм бай китапханә.

Тамаша залы өч йөз кешелек, ә авылда барлыгы ике мең биш йөз кеше яши. Биредә кич саен кино була, еш кына гастрольгә чыккан труппалар да килә. Халыкның фильм һәм спектакльләр яратуы нык сизелә. Без килер алдыннан берничә көн элек илле сыер савучы Чаллыга Казаннан килгән татар труппасының спектаклен карарга барганнар.

Китапханәдә алты меңнән артык китап бар. Шулар арасында француз язучылары да күп. Мәсәлән, Бальзак, Стендаль, Гюго, Мериме, Жюль Верн һәм башкалар.

Колхоз — дәүләт тарафыннан бушлай һәм мәңгелеккә бирелгән җирне эшкәртүче ирекле кооперация ул. Колхозчы һәм совхоз эшчесенең хезмәте әллә ни аерылмый дип әйтерлек, чөнки колхозны да, совхозны да авыл хуҗалыгы машиналары, техника һәм ашламалар белән дәүләт тәэмин итә. Аерма шунда ки, совхоз дәүләт милке санала һәм аңа буйсына, ә колхоздагы бөтен байлык (корылмалар, машиналар, терлек, җитештерелгән продуктлар) колхозның үзенеке.

Совхоз директорын дәүләт үзе билгели. Колхоз председателе гомуми җыелышта өч ел срокка сайлана.

Гомуми җыелышта колхозның эше елына ике тапкыр тикшерелә. Идарә унбер кешедән тора. Председатель һәм идарә белән беррәттән, аларның эшен тикшереп тору өчен ревизия комиссиясе дә сайлана. Председатель, идарә членнары һәм ревкомиссия теләсә кайсы вакытта күпчелекнең теләге белән яңадан сайлана алалар.

«Коммунизм» колхозында идарә һәм ревизия комиссиясенең егерме биш проценты хатын-кызлардан тора, партиясезләр кырык биш процентны тәшкил итә.

Председательләре коммунист, партком члены. Монда бу турыда: «Мәҗбүри түгел, ләкин шулай булганда яхшырак», — диделәр. Партия оешмасында туксан өч кеше бар. Колхоз председателенең эше 1959 елны алты кечкенә колхозны берләштергәч башланып китә. Алты авыл бер колхоз составына керәләр. 1941 елны председатель әле унбиш яшьлек малай гына була.Ирләрнең күбесе сугышка киткәч, ул укуын бүлеп колхоз эшенә тотына. Унҗиде яшендә аны да фронтка алалар, сугышта ул яралана. Җиңүдән соң 1950 елга кадәр армиядә хезмәт итә. Кайткач, укуын дәвам итә, соңыннан үзе балалар укыта. Ләкин игенчелек, җир аны үзенә тарта — ул күрше колхозда эшли. Аннан «Коммунизм» колхозына күчә. 1974 елны председатель итеп сайлана. Аны район советына депутат итеп тә сайлыйлар. Бу гади һәм типик биография.

Без председательнең ак, алсу челтәрләр белән бизәлгән пөхтә өендә сөйләшеп утырабыз. Ул монда вакыт үтү белән саргайган бер фото суза. Анда председательнең әтисе — 1935 елда узган колхозчылар съезды делегаты төшерелгән. Фотоның нәкъ уртасында бер төркем колхозчылар белән Сталин һәм заманның җаваплы кешеләре басып тора.

Хәзер авылда күп нәрсәнең үзгәргәнен сөйли председатель. Бигрәк тә 1969 елны булган колхозчылар съездыннан соң.

— Колхозның яңа уставы искергән методларны күптән инде кире какты һәм колхоз тормышына күп төрле яңалыклар өстәде. Хәзер гомуми җыелыш — колхоз белән идарә итүдә иң югары орган...

Башкарылган эшнең күләменә һәм сыйфатына карап колхозчылар хезмәт хакын акчалата алалар. Продуктларны үзкыйммәтенә сатып алу мөмкинлеге тудырылган. Һәрберсенең җир участогы бар. Анда

җиләк-җимеш, яшелчә үстерәләр, мал-туар асрыйлар, артык продуктларын базарга илтеп саталар. Колхозда хосусый милеккә бирелгән җирләр 200—500 квадрат метрны тәшкил итә, шуның өстенә һәр хуҗалыкта диярлек сыер, бозау, сарыклар, дуңгыз асрыйлар, кайберәүләрнең умарталары бар. Көтүләре болында йөри.

Соңгы елларда Татарстан авылында тормыш шактый яхшырган, модернизация һәм специализация бик кызу темплар белән алып барыла.

Биредә бәрәңге үстерү һәм сөт җитештерү бик зур урын алып тора. Монда 320 гектар җирне бәрәңге били, 3 200 баш терлекнең 1 000 башы мөгезле эре терлек. 3 500 гектардан артык җиргә бөртекле ашлык чәчелгән.

Авылда тормыш көннән-көн яңара. Һәр өйдә газ, электр, радио, телевизор, көнкүреш аппаратлары бар. Колхозда яшәүче 500 гаиләгә 25 автомобиль һәм 260 мотоцикл туры килә.

Мәктәп тә культура сарае, аның китапханәсе һәм тамаша залы кебек үк матур. Чәчәкләр белән бизәлгән бакча сукмагы безне якты, киң коридорлы, иркен класслары булган дүрт почмаклы бинага китерә.

Мәктәп сигезьеллык һәм унъеллык белем бирә. Монда җиде яшьтән унҗидегә кадәр булган кызлар һәм малайлар укый. Советлар Союзының һәр республикасында ата-аналарга милли мәктәп белән (укыту ана телендә алып барыла, ләкин кайбер предметлар рус телендә керә) русча укытыла торган мәктәпне сайлау хокукы бирелгән (соңгысында ана теле һәм әдәбият өйрәнү мәҗбүри). Бу мәктәптә болар икесе дә практикага кергән.

Менә без татар теле һәм әдәбияты укытыла торган класста. Яшь кенә укытучы миңа рәсемле альбомнар күрсәтә. Рәсемнәрне укучылар үзләре ясаган. Алар төрле әдәби вакыйгаларга, язучыларга багышланганнар. Мәсәлән, Муса Җәлил, Тукай, хәзерге заман татар әдипләре.

Төп фәннәр монда татар телендә укытыла, ә укучыларга югары уку йортларына керү уңайлы булсын өчен, кайбер предметлар рус телендә керә. Бу чара татар мәктәпләрен тәмамлап югары уку йортларына имтихан тотучы яшьләрнең хәлен шактый җиңеләйтә. Киләчәктә аларга укыту рус телендә генә алып барыла торган шартларга күнегү дә җиңелрәк булачак.

Русчадан СОЛТАН ШӘМСЕТДИНОВ тәрҗемәсе.

## Дамир Шәрәфетдинов

# САБАН ТУЕ— ХАЛЫК ЯШЬЛЕГЕ

Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр, дип, уйларым...

**Г. ТУКАЙ.**

Берәр бәйрәмме сабан туй!
Нәрсә соң ул сабан туй!
Сабан туйлар төрле була,
Ә белмәсәң, телең тый.

**А. Твардовский.**

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай шигъриятеннән һәм рус совет шагыйре А. Твардовскийның «Василий Теркин» поэмасыннан күңелләргә күчкән әлеге шигъри юллар илебезнең төрле почмакларыннан җыелган КамАЗ төзүчеләренең күбесенә, ихтимал, башта ачык аңлашылып та җитмәгәндер. Ә бүген исә КамАЗда бу бәйрәмне — яз, хезмәт бәйрәмен сагынып көтмәгән, анда катнашырга теләмәгән бер генә кеше дә юктыр.

Төрле йолалар, төрле гореф-гадәтләр тәэсирендә тәрбияләнеп үскән бу яшьләрнең күңелен милли татар бәйрәме — сабан туе үзенең кайсы ягы белән әсир итә алды соң?

Беренчедән, әлбәттә, һәркемне яктылыкка, бәхеткә әйдәүче көр күңелле халыкчан рухы белән алдыргандыр. Сабан туенда халыкның күп гасырлардан килгән шаянлыгы, тапкырлыгы бергә тупланган. Бу бәйрәмгә килгән кеше беркайчан да читтән күзәтүче, битараф тамашачы гына булып кала алмый, ирексездән үзе дә бәйрәм шуклыгына бирелеп китә. Шулай булмый ни... Күңелле милли уеннарны, корыч беләкле батырлар көрәшен, бернинди иярсез-нисез елгыр аргамакларга атланып чабучы яшүсмерләрне, җилләрне узып килүче җитез йөгерешчеләрне караганда кемнең генә күңеле җилкенми калыр икән?!

Икенчедән, соңгы елларда илебездә булган зур үзгәрешләр бу борынгы бәйрәмгә дә йогынты ясый килә. Элгәре якын күршелек, туган-тумачалык җепләре белән бәйләнгән берничә авыл, бер төбәк игенчеләренең бергә җыелып күңел ача торган татарга гына хас бу бәйрәме хәзер КамАЗда чын-чыннан зур хезмәт тантанасына, интернациональ бәйрәмгә әверелә, кояш нурында ялтыраган бриллиант бөртегедәй, төрледән-төрле төсләр белән балкый. КамАЗ белән туганлашудан аның эчтәлеге та-

гын да байый, тагын да киңәя. Интернациональ эчтәлек һәм интернациональ яңгыраш бу бәйрәмнең милли үзенчәлеген, халыкчанлыгын тагын да матурлый. Чөнки, Ф. Энгельс әйтүенчә, чын милли эчтәлек бер үк вакытта чын интернациональ яңгыраш та таба.

Сабан туеның милли традицияләре мәйдан сайлаудан ук башлана. Борын-борын заманнардан ук килгән бу йола буенча ул табигать кочагында, киң болында үткәрелә. Сабан туе булачак мәйданда иртә таңнан ук шыгы-зыгы башлана. Бәйрәмне оештыручылар, сәүдә, гомуми туклану оешмалары өчен бу көнне мәшәкать җитеп ашкан була. Чөнки меңләгән кунакларны йөзгә кызыллык китермәслек итеп каршы алырга, моңарчы киек-кошлар гына сәйран иткән яшел болында кибетләр ачарга, ларьклар корырга кирәк. Алар үзләренең тышкы күренешләре белән генә түгел, «Чулпан», «Төнбоек», «Миләүшә» дигән кебек шигъри исемнәре белән дә халыкны җәлеп итсен, бөдрә таллар күләгәсендә, пар бөркеп, самаварлар да сайрашып утырсын, ачык һавада төрле халык ашлары әзерләү өчен учагы да булсын. Һәм КамАЗның уңганнары чыннан да йөзгә кызыллык китермиләр. Учаклар янына элеңгән шаян плакатларны уку белән үк бирегә килгән һәркемнең йөзендә елмаю балкып китә. Әйтик, «Татып кара КамАЗ шашлыгын, үзеңне Кавказдагы кебек хис итәрсең» дигән язуны укыгач, шашлык учагы яныннан беркем дә болай гына узарга теләми. Арырак китсәң, төрле-төрле сыйхөрмәттән озын-озын өстәлләр сыгылып тора: өчпочмак, вак бәлеш, гөбәдия, чәк-чәк, баллы прәнник, квас — җаның ни тели!

Бәйрәм башлануын хәбәр итеп, җиз быргылар кычкырта. Мәйданда тынлык урнаша. Юл аркылы сузылган төрле төстәге тасмаларны өзеп, түгәрәк эченә автомобильләр төркеме килеп керә. Аларның һәрберсендә, ал байракларны баш өстенә күтәреп, КамАЗ төзүчеләренең иң алдынгылары басып килә. Сабан туе байрагын күтәрү хезмәт алдынгыларына ышанып тапшырылган. Элек-электән килгән йола буенча, милли киемнәргә киенгән татар кызлары алар алдында милли сый — чәк-чәк тотып килә, балалар чәчәк бәйләме бүләк итә.

Җитәкчеләрнең кыска гына котлау сүзеннән соң меңләгән үзешчән җырчылардан торган хор Ватан турында, партия турында җыр башкара, аннары бу җырны такмаклар, СССР халыкларының милли көйләре алыштыра.

Шул арада бәйрәм кызганнан-кыза бара, мәйданда иң элек малайлар көрәшә, аннары электәге сабан туй батырлары, әле хәзер дә дәртен, гайрәтен җуймаган ветеран картлар, аксакаллар көч сынаша. Шуннан соң гына бу бәйрәмнең традицион бүләге булган симез тәкәгә дәгъва итүче баһадирлар көрәше башлана.

Сабан туеның программасы гаять киң: чүлмәк вату, аркан тартышу, әркка капчык киеп, авызга йомыркалы кашык кабып, җилкәгә көянтә-чиләк күтәреп йөгерешү, салам тутырылган капчык белән сугышу кебек милли уеннар һәм шул ук вакытта спортның хәзерге төрләре... Ә икенче мәйданда, вакытлыча гына корып куелган зәңгәр түбәле сәхнәдә үзешчән җырчылар, музыкантлар, биючеләр һөнәр күрсәтә. Хәтта сабан туеның иң көчле батыры билгеле булгач та, йөгереш, ат чабышы һәм спортның башка төрләре буенча җиңүчеләр бүләк алганнан соң да халык таралышырга ашыкмый, бәйрәм элекке дәрт, элекке ашкыну белән дәвам итә.

Сабан туе ул шундый бәйрәм: аның башы бар, ахыры юк. Ул мәйданнан кичке урамнарга күчә, дәртле җырлар, ашкынулы биюләр рәвешендә, әле анда, әле монда төн буе дәвам итә.

Сабан туе бер КамАЗда гына түгел, Татарстанның башка шәһәрләрендә дә шулай ук күңелле уза. Аны Әлмәт нефтьчеләре дә, Түбән Кама химиклары да, Зәй, Зеленодольск, Казан эшчеләре дә күтәренке күңел, сүнмәс дәрт белән бәйрәм итә һәм шунысын да әйтеп китәргә кирәк: аның географиясе Татарстанда гына да чикләнми. Оренбургта, Ташкентта, Ленинградта һәм Мәскәүдә һәр язда халык хезмәт уңышлары белән сабан туена килә. Сабан туе турындагы материаллар Ленинградтагы Этнография музеена куелган, шулай ук алар СССР халыкларының милли бәйрәмнәре күргәзмәсендә дә күрсәтелделәр.

Соңгы елларда сабан туе халыкара мәйданга да чыга башлады, яшьләрнең халыкара «Волга» лагеренда уңыш казанды. ВЛКСМ Үзәк Комитетының яшь туристлар бюросы тарафыннан 1976 елда уздырылган бөтенсоюз смотр-конкурсында «Волга» лагеренең сабантуе программасы беренче урынны алды.

Зеленодольск һәвәскәрләре төшергән «Сабан туй» исемле фильм Венада кино сөючеләрнең бөтендөнья конкурсында истәлек-медаль белән бүләкләнде.

Сабан туе — халкыбызның иҗат, хезмәт, сәнгать һәм спорт фестивале. Аның күп гасырлардан килгән тарихы, бай традицияләре бар. «Сабан туе» сүзенең асыл мәгънәсе беренче карашка һәркемгә яхшы аңлашыла кебек. Сабан сөрү, җир сукалау, сабанга төшү, сабан ашлык... Шулай ук «туй» сүзенең дә мәгънәсе шактый киң. Ул өйләнешү, никах мәҗлесе мәгънәсендә генә түгел, зур бәйрәм, зур тантана мәгънәсендә дә кулланыла.

Ләкин сабан туеның кайчан, кайсы заманнарда барлыкка килүе турында төгәл мәгълүматлар юк. Бәлки аны иң элек безнең утрак игенчелек белән көн күрүче борынгы бабаларыбыз бәйрәм итә башлагандыр, ә бәлки аның тамырлары халкыбызның күчмә терлекчелек чорына ук барып тоташадыр.

Һәрхәлдә, шунысы бәхәссез: сабан туен мәҗүсилек йолалары да, дини хорафатлар да түгел, бәлки хезмәт үзе барлыкка китергән. Димәк, сабан туе — безнең борынгы бабаларыбыз мирасы, халыкның гомуми иҗат хәзинәсе. Ул үзенең үсү, камилләшү чорында күп буыннар тарафыннан баетылган, тора-бара аңа башка халыкларда киң таралган хезмәт бәйрәмнәренең дә йогынтысы тигән. Күренекле чуваш галиме, педагогия фәннәре докторы Г. Волков «Сөрәнтуй», «Акатуй» уеннары турында яза. Бу бәйрәмнәрдә дә төрле җырлар, биюләр, ат чабышлары булган. Шәригать кануннарына карамастан, кызлар, егетләр бергә җыелып күңел ачканнар. Шулай итеп, сабан туе күп төрле күңел ачу бәйрәмнәреннән үзенә кирәклесен алган.

Сабан туен элек-электән авылның иң абруйлы картлары, кабилә, ыруг традицияләрен саклап килүче аксакаллар оештырган, алар алып барган. Сабан туенда әле хәзер дә буыннан-буынга күчеп килүче язылмаган законнар хакимлек итә. Хәтта төрле уеннарның — көрәш, йөгереш, ат чабышларының тәртибе, үзара чиратлашуы да бу көнгә кадәр үзгәрмәгән. Элек-электән бәйрәмгә хәзерлек бер-ике атна алдан башланган. Аксакаллар бәйрәм уздырыласы көнне билгеләгәннәр һәм мәйдан сайлаганнар. Бәйрәм бүләге җыю, гадәттә, яшь-җилкенчәккә тапшырылган. Аларны «бирнә җыючы» яки «сөлге җыючы» дип атаганнар. Авыл халкы бәйрәм хөрмәтенә хәзинәсендә булганны кызганмыйча чыгарып биргән. Бирнә җыю үзе үк бер бәйрәмгә әверелеп киткән, өйдән өйгә, тәрәзәдән тәрәзәгә йөргән вакытта бирнә җыючы яшьләр хуҗага төрле-төрле тапкыр сүзләр белән дәшкәннәр, җырлар җырлаганнар, такмак-такмаза әйткәннәр. Кайбер яклардагы «сөрән сугу» — йомырка җыю йоласы аеруча кызык уза торган булган. Башлап бүләк җыйган егет артыннан дистәләгән җайдак яшьләр куа киткән, шул ук язылмаган законнар буенча, кем куып җитә, бүләк шуның табышы ителгән.

Бүләк җыю йоласы кайсыбер районнарда әле хәзер дә үзгәрешсез саклана. Әйтик, Балтач якларында иртәгә сабан туе дигән көнне кыңгыраулар таккан пар атларга төялгән яшьләр гармун уйнатып, җырлар җырлап авыл әйләнәләр. Һәр йорт алдында тукталып, алар, хәзерге телебездә инде ят тоелган, чал тарихның үзеннән сакланып килгән сүзләрне такмаклыйлар.

— Арапә, арапә!..

Бүтән төбәкләрдә киң таралмаган бу сүз «сабан туена бүләгеңне бир» дигән мәгънәне аңлата. Ә бүләкләр — яулык, җаймә, чигүле сөлге... Аларны шулай ук, борынгыдан килгән йола буенча, озын колга башына элгәләр.

Инде әйтелгәнчә, һәр район үзәгендә диярлек яхшы җиһазландырылган стадион, бакча, парк булуга карамастан, сабан туе уздыру өчен халык табигать кочагына агыла. Әйтик, Зеленодольск шәһәрендә бәйрәм уеннары Идел буенда, Чаллыда һәм Түбән Камада — киң болынлыкта, Әлмәттә — Зәй елгасы буенда, Апас һәм Буада — Зөя, Сабада — Мишә, Актанышта — Сөн, Мөслимдә — Ык елгалары буенда уздырыла. Казан халкы да шул йоланы саклый.

Бәйрәм көнне авыл халкы, иртә таңнан кузгалып, алдан сайланган мәйданга юнәлә. Иң алдан абруйлы, дәрәҗәле ил картлары атлый, арадан берсе, байрак йөртүче кебек, чигүле сөлгеләр эленгән колга күтәргән. Колганы мәйданның урта бер җиренә утырталар, тамашачылар, шуның тирәли зур түгәрәк ясап, яшел чирәмгә утыралар.

Югарыда әйткәнебезчә, сабан туен башыннан ахырынача шул ук аксакаллар алып бара. Җиңүчене билгеләүче дә, бүләк бирүче дә алар. Ә бүләк өчен һәркем ярыша ала. Әлеге язылмаган законнар буенча, җиңеп чыгучы гына түгел, күп очракта җиңелгәннәр дә бүләкләнә. Әйтик, аягын авырттырган йөгерешче дә өлешсез калмый, чабыштан иң соңгы булып килгән атның да муенына чигүле сөлге бәйлиләр. Бу йола да хәзерге көнгә кадәр саклана килә. Октябрь районы авылларында иң соңгы булып килгән чабышкыга сөлгене бабайлар түгел, әбиләр тага. Беренче карашка артык искитәрлек ягы булмаса да, бу йола халыкның нечкә күңелле булуын, малга да игътибарын күрсәтә. Атлар чабышка катнашты, хәленнән килгәнчә ярышты, халыкның күңелен ачты. Димәк, беренче килдеме, икенчеме, иң азакка калдымы — ул барыбер бүләккә лаек.

Гомумән, көрәш, йөгереш һәм ат чабышы, картлар әйтмешли, сабан туеның кендеге. Ә атка зур хөрмәт бабаларыбыз болгарлардан ук килә. Болгар казылмаларында, йорт түбәләрендә, стеналарда, савыт-сабаларда еш кына ат сыны, ат башы сурәте табыла. Узган гасыр тарихчысы М. Рыбушкин: «Татар чабышкылары гәүдәгә кечкенә, ябык, артык күзгә ташланырлык түгел, әмма бәйгедә искиткеч елгыр», — дип язган.

Татар халкы элек-электән үзенең батырлары белән дан тоткан. Халык аларны яраткан, үз итеп, алып батыр, пәһлеван дип йөрткән. 922 елда Болгар шәһәренә сәяхәт кылып кайткач, Әхмәт ибн Фадлан үзенең юлъязмаларында шундый батырлар турында искә ала. Аннан шактый соң, 1131 елда Болгарда булган сәяхәтче Әбү Хәмит әл-Гарнати шулай ук бу илдәге баһадирлар турында сокланып сөйли. Үзенең көченә, гайрәтенә карамастан, «ул кече күңелле, ягымлы, тыныч холыклы иде», — дип яза Әбү Хәмит шундыйларның берсе турында. Борынгы батырлар, пәһлеваннар халык әкиятләрендә дә сурәтләнгән. Һәм хәзерге сабан туе батырларында да без борынгы пәһлеваннарга хас гүзәл сыйфатларны күрәбез. Әйтик, Минзәлә батыры шофер Раббани Гайфуллин, Актаныш егете Марсель Гыйлаев, Арчадан Рәдис Сәйфуллин, Түбән Камадан Данил Галиев, Сарман укытучысы Зөфәр Ханов — болар барысы да тыйнак, сабыр, киң күңелле кешеләр.

Ф. Вәлиев «Урта Идел халыкларының борынгы сәнгате» исемле китабында болгар тарихыннан кызыклы мисаллар китерә. Болгар хәрабәләрендә табылган балчык чүлмәктә үзара көрәшүче ике батыр сурәте төшерелгән. «Социалистик Татарстан» газетасында XVII гасырда яшәгән галим Катиб Чәләби төзегән энциклопедиядән гаять кызыклы мисаллар китерелгән иде. Газета мәкаләсендә Болгар җирендә туып үскән Лачын Хисаминың XIII гасырда язылган «Мәйданда ярышучы көрәшчеләргә бүләк» исемле китабы телгә алына. Әлеге мисаллардан күренгәнчә, хәзерге татарча көрәшнең тамырлары бик борынгы заманнарга, болгар чорына ук барып тоташа дип уйларга нигез бар. Ул элек-электән спортның бер төре булып килгән, халыкта аның үз кагыйдәләре, үз традицияләре формалашкан. Батырларны көрәшкә хәзерләү шул ук аксакаллар киңәше буенча үткәрелгән.

Халык авыз иҗатында сабан туе батыры һәрчак гади халык вәкиле, ярлы егет була. Ул көрәштә үзе яулап алган симез сарыкны кул очына күтәреп мәйдан әйләнә. Шуның белән халык алдында тагын бер кат көчен, гайрәтен күрсәтә. Батыр калган егеткә сарык белән бергә яшь киленнәр чиккән зиннәтле сөлге бүләк итәләр. Бу сөлгене батыр өчен аеруча кадерле бүләк исәпләнгән һәм ул аны, яшьлек истәлеге итеп, гомере буе саклаган. Бу матур йола Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда да телгә алынган.

Шәригать канунннарын бер читкә куеп, халыкның сабан туенда күңел ачуына, хәтта намаз калдыруына динчеләр дә күз йомарга мәҗбүр булган. Әйтик, Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан 1841 елда чыгарылган журналда түбәндәге юлларны укырга мөмкин: «... аеруча шунысы гаҗәп, монда муллалар үзләре дә катнаша, кояш баер алдыннан алар, өлкәннәр белән бергә, шунда, халык гөр килеп бәйрәм иткәндә, бик бирелеп кичке намазларын укыйлар». Бу турыда шул заманның күренекле галиме К. Фукс та язып калдырган.

Шәригать законнарына һич сыешмаса да, сабан туена хатын-кызлар да катнашкан. Муллаларның, куштан картларның өркетүенә карамастан, сабан туе кичендә яшь кызлар үзләренең сөйгән егетләре белән очрашкан, чишмә буйларында уен корган, җырлар җырлаган, вәгъдәләр бирешкән.

Сабан туе халыкның теләкләрен, өметен, яктыга, иреккә, матурлыкка омтылуын чагылдырган. Шуңа күрә аның алдында ислам дине кануннары да көчсез булып калган. Әмма революциягә кадәрге татар авылларында үткәрелгән сабан туйларында сыйнфый каршылыклар барыбер бик ачык чагылган. Байлар кешене кимсетә, түбәнсетә торган уеннарны хубрак күргәннәр. Көрәштә бай балалары җиңеп чыкса, ярлы халыкны кимсетү өчен бу тагын бер сылтау булган. Сабан туе ветераннары И. Әзимов һәм Г. Гобәйдуллиннарның истәлекләреннән күренгәнчә, байлар тарафыннан көрәштә хәрәмләшү, чабышта ярлы атының башына сугып, аны артка калдыру, гадел көрәштә җиңеп чыккан ярлы баласын санга сукмыйча, бүләкне башкага бирү кебек гаделсезлекләр кабатлана килгән.

Гади халык арасыннан чыккан батырларга Казан кебек зур калаларда мәйдан тоту бик сирәк эләккән. Чөнки аның өчен көч, гайрәт кенә түгел, кесәңдә мал булу да соралган. Революциягә кадәр дә Казанда спорт клублары, көрәш секцияләре эшләгән. Ләкин хуҗалары, рәисе, сәркатибе я князь, я маркиз, я граф булган. Буш кесә белән якын барып кара! Аның өстенә, керү взносы ярлы-ябагайның хәленнән килерлекме!..

Бөек Октябрь революциясеннән соң гына илебез халыклары формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик чын халык культурасын үстерергә мөмкинлек алдылар. В. И. Ленин: «... элекке культураның иң зур казанышларын файдаланмыйча пролетариат культурасын үстерү мөмкин түгел», — дип язды. Даһи юлбашчының шул тәгълиматы нигезендә, коммунистлар партиясе һәр халыкның алдынгы традицияләренә, культура үсешенә киң юл ачты.

Татар халкының милли бәйрәме — сабан туе да социалистик эчтәлек белән баеды. Ул иректе хезмәт, интернациональ дуслык бәйрәменә әйләнде. Анда үз язмышына хуҗа булган татар халкының бөтен рухи байлыгы, җорлыгы, тапкырлыгы ачык чагыла.

Хәзер сабан туе язгы кыр эшләре беткәннән соң, Татарстан республикасы тезелгән көнгә туры китереп уздырыла. Иң элек ул турыдан-туры хезмәт коллективларында — колхозда, совхозда, район үзәкләрендә уза, аннары сабан туе батырлары республиканың барлык районнарыннан Казанга килә.

Авыл хезмәтчәннәре бу бәйрәмгә кыр эшләрен һәркайда югары сыйфатлы итеп, үз вакытында төгәлләргә тырыша, шулай ук шәһәр халкы да сабан туен хезмәттә, укуда, спортта югары күрсәткечләр белән каршыларга омтыла.

Сабан туена хәзерлек һәм аны тиешенчә уздыру мәсьәләләрендә җәмәгать оешмаларының роле гаять зур. Әйтик, КамАЗда бу бәйрәмне уздыруга үзеннән иң зур өлеш керткән коллективка махсус приз билгеләнә.

Бәйрәм тантанасын оештыру өчен шәһәр һәм район комиссияләре төзелә, халыкның борынгы йоласы буенча, анда аксакаллар да кертелә. Бу комиссияләр барлык хәзерлек эшләрен алдан планлаштыра, район газеталары һәм җирле радио челтәре аша чыгышлар оештыра, плакатлар, афишалар чыгара. Сабан туе мәйданы, халык ял итә торган урыннар, бакчалар, парклар, урамнар хезмәт һәм халыклар дуслыгын чагылдыра торган лозунглар, өндәмәләр белән бизәлә. Әйтик, Бауман һәм Идел буе районнары хезмәт ияләре һәр ел саен сабан туе уздыра торган каенлыкта «Бүген сабан туе!», «Яшәсен тынычлык!», «КПССка дан!» дип язылган аллы-гөлле шарлар ерактан ук күренеп, күңелдә бәйрәм хисе уятып тора. Төрле транспарантлар һәр ике район хезмәт ияләренең социалистик ярыштагы уңышлары турында сөйли.

Тышкы бизәкләре белән генә түгел, бөтен эчтәлеге белән сабан туе хезмәт, дуслык, туганлык идеяләре белән сугарылган була.

Кайбер районнарда сабан туен тигез рәт булып тезелгән мотоцикллар ачып җибәрә. Аларның баш очында унбиш союздаш республиканың дәүләт байрагы җилферди. Апас районында сабан туе ачылуга, партия, совет, комсомол оешмалары җитәкчеләре белән бергә, халыкны котлап, Чувашстаннан килгән кунаклар — үзара ярышучы Яльчик районы вәкилләре чыгыш ясый. Кунаклар сабан туе уеннарына да катнаша. Әйтик, Чүпрәле районында Чувашстан батыры Павлов елның-елында зур бүләкләр ала, ә Космовский исемендәге культура йорты коллективы халык талантлары ярышында берничә ел рәттән җиңүче булып килә. Актанышта сабан туен Башкортстанның Илеш районы белән берлектә уздыру матур гадәткә әйләнеп киткән.

Саный китсәң, мондый мисалларның санына чыгышлы түгел. Сабан туе хезмәт алдынгыларын хөрмәт итүгә багышланган яңа йолалар, яңа гадәтләр белән тагын да баеп бара.

Мондый яңа йолалар хәзер артканнан-арта. Беренчедән, сабан туе флагы күтәрү. Моңа инде карты-яше күнегеп бара. Җәйге зәңгәр күктә ал байрак җилферди башлаганнан соң гына бәйрәм ачылган, тантана башланган исәпләнә. Байракны иң алдынгы эшчеләр, колхозчылар, социалистик ярыш маяклары күтәрә. Колхозларда бу мактаулы вазифаны, гадәт буларак, алдынгы механизаторлар, иң яхшы терлекчеләр үти. Кайбер районнарда аларга шунда ук «Язгы кыр эшләре батыры» дип язылган ал тасма тапшыралар. Зәй районында, язгы кыр эшләре батырын, сабан туе батырына тиңләп, аңа традицион бүләк — сарык тапшыру гадәткә кереп киткән. Ә кайбер якларда байрак күтәрергә берьюлы ике батыр — узган елгы сабан туе батыры һәм быелгы кыр батыры чыга. Питрәчтә исә сабан туе байрагын хөрмәт казанган хезмәт һәм сугыш ветераннары күтәрә. Күп мәртәбә биредә сабан туен шушы якларда туып үскән герой — Брест крепосте каһарманы П. М. Гаврилов ачып җибәрде. Әлмәттә байрак күтәрү тантанасы тагын үзенә бер төрле: узган елгы сабан туй батыры белән бергә шәһәрнең почетлы гражданнары да байрак күтәреп мәйдан әйләнә. Аннары алар иң хөрмәтле кунаклар өчен эшләнгән махсус трибунада урын алалар. Лениногорск, Чүпрәле, Тукай районнарында хезмәт батырлары, бәйрәмчә бизәлгән ачык машиналарга утырып, сабан туена җыелган халык алдыннан уза.

Шулай итеп, бәйрәм ачу тантанасы һәркайда фидакарь хезмәткә дан җыры, җиңү гимны булып яңгырый.

Хезмәттәге уңышларга йомгак ясау белән бергә, сабан туенда халык талантларына да зур игътибар бирелә. Бүгенге сабан туен җырдан, музыкадан, дәртле биюләрдән башка күз алдына китерү дә мөмкин түгел. Хәзер сабан туенда халык иҗатының күмәк формаларына аеруча киң мәйдан ачыла. Югарыда әйткәнебезчә, КамАЗда сабан туен меңләгән үзешчәннәрдән торган хор ачып җибәрә. Казанның Ленин һәм Мәскәү районнарында Гайдар һәм Ленин исемендәге культура сарайларының халык хоры чыгыш ясый, Әгерҗедә шулай ук бәйрәмне район культура йорты үзешчәннәре ача, Апаска Татарстан җыр һәм бию ансамбле килә, Түбән Камада «Яшьлек» музыкаль ансамбле «Сабан туе» исемле хореографик композиция башкара.

Соңгы елларда сабан туенда үзешчән сәнгать конкурслары уздыру гадәткә кереп китте. Мондый конкурслар Тәтеш, Кама Тамагы, Лениногорск, Апас районнарында аеруча уңышлы уза. Бу чара, һичсүзсез, халык бәйрәмен тагын да тирәнрәк эчтәлекле итә, тагын да баета һәм халык талантларының осталыгын арттыруга зур этәргеч була.

Һәм, ниһаять, сабан туе — физкультура, спорт, сәламәтлек бәйрәме. Ул безгә төсен җуймас җәүһәр бөртекләрен саклаган кебек, күп гасырлар аша халкыбызның төрле уеннарын, физкультура, спорт күнегүләрен саклап килгән. Бу уеннар яшь буынны сәламәт, таза итеп үстерергә, аларда физик көч һәм рухи ныклык тәрбияләргә ярдәм итә. Спортның мондый милли төрләре еллар узу белән үзенең әһәмиятен югалтмаган.

Борынгыдан килгән физик күнекмәләрнең кайберләре, әйтик, йөгереш, сикереш хәзер барлык халыклар өчен дә уртак булган гомуми спорт кагыйдәләре нигезендә уздырыла. Шулай ук көрәш, гер күтәрү, ат чабышы кебек милли уеннар өчен дә тегәл кагыйдәләр эшләнгән. Тик сабан туе уеннарының кайбер төрләре, физкультура һәм спорт оешмаларының тиешенчә игътибар итеп җиткермәве аркасында, әле хәзергә кенә кадәр көлкеле уеннар булып кына кала килә. Әмма халык уеннары арасында үзләренең эчтәлекләре белән һәм башкарылу техникасы җәһәтеннән бүгенге спорт таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә формалашканнары байтак һәм, хуҗаларча белеп файдаланганда, аларны югары класслы спортчылар тәрбияләү өчен кулланырга мөмкин.

Татар халкының физик культура күнекмәләрен һәм спорт уеннарын фәнни өйрәнүгә соңгы елларда игътибар сизелә башлады. Әйтик, спортчы һәм галим Э. Галиев, шундый уеннарны өйрәнеп, диссертация язды. Ул аларны физкультура дәресләрен җанландыру өчен мәктәп программасына да кертү файдалы булачак дип саный.

Әйткәнебезчә, борынгы заманнардагы кебек үк, бүгенге көндә дә ат чабышы һәм көрәш сабан туе программасының үзәгендә тора. Көрәш буенча РСФСР спорт комитеты тарафыннан расланган кагыйдәләр дә басылып чыкты. Бу кагыйдәләр буенча сабан туенда гына түгел, елның теләсә кайсы вакытында физкультура-спорт җәмгыятьләрендә татарча көрәш беренчелегенә ярышлар уздырыла. Ярышта җиңүчеләргә спорт разрядлары һәм «РСФСРның милли спорт мастеры» дигән исем бирелә. Көрәш секцияләрен оештыручылар өчен яшь көрәшчеләр хәзерләү буенча махсус кулланмалар 1974 елда аерым китап булып чыкты (М. Сәхабетдинов, Д. Шәрәфетдинов. «Татарча көрәш»). СССР спорт мастеры М. Сәхабетдинов татарча көрәш буенча диссертация яклады.

Шулай итеп, спортның аерым төре буларак, татар көрәше үзенең әһәмиятен югалтмый, киресенчә, халыкта торган саен киңрәк тарала бара.

Сабан туе ветераны, танылган чабышчы Җ. Хәбибуллин халык бәйрәмнәрендә атлы спорт уеннары кагыйдәләрен эшкәртте. Ул, татарча чабышлар белән берлектә, «Сөрән сугу», «Кыз куу» уеннары һәм «Пар ат» ярышлары да уздырырга тәкъдим итә. Җ. Хәбибуллинның бу хезмәте моңарчы телдән-телгә күчеп килгән спорт кагыйдәләрен җыю һәм тәртипкә салу буенча беренче тәҗрибә булып тора.

Шул уңайдан аркан тартышу уенына да тиешенчә игътибар итәргә, спортның аерым төре буларак, аны халык арасында киң җәелдереп җибәрергә, район, республика спорт җәмгыятьләре һәм бигрәк тә «Урожай» ирекле җәмгыяте программасына кертергә күптән вакыт. Дөрес, спортның бу төре хәзергә бернинди календарьга, бернинди методик кулланмага да кертелмәгән. Шуны сылтау итеп, кайбер спорт җитәкчеләре әле хәзер дә аннан йөз чөереп киләләр. Ә соң нигә халкыбызның бу эштә гасырлардан килгән матур традициясен гомуми халык хәзинәсенә әверелдерүне без үзебез күтәреп чыкмыйбыз? Сүз уңаенда шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: 1924 елга кадәр аркан тартышу хәтта Олимпия уеннары программасында да булган. Һәм хәзер дә аның буенча ара-тирә Европа күләмендә ярышлар уздырыла. Аркан тартышу буенча дистәдән артык ил спортчыларын берләштергән махсус федерация бар. Димәк, тиешенчә игътибар булган очракта, спортның бу төре буенча да без халыкара мәйданга чыга алыр идек.

Болардан тыш хәзерге җәйге хоккейга гаять охшашлы «кәшәкә» уены һәм җәядән ук атышу уеннары да бездә бөтенләй онытылып килә. Ә бит «кәшәкә» сүзен әле XI гасырда ук күренекле галим Мәхмүд Кашгари төрек телләре сүзлегенә керткән. Болгар чорында ук киң таралган ук атышу ярышлары исә казакъ халкы эпосында телгә алына. Һәм шулай ук туплы хоккей, ук ату ярышлары Олимпия уеннарында хәзер дә үткәрелә. Колгага менү, салам тутырылган капчык белән бүрәнә өстендә сугышу, аякка капчык киеп йөгерешү, таш күтәрү кебек сабан туе уеннары да, спорт оешмалары тарафыннан тиешле игътибар булган очракта, яшьләрне физик яктан чыныктыру буенча гаять әһәмиятле чара булып китәр иде.

Сабан туе оештыручылар арасында һәм матбугатта бәйрәм традицияләре буенча төрле бәхәсләр чыккалап тора. Еш кына классик көрәш мастерлары авылдан авылга, районнан районга йөреп, барлык бүләкләрне үзләренә җыялар, милли көрәш батырлары бер читтә кала килә, имеш. Бу мәсьәләдә канәгатьсезлек белдереп, журналист Н. Гыйззәтуллин чит кешеләрне сабан туена катнаштырмауны алга сөрә. Чынлап та, спорт осталарының гади көрәшчеләр белән ярышып бүләк җыюын һичничек хуплап булмый. Ләкин кайберәүләр сабан туе мәйданы һәркем өчен ачык булырга тиеш дигән караштa торалар. Күрәсең, бу мәсьәләләр буенча да халыкның элек-электән килгән йолаларын онытып бетерергә ярамыйдыр. Махсус хәзерлек алган батырларны уеннарны оештыру һәм үткәрүдә катнаштыру һәм шул эш өчен бүләкләү гаделрәк булыр иде кебек. Андый пәһлеваннар сабан туена бүләк җыю өчен генә килмидер, әлбәттә. Әйтик, Чүпрәле районына елның-елында сабан туена Магаданнан элекке сабан туе батыры Мансур Айзатуллин кайта. Шундый ерак юл узып, сабан туена кайту өчен аңа, әлбәттә, һичкем командировка бирми. Шулай булгач, көрәшеп бүләк алу аңа нинди файда, нинди табыш китерсен икән? Аннары бит хәзерге авыл көрәшчеләре дә төшеп калганнардан түгел. Татарстанда туып үскән сабан туе батырларыннан илледән артык кешегә хәзер РСФСРның спорт мастеры дигән исем бирелгән. Боларга

инде спортның башка төрләре буенча махсус хәзерлеге булган танылган мастерлар да көндәш була алмый.

Аннары шуны да әйтеп китәсе килә: махсус бүләкләр белән бергә сабан туе батырларына Мактау грамоталары, дипломнар, истәлекле значоклар да тапшыру гадәткә керсен иде.

Сабан туе вакытында ГТО тапшыру мәсьәләсендә дә еш кына бәхәс чыга. Язучы М. Мәһдиев: «Сабан туен ГТО нормасы тапшыру чарасына әверелдерергә ярамый»,— дип язды. Ә педагогия фәннәре докторы, профессор Я. Ханбиков һәм педагогия фәннәре кандидаты Э. Галиев, киресенчә, моны уңай күренеш дип саныйлар.

Сүз дә юк, спортның хәзерге төрләре сабан туеның эчтәлеген баета гына бара. Әмма шул ук вакытта сабан туеның спорт ярышы гына түгеллеген дә онытырга ярамый. Барыннан да бигрәк сабан туе — ул халыкның күңел ачу бәйрәме, барлык уңышларга йомгак ясый торган хезмәт тантанасы. ГТО нормалары тапшыру белән генә мавыккан очракта ул спорт җәмгыятьләренең кайбер эшлексез җитәкчеләре өчен төрле отчетлар язу, күз буяу чарасына әверелеп китәргә мөмкин. Шул ук вакытта сабан туенда ГТО нормаларын пропагандалау да беркемгә дә зыян китерми. Бу мәсьәләдә бездә инде шактый уңай тәҗрибәләр бар. Әйтик, Мамадышта, Кукмара, Балтач, Әлмәт районнарында менә берничә ел инде «Кышкы сабан туе» уздырыла. Бу бәйрәмнәр, халык уеннары белән бергә, спортның хәзерге төрләрен дә эченә алган үзенчәлекле спартакиадага әверелеп бара.

Хәзер гомумхалык бәйрәме — сабан туеның «кече туганнары» да дөньяга килде. Мәктәпләрдә, пионер лагерьларында, «Васильево», «Крутушка» ял йортларында сабан туе уеннары уздыру инде чын-чыннан матур традициягә әверелеп китте.

Безнең бу милли бәйрәмебез елдан-елга киңрәк җәелә, интернациональ эчтәлек ала. Бөтен дөнья халыклары Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгын уздырырга җыенган чорда сабан туе тагын да күтәренке рух белән, гомуми халык тантанасы булып үтте. «Советская Татария» газетасында әйтелгәнчә, сабан туе ул — талантлы халыкның үзешчән бәйрәме. Менә шулай бирелеп күңел ача белә торган халык, җир җимертеп эшли дә, бетмәс-төкәнмәс физик һәм рухи көчен илгә күрсәтеп яши дә белә.

## Госман Хәбибуллин,

# ГАЛИМ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

**Бу көндә Казан 140 мең нәфесле (йортлы) бер зур шәһәр булып (1910 ел исәбе буенча — Г. Х.) бөтен Шәрык Русиянең, хәтта Кавказ, Урта Азия һәм Сибирия вилаятьләре (төбәкләре) өчен дә һөнәр, сәнәгать (промышленность), гыйлем вә мәгърифәт хәзинәсе булып санала.**

**(Г. Әхмәрев. «Казан тарихы». 1910 ел.)**

Соңгы елларда татар халкының бай әдәби, тарихи мирасын һәм иҗтимагый фикерен өйрәнү эше сизелерлек алга китте. Без бу җәһәттән тарихчылар Рәфыйк Нәфиков, Миркасыйм Госманов, Сәвия Михайлова, философ Яхъя Абдуллин монографияләрен һәм «Казан утлары» журналы битләрендә басылып чыккан күп санлы мәкаләләрне күздә тотабыз. Бу авторлар татар халкын агартуда зур хезмәтләр күрсәткән мәгърифәтче-галимнәр Ибраһим Хәлфин, Хөсәен Фәезханов, Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри һ. б. турында кызыклы һәм әһәмиятле материаллар язды.

Шулай да үз чорында шактый күп эшләгән һәм бик әһәмиятле фәнни әсәрләр калдырган галимнәребезнең кайберләре турында без бик аз беләбез әле. XIX йөзнең соңгы чирегендә фән мәйданына килеп зур-зур хезмәтләр иҗат иткән тарихчы, этнограф, педагог һәм тел галиме Гайнетдин Әхмәрев — шундый галимнәрнең берсе. Гәрчә Әхмәрев язганнар Болгар һәм Казан тарихы буенча эшләүче галимнәр өчен ышанычлы чыганаклар булып хезмәт итсәләр дә, аның иҗатын татар халкының иҗтимагый фикер тарихына бәйләп карау чираты җитми килде.

Бу чыгышта Г. Әхмәревнең тормыш юлы һәм иҗаты күзәтелер, аның халкыбыз һәм Казан шәһәре тарихын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре барланыр.

*

* *

Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәрев 1864 елда элеккеге Зөя өязе Наратлы авылында гади крестьян гаиләсендә туа. Үз авылындагы мәдрәсәне тәмамлагач, 17 яшьлек сәләтле егет Казанга килә һәм 1881 елда учительская школага укырга керә. Биредә дөньяви фәннәр укуы Әхмәревнең фикере һәм дөньяга карашы формалашуга зур йогынты ясый. Аның тарих фәне, бигрәк тә үз халкының үткәне белән кызыксынуы да шушы школада укыган елларда башлана. Рус тарихчыларының әсәрләрен уку белән бергә, ул гарәп һәм фарсы телләрендәге чыганаклар белән дә таныша. Аны бигрәк тә гарәп илгизәрләренең һәм рус елъязмачыларының татар халкының борынгы бабалары булган Идел буе болгарлары хакындагы язмалары кызыксындыра. Ә татар тарихчысы Ш. Мәрҗанинең тарихи әсәрләре, бигрәк тә 2 томдагы «Мостафад әль-Әхбары»ы Әхмәрев өчен кулдан төшмәс китапка әверелә.

1885 елда, учительская школаны уңышлы тәмамлаганнан соң, Г. Әхмәрев Алабуга өязе Биектау авылына рус теле укытучысы итеп билгеләнә. Соңыннан ул Тәтеш шәһәрендәге татар училищесында рус телен укыта. Тәтештә эшләгәндә (1891—1903)

инде байтак тормыш тәҗрибәсе һәм тарих фәнендә теоретик хәзерлеге булган яшь галим беренче фәнни адымнарын ясый. Әмма биредә шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, фәнни тикшеренү эшләрен оештыручы һәм аны житәкләүче үзәкнең булмавы сәбәпле, Г. Әхмәрев кебек сәләтле яшьләр үзләренең иҗади эзләнүләрен үзлекләреннән башкарырга мәҗбүр булалар. Аннары борынгы дәвердә татар галимнәре тарафыннан язылган тарихи әсәрләрнең азлыгы соңгы чор тарихчыларын яңа төр чыганаклар эзләүгә этәрә. Мәсәлән, без И. Хәлфин, Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗани, К. Насыйриларның археология материалларыннан, эпиграфик истәлекләрдән (кабер ташларындагы язмалар), халык телендә гасырлар дәвамында сакланып килгән төрле риваять һәм легендалардан киң файдаланганлыкларын беләбез. Әхмәрев тә, үзенең өлкән замандашлары кебек үк, археология материалларын җентекләп өйрәнә.

Идел буе халыклары, шул исәптән татар халкының да тарихын киң планда өйрәнүгә 1878 елда Казан университеты каршында төзелгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте зур этәргеч ясый. Бу җәмгыятьне оештыручы һәм аның беренче членнары И. А. Бодуэн-де-Куртенэ, И. Ф. Готвальд, Н. П. Загоскин, В. В. Радлов, С. М. Шпилевский һ. б. күренекле рус галимнәре була. Озак та үтми, Ш. Мәрҗани, Мөхәммәтҗан Заһитов, Габдрахман Ильяси, К. Насыйри һ. б. татар вәкилләре археология җәмгыятенең членнары итеп сайланалар. Бу әлбәттә, очраклы хәл булмый. Чөнки җәмгыять оешкан көннән үк аның житәкчеләре үз сафларына җирле халык, шул исәптән татар галимнәрен һәм интеллигенция вәкилләрен дә кертү чарасына керешәләр. Хәтта бу турыда җәмгыятьнең председатель урынбасары С. М. Шпилевский 1879 елның 19 мартында махсус чыгыш та ясый. Билгеле, иске татар тарихи чыганаклары буенча Мәрҗани, Ильяси, Насыйри кебек белгечләрнең рус галимнәренә ярдәме зур булачагы ачык аңлашылса кирәк. Г. Әхмәрев кебек яшь талантны рус галимнәре бик тиз күреп алалар һәм аны археология җәмгыятенә хезмәттәшлеккә җәлеп итәләр. 1893 елның 19 сентябрендә ул шул җәмгыятьнең член-сотрудникгы итеп сайлана.

1891 елда Алабуга өязенең Биектау авылында укыткан вакытында Г. Әхмәрев «Городище Япанчино на реке Кубне (левый приток Свияги)» дигән беренче фәнни хезмәтен яза[1]. Ә 1894 елда бу мәкалә шул исем белән археология җәмгыятенең «Хәбәрләр»ендә басылып та чыга. Күләме зур булмаган бу язма җәмгыять галимнәренең игътибарын кай ягы белән кызыксындырган соң? Бу сорауга җавап бирү өчен түбәндәге мәсьәләне ачыклап үтү кирәк булыр. Болгар-Казан дәүләтләре дәвереннән сакланып калган язма чыганакларны, шулай ук археологик, нумизматик, эпиграфик истәлекләрне барлау һәм өйрәнү эшендә күренекле рус галиме С. М. Шпилевский зур хезмәт күрсәтә. Ул IV Бөтенроссия археология съезды ачылу алдыннан үзенең 585 биттән торган фундаменталь хезмәтен яза[2]. Кайбер төгәлсезлекләрен исәпкә алмаганда, бу хезмәт борынгы Болгар-Казан дәүләтләре территориясендә сакланып калган археологик һәм эпиграфик истәлекләрне тулырак туплаган бердәнбер китап булып тора. Ләкин теге яки бу шәһәрнең кайчан нигезләнүен һәм җимерелүен, анда нинди халыклар яшәвен, аларның культура һәм һөнәр җәһәтеннән ни дәрәҗәдә үскән булуын билгеләү өчен археологик материалларны җыеп өйрәнү генә җитми. Болар белән бергә тарихи язма чыганакларны, халык телендә буыннан-буынга сакланып килгән риваятьләрне, тел үзенчәлекләрен, кабер ташларындагы язуларны да җентекләп өйрәнергә кирәк. Г. Әхмәровнең без күрсәтеп үткән мәкаләсе шушы төр чыганакларның барысын да тикшереп, Зөя өязе Япанчы дигән авыл янында сакланып калган шәһәрлекнең борынгы тарихын билгеләүгә багышланган. Автор бу хезмәтендә Татар Наратлысы авылында яшәгән Хәмит Ишмөхәммәтев дигән кешенең тарихи язмаларын да кулланган[3]. Төрле чыганакларны җентекләп тикшергәннән соң Әхмәрев шундый нәтиҗәгә килә: халык

---

[1] Бу мәкаләнең төп нөсхәсе 1361 нче номер белән Казан университеты каршындагы гыйльми китапханәнең кулъязмалар бүлегендә саклана.

[2] Кара: С. М. Шпилевский. Древние города и другие Булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877.

[3] Әхмәрев әйтүенчә, бу кеше үз заманы өчен шактый югары дәрәҗәдәге татар укымышлыларыннан булган. Ул берничә мәртәбә Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренә сәяхәт иткән, шулай ук тарихи язма чыганаклар җыю белән дә шөгыльләнгән. Ишмөхәммәтев XIX йөзнең 60 нчы елларында үлә, аның көнчыгыш телләрендә язылган бик күп тарихи кулъязмалары кала.

телендә сөйләнеп килгән риваятьләргә караганда, элек бу шәһәрлектә Болгар дәүләте кул астында булган мәҗүси халык яшәгән. Соңыннан ул Биләр князьләре Нурат һәм Дурт Имән тарафыннан җимерелгән. Нурат үзенең сугышчылары белән шушы шәһәрлектән ерак түгел бер урынга килеп утырган. Шуңа күрә, — дип яза риваятьләргә таянган Әхмәрев, — бу авыл князь исеме белән Наратлы дип аталган. Шуныси да әһәмияткә ия, автор Япанчы шәһәрлегендә мәҗүси халыклар яшәгәнен һәм Япанчы дигән исемнең дә мари һәм удмурт телләре ярдәмендә аңлатылу мөмкинлегенә игътибар итә. Бу урында Әхмәрев үзен сәләтле һәм яхшы хәзерлекле тел белгече итеп тә күрсәтә. Аның бу кечкенә генә мәкаләсе хакында болай озын итеп сөйләвебез очраклы түгел. Беренчедән, бу Әхмәревнең басылып чыккан беренче фәнни хезмәте. Икенчедән, монда аның гыйльми тикшеренүдә, фикерләрен җәмәгатьчелеккә җиткерүдә өметле каләм иясе икәнлеге дә чагылып үтә. Әхмәревнең бу әйбәт сыйфатлары киләчәк хезмәтләрендә тагын да үсә төшә.

Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә член булып сайлануы, университет һәм җәмгыятьнең галимнәре белән фәнни бәйләнештә торуы Г. Әхмәревнең иҗатына сизелерлек уңай тәэсир ясый. Ул тиз арада җәмгыять эшендә киркле һәм талантлы белгеч булып таныла. Фәнни эзләнүләрне белеп һәм югары дәрәҗәдә башкаруы өчен аны еш кына җәмгыять исеменнән теге яки бу төбәккә командировкаларга җибәрәләр. Шундый командировкаларның берсендә Әхмәрев фәнни ачыш ясый. Болгар дәүләтенең иң зур шәһәрләреннән берсенең — Суварның урынын таба. Шуңарчы күп еллар буена бу шәһәрнең урыны кайдалыгы турында төрле фикерләр яшәп килгән. Мәсәлән, күренекле нумизмат, 1846 елда Петербургта төзелгән рус археология-нумизматик җәмгыятен оештыручыларның берсе П. С. Савельев Суварны Свияжск (Зөя) урынында булган дип исәпли, ә кайберәүләр исә аны Спасск (Татарстандагы хәзерге Куйбышев) шәһәре белән бәйлиләр.

Әхмәрев, 1893 елның җәйге командировкасы нәтиҗәләренә нигезләнеп, Сувар шәһәренең урыны Спасс өязе Кузнечиха авылы урынында булганлыгын ышанычлы дәлилләр белән исбат итә. Аның бу әһәмиятле фәнни ачышы университет һәм җәмгыять галимнәре тарафыннан зур бәя ала. Бу турыда археология җәмгыяте «Хәбәрләр»ендә аның председателе профессор Н. А. Фирсов, секретаре мәшһүр тюрколог Н. Ф. Катанов, профессор И. Н. Смирнов, И. Л. Износков, М. М. Хомяков һ. б. язып чыга. Ә 1894 елда Әхмәрев, җәмгыять тапшыруы буенча, Спасс өязенең башка археологик истәлекләрен дә тикшерә. Ул табып алып кайткан тарихи материаллар археология музее коллекцияләрен баетуда зур өлеш була. Мәсәлән, Сувар экспедициясеннән Әхмәрев 97 төрле әйбер, ә 1894—1895 елларда Спасс һәм Тәтеш өязләренә барган командировкасы вакытында 52 борынгы истәлекләр үрнәген алып кайтып музейга тапшыра. Ул җәмгыятьнең җыелышларында һәм утырышларында да актив катнаша. Г. Әхмәревнең искедән сакланып калган татарча язма чыганаклардан файдаланып язылган докладлары, Болгар һәм Казан тарихына караган язма истәлекләрне тикшерү турындагы чыгышлары җәмгыять членнары арасында зур кызыксыну уята. Мәсәлән, җәмгыять секретаре профессор Н. Ф. Катанов Әхмәревнең 1894—1895 елларда археология һәм этнография материаллары җыю максаты белән Тәтеш һәм Спасс өязләренә баруы турындагы зур һәм тәфсыйлле докладына югары бәя бирә.

Г. Әхмәрев 1903 елда семьясы белән Казанга күчеп килә һәм Иске татар бистәсендәге татар мәктәбенә рус теле укытучысы булып урнаша. Шул вакыттан башлап аның фәнни эшчәнлеге сизелерлек активлаша.

Безгә Г. Әхмәревнең русча язылган унбишләп фәнни мәкаләсе билгеле. Аларның барысы да дип әйтерлек 1893—1910 елларда Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең «Хәбәрләр»ендә басылып чыккан. Шулар арасыннан фәнни яктан әһәмиятлерәкләре һәм күләмнәре ягыннан да зурраклары түбәндәге әсәрләр:

Мишәрләр һәм аларның телләре турында. Казан, 1903 ел.

Казан татарларының туй гадәтләре. Казан, 1907.

Типтәрләр һәм аларның килеп чыгышлары. Казан, 1908.

XIX йөзнең соңгы чирегендә татар халкының һәм аның бер этник группасы булган мишәрләрнең дә килеп чыгышы мәсьәләсе белән кызыксыну көчәя башлый.

Билгеле, бу проблема археология җәмгыяте галимнәре игътибарыннан читтә калмый. Мәсәлән, җәмгыятьнең 1895 елның 27 октябрендә булып узган гыйльми утырышында мишәрләрнең этногенезы мәсьәләсе карала. Бу утырышта «мишәрләрнең телен һәм гадәтләрен өйрәнү өчен аларның авылларына махсус экспедиция оештыру» турында карар кабул ителә. Бу эштә Г. Әхмәрев башлап йөрүчеләрнең берсе булган дияргә мөмкин. Мишәрләрнең килеп чыгышы мәсьәләсен ул объектив тарихи шартларга бәйләп чишәргә омтыла. Хезмәтен язганда автор кулланган чыганаклар игътибарга лаек. Ул мишәрләрнең тел үзенчәлекләрен, алар хакындагы тарихи язма чыганакларны һәм риваятьләрне, авылларының килеп чыгышы һәм аталышларын, физик һәм рухи сыйфатларын, көнкүреш һәм әхлакларын, киемнәрен һ. б. якларын бик җентеклəп тикшергән, алар турында гаять бай мәгълүмат китергән. Г. Әхмәревнең бу хезмәте рус галимнәре арасында зур кызыксыну һәм яклау тапкан. М. М. Хомяков һ. б. галимнәр аның бу әсәрен уңай бәяләгәннәр һәм үзләренең хезмәтләрендә файдаланганнар. Чыганакларга бай булуы белән бу хезмәт әле бүген дә үзенең фәнни кыйммәтен югалтмаган.

Әхмәревнең Казан университеты һәм археология җәмгыяте галимнәре белән иҗади бәйләнеше һәм дуслыгы аеруча игътибарга лаек. Егерме елга якын Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә член булып тору дәверендә ул Казан университеты профессорлары И. А. Александров, Н. Ф. Высоцкий, Н. Ф. Катанов, Д. А. Корсаков, П. И. Кротов, Н. П. Загоскин һ. б. лар белән аралашып яшәгән һәм эшләгән. 1894—97 елларда җәмгыятьнең секретаре, ә 1898—1914 елларда председателе булып эшләгән күренекле галим, профессор Н. Ф. Катанов Г. Әхмәревне җәмгыять членлыгына тәкъдим итеп кенә калмаган, ә озак еллар буена аның белән якын иҗади мөнәсәбәттә булган.

1907 елда җәмгыять каршында Казан губернасының археологик һәм этнографик картасын төзү буенча махсус комиссия төзелә. Аның составына П. И. Кротов, П. А. Пономарев, Н. В. Никольский, Я. Д. Коблов һәм Г. Әхмәрев кертелә. Берничә ел дәвамында бу комиссия Казан губернасында археологик һәм этнографик эзләнүләр алып бара.

Әйтеп киткәнебезчә, бу җәмгыять эшендә алдынгы татар вәкилләре дә актив катнашалар. Г. Әхмәревкә күренекле татар мәгърифәтче-галиме К. Насыйри белән берничә ел дәвамында бергә эшләргә туры килә. Аларның фәнни хезмәтләре җәмгыять «Хәбәрләр»ендә басылып бара.

Археология җәмгыятенең озак еллар дәвамында тупланып килгән бай һәм зур музее белән китапханәсе дә була. Алар Россиянең башка шәһәрләреннән, шулай ук чит илләрдән алынган китаплар белән даими тулыландырыла. Димәк, Г. Әхмәрев һәм К. Насыйри үзләренең фәнни хезмәтләрен язганда китапханә һәм музей фондларыннан һәр вакыт файдалана алганнар. Җәмгыять Россиянең 150 гә якын, чит илләрнең 50 дән артык гыйльми җәмгыятьләре белән даими бәйләнештә торган. Мәсәлән, ул үзенең «Хәбәрләр»ен Петербург, Мәскәү, Киев, Харьков, Рига, Ташкент, Одесса, Воронеж, Саратов, Тифлис, Симферополь кебек шәһәрләргә җибәрүдән тыш, Австралия, Австро-Венгрия, Төньяк Америка (Калифорния университетына), Англия, Болгария, Германия, Италия, Төркия, Швеция һ. б. илләрнең гыйльми оешмаларына җибәргән. Алар исә үзләренең гыйльми җәмгыять материалларын һәм китапларын Казанга җибәреп торганнар. Димәк, без Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г. Әхмәрев һ. б. ларның җәмгыять «Хәбәрләр»ендә басылып чыккан әсәрләрен Россиянең башка шәһәрләрендә генә түгел, ә күп кенә чит илләрдә дә укыганнар, өйрәнгәннәр һәм үз хезмәтләрендә файдаланганнар дип әйтә алабыз.

Инде Г. Әхмәревнең татарча язылган фәнни хезмәтләренә күчик. Безнең барлавыбызча, ул татар халкының тарихына һәм педагогия мәсьәләләренә багышланган 20 дән артык мәкалә һәм китап язган. Шулар арасыннан иң әһәмиятлеләре итеп «Болгар тарихы» (Казан, 1909 ел) һәм «Казан тарихы» (Казан, 1910 ел) исемле китапларын атарга кирәк. Бу әсәрләрнең фәнни кыйммәтләрен бәяләүдән элек, Г. Әхмәревнең иҗтимагый-фәнни эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән бер мөһим мәсьәләне ачыклап китик. Ул — Әхмәревнең Шәрык клубы эшендә актив катнашуы.

1907 елның 1 декабренда Казан шәһәрендә ачылган Шәрык клубы эшенә старшиналар советы җитәкчелек иткән. Клуб ачылганнан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр Г. Әхмәрев старшиналар советы члены вазифасын үти һәм аның иң актив эшлеклеләренең берсе була. Ул татар халкының борынгы тарихы буенча дистәләрчә лекция һәм докладлар белән чыгыш ясый.

Г. Әхмәревнең тарихи карашларын һәм иҗтимагый-политик процессларны яктыртуда нинди юнәлештә торуын билгеләү өчен XIX йөзнең соңгы чиреге татар историографиясендә булган үзгәрешләрне ачыклап китү кирәк булыр.

Мәгълүм ки, XIX йөзнең икенче яртысында рус тарихи фәненең үсеше Россиянең социаль-экономик тормышындагы катлаулы процесслар белән тыгыз бәйләнгән хәлдә бара. Крепостное правоның җимерелүе, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе, революцион көчләрнең азатлык өчен барган туктаусыз көрәше — боларның барысы да рус историографиясенең торышына зур тәэсир ясый. Гомуми буржуаз үсеш процессына тартылган Россия халыкларында да, шул исәптән татар халкында, русның алдынгы иҗтимагый фикере йогынтысы нәтиҗәсендә яңа тарихи фикер формалаша башлый. Шиһап Мәрҗани тарафыннан нигезләнгән татар буржуаз тарих фәне XIX йөзнең соңгы чирегендә кризиска дучар булды. Үз чоры өчен прогрессив булган татар буржуаз историографиясе XIX гасырның ахырында либераль-буржуаз тарихи агым белән якынайды һәм үзенең иҗтимагый-политик йөзен үзгәртте. Шуның белән бергә татар историографиясендә прогрессив-демократик юнәлеш барлыкка килде. Үзенең иҗади эшчәнлеген халык массалары белән бәйләгән бу агымның күренекле вәкилләре булып, атаклы мәгърифәтче-галим Каюм Насыйри һәм Гайнетдин Әхмәрев тордылар. К. Насыйри үзенең бөтен гомерен татар халкын агартуга, массалар арасында мәгърифәт орлыклары чәчүгә багышлаган булса, Г. Әхмәрев тә кыска гына гомерен үз халкының тарихын, этнографиясен, телен өйрәнүгә һәм уку-укыту системасын камилләштерүгә багышлады.

Әхмәрев фикеренчә, тарих фәне — үткән заманның хәленнән хәбәр бирүче бер фән. Ул, һәр милләтнең үзенә махсус тарихы була, шуның кебек үк безнең дә (татар халкының — Г. Х.) үзебезгә махсус тарихыбыз булырга тиеш, дип карый. Аның фикеренчә, тарих, беренче чиратта — халык массалары тарихы. Шәрык клубында күп тапкыр лекция һәм докладлар белән чыгыш ясавы, татар халкы тарихына мөнәсәбәте булган борынгы язма истәлекләрне, халык телендә сакланып калган төрле риваятьләрне җыюы — боларның барысы да татар халкының тарихын булдыруга юнәлдерелә.

«Болгар тарихы»исемле әсәрен Әхмәрев болгарларның борынгы бабалары кем булганлыкларын ачыклаудан башлый. Бу хакта күп төрле чыганакларны тикшергәннән соң, автор болгарларның төрки халыклар нәселеннән булуын яңа материаллар белән ачыклап үтә[1]. Ә Идел буе болгарларының хәзерге Казан татарларының бабалары икәнлеген исбатлауга аерата игътибар итә. Моның шулай икәнлеген Әхмәрев ныклы дәлилләр китереп исбатлый, ә бу мәсьәлә буенча аңарчы хөкем сөргән ялгыш карашларны нык тәнкыйтьли. Болар тагын бер тапкыр аның тарихи чыганакларны һәм теге яки бу проблема буенча язылган фәнни хезмәтләрдән файдаланганда тәнкыйть методы белән эш итүен күрсәтәләр. Автор Болгар дәүләтенең чикләре, шәһәрләре, күршеләрендә яшәгән халыклар турында тәфсилле мәгълүмат бирә. Ул Болгарның күрше халыклар һәм чит илләр белән сәүдә итүен тарихи факторлар белән яктырта. Шулай ук әсәрдә болгар халкының гадәт һәм йолалары, дине, дәүләт эшлеклеләре һ. б. турында гаять бай һәм кызыклы мәгълүмат китерелгән.

Г. Әхмәревнең «Казан тарихы» дигән әсәре «Болгар тарихы»ның дәвамы итеп каралырга тиешле. Моның шулай икәнлеген авторның түбәндәге сүзләреннән дә ачык күрергә мөмкин. «Болгар дәүләте тузганнан соң, — ди автор, — аның урынында Казан ханлыгы төзелгән. Болгар вә Казан гадәттә бер-берсеннән аерым, ягъни икесе ике мәмләкәт кеби саналып йөртелсәләр дә — боларның тарихи хәлләрен дикъкать илә тикшергәндә бер-беренә мөнәсәбәтләре, хәтта икесе бер мәмләкәт

---

[1] Идел буенда яшәгән болгарларның төрки халыклар нәселеннән булуы турында «Мостафад эль-Әхбар фи Әхвале Казан вә Болгар» исемле әсәрендә Ш. Мәрҗани нигезле итеп әйтеп үтә.

булганлыгы ачык беленә. Казанның да халкы шул ук болгар халкы булып, аларның барча гадәтләре, кәсеп вә һөнәрләре дә болгарларныкы булган»[1]. Шунысы да әһәмияткә ия, Г. Баттал, З. Вәлиди кебек милләтче галимнәр этник тарихны бөтенләй онытып, гел политик тарих белән мавыккан вакытта Г. Әхмәревнең социаль һәм этник мәсьәләләргә төп игътибар бирүе күренә. Автор бу әсәрендә Казан татарларының күршеләре булган башкортлар, марилар, мордвалар һ. б. халыклар турында да мәгълүматлар китерә. Казанның политик тарихын яктыртканда ул аны дәүләт эшлекләләре тарихын тасвирлауга гына кайтарып калдырмый. Шулай ук, буржуаз галимнәр кебек, аларны идеаллаштыру юлына да басмый. Әйтергә кирәк, буржуаз тарихчылар Казан ханлыгының җимерелүенә төп сәбәп итеп ханнар арасында килеп чыккан низагларны һәм төрле политик төркемнәр арасында тәхет өчен барган көрәшне күрсәттеләр. Ә халык массаларының ханнар һәм бәкләр тарафыннан булган рәхимсез изүләргә чыдый алмыйча, аларга каршы баш күтәрү очракларына аңлы рәвештә күз йомып үттеләр. Г. Әхмәрев исә, татар демократик историографиясенең бер вәкиле буларак, халык массаларының ирек өчен көрәшләренә дә игътибар итә.

Ул Казан ханнарына ясак түләп торган чуваш, мари, мордва, удмурт кебек халыкларның изүгә каршы чыгышларын да күрсәтә.

XIX йөздәге татар галимнәре И. Хәлфин, Х. Фәезханов, Ш. Мәрҗани, К. Насыйрилар үз заманында Болгар иленә килеп алар хакында бай мәгълүмат язып калдырган гарәп илгизәрләренең һәм рус елъязмачыларының болгарлар, Казан татарлары һ. б. төрки халыклар турындагы мәгълүматларыннан бик киң файдаланганнар, аларны ышанычлы чыганаклар дип күрсәткәннәр. Г. Әхмәрев гарәп илгизәрләренең Олуг Болгарга килүләре һәм болгарлар хакында язып калдырган мәгълүматларын үз хезмәтләрендә файдаланып кына калмый, бәлки киң халык массаларына җиткерү максаты белән 1908 елда «Йолдыз» газетасы битләрендә ибн Фадлан, ибн Рустә һәм Әбү Хәмид әл-Гарнатиларның язмаларын татар теленә тәрҗемә итеп бастыра, бу өч сәяхәтченең әлеге мәгълүматларын һәрберсен аерым китап итеп бастырып чыгару ниятендә торуын әйтә.

Г. Әхмәрев эшчәнлеге өчен хас булган тагын бер сыйфат шул — ул да булса аның халыкта тарих фәненә мәхәббәт уятуы, тарихи язма истәлекләрне, риваятьләрне җыюны оештыруы. Бу җәһәттән ул үзе болай дип яза: «Дәхи халыкның гадәтләрендә, кәсепләрендә (исемнәр, мәкальләр, җырлар, бәетләр кеби) милләт тарихы өчен күп хәбәрләр табарга мөмкин. Болай булгач, «тарих юк» дип зарланып кына уздыру... бер дә муафыйк түгел, бәлки зур гафиллектер. Нәсел-нәсәпләребезне яхшылап белмичә асылсыз вә дәлилсез үзебезне татар санап яки... «без татар түгел — мөселман яки төрки» дип ачуланышып йөрү бер дә мәгърифәттән түгел. Асылыбызны яхшылап тикшереп, милләтебезнең тарихын барлыкка чыгару өчен үзебезгә тырышу лазим буладыр, тырышмый, әзләми ни кадәр торсак та безгә тарих китереп бирүче булмас. Тырышсак, үзебезнең кем икәнлегебезне белербез һәм гайре мәмләкәтләргә аңлатырбыз, дәхи ватан вә милләтебезнең тарихын да барлыкка чыгарырбыз»[2].

Озак вакытлар авырып ятканнан соң 1911 елның 20 сентябрендә 46 яшендәге Г. Әхмәрев вафат була. Аның үлеме фән өчен зур югалту буларак кабул ителә. Рус һәм татар матбугаты битләрендә Әхмәревнең вафаты уңае белән күп санлы некрологлар басыла. Аларда аның киң карашлы, талантлы галим һәм җәмәгать эшлеклесе булганлыгы күрсәтеп үтелә. Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте идарәсе членнары Әхмәревнең үлемен зур югалту дип белдерә һәм аны «Җирле халыкларның тарихларын һәм көнкүрешен өйрәнүгә зур өлеш кертүче, шулай ук җәмгыять эшендә актив катнашучы галим» буларак искә ала.

[1] Г. Әхмәрев. Казан тарихы. Казан, 1910 ел, 3 бит.
[2] Г. Әхмәрев. Ватан вә милләт тарихы хакында. «Казан мөхбире», 1906 ел, 14 апрель, № 68.

**Геннадий Волков,**
педагогия фәннәре докторы,
профессор

# КАЗАН — МӘХӘББӘТЕМ МИНЕМ

Укыту округының алты губернасын университеты тирәсенә туплаган Казанга, культура үзәге буларак, Идел буеның бар халыклары элек-электән тартылып яшәде. Өстәвенә, татар халкының үз вакыты өчен тиешле дәрәҗәдә югары культурасы, беренче чиратта, әлбәттә, төрки халыклар арасында таралып, аларның рухи казанышларына уңай тәэсир ясап килде.

«Чувашстан АССР тарихында» (I том, 35—48 битләр) татарлар белән чувашларның ерак бабаларының территория, дәүләт, этник һәм культура ягыннан якынлыгы турында фикер әйтелә. Казан шәһәренә нигез салуда татарлар белән бергәләп чувашларның катнашуы мөмкинлеге бик ихтимал. Татарларга тугандаш кабилә вәкилләре буларак, чувашлар Казанның беренче кешеләре арасында һичшиксез булгандыр. Казан турында легендалар һәм тарихи риваятьләрнең, Казанга багышланган җырлар һәм табышмакларның күплеге бер дә очраклы хәл түгел. Һәр хәлдә, татар һәм чувашларның Казан йогынтысында формалаша килгән тарихи һәм рухи-әхлакый якынлыгын инкарь итә алмыйбыз. Шунлыктан татар тел галимнәренең чувашның «Хозан-Хузан-Хусан» кебек атамаларын аеруча игътибар белән тикшеренүләре аңлашыла.

Хәлбуки, бу тема — бик киң колачлы өлкә, аңа күп томлы монографияләр багышларга мөмкин. Шушы проблеманың шәхсән минем үземә кагылган өлеше дә бар, чөнки Казан минем тормышымда искиткеч зур урын тота. Бу фактның үзендә генә дә шәхсинең иҗтимагый, миллилекнең интернациональлек белән кушылуын күрергә була. Казан — чуваш халкы тарихының мөһим һәм аерылмас өлеше ул. Әгәр мин халык улы икәнмен, димәк, Казан — безнең халыкның тәрҗемәи хәленнән бер кисәк.

Шулай диюем белән мин хакыйкатькә хилафлык эшләмим. Фикеремне дәлилләп кайбер мәгълүматлар гына китерим.

«Чувашстан АССР тарихы»ның беренче томы 230 битле, шулардан туксан ике биттә, ә икенче томда кырык дүрт биттә Казан исеме берничә мәртәбә искә алына. Өстәвенә, аның исеме аталмаган очраклар тулып ята: тарихи вакыйга турында әйтелә, ә урыны күрсәтелми, чөнки аның Казан икәнлеге һәркемгә мәгълүм. Фәннәрнең бөтен тармаклары буенча чувашлар турында җитди гыйльми

басмалар революциягә кадәр Казанда басылды. Шушы борынгы шәһәрдә беренче чуваш әлифбасы чыкты, чуваш газетасы оештырылды, беренче сүзлек дөнья күрде, чуваш теленең күп томлы сүзлеген бастыру башланды, этнография буенча тәүге хезмәтләр, халык авыз иҗаты җыентыклары эшләнде. Казан университетында күренекле чуваш мәгърифәтчесе И. Я. Яковлев белем алды. Шунда татар мәдәнияты әһелләре белән дуслашып, аларның әдәби һәм фәнни телен үзләштерде (ә сөйләм телен ул яшьтән белә иде). Иң сирәк тарихи документлар нәкъ менә Казан архивларында һәм китапханәләрендә сакланды.

Казан — чуваш халык иҗатында поэтик образ. Бу образ каршылыклы: аңарда шәһәрнең мәһабәтлелеге белән соклану һәм горурлану, губерна чиновниклары алдында сагаеп калу хисләре дә бар. Әлбәттә, чувашларны буйсындырып яшәгән Казан ханлыгы чорыннан калган катламнар да юк түгел. Моңсу «Элшел» җырында Казан шәһәрендә юллар кәгазьдән дип җырлана. «Уразмәт», «Иван кыры», «Тархан», «Тархан авылына нигез салу», «Сарри — батыр», «Казанны алу» кебек риваятьләрдә ханлык чорындагы Казан турында сүз бара.

«Казанны алу» турындагы риваятьтә кызыклы шундый бер деталь бар. Иван Грозный гаскәрләре арасында чувашлардан гаҗәеп оста гөсләче була. Гөсләнең көмеш тавышы үз шәһәрләрен каһарманнарча саклаучы татарларны да әсәрләндерә. Бу гөсләчене үзләренә кунакка чакырырга дип, рус гаскәрләре станына татарлардан кеше килә. Мондый хәл гаҗәеп беркатлылыгы белән үзенә җәлеп итә: шушындый авыр чорда да татарлар кунакчыл гадәтләрен онытмыйлар, гүзәллекне аңлыйлар һәм бәһали беләләр. Әмма кунакка киткән чувашның адымнарын санап, ике араның ераклыгын белеп, руслар, җир астыннан юл казып килеп, ныгытманы шартлаталар һәм Казан яулап алына.

Кайбер очракларда ханлык һәм губерналык чорлары бердәм бәйләнештә алынып, чувашларның Казанга бәйлелеген куәтли. Бу яктан караганда табышмаклар кызыклы. Мәсәлән, мич якканда төтен чыгуы турындагысының унлап варианты билгеле. Әйтик, берсе шундый: «Әтисе киенгәнче, улы Казанга барып җитте». Башка вариантларында исә Сарай яки Мәскәү исемнәре искә алына. Табышмакның барлыкка килүе узган гасырларның налог системасы белән бәйләнгән, ә шәһәр исемнәренең төрле булуы XIV һәм XVII гасырларда чуваш җиренең идарә итү үзәкләренең алмашынуы турында сөйли. Чувашларның Казанга бәйлелеге шул кадәр бәхәссез, шул кадәр илаһилаштырылган ки, халык аңында губерна үзәге ханлык башкаласы буларак та сакланып калмаган булса, «Казаннан указ килмиенчә такта ярылмаячак», «Казаннан указ килми торып, тимер капкалар («алтын ишек») ачылмаячак» кебек табышмаклар тумаган булыр иде. Казаннан башка җил дә исми, яфрак та селкенми, барысын да Казан хәл итә. Әгәр тимер капка һәм алтын ишекләрнең кояш чыгу, таң ату, көн тууны аңлатуын искә алсак, табышмакның мәгънәсе гаять тирән булуын күрербез. Һәм бу хәл Казанның губерна үзәге һәм Чуваш җиреннән көнчыгышта урнашкан булуыннан гына килеп чыкмый. Казанның илаһилыгы нзелгән һәм юаш чуваш халкының аңына гасырлар буена сеңдерелә килгән: губерния ханлык чорында башланганнарны бары тик дәвам иттергән һәм ныгыткан гына. Моның шулай икәнлеге табышмакларның Казан губернасыннан читтә яшәгән чувашларда да таралган булуы раслый.

Казан турындагы мәкальләр дә сакланган. Берсен генә булса да төп нөсхәдәгечә китерик әле, чөнки үзенең яңгырашы белән бик тә

шигъри ул: «Ху асна пел те Хусана кай», ягъни «Зиһенеңне сынап карыйсың килсә, Казанга бар». Бу мәкаль халыкның «Язмышыңны сынап бак, Мәскәүгә бар» кебек әйтеме белән аваздаш. Мөгаен, болар чуваш тарихының төрле чорларына караган бер үк эчтәлектәге мәкальнең төрле вариантлары гынадыр.

Мин чуваш халкы белән Казан мөнәсәбәтләрен идеаллаштыру ягында тормыйм, әлбәттә. Әлеге мөнәсәбәтләрдә революциягә кадәр Казан ханлыгының деспотлык режимы һәм царизмның колониаль политикасы нәтиҗәсендә милли һәм социаль изү тудырган кытыршылыклар да аз түгел. «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» формуласы күп гасырлар дәвамында тоткарлыксыз гамәлдә булды. Шулай да Казанны төзүчеләр, аның гүзәллеген иҗат итүчеләр, асыл тарихын тудыручылар хезмәт иясе татарлар, руслар һәм башкалар булды.

Сүземне «Казан һәм казанлылар минем үз язмышымда» дип башлаган идем бит әле. Хак сүз: ул минем аңыма бала чактан җыр, әкият, табышмак, мәкаль, хикәят... булып керде. Казан — җыр, Казан — легенда, Казан — табышмак, Казан — зирәк фикер... Ләкин болар барысы да безгә революциядән соң гына иреште. Ул халыклар мөнәсәбәтләрендә үзара үпкәләшү хисләрен юып төшерде. Һәм безнең алга Маяковский җырындагы Кызыл Татарстан башкаласы Казан калыкты.

Бөек Октябрь... Казан — революцион легенда, революцион җыр, революцион фикер, революцион мәдәният... Революцион күтәрелеш, яңа мөнәсәбәтләр...

Чуваш халкының революцион елъязмасы һәрчак Казанга мөрәҗәгать итә. Казандагы революцион вакыйгалар һәм большевикларның образлары чуваш хезмәт ияләре аңында мәңгегә онытылмас булып уелды.

«Интернационал» һәм «Марсельеза» тәрҗемәчесе Тимофей Семенов (ТАЭР) үзенең дусты Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә большевиклар көрәшенә кушыла. Тугандаш ике халыкның революционерлары дуслыгы рухландыргыч көчкә ия һәм азатлыкка омтылган халыкларның алдагы көрәшләрендә туганлык үрнәге булды. Казанда эш алып барган беренче чуваш революционерларына Мулланур Вахитовның зур булышлыгы тиде.

Казан белән бәйләнешле һәм чуваш халкы өчен хәлиткеч әһәмияткә ия булган революцион вакыйгалар елъязмасына күз салыйк. Болар — күренешләр генә түгел, бәлки зур тарихи юл этаплары:

1917 елның 26 октябре — Казанда власть Советлар кулына күчте.

1917 елның 30 октябре — Чабаксарда власть Советлар кулына күчте.

1917 елның 18 ноябре — Ядринга крестьян депутатларының Казан губерна Советы вәкиле И. Г. Кадыков килде. Хәрби-революцион комитет төзелде.

1917 елның декабре — Казанда чуваш театры төзелде.

1917 елның 10—16 декабре — Казанда чуваш хәрби-округ съезды булды.

1918 елның 12 январе — 1 феврале — Казанда Беренче Бөтенроссия чуваш хәрби съезды эшләде.

1918 елның 14 январе — Чуваш театрының беренче спектакле куелды.

1918 елның 28 феврале — «Канаш» («Совет») газетасының беренче саны чыкты.

1918 елның 5 марты — Казанда Чуваш сул социалистик комитеты оешты.

1918 елның 9—13 июне — Казанда Беренче чуваш эшче-крестьян съезды эшләде.

1918 елның 30 октябре — РКП(б) ның Казан губерна комитеты каршында чуваш секциясе оешты.

1920 елның 4—8 феврале — чуваш коммунистик секцияләре, ячейкалары һәм коммунист чуваш активистларының Беренче Бөтенроссия съезды үтте.

1925 ел — Казан Көнчыгыш педагогия институтында чуваш теле һәм мәдәнияте бүлеге ачылды...

Шулай итеп, хезмәт ияләренең революцион аңы үсеше, Чувашстанда политик, партия, культура төзелеше казанлы большевиклар җитәкчелегендә һәм катнашында барды.

Совет властеның беренче елларыннан башлап, Казан чувашларга культура күтәрелешендә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә, фәнни тикшеренүләр җәелдерүдә иң эшлекле ярдәм күрсәтте.

Гимназист Володя Ульянов тарафыннан университетка керергә әзерләнгән Н. М. Охотниковның чирек гасыр басылмый яткан хезмәте — «Чуваш баласының үзенең тәрбиясе турында язмалары» 1920 елда Казанда дөнья күрүе бик тә гыйбрәтле хәл. «Язмалар» мөһим этнографик документ кына түгел, бәлки революциягә кадәрге классик чуваш әдәбиятына кыйммәтле өлеш тә булып тора. Шуннан башланган эш «Чувашлар» дигән икe томлы фундаменталь хезмәт булып үсте. Бу хезмәт тә шулай ук СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы галимнәре ярдәмендә тормышка ашырылды. Революциядән соң Казанда күренекле чуваш галимнәре Н. В. Никольский, Н. И. Ашмарин, В. Г. Егоров һәм башкаларның эшчәнлеге колач җәйде. Чуваш драматургиясе классигы П. Н. Осиповның иҗади эшчәнлеге башланды. Казанда бөек Хузангайның канатлары ныгыды.

Казан, Нижний Новгород һәм Сембер белән берлектә, чуваш эшчеләр сыйныфын формалаштырды.

Болар барысы да — чуваш халкының биографиясе, аның тарихы, димәк, аның улларының да биографиясе.

«Без барыбыз да Казаннан чыктык» диде төпчек энекәшем Зинон, шушы очеркның беренче вариантын укыгач. Ул Казан медицина институтын тәмамлады, шунда кандидатлык диссертациясе яклады; ә уртанчы энем биредә үк фәннәр докторы булды. Икесе дә Чуваш университетының медицина факультетында эшлиләр.

Чуваш университеты... Ул — Казан университетының улы. Барлык фәннәр буенча аның төп гыйльми кадрлары казанлылар булды.

И. Я. Яковлев исемендәге чуваш педагогия институты 1930 елда Казан Көнчыгыш педагогия институтының чуваш бүлеге җирлегендә туды һәм аның һәртөрле ярдәме белән үсте һәм үсә.

Бу юлларны язучы үзе дә, фән кешесе буларак, Казанда формалашты. Казан — җыр, Казан — хыял, Казан — фикер... Моны мин үзем татыдым, йөрәгем белән сиздем. Шушы җырны мин Казанда җырлый алдым, хыялымны тормышка ашырдым, фәнни хезмәтләремне яздым.

Язмышымда зур урын тоткан бик күп казанлыларның исемнәрен хөрмәтләп күңел түремдә йөртәм.

Институт тәмамлагач, Казан педагогия институты аспирантурасына барырга карар кылдым. Кешеләрнең төрлесе бар, шул исәптән вак җаннар да очрап куя, шундыйлар арасыннан:

— Йөрмә... Анда үзләренекен генә алалар,— диюче табылды.

Үз белгечлегем буенча хәлләрем ышанычлы иде. Немец теленнән дә өрекмим. Минем өчен иң хәлиткеч имтихан партия тарихыннан иде.

Бер урынга без өчәү җыелганбыз, калган икесе татар кызы белән татар егете иде.

Менә комиссия председателе М. Р. Булатов нәтиҗәләрне әйтә: начар, канәгатьләнерлек... һәм миңа мөрәҗәгать итеп:

— Сезнең белемегез дә тулырак, фикерегез дә бар. Бу — бик яхшы. Ләкин җавабыгызда кайбер детальләр, фактлар җитенкерәмәде, шунлыктан сезгә «яхшы» билгесе кую белән чикләндек,— диде.

Шулай итеп, мин профессор В. М. Гороховның аспиранты булып киттем. Миңа ул татар мәгарифе тарихы проблемаларын эшкәртүне йөкләде. Гарәп алфавитын белмәү бөтен эшне токарлый иде. Ярдәмгә доцент Т. Я. Корбанов килде. Мин аңардан күп нәрсәгә өйрәндем.

Факультет парторгы Раилә Низаметдиновна Терегулова җитәкчелегендә мин артык юашлыгымнан арындым, докладлар, лекцияләр укый башладым, әңгәмәләр уздырырга күнектем. Ул мине гел күтәрә килде: тиздән мин партия өлкә комитетының штаттан тыш инструкторы сыйфатында эшләр башкара башладым. Мин коммунист буларак та Казанда формалаштым диясем килә.

Әмма иң мөһиме — Казанны мин педагоглык бишегем дип саныйм. Биредәге галимнәр, педагоглар, зур түземлелек күрсәтеп, тырышып, миннән педагог-галим үстерделәр.

Чабаксардан чакыру килгәч, ректорыбыз Ю. А. Туишев:

— Сине Чабаксар таләп итә... Турысын әйткәндә, теләгем үзебездә калдыру иде... Ләкин, мөгаен, бу чуваш халкына карата туганнарча мөнәсәбәт булмастыр,— диде.

Минем өчен кадерле кешеләр Казанда күп, аларның игелекләрен, үрнәкләрен һич онытасым юк. Алар миндә үз халкыма мәхәббәт хисе тәрбияләделәр: алар өчен интернационализм үзеңнекеннән баш тартуны, читләшүне түгел, бәлки коммунист шәхесендәге сыйфатлар комплексында миллилекнең дә булуын эченә ала.

Бу хакта аерым тукталып китү дә артык булмастыр.

Милли нигилистлар карашынча, теләсә нинди милли хис милләтчелек санала. Нигилист интернациональлекне антимиллилек белән буташтырып яши. Интернационализм җирлегендәге саф милли хис коммунист өчен изге ул. Әмма «ракета тизлеге белән мең елларга алга ашкынучы милли нигилистлар» (Хузангай) өчен изге бер нәрсә дә юк. Милли мәсьәләдәге ике тенденцияне — якынаю һәм чәчәк атуны алар сүздә генә кабул итәләр, чынлыкта исә чәчәк ату һәм якынаюны алар бер мәгънәдә генә — йотылу (ассимиляция) мәгънәсендә генә таныйлар. Бу сүзне кулланырга алар бик яраталар һәм «ирекле» бит дип акланалар. Мин андыйларны якыннан беләм, аларның тел төбен башкалар фикере һәм хисләре өстеннән көчләү дип бәялим, чөнки аның асылы пропаганда белән көчләүгә кайтып кала. Минемчә, милләтчелек һәм милли нигилизм — бер үк медальнең ике ягы, аның исеме — битарафлык. Халыкларның туганлыгына карата битарафлык, туган халкына карата битарафлык. Әгәр дә нигилистларга үз вакытында каршылык күрсәтелмәсә, битарафлыкның дошманлыкка әверелүе бик мөмкин...

Патриот һәм интернационалист хисле татарларның үз халкына мәхәббәте мине һәр вакыт сокландыра. Шушы мәхәббәт тугандаш гаилә хисен баетып, яктыртып, җылытып килә. Маркcның: «Һәр милләт башкалардан өйрәнә ала һәм өйрәнергә тиеш», дигән сүзләренең чын мәгънәсенә мин Казанда төшендем. Татарлар белән дуслык минем өчен зур әһәмияткә ия булды. Уңай үрнәк һәрчак актив һәм йогынтылы ясаучан. Мин татарлардан тырышып өйрәндем. Һәрхәлдә, татарлар үрнәге, милли үзаңымны үстерә һәм формалаштыра барып, минем марксистик-ленинчыл карашка нигезләнгән интернациональ сиземләвемне баетты һәм чарлады.

Шәкертлек чорымда шундый хәл булган иде. Мин татарлар турында, аларның тарихи үрнәге, яңа эпоха, яңа илебез гражданины, интернационалистның кешелек дәрәҗәсе хисен яшәтүче камил милли горурлыкның тормышчан көче турында язган идем. Һәм чуваш тарихчы профессорларыннан табылды шундый берәү, кулъязманы кызыклы дип тапса да, ул булган кадәресе өстенә татарларның мөселманлык милләтчелеген дә онытмаска өндәде. Минем өчен бу хәл — татар коммунистының мөселманлык милләтчелеге — авыру хыял җимеше булып тоелды. Үземнең «Этнопедагогика» дигән хезмәтемдә мин әлеге профессорга Муса Җәлил мисалына мөрәҗәгать итеп җавап бирдем.

Татарстаннан киткәч тә Казанга рухи һәм әхлакый тартылу эчке бер ихтыяҗга әверелде. Анда чакта ук мин «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» газеталарына, «Казан утлары» журналына язышa идем. Нәкъ минә шушы басмалар минем чуваш халкының милли герое И. Я. Яковлевның мәгърифәтчелек эшчәнлегенең тарихи әһәмияте турындагы концепциямне яклап чыкты. Казан галимнәре белән идея һәм рухи бердәмлек хисе күп очракларда минем хезмәтләремдә, лекция һәм докладларымда татар материалын файдаланырга мөмкинлек тудырды. Кимендә йөзләгән хезмәтемдә мин татарлар турында — аларның милли характеры, прогрессив традицияләре хакында яздым, аларның әкиятләрен, табышмакларын, мәкальләрен китердем, Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Муса Җәлил авторитетына таяндым. Чуваш крестьяннарының тугандаш татарларга кагылышлы фольклорда сакланган фикерләрен язып алдым һәм бастырып чыгардым.

Рәхмәт хисе берьяклы булмый. Булмаска тиеш. Хәлемнән килгәнчә мин дә яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә тырыштым. Казан укытучыларына лекцияләр һәм докладлар укыйм, диссертацияләргә рәсми оппонент сыйфатында чыгышлар ясадым, ВАК тапшыруы буенча аларның хезмәтләрен рецензияләдем.

Татарстаннан тыш та казанлылар белән онытылмас очрашуларым булды. Шулардан берсе йөрәк түремдә саклана. Ул 1954 елның январенда Муса Җәлилнең Мәскәүдәге квартирасында булды. Ул чакта әле шагыйрь Советлар Союзы Герое да, Ленин премиясе лауреаты да түгел иде... Әмма Җәлилнең дуслары үзләренең Герой дуслары булуларын, Җәлилнең хәбәрсез югала торган шәхес булмавын беләләр иде. Минә алар — композитор Н. Җиһанов, шагыйрь Ә. Фәйзи, РСФСР һәм ТАССРның халык артисткасы Ф. Ильская, педагог Т. Корбанов... Мине кунакка нәкъ минә ул чакырды, коммунист шагыйрь фронтка, үлемсезлеккә киткән квартирага алып керде.

Җәлилнең сугышчан көрәштәшләре чувашлар да булуы турында беренче тапкыр мин шунда ишеттем. Әңгәмә татарча барды. Тугандаш халыкларның культура эшлеклеләрен тыңлаганда, мин татар теле турында рәхмәт хисе белән уйландым... Татар теле миңа үзбәк, казакъ, кыргыз һәм әзербәйҗан... телләрен аңлауга юл ачты.

Соңыннан мин Җәлил иҗатын пропагандалаучыларның берсе булып киттем.

Озак еллар дәвамында Мәскәүдә яшәп, татарлар белән дуслыгымны мин илебез башкаласында да дәвам иттерәм, мин аларга якташларыма караган кебек карыйм. Бу дөньяда яшәве миңа алар белән күңеллерәк.

Минем Казанга мәхәббәтем, казанлыларга рәхмәтем аңлашыла. Бу шәһәр минем йөрәккә мәңгегә кереп урнашты. Казан — халкымның биографиясендә булган кебек, минем дә шәхси биографиямдә һәм мондый биографияләр меңнәрчә.

Шәриф Рахманкулов

# БИЮ — ЕГЕТ ҺӨНӘРЕ

Балет группасының иҗат кичәсе бара. Программада — балет спектакльләреннән алынган күренешләр, аерым номерлар.

Кичә «класс-концерт», ягъни театрлаштырылган бию дәресен күрсәтү белән башланып китте. Балет составының «гәүдәсе» булып саналган кордебалет[1] башкаруында бу күренеш тамашачыларда җылы тәэсир калдырды. Бию техникасы, балет группасындагы артистларның сәләт, осталык дәрәҗәләре «класс-концерт»та бик яхшы күренә. Һәм артистлар үз максатларына ирештеләр дә: тамаша залын күмгән кул чабулар шуны раслады. Зал тынып бетәр-бетмәс сәхнә уртасына солистка чыгып басты.

Таң калдырырлык матурлыгы белән ул бер мизгел эчендә тамаша залын сихерләп өлгерде. Үтә күренмәле күлмәк эченнән, рентген нурлары белән яктырткандай, зифа сыны беленеп тора. Менә ул берничә секундка мәрмәр һәйкәлдәй катып калды. Һәм нәфис, салмак хәрәкәтләр белән биеп китте. Шәрык хатын-кызлары биюе иде бу.

Сәхнәгә балеринаның партнеры чыкты. Тән төзелеше ыспай һәм килешле, физик көчен сиздереп тора. Биюче сәхнәдә күренүгә, залда тагын көчле кул чабулар яңгырады. Борынгы статуяларны хәтерләткән бу солтанәт гәүдәле егет балерина янына килеп басты, тагын оркестр телгә килде, дуэт башланды.

Сагыш һәм наз белән тулы адажиода[2] ике яшьнең күңелендәге мәхәббәт хисләре ачылганнан-ачыла... Тирән кичерешләр, газаплар аша кушылган ике саф йөрәк тантана итә. Адажио тамашачыларның да күңелләрен дулкынландырды. Башкаручыларны алар сәхнәгә кат-кат чакырып алды.

Шул чак сул ягымда утыручы олы яшьтәге бер тамашачыга күзем төште. Аның күзләре яшьләнгән, йөзендә шатлану да, дулкынлану да сизелә. Күрәсең, бию нык тәэсирләгән. Мин аны борчымаска булдым.

Антракт вакытында күршем үзе, миңа мөрәҗәгать итеп, сүз башлады:

— Беренче тапкыр күрәм... Болай булыр дип уйламаган идем... Минем улым ул!

Фәиз аганың гаҗәеп гаилә тарихын беренче тапкыр мин әнә шунда ишеттем.

Баласы туып яше тулар-тулмас ул үзе армия сафына алына. 1938 елны Хасан күле янында япон самурайлары белән булган бәрелештә катнаша. Тиздән аларның часте Халхин-Гол янына китә, ә биредән инде, өенә дә тукталмыйча, Фәиз ага туптуры фин сугышына барып керә. Хәрби хезмәткәр сыйфатында гаиләсен үз янына — Вильнюс шәһәренә — алдырып бергә тыныч кына яшибез дигәндә, Бөек Ватан сугышы башланып китә. Беренче көннәрдән алып — Фәиз ага тагын ут эчендә, сугышның алгы сызыгында

[1] Кордебалет — балет артистларының күмәк биюе.
[2] Адажио — озаклап биелә торган салмак, сузынкы бию.

Бу вакытта Наилә ханымда көчле үпкә авыруы башлана. Врачлар дүртенче яшенә чыккан Ревдарны ана янында тотуны мәгъкуль күрмиләр. Хәер, ананың бала карарлык хәле дә булмый. Наилә ханымны больницага салалар, ә нәни Ревдарны Алитус шәһәрендәге балалар йортына бирәләр.

Дошман Литва чигенә якынлаша башлагач, Наилә ханым яткан больница тылга озатыла, Алитустагы балалар йорты да башта Белоруссиягә, аннары Украинага, тагын берникадәр вакыттан соң Казагыстанның Җамбул шәһәренә күчерелә.

— Сугыш беткәч гаиләмне эзләргә тотындым... Ташкентта Наиләмне таптым,— дип сөйли Фәиз ага.— Көчле авыру бичаракаемны бөтенләй егып салган. Баладан аерылу да үзенә нык тәэсир иткән. Шуның өстенә минем хәбәрсез югалуым турында кәгазь дә килгән икән. Шушы газаплар аны тәмам какшатып ташлаган... Менә бит ул язмыш... Зур өметләр, эчкә сыймаслык шатлыклар белән кайтам, ә мине әнә шундый кайгы-хәсрәт көтеп тора.

Фәиз ага көрсенеп тирән сулап ала да, шактый вакыт сүзсез утырганнан соң, сөйләвен дәвам итә:

— Ревдарны эзләп киттем. Ул Җамбул шәһәрендә генә икән. Барам, ә бала мине танымый. Күп еллар узды шул, ничек хәтерендә тотсын. Баламны алырга уйлаган идем, киңәш итмәделәр. Нишлисең бит, киттем. Төньяк Боз океаны ярларында хезмәт иттем... Менә быел, 1960 ел кергәч кенә, кайттым. Бөтенләйгә... Ревдарны күрергә Казанга килдем. Үскән, әнә нинди егет булган. 23 яше тулды бит... Үземне әйтмим дә инде. Мин гомер-гомергә хәрби кеше, кадровик. Мәрхүмә анасы инженер иде. Гомумән, нәселебез белән без сәнгатьтән ерак кешеләр, ә менә улыбыз балет юлын сайлаган. Күңеле тарткандыр, күрәсең.

Әмма бу урында Фәиз ага аз гына ялгыша. Ревдар башта сәхнәгә уена да китереп карамый, ул кечкенәдән үк рәсем сәнгате белән мавыга. Җиде классны тәмамлау алдыннан балалар йорты җитәкчеләре аны художество училищесына урнаштыру турында уйлаша башлыйлар. Малайның балетка кереп китүе бөтенләй көтмәгәндә була.

Шулай җәй урталарында балалар йортына комиссия килә. Моңа чаклы килгән комиссияләргә һич тә охшамаган була ул. Әүвәлгеләре балалар йортындагы тормыш-тәрбия шартларына, ашау-эчү, кием-салым ягына ныграк игътибар итсә, хәзер килгән комиссия әгъзалары исә фәкать балаларның буй-сыны, аяк-кулы, тез буыннары, тышкы кыяфәте белән кызыксына, һәр баланы җентекләп карый, энә күзеннән үткәрә.

Балалы йортта сер ятмас дигән кебек, комиссиянең килү максаты да беленә. Балалар арасында: «Бездән артист ясыйлар икән...» дигән сүз тарала. Әмма Ревдарның бу сүзгә бер дә исе китми, ул художество училищесы турында гына хыяллана.

Комиссиянең килүе дә онытылган, балаларның «артист булабыз» дип йөрүләре дә сүрелгән чак иде. Ревдарны мөдирә апасы чакырып алды:

— Я, акыллым, үзеңне тәбрик итәм. Берничә көннән Ташкентка китәсең, хореография училищесында укый башлыйсың... — диде ул.

Дәресләрен дикъкать белән тыңлап, күнегүләрен тырышып үтсә дә, Ревдар һаман әле үзенең кем булып чыгачагын аңлап җиткерми. Бер көнне укытучы абыйлары Евгений Петрович үз группасын театрга алып бара. Классташлары белән бергә Ревдар да гомерендә беренче тапкыр хан сараедай мәһабәт бинага, Алишер Нәвои исеме белән аталган Үзбәк опера һәм балет театрына керә, андагы гүзәллекне күреп хәйран кала. Балалар стеналардагы бизәкләрне куллары белән сыйпап-сыйпап карыйлар, һәрбер бүлмәне ачып, йомшак урындыкларына утырып, кыр кебек киң һәм иркен залларында чабышып йөриләр.

Тамаша залы. Сәхнәдә балет спектакле. Менә бер төркем кызлар. Арадан берничәсен Ревдар танып та алды: үзләре белән бергә балет мәктәбенең соңгы курсында укучылар. Ләкин аларның биюенә малайның исе дә китми. Ул стенадагы бизәкләргә сокланып утыра. Бу вакытта сәхнәдә күмәк бию бара.

Һәр хәрәкәт зур шигъри хисләр белән башкарылса да, бию Ревдарга әллә ни тәэсир итми. Әллә беренче тапкыр күргәнгә һәм аңлап җиткермәгәнгә, йөзендә бернинди дә үзгәреш сизелми. Хәер, балаларга гына түгел, зурлар өчен дә балетны аңлау җиңел түгел. Тамашачыдан беркадәр әзерлек: хыялга бирелү, күз алдына китерә,

фараз итә белү һәм музыканы тою, сиземләү сәләте сорала. Ә сәнгать сараена беренче тапкыр кереп, беренче тапкыр сәхнә уены күргән балага андый әзерлекләр каян килсен...

Менә сәхнәгә тәненә сыланып торган ап-ак киемле, коеп куйгандай мәһабәт гәүдәле бер егет килеп чыкты. Аның йөзен күрүгә, Ревдарның күңеле талпынып куйды. Карасана! Укытучы абыйлары икән бит. Евгений Петрович Новиков!.. Ул, кош кебек, бушлыкта очып йөри, күз иярмәс җитезлек белән бөтерчектәй бөтерелә, кеше хәтле кешене, эһ тә итмичә, кул очларында күтәреп йөртә...

Моңарчы битараф булып утырган малайның йөрәге еш-еш тибә башлый. Ул укытучы абыйсының көченә, нәфис хәрәкәтләренә соклана. Аның күңелендә дә әнә шундый көчле, шундый мәһабәт балет артисты булу теләге уяна.

Евгений Петровичның таза кулларын күргәч, Ревдар үз беләкләрен капшап карый. «Бик сыек шул, мин болай булдыра алмам!» дип уйлап куя ул әченнән генә.

...Спектакльләрне күбрәк караган саен, балет сәнгате Ревдарга якынайганнан-якыная, бию серләре, үзенчәлекле алымнары ачылганнан-ачыла бара. Балет техникасы станок янында көндәлек гадәти күнегүләрдән башлана. Ревдар да үзенең техник «гамма»сын зур тырышлык белән баета килә. Балет артистының һәрбер буыны нык һәм сәламәт булырга, аеруча аяк табаннары, тез буыннарының көчле, таза булырга тиешлеген хәзер инде ул яхшы белә, тәҗрибәле педагог җитәкчелегендә күнегүләрен һәр дәрестә катлауландыра бара. Акрынлап-акрынлап бию хәрәкәтләренең төрләре арта, ә соңгы классларда инде ул өчле тур [1] ясый, сикерү, бөтерелү, антрашалар [2] да эшли.

Болар барысы да зур көч сарыф итүне сорый торган хәрәкәтләр. Ревдарның баштарак егылып калган чаклары да булгалады. Ләкин ул инде хәзер, балет артисты хезмәтенең авырлыгыннан куркып, «юк, бу эш миннән булмас», дими. Хореография һәм күнегүләрдән тыш, музыка, гомуми белем дәресләре дә вакытны күп ала. Тарихны, географияне укырга, математиканы өйрәнергә, рус һәм үзбәк телләрендә иркен сөйләшә белергә, анатомия, физиология, психология фәннәрен дә үзләштерергә кирәк.

Менә Ревдарга балерина белән парлап бию күнегүләренә күчәргә вакыт җитә. Ялгыз биюләрдә уңышка ирешсә дә, балерина белән биегәндә Ревдар образның бөтенлеген таркатып җибәргәли. Билгеле, беренче тапкыр партнерша белән биегәндә һәр икесенең дә игътибары башлыча техникага туплана, «күтәрә алсам ярар иде», «егылып төшмәмме икән» дигән шөбһәле уй башларыннан чыкмый. Балеринаны күтәргәндә артистның көчәнүе тамашачыга сизелмәскә, кул-аяк хәрәкәтләрендә дә нәфиссезлек булмаска тиеш.

Соңгы классларда Ревдар, практика төсендә, кайбер көндезге спектакльләрдә дә катнаша. Үзбәк дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Кызыл мәк», «Ал чәчәк», «Доктор Айболит», «Канатлы ат» кебек балетларда бии. Репетицияләр вакытында балетмейстерның һәрбер сүзен, артистларга биргән күрсәтмәләрен, киңәшләрен дикъкать белән тыңлый, тәҗрибәле артистларның чыгышларын, хәтта аерым хәрәкәтләрен игътибар белән күзәтә, образларның эшләнешенә үзенчә анализ ясый. Бию хәрәкәтләренә ул тирән мәгънә салырга тырыша, дәрт, ялкын өсти бара, шуның белән бергә, пантомима сәнгатен — ым белән сөйләшү алымнарын, ишарә телен өйрәнә.

Менә шулай, алты ел буена — һәр көн дәрес, һәр көн репетиция, спектакльләр...

Диплом спектакле көне, башка укучылар белән беррәттән, Ревдар өчен дә тантаналы көн була. Яшь артистлар «Бакыр җайдак» балетыннан бер пәрдә күрсәтергә әзерләнәләр. Ревдарга төп герой — Евгений образы тапшырыла.

Әсәрдә ике тема бер-беренә үрелеп бара: беренчедән, Евгений белән Парашаның мәхәббәт трагедиясе, икенчедән, бөек Россиянең данына, куәтенә мәдхия җырлау. Тирән иҗтимагый мәгънәле бу әсәрнең эчтәлеген пластик сәнгать алымнары белән тамашачыга җиткерү искиткеч зур осталык сорый. Һәм Ревдар ул сынауны уңышлы үтә.

---

[1] Тур — биеп бөтен сәхнәне әйләнеп чыгу.
[2] Антраша — югарыга сикереп аякны аякка сугу.

Ташкент хореография училищесын тәмамлап чыккач — 1956 елда — Ревдар Садыйковны Казанга, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрына эшкә җибәрәләр.

Хәзерлегенә һәм сәләтенә карап, беренче көннән үк яшь артистны штатка солист итеп алалар һәм аңа «Шүрәле» балетыннан Былтыр ролен тапшыралар. Төп герой ролен ышанып бирүләренә куанып бетә алмаса да, күңеленнән бераз борчыла һәм шикләнә иде Ревдар. Озак еллар буе сәхнәдә эшләп чыныккан Н. Юлтыева, А. Гацулина, Ә. Нарыков, Б. Әхтәмов кебек талантлы, зур тәҗрибәле солистлар белән янәшә торып, аңа гаять тә җаваплы Былтыр образын башкарырга туры киләчәк. Шуның өстенә Мәскәүдә узасы татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерлек башланган. Декада вакытында «Шүрәле» балеты да күрсәтеләчәк. Балет илебезнең күп кенә театрларында, Мәскәү, Ленинград сәхнәләрендә куелган һәм чит илләрдә дә уйналган. Мәскәүле Аскольд Макаров һәм Ленинградлы Владимир Васильевтан соң сәхнәгә чыгу, Мәскәү тамашачылары алдына басу унтугыз яшьлек дебютант өчен авыр да, җаваплы да иде.



*«Шүрәле» балетыннан күренеш.*
*Шүрәле — Р. Садыйков.*
*Сөембикә — С. Хантимерова.*


Ревдар башта балетмейстер күрсәтмәләрен, киңәшләрен ала, либретто белән таныша һәм Тукай әсәрләрен йотлыгып укый. Балетның музыкасын аеруча бирелеп һәм дулкынланып тыңлый.

Фәрит Яруллин музыкасы образларга, хисләргә гаять бай. Былтыр темасы музыкада моңлы лирик һәм героик планда бирелгән, ул җылылыгы, эчкерсезлеге һәм дәртлелеге белән аерылып тора. Музыка ярдәмендә Ревдар үзе башкарачак образны күз алдына бастыра башлый, музыкадан образ импульсын сосып ала-ала, аларны бию хәрәкәтләренә күчерә. Ягъни образның пластик «текст»ын кисәкләргә бүлеп өйрәнә. Ритмик сурәтләр, күз карашы, ишарәләр, кул, тән, аяк хәрәкәтләренә үрелеп, образ гәүдәләнә башлый...

Халкыбызга хас гаделлек, тапкырлык, батырлык, мәхәббәтең өчен, илең, халкың өчен үз-үзеңне корбан итәргә әзер тору — Ревдар иҗат иткән Былтырның төп сыйфатлары әнә шулар. Шүрәле тозагына эләккән кош-кыз Сөембикәне коткару өчен көрәш юлына баскан гади крестьян егете соңра көчләүләргә, золымга каршы күтәрелгән халык батыры булып гәүдәләнә.

Казан тамашачылары дебютантны җылы каршылыйлар. Сәхнәдә Р. Садыйков иң элек образның лирик ягын ачарга омтыла, аннан соң аның батырлык сыйфатларына басым ясый. Бу беренче роль, беренче адым яшь артистның зур сәләткә ия булуын күрсәтә һәм аны өметле иҗат кешесе итеп таныта.

Декада көннәрендә балет Мәскәү тамашачыларына күрсәтелә. Былтыр образына сәнгать белгечләре анда да югары бәя бирә. «Музыка» журналында басылган мәкаләдә Ревдар Садыйков иҗатына карата менә нәрсә әйтелә:



*«Су анасы» балетыннан күренеш.*
*Су анасы — Л. Синельникова. Алмай — Р. Садыйков.*

«Халык бездән Садыйковның бу партияне үтә дә нечкә, үтә дә кыю башкаручы булуын тануны таләп итә. Аның алымнарының үзенчәлеге нәрсәдән гыйбарәт соң? Садыйков берничек тә милли колоритка басым ясамый. Балетмейстер тарафыннан хореографик хәрәкәтләргә кертелгән «татар» бизәкләрен дә күпертми. Аның өчен болар сулыш алган кебек табигый... Садыйков иҗат иткән Былтыр — нык ихтыярлы, көчле кеше, төрле стильләштерүләр булмауга карамастан, нәкъ татар әкиятләрендәге чын батыр... Садыйков беренче партиясе белән үк илаһи көчкә ия булган, куәтле һәм бөтен характерлар иҗат итәргә сәләтле икәнен күрсәтте».

Алдагы елларда Ревдар үз талантының нәкъ шушы сыйфатларын образдан-образга тагы да үстерә бара.

Әнвәр Бакировның «Алтын тарак» балетында иҗтимагый тигезсезлеккә, җәберзолымга каршы торучы халык улы, ташчы Гайфи образы да Садыйков трактовкасында үзенә бер төрле лирик җылылык белән сугарылган. Ә инде балетның яңартылып куелган постановкасында бу образның идея юнәлеше тагы да көчәйтелә.

А. Ключаревның «Тау әкияте» балетында Р. Садыйков Клим, Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетында шагыйрь ролен башкара. Соңгысы балет өчен авыр һәм үтә катлаулы образ. Берninди сүзсез, фәкать бию хәрәкәтләре белән генә шагыйрьнең кичерешләрен, уй-фикерләрен тамашачыга җиткерү, әлбәттә, чиксез кыен. Шулай да Садыйков бу кыенлыкларны җиңеп чыга, шагыйрьнең психологиясен ачуда кызыклы тәҗрибә ясый. Татар халык әкиятләренә нигезләнеп эшләнгән «Раушан» балетында ул Гали ролен уйный. Р. Садыйков башкаруында Гали — үтә шаян, үзсүзле, олылар сүзенә илтифат итмичә, үз белдеге белән йөрүе аркасында көтелмәгән бәлаләргә очраган малай итеп бирелә. Ә инде балетның «Сихерләнгән малай» дип исемләнгән яңа вариантында Ревдар убырлы карчык ролендә чыга. Гомумән, соңгы елларда Садыйков сихри образларга алына башлады. «Шүрәле» спектаклендә дә ул Былтыр образыннан Шүрәлегә күчте. Үзенең гаҗәп оста һәм төгәл эшләнгән хәрәкәтләре һәм кыланышлары белән ул бу хәтәр карачкыларны тәмам «терелтеп», ышандырырлык итеп тамашачы алдына бастыра.

Миңа «Сихерләнгән малай» балетын фәкать балалардан гына торган тамашачы белән дә карарга туры килде. Спектакль беткәннән соң гадәттә төп рольләрне башкаручы артистларны чәчәкләр белән бүләклиләр. Бу көнне нәни тамашачылар исеменнән букетларны мәктәпкәчә яшьтәге кызлар тапшырды. Менә шунда Ревдарга чәчәк бирергә тиешле кыз, убырлы карчык булып киенгән артист алдына килеп басуга, куркуыннанмы, әллә юкса нәфрәтләнүеннәнме, чәчәкләрен бирмичә, кырт борылып, залга төшеп китә башлады. Шушы кечкенә генә вакыйга образның балага ни тикле тәэсир итүе турында сөйли түгелме?!

Шүрәле образында Р. Садыйков аеруча зур уңышка иреште. Сыңар мөгезле, озын бармаклы куркыныч урман иясенең хәрәкәтләре өчен артист махсус алымнар таба алган. Биюченең кыяфәте дә, йөреше дә, йөгерү-сикерүләре дә кыргый. Әйтерсең Кырлай урманындагы «чын» шүрәлене тотып сәхнәгә бастырганнар!

Опера спектакльләрендәге биюләрне исәпкә алмастан, фәкать балет спектакльләрендә генә дә Р. Садыйков кырыктан артык партия иҗат итте. С. Прокофьевның «Таш чәчәк» балетында алтын куллы Данил, Минкусның «Дон Кихот»ында купшы Базиль, Щедринның «Кармен-сюита»сында кырыс холыклы Хозе, Чайковскийның «Аккош күле» балетында Принц һәм тагын бик күп спектакльләрдә төрле музыкантлар, шаһзадәләр, дәрвишләр, мәҗнүннәр...

Бер-берләренә капма-каршы характердагы, төрле милләт, төрле ил кешеләрен гәүдәләндергән барлык бу образлар Ревдар Садыйковның илһам куәте белән татар сәхнәсендә яшәү көче алдылар. Актерның иҗат диапазоны елдан-ел киңәя килде. Безне аның уенындагы табигыйлек үзенә җәлеп итә, ышандыра һәм без артист белән бергә вакыйга эченә кереп китәбез: әрнүле аерылышу, көнләшү газабы кичерәбез, мәхәббәттән көч алабыз, җиңү тантанасы белән яшибез.

Р. Садыйков үз-үзенә үтә таләпчән артист. Тамашачыларның мәхәббәтен яулавына, зур дәрәҗәгә ирешүенә карамастан, тынычланып, тукталып калырга теләми. Репетицияләрдән калып янсә берәр-икешәр сәгатькә иртәрәк килеп, өстәмә күнегүләр ясый. Хәтта спектакль кабул ителеп, күп мәртәбәләр уйналса да, образ өстендә эшләвен дәвам иттерә. Эзләнә-уйлана, хәрәкәтләрен ачыклый, яңарта...


Ревдарның тагы бер үзенчәлекле ягы шунда: уйнаган рольләренә кире кайтмаска, икенче, яңа рольне алырга тырыша ул. Бөек Дантеның «Илаһи комедия»се буенча эшләнгән «Франческа да Римини» балетында башта ул лирик табигатьле Паоло, ә инде шул ук балетның берничә елдан соң куелган яңа постановкасында мәкерле, усал, көнчел Джотто образын башкара, «Дон Кихот»та Эспада һәм Базиль образларында бии һ. б.

Иҗатында гына түгел, шәхси тормышында да Ревдар тик тора белми. Барысына да житешә, барысына да өлгерә ул. Кайда гына, кайчан гына булмасын, аны гел эш өстендә очратасың. Бер килгәндә тәрәзәсенә пыяла куеп йөргән чагын күрәсең, икенчесендә дрель белән таш стена тишеп маташа, өченчесендә биленә алъяпкыч бәйләп, кухняда кайнаша...

Ревдар бала чактан ук мавыккан рәссамчылыгын да ташламый. Хәзер инде аның бу сәләте шактый камилләшкән. Элегрәк сурәтләрен кәгазь битләренә генә ясаган булса, хәзер инде буяу белән киндергә картиналар яза, агач тамырларын сырлап, калайны чокып, төрле сыннар, төрле күренешләр ясый. Ул боларны көн үткәрү өчен генә эшләми. Профессиональ яктан аның барлык хезмәтләре бер үк дәрәҗәдә булмаса да, күбесе һәвәскәрлектән өстен тора. Рәссамның бу хезмәтләрендә аның уйхыяллары гәүдәләнә, замандашларына, әйләнә-тирәгә, табигатькә мөнәсәбәте чагыла.

Болардан тыш, Ревдар фото һәм кино төшерү белән дә кызыксына. Үзе төшерә, тасманы үзе эшкәртә, үзе ясый һәм үзе күрсәтә. Дуслары, иптәшләре белән бергә җыйналып карыйлар, фикер алышалар, тәҗрибә уртаклашалар, бәхәсләшәләр.

Табигать аңа әнә шундый бай сыйфатлар биргән, талант һәм кешелеклелек бүләк иткән. Һәм Ревдар үзе эшли торган театрда гына түгел, башка шәһәрләрдәге театрларда да бу хакта яхшы беләләр. Горький яки Куйбышев, Чиләбе янсә Оренбург шәһәрләрендәге опера һәм балет театрларында игълан ителгән балет спектакльләре берБер сәбәп белән өзелү алдында калган очраклар була. Шундый чакта Татар дәүләт опера һәм балет театры дирекциясе адресына еш кына мондый эчтәлекле телеграммалар килеп төшә: «Коткарыгыз. Бүгенге «Мәхәббәт легендасы» спектаклендә герой-



*«Мисыр төннәре» балетыннан күренеш.*
*Амун — Р. Садыйков. Вероника — Г. Бәширова.*

ны бию өчен Ревдар Садыйковны җибәрегез», «...маршруты белән оча торган самолетка билет калдырылган. Арбенинны башкару өчен Садыйков Ревдарны көтәбез...». Сәнгать өлкәсендәге хезмәттәшләрең кыен хәлдә калганда ярдәм кулы сузмый мөмкинме соң?!

Республиканың кыр батырлары, завод-фабрика алдынгылары өчен оештырылган концертларда да Р. Садыйковны еш очратасың. Автобустамы, йөк машинасына утырып йөрергә туры киләме,— иң әһәмиятлесе анда түгел. Аның өчен иң әһәмиятлесе— тамашачыларга матур иҗат җимеше бүләк итү.

Р. Садыйковны әле бу шәһәргә, әле теге илгә бара торган бригадаларга чакырып кына торалар. Соңгы җиде ел эчендә генә дә ул Мәскәү һәм Казан артистлары белән бергә унбер илнең алтмыштан артык шәһәрендә булып кайтты. Европа, Азия, Америка континентларында яшәүче дистәләрчә мең тамашачыларга ул татар халкының да кайнар сәламен ирештерә, гүзәл сәнгать өлгеләрен алып бара. Концертларда ул еш кына «Шүрәле» балеты күренешләрен, А. Ключаревның «Чыбыркылы егет»ен, татар халык биюләреннән «Әпипә», «Су буенда көрәшү» һ. б. биюләрне башкара.

Күп милләтле совет халкының аерылгысыз бер өлеше булган татар халкының хо-

реографик сәнгате үрнәкләре дә чит илләрдәге тамашачыларда зур кызыксыну тудыра.

Р. Садыйковның иҗат юлы гел уңышлар-казанышлардан гына торган икән диган фикер дөрес булмас иде, әлбәттә. Иҗат эше тоташ уңышлардан гына тормый. Ревдарның да эшләнеп бетмәгән образлары да, канәгатьләндереп җиткермәгән рольләре дә булмады түгел. Ул гынамы, сәхнәгә басып бии башлавына алты ел тулды дигәндә зур күңелсезлеккә очрап, сәхнә белән бөтенләйгә саубуллаша язды. Ул көтмәгәндә авыр травма ала. Биюче өчен бу — чын фаҗига. Балет өчен яраксыз булып калуың да мөмкин. Ләкин Ревдар ышанычын җуймый, авыртуларга, сызлануларга түзә, һаман балет турында хыялланa. Аңардагы түземлелек һәм ышаныч врачларны да гаҗәпкә калдыра. Бер ел дигәндә ул сәхнәгә баса, яңадан бии башлый.

Балет сәнгате, гомумән, борчулы, мәшәкатьле, авыр хезмәт. Зур театр солисткасы, СССР халык артисты Екатерина Максимова кайчандыр бу турыда мондый сүзләр әйткән иде: «...кайбер чакта мин балетны дошман күрәм, аңа ләгънәт укыйм. Я алла, җирдә шул кадәр һәйбәт һөнәрләр барында, нигә балерина хезмәтен сайладым икән, дип уйлаган чакларым да була...»

Күп еллар буе балет хезмәтенең авырлыгын да, шатлыкларын да кичергән Ревдарның үзен тыңлап карыйк: «Чыннан да, балет һөнәре шатлыклар гына түгел, әллә никадәр борчу-мәшәкатьләр китерә торган авыр хезмәт,— дип сөйли ул.— Бу һөнәрне сайладыңмы, бер генә минутка да үзеңнең балет артисты икәнлегеңне онытырга хаклы түгелсең. Гәрчә бер генә көн, бер генә тапкыр биюче икәнеңне истән чыгару да — күңелсез нәтиҗәләргә китерә, үч алучан була. Шуңа күрә дә балет артисты күп нәрсәләрдән ваз кичәргә мәҗбүр. Хәтта ялга чыккан айда да онытылып китәргә ярамый. Бер генә көн класс күнегүләрен калдырдыңмы, гәүдәңне нормаль хәлгә кертү өчен, көннәр, атналар буена станок янында тир түгәргә туры килә. Иң элек класс,— дип дәвам итә ул сүзен.— Класс күнегүләреннән тыш биеп булмый. Театрга кичә генә алынган кордебалет артистына да, зур тәҗрибәле, шөһрәт казанган сәхнә остасы өчен дә бер үк дәрәҗәдә фарыз нәрсә. Атналар буе спектакльләрдә уйнамаска мөмкин, әмма класс күнегүләре өзлексез дәвам итәргә тиеш. Балетта репетиция дә җиңел бирелми. Уйналачак роленә генә түгел, ә эшләнгән, берничә тапкыр уйналган спектакльгә дә әледән-әле репетицияләр ясалып тора. Репетиция вакытында хәрәкәтләр чарлана, үзгәрешләр кертелә, чистартыла, урыны-урыны белән яңартыла... Гомумән, образ өстендә эшләүнең чиге юк. Драма артисты бер үк сүзне төрле мәгънә салып әйтә алган кебек, хореография сәнгатендәге хәрәкәтләргә дә төрле интонация, ягъни, спектакльнең эчтәлегенә, характерларның үзенчәлегенә яраклаштырып, төрле мәгънә иңдереп була. Бу инде һәрбер артистның иҗат фантазиясенә, актерлык осталыгына бәйләнгән».

Р. Садыйковның уңышлары гаять зур көч куеп яулап алынган. Балет хезмәтен чиксез яратуы, үзен аямыйча өзлексез эшләве нәтиҗәсендә аның иҗаты күзгә күренеп үсте.

Сәхнәдә өч ел биегәннән соң, егерме ике яшьлек Ревдар Садыйковка Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә. Ә егерме алты яшендә ул Татарстанның халык артисты һәм утыз өч яшендә РСФСРның атказанган артисты исеменә лаек була. 1973 елда, «Су анасы» балетындагы образы өчен, аңа Тукай премиясе лауреаты исеме бирелә.

Ревдар Садыйковның балетта бии башлавына инде егерме ел. Сәхнә өчен бу алай артык күп тә түгел. Драма артистлары сәхнәдә иллешәр ел уйныйлар. Алар өчен егерме еллык хезмәт — үсү, танылу еллары гына. Әмма балетның үз законы — хореография сәнгатенең үзе кебек төгәл һәм кырыс законы бар: егерме ел эшләвең бик җитә...

Әмма бу әле аның хезмәт юлына чик куелды диган сүз түгел. Образлы итеп әйткәндә, Идел пароходыннан төшеп, диңгез корабына утыру гына әле ул. Ревдар Садыйковның татар сәнгате өлкәсендәге хезмәт юлы педагог-хореограф һәм балетмейстер сыйфатларында да озак дәвам итүен телик.

Үзбәк Гыймадиев

# ТУКАЙ МИРАСЫ ТУРЫНДА «ЯЛТ-ЙОЛТ»

Мәгълүм булганынча, Тукай үлгәннән соң аның шәхесе һәм иҗаты тирәсендә идея көрәше тагын да көчәя, катлаулана. Татар реакционерлары, руханилар, буржуаз милләтчеләр шагыйрьнең кешелек намусын каралрга маташып, әшәке гайбәтләр тараталар. Шундый шартларда шагыйрь мирасын дөрес һәм объектив бәяләү бик мөһим була.

Без Тукай мирасы тирәсендә барган көрәшне тоташ колачларга дәгъва итмичә, бу мәсьәләдә «Ялт-йолт»ның позициясен ачыклау, аның шагыйрь турындагы фикерләрен күзәтү максатын гына куябыз.

«Ялт-йолт» — Октябрьга кадәрге иң йогынтылы матбугат органнарының берсе. Тукай гомеренең соңгы өч елы бу журналдан аерылгысыз. Журнал чыга башлаганнан алып ул аның җаваплы секретаре вазифасын үти, гамәлдә исә фактик редакторы, идея җитәкчесе була. Журналның йөзен билгеләүче төп материалларның авторы да Тукай. Шуңа күрә шагыйрьнең үлеме ялт-йолтчыларга аеруча нык тәэсир итә. «Габдулла әфәнде Тукаевның вафаты «Ялт-йолт» идарәсе өчен гомергә онытылмаслык бер югалту вә гаять зур бер хәсрәт булды»,— дип яза ул шагыйрь истәлегенә багышланган некрологта (1913, 55 сан).

«Тукаевның үлүенә бу көн бөтен татар баласы егъласа, «Ялт-йолт» һәйәт тәхририясе (редколлегиясе — Ү. Г.), һич шөбһәсез, үкерергә тиешледер, — диелә шул ук сандагы икенче бер мәкаләдә. — Шагыйрьнең үлеме «Ялт-йолт» өчен бигрәк тә олуг зыягь (югалту — Ү. Г.) булды, дөньяга килгән көненнән бирле мөттәсил (өзлексез — Ү. Г.) көлеп кенә торган «Ялт-йолт» һәйәт тәхририясе дә ул көлкеләр урынына бу көн әрнеп егъларга мәҗбүр булды. «Ялт-йолт» күп көлә иде — инде башкалардан артыграк егълый...» (1913, 55 сан).

«Ялт-йолт» тирәсенә тупланган демократ язучылар һәм журналистлар Тукай рухын сакларга, аның традицияләрен дәвам иттерергә омтылалар. Журналның 1913 ел 10 апрель саны тоташ Тукай истәлегенә багышлана. Тукай вафатының еллыклары уңае белән чыккан (1914 елның 71 нче, 1915 елның 88 нче, 1916 елның 109 нчы) саннарда шагыйрь турында күп мәкаләләр, истәлекләр, шигырьләр, хәбәрләр урнаштырылган. Әле генә кичерелгән, хәтердән җуелып өлгермәгән кайнар эзләр, тойгылар буенча язылганга, алар аеруча кыйммәтлеләр. Алардагы фактлар һәм детальләр шагыйрьнең шәхесен, тормышын һәм иҗатын өйрәнүдә, фәнни биографиясен тулыландыруда мөһим чыганак булып торалар. Тукайны өйрәнү фәненең бүгенге торышына өлеш булырдайлары да очрый.

Тукай биографиясен язу буенча башлангыч адым «Ялт-йолт»та ясала. Шагыйрьнең тормыш юлы беренче тапкыр төп өч чорга бүлеп карала: бала чагы, Уральскидагы тормышы һәм Казанда үткәргән еллары.

Журналда башлыча Тукайның Казандагы тормышы яктыртыла. Сәгыйть Рәмиевнең Казанда шагыйрь белән беренче очрашуы турындагы истәлектә, мәсәлән, игътибарга лаек детальләр бар. Моңа кадәр Тукайның Казанга килү вакыты 1907 елның көзе дип кенә әйтелсә, журналда «яңгырлы, болытлы октябрь» дип төгәлрәк күрсәтелә.

Журналда Тукайның гаҗәп талантлы, гали рухлы («зур җанлы, саф вөҗданлы») кеше булуы белән бергә, гадилеге, тәкәллефсезлеге ассызыклана. «Мин садә идем,

мин садә тордым. Мин садә яздым. Мин шул хәлем белән татарның әхвәл вә тормышына бер сәнам булдым», — кебек шагыйрь исеменнән сөйләнгән сүзләрдә аның халык күңеледәй гадилеге һәм ул гадилекнең мәгънәсе, җирлеге ачыла.

Әйтеп кителгәнчә, ул чакта Тукай шәхесенә тап төшерә торган уйдырмалар аз булмаган. Мәсәлән, Тукайның вафатына бер ел тулу уңае белән язылган мәкаләдә «Ил» газетасы Тукайны шәһәрнең «зыялылары», хатын-кызлар белән аралашмауда, үз эченә бикләнгәнлектә гаепли. Янәсе, бу сыйфатлар шагыйрь иҗатына зур кимчелек китергән. Кайберәүләр Тукайның вакытсыз үлемен аның шәхси кимчелекләре белән аңлатырга омтылалар. Тукайның яшьли һәлак булуын язмышка, тәкъдиргә кайтарып калдыручы, аның үлемен, бу «былчырак» дөньяны ташлап, иркен, рәхәт, илаһи дөньяга китү дип аңлатучы дини «фәлсәфәләр» дә очрый.

«Ялт-йолт» сәхифәләрендәге материалларның зур күпчелеге шагыйрь өстенә ташланган уйдырмаларны хөкем итү булып яңгырый. Г. Харис «Ялт-йолт»ның 1914 елгы Тукай санын ачып җибәргән шигырендә («Бөек шагыйрь мәрхүм Габдулла Тукаевка»), болай ди:

> **Кимсетсәләр кимсетсеннәр — син ким түгел,**
> **Тиңләсәләр тиңләсеннәр — син тиң түгел.**
> **Тыныч йокла каберендә, и гали күңел,**
> **Сукырларның бәһалавы берни түгел.**

«Син һәммәсеннән югары» исемле памфлетта да шундыйлар камчылана. Тукай исән чагында ук аңа өстән генә карап, «җырчы татар малае» дип түбәнсетергә омтылучыларга (Г. Исхакый кебекләр күздә тотыла) җимергеч отпор бирелә: «Үзләренең репутацияләрен әллә нинди предательстволар берлә былчыраткан ул сатлык җаннарның андый түбән сүзләре генә синең голувиятеңә (югарылыгыңа, бөеклегеңә — Ү. Г.) бер дә кимчелек китерә алмыйлар. Син аларның һәммәсеннән бик күп гали торасың...» (1914, 71 сан).

«Тукаев гомумән күп кеше белән танышырга, хосусән, интеллигентлар, хатын-кызлар бергә утырышырга яратмый торган иде», — ди Ф. Туктаров, аны дөньядан аерылган, үз эченә бикләнгән «дәрвиш» итеп күрсәтмәкче булып. Моны Тукайның «тормыш вә табигатендә бер нәзакәт юклыгы» белән аңлатырга маташа. Ә чынлыкта, бу — Тукайның халык алдында дәрәҗәсен төшерергә, әдәбиятта тоткан урынын киметеп күрсәтергә көчәнү генә була. Туктаров үзе үк әйтә: Тукай «Казанның зыялы фамилияләрендә вә могтәбәр милләтпәрвәр байлар мәҗлесендә бер мәртәбә дә булмады», — ди. Менә кемнәр белән аралашмаган, кемнәрне өнәмәгән Тукай! Ә инде фикердәшләре, мәсләктәшләре белән якын дус та, эчкерсез сердәш тә була шагыйрь. Тукайны якыннан белгән Солтан Рахманколый истәлеге моны бик яхшы раслый (1913, 55 сан). «Сөйләшергә бик дәртле дә, оста да булганлыктан, юк кына нәрсәләрне гаять дәрәҗәдә рәгъбәтле вә җазибәле (кызыклы һәм тәэсирле — Ү. Г.) сөйли торган иде (...), — ди ул шагыйрь турында. — Сөйләгән сүзенең әһәмиятен аңлапмы, яхуд сөйләүченең үзенә ригаяттәнме (хөрмәт итеп — Ү. Г.), дикъкать белән тыңлаучыга сөйли торган сүзеннән бер дә арымый торган иде». «Ул кешенең аз гына булса да дикъкатен аулярлык булмаган сүзне сөйләргә тарсына да, хурлана да иде», — дип, шунда ук Тукайның сүз кадерен белеп сөйләвен дә әйтеп үтә.

С. Рахманколый истәлегендә Тукайның музыка яратуы, «музыкага гаять хисле» булуы турындагы сүзләр дә игътибарга лаек. «Мин җырлаган вакытта, минем музыка хаталарымны табып төзәтә торган иде», — ди ул. Димәк, Тукай сәнгатьнең иң нечкәсен — кеше күңеленең иң серле кылларын тибрәтә торганын да гаять тирәнтен аңлаган.

Тукайның хатын-кызга, мәхәббәткә карашы турында ул заманда байтак уйдырмалар сөйләнгән, гайбәтләр йөргән. Шагыйрьнең хатын-кыздан читләшүе, оялчанлыгы Фатих Әмирхан истәлекләрендә дә чагыла (мәсәлән, «Тукай һәм хатын-кыз» дигән истәлеге) [1]. «Ялт-йолт»та да (мәсәлән, «Тукай җир асты дөньясында» исемле мәкаләдә) шуңа ишарәләр бар. Биредә «шагыйрьнең шәхси кимчелекләре белән аның иҗатын бутау» (Г. Халит) [2] шикелле фактларга очрыйбыз. Мондый чыгышларга исә үз вакытында беренче булып «Ялт-йолт» җитди отпор бирде.

---

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр, ике томда. 2 том, Казан, 1958, 502 бит.
[2] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 23 бит.

«Ялт-йолт»та «Тукай һәм хатын-кыз» мәсьәләсе тар мәгънәдәге интим мәхәббәт рәвешендә генә түгел, ә киңрәк планда, хатын-кызларны гаделсез җәмгыятьтәге коллык хәленнән азат итү төсендә куела. Тукайның «хатын-кызларны ифрат дәрәҗәдә яратканлыгы, күңеленнән хатын-кызларны сөюе» турындагы раслаулары белән журнал Г. Исхакый ишеләрне хөкем итеп кенә калмый, ә бәлки шагыйрьнең, татар бае тарафыннан мәсхәрәләнеп урамга ташланган кызлар, ерткыч, фахиш ирләре тырнагында изелгән хатыннар турында язып, аларның аяныч хәле өчен «кайгыруына» басым ясый (1915, 88 сан).

Шул ук вакытта Тукайга мәхәббәт лирикасы да ят булмавы, аның бу темага күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек җәүһәрләр иҗат иткән шагыйрь булуы билгеләнә. «Кулың» (журналда «Ак кул» дип исемләнә), «Мәхәббәт» һ. б. шигырьләр шуңа мисал итеп китерелә.

**Җир яшәрмәс, гөл ачылмас, төшми яңгыр тамчысы,**
**Кайдан алсын шигърен шагыйрь, булмаса илһамчысы.**

«Мәхәббәт» шигыреннән китерелгән бу юлларда шагыйрьнең реаль шәхесләрдән илһам алып иҗат итүе ачык чагыла булса кирәк. Шигырьнең соңгы юллары тагы бер кат Тукайның саф һәм көчле мәхәббәт каһарманнары алдында баш июе, үзенең дә, алар кебек, гыйшык утында януын раслап әйтелә:

**Кайда Фәрһад белән Мәҗнүн! Мин аларның таңчысы!**

«Ялт-йолт» Тукайны «тиңсез шагыйрь» (1913, 55 сан), «бердәнбер чын шагыйрь» (1915, 88 сан) дип бәяләү белән генә чикләнми, бәлки «залим кара көчләр астында югала язып, тик соңгы елларда гына башын калкыткан татар әдәбиятының» «башчысы», «рухы» итеп исәпли (1913, 55 сан). Аның татар әдәбияты горурлана алырлык «мәктәп» — гүзәл сыйфатлар белән аерылып торган бөтен бер идея-художество юнәлеше барлыкка китергәнлеген күрсәтә. «Син үзеңнән соң киләчәк бик күп шагыйрьләргә юл күрсәттең вә эз салдың. Хасыйл (җыеп әйткәндә, кыскасы — Ү. Г.), син татар әдәбияты өчен җибәрелгән «әдәбият пәйгамбәре» идең. Син шушы вазифаны үз дәрәҗәңдә яхшы үтәдең, мөмкин булган кадәресен эшләдең. Син татарча шигырьнең атасы, шигырь вә шигърияттнең бик озак вакытка кадәр бабасы булырлык дәрәҗәгә лаек булып киттең», — диелә аның сәхифәләрендә (1914, 71 сан).

Вакыт үткән саен, Тукайның татар әдәбиятында тоткан тарихи һәм реаль урынына мөнәсәбәттә ялт-йолтчылар позициясенең дөрес булуы ачыграк күренә барды. Татар поэзиясенең әйдәп баручы олы шагыйрен югалтуы вакыт үткән саен ныграк сизелә иде. Аерым алганда, бу хәл Тукай вафатыннан соң ике ел үткәч чыккан «Юксынабыз» исемле мәкаләдә дә (1915, 88 сан) чагыла: «Матбугат вә әдәбиятыбызның кайсыдыр бер почмагы китек, анда нәрсәдер бер нәрсә җитешми. Күңел шул җитешмәгәнлек вә шул китеклекне сизә, әллә кайдан әллә нәрсә эзләнә. Ул шигырьләр дә укып карый, газета вә журналлар да укып карый, көлке журналларын да укый. Ләкин шул нәрсәләрнең һәммәсендә үзенә иң якын вә иң ләззәтле бер нәрсәне тапмыйдыр, ул әллә нәрсәне юксына. Ләкин аның шул нәрсәсен бирүче вә табучы хәзергә кадәр юк әле». Сөекле шагыйрьне юксыну, шуңа әрнү, көенү сүзләре...

«Тукай шигырьләре илә үзен гөлбакчасында шикелле рәхәттә сизгән татар рухы хәзер шигырь исеме белән аталган чәнечкеле агачлар арасында газап күрәдер», — дип яза «Ялт-йолт», шагыйрь иҗатының иң кыйммәтле сыйфаты — халыкчанлык булуына ишарә белән. «Тукай — халык шагыйре» дигән тәгъбир беренче тапкыр Ф. Сәйфи-Казанлы тарафыннан кулланыла һәм нигезләнә. «Һәрбер халык тарихының иң гүзәл сәхифәләре шул халыктан үзләрен халыкның сәгадәте өчен корбан иткән каһарманнары белән генә була. Менә безнең Тукаебыз да татар халкының ае, ае гына түгел, кояшы иде», — дип яза ул һәм аны татар халкына үзенең «шүрәле бармаклары белән кытыклый-кытыклый рух өргән исрафил» дип атый (1913, 55 сан).

Тагы бер елдан соң язылган баш мәкаләдә бу фикер тагы да үстерелә: «Син, Тукай, кадерле халык шагыйре, үзеңнең моңлы сазларың берлә халыкның гасырларча ач торган рухын газәләндердең (...) Син бит татарның үз хәятында, аның рухына керә алып, аның чын кайгы вә хәсрәтен моңлы иттереп көйли алган беренче баласы идең.

Син генә аның кайгы-хәсрәтен уртаклаша алдың. Син генә аның бөтен шатлык вә кайгыларын, кәгазь өстенә кара төшереп, бәхак (чын, дөрес — Ү. Г.) тасвир итә алдың».

Шуны да әйтергә кирәк, ул чакта халыкчанлыкны милләтнең барлык сыйныфлары өчен уртак мәгънәсендә аңлау шактый киң таралган иде. Кайберәүләр Тукайны да татар милләтенең барлык сыйныфлары өчен уртак тойгылар җырчысы итеп күрсәтергә маташалар, аның иҗатында «татарлык рухы»на басым ясап, «милли шагыйрь» дип бәяләүдән ары китмиләр. Буржуаз милләтчелек күренешенең бер чагылышы иде бу. Г. Халит дөрес әйтә: «Бигрәк тә Тукайны үзләренең остазы дип санаган яшенчеләр, ялт-йолтчылар (ягъни «Яшен» һәм «Ялт-йолт» журналлары тирәсенә тупланган кешеләр) милләткә һәм Тукайга ике мөнәсәбәт барлыгын басым ясап сөйләделәр, моңа карата билгеле бер ачыклык керттеләр. Алар Тукайның милли шагыйрь булуын милләтнең күпчелек өлешен тәшкил иткән хезмәт халкына бәйләп аңладылар». (Тукай турында замандашлары, 21—22 битләр). «Ялт-йолт»та бу сүзләрне раслаучы дәлилләр күп. Журнал Тукай истәлегенә багышланган саннарның беренчесендә үк «милләт» сүзе белән күз буяп, кесәләрен калынайтучыларга» отпор белән чыга һәм башлаган юлын алга таба да дәвам итә. «Ул үзе ач булды, ялангач булды, һәр вакыт фәкыйрьлек ачысында яшәде, ләкин шул авыр хәленә бер генә дә илтифат итмәде. Чөнки ул бөтенләй башка кеше иде. Аның теләге — корсак, бүксә түгел, аның теләге, идеясе — татарны, халыкны сөю, аның мәхәббәте — аның киләчәк шөһрәте өчен яшәү иде», — кебек юллар шул хакта ачык сөйли (1915, 88 сан). Тукайның киң катлам хезмәт иясе массалары белән туганлыгы, тормышының халык тормышыннан аерылгысыз булганлыгы чагыла әлеге юлларда. Шул уңай белән А. Кольцов иҗатының халыкчанлыгы турында Добролюбов фикерләрен хәтергә төшерү урынлы: «Ул (Кольцов — Ү. Г.) үзе гади халыкның мохтаҗлыкларын башыннан кичерде, үзе алар белән яшәде, үзе дә безнең гади кешеләребез яшәгән хәлдә булды. Шуның өчен Кольцовның шигырьләрендә рус кешеләре уйлап чыгарылган затлар булып түгел, ә чын кешеләр булып торалар»[1].

Тукай да, Кольцов кебек үк, халыкның аерылмас кисәге булды, аның уйлары, тойгылары белән яшәде. Шул чакта Г. Ибраһимов әйткәнчә, «шул заманда халык ни уйлый, ни хис кыла, ниләр язгалый, Тукаевта да шул»[2].

«Ялт йолт»та Тукай әсәрләренең эчтәлеге генә түгел, формасы да халыкчан булуы күрсәтелә. Бередә, барыннан да элек, әсәрләрнең теле күздә тотыла. «Тукай, — ди Ф. Сәйфи-Казанлы, — татар халкының (...) телен шомарткан, зиннәтләгән, шул тел белән халыкның кайгысын, шатлыгын җырлый-җырлый уртаклашкан» шагыйрь. Нәкъ менә теле матур, халыкка аңлаешлы булганга, Тукай шигырьләре укыганда «һәрбер татар баласының тамырларында йөри».

Шул ук вакытта «Ялт-йолт», Тукайның искиткеч популярлыгы сере матур сүзләр сөйләүдә, ягъни әсәрләренең форма камиллегендә генә булмыйча, ә иң мөһиме — тирән мәгънәлелектә, заманның алдынгы идеалларын чагылдыруында икәнлегенә дә игътибар итәргә онытмый. Тукайга багышланган саннарның соңгысында (1916, 109 сан) урнаштырылган «Олуг Тукай» исемле мәкаләдә болай диелә: «Ул бу дәрәҗәне (татар халкының иң популяр шагыйре дәрәҗәсен — Ү. Г.) шигырьләрендәге нәфәсәт сәнгате белән генә алмады. Чөнки ул язган шигырьләрендә сүз теземенә генә карамый иде, чөнки ул шигырьләрендә коп-коры бер әдәби нәзакәт кенә эзләми иде... Аның каләменнән язылган һәрбер сүздә гомуми бер мәгънә, аның каләменнән үткән һәрбер җөмләдә (...) бер азык, аның каләменнән чыккан һәрбер шигырьдә гыйбрәт алырлык милли бер фаҗига яки нәмунә (үрнәк — Ү. Г.) булырлык бер тасвир бар иде».

Журнал татар әдәбияты тарихына күз ташлап, аның халыкка якынаюында, халыкның уй-хисләрен, теләк-өметләрен чагылдыручы әдәбиятка әверелә баруында Тукайның гаять зур роле булуын күрсәтә. Габдулла Тукай — яңа әдәбиятның әйдәп баручысы, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдмәндләр — зур киләчәге булган шушы әдәбиятның төп вәкилләре. Алар, ди журнал, «телләрен акрын-акрын халык теленә якынлаштырып һәм рус әдәбиятыннан үрнәк алып, татарларның, гомумән, Россия төрекләренең[3], мәдәни һәм милли хәрәкәтенең башында, алдында баручы яшь сый-

[1] Н. А. Добролюбов. Полное собрание сочинений. ГИХЛ, М.-Л., 1934—1941, т. 1, стр. 153.
[2] Г. Ибраһимов. Татар шагыйрьләре. Оренбург, 1913, 85 бит.
[3] Ул чакта Россиядә яшәгән төрки халыкларны еш кына төрекләр дип атаганнар.

ныфның уйларын, идеалын татар халкының һәммә аерым шәхесләренә төшенерлек, мөгайян (анык, билгеле — Ү. Г.), ачык бер тарызга (рәвешкә — Ү. Г.) китереп җырладылар».

«Ялт-йолт» фикеренчә, рус һәм дөнья әдәбиятының прогрессив үрнәкләреннән өйрәнү — Тукай иҗатының гөрләп чәчәк атуына китергән сәбәпләрнең берсе. Журналда Тукайның бигрәк тә Пушкин һәм Лермонтов белән рухи-эстетик якынлыгына басым ясала. Хәзер инде бу — һәркемгә мәгълүм хакыйкать. Шулай да без «Инородческое обозрение»дә[1] Тукайның «Пушкин һәм мин»[2] исемле юмористик шигыренә А. Емельянов тарафыннан ясалган анализга журналның мөнәсәбәтен билгеләп үтәргә телибез. Емельянов татар шагыйренең үзен Пушкин белән тиңләвен «дикъкатьне җәлеп итә торган» күренеш, дип исәпли. «Ялт-йолт», аңа теләктәшлек белдереп, болай ди: «Хакыйкатән, бу дөрес: шагыйрь бу шигыре илә үзенең хезмәте Пушкинның олуг хезмәте алдында шундый кечкенә икәнлегене сөйләп, үз-үзеннән һөҗү итсә дә, үзендә Пушкин белә ярышырлык, тиңләшерлек бер хасиять бар икәнен дә күрсәтә. Гуя ул — татар халкы алдында кечкенә бер Пушкин». Тукай үзен Пушкин белән янәшә куйганда, һичшиксез, аның бөеклеген, иҗади колачын яхшы белеп эш иткән. Шагыйрь һәм гражданин буларак Пушкинны үзенә остаз, шигъри биеклек итеп санаган. Шул биеклеккә күтәрелергә омтылган. Тукайның Пушкин белән Лермонтовны яратып укуы, алардан өйрәнүе хакында С. Рахманколый истәлегендә дә әйтелә. Аның сүзләренә караганда, Тукай Пушкинның даһи инглиз шагыйре Байронга ияреп язган шигырьләрен аеруча яраткан. Рахманколый Тукай иҗатында Пушкин белән Лермонтовның шифалы йогынтысы белән беррәттән «байронизм рухы» да сизелүен әйтә.

Әлеге истәлектән Тукайның Шекспир иҗатына да сокланып караганлыгы күренә. Ул аның «Тимон Афинский» трагедиясен берничә тапкыр укып чыккан. Тимон образы аңа нык тәэсир ясый һәм ул «Тимон Афинский шикелле галиҗәнаб булсаң иде», дип әйтә торган булган. Тимонның Тукай күңеленә хуш килүе гаҗәп түгел. Афина бае Тимон кешеләргә карата гаять юмарт, ярдәмчел була. Ләкин, бөлгәч, элек аның исәбенә яшәгән «дуслары» аннан йөз чөерәләр. Тимон, акча хакимлегенә, ялганга корылган җәмгыятькә ачу итеп, дәрвиш булып китә. Урманда, туену өчен агач тамырлары казыган чакта, хәзинә таба. Аның шушы чиксез байлыкны күргәч сөйләгән монологында[3] комсызлык, акчага хирыслык, алтын хакимлеге — җәмгыятьтә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне бозучы, кешеләрне аздыручы төп явызлык булуы турындагы фикер аеруча көчле яңгырый. Шекспир әсәрендәге Тимон сүзләре Тукайның тормыш принципларына да, идея-эстетик идеалларына да бик якын.

Әдипнең, художникның акчага, байлыкка буйсынмаска, аңардан өстен торырга тиешлеген Тукай шәхси тормышы белән дә, иҗаты белән дә раслады. Бу хакыйкать «Ялт-йолт» сәхифәләрендә дә киң чагылыш тапты. «Тукайның акчага сатылмавы, байлыкка исе китмәве беренче, матур, гали сыйфатларыннан иде... — дип яза, мәсәлән, «Лачын» кушаматлы автор. — Тукайның алтынга исе китми, байларга тәлинкә тотмый, ул турыда сөйләүне дә яратмый. Менә Тукайның бу сыйфатын күп кеше белә, аңлый. Аның шигырь, назымнарында да күп вакыт байларны каһәрли, фәкыйрьләрне яклый, кызгана торган мисрагларга күп ук очрап була» (1914, 71 сан).

«Ялт-йолт»ның рәсми нашире Ә. Урманчеев истәлеге дә Тукайның язучы, художник капиталдан өстен булырга тиеш, дигән карашын раслый. Исеме Россия күләмендә яхшы таныш булган бер татар бае аны үзенә эшкә чакыра. «Менә шул вакыт,— дип яза Ә. Урманчеев, — кечкенә гәүдәле, олы йөрәкле шагыйрь ни эшли? Ул хатны иртә белән алгач та укып ташлый да, аңа шул минутта ук җавап яза. Мине чакыртып, ул хатны укый. Бу җавап шул кадәр ачы иде ки, шөбһәсез, алтыннарына мәгърур булган бай, моны алгач, чын мөхәррирлек янында акчаның никадәр зәлил (түбән, хурлыклы — Ү. Г.) булганын аңлагандыр.

Бер тиенсез йөргән чакта бу кадәр олылыкны, шөбһәсез чын мөхәррир булмаган кеше катгыян эшли алмас!» (1913, 55 сан).

«Тукай 27 яшен дә тутырмастан һәлак булды. Ләкин, — дип яза «Ялт-йолт», — күбәләк гомере кадәр генә гомерендә дә милләткә булган бурычын үтәде һәм артыгы

[1] «Инородческое обозрение», 1913, № 13, стр. 239—240.
[2] Тукайның Пушкиннан өйрәнүе турында күп язылса да, бу шигыре нигәдер читләтеп үтелә.
[3] К. Маркс үзенең әсәрләрендә Тимон Афинскийның бу монологын берничә тапкыр цитата итеп китерә.

белән үтәде...» (1916, 109 сан). Икенче бер урында «Тукай безнең тормышыбызның корбаны булды» диелә. Бу — феодаль буржуаз тормыш, кешеләрне көчләүгә, ирексезләүгә, изүгә, гаделсезлеккә корылган тормыш. Бу «мәлганәт» (ләгънәткә лаек — Ү. Г.) дөнья аз гына вакыт эчендә халкы өчен «гакылларны хәйран калдырырлык» эшләр башкарган талантларны да һәлак итә. «Бу түбән дөньяда, пәст хәят (пычрак, әшәке тормыш — Ү. Г.) эчендә» Тукай кебек художникларга тынчу, авыр. Аның «бөтен тирәсе рия (ике йөзле — Ү. Г.), бөтен тирәсе сәүдәгәр, сатлык җаннар, милләт пәрдәсе артына каплана торган надан сухтәләр белән тулган...» (1913, 55 сан).

Ирексездән А. М. Горькийның Сергеев-Ценскийга язган хаты хәтергә килә. «Бу дөнья художниклар өчен түгел, анда һәр вакыт аларга кысынкы һәм уңайсыз булды — шуңа күрә аларның роле мактаулырак та, батыррак та»,— дип язып, мисалга «ачлыктан һәм чахоткадан үлгән» Тукайны китергән иде. Шуның белән бергә, Тукайның «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы» дигән шигырь юлларында шатлык авазы ишетүе турында да искәрткән иде[1].

Бөек пролетар язучысы сүзләренә авваздаш фикерләрне «Ялт-йолт»та да очратырга мөмкин. Аның битләрендә якты талантның феодаль-капиталистик шартларда, тончыктыргыч реакция кысымы астында иртә һәлак булуына, күп гүзәл әсәрләрне үзе белән алып китүенә ачыну, әрнү чагыла.

Журналда Тукайның буржуаз наширләр, китап сәүдәгәрләре тарафыннан рәхимсез талануы, аның әсәрләрен басып таратканда, наширләрнең, башлыча, күбрәк табыш алу, кесә калынайту максатын күзәтүләре турында әйтелә. «Ул шигырь яза — мәҗмуга була. Аны китапчыларга бирә. Ул сәүдәләшеп тормый. Тегe комсызлар үз ирекләре белән, шәфкатьләре килеп, күпме хак куялар, шуңа Тукай разый була. «Комсыз китапчылар» Тукайга вәгъдә иткән гонорарны да рәхәтләндереп бирмиләр. Бик мохтаҗ вакытларында записка белән бер сум-илле тиенләп кенә алып тора. Шуның өчен,— ди «Ялт-йолт»,— Тукайның вакытсыз чахоткага эләгүенә, әлбәттә, аның тормышының начарлыгы беренче сәбәп булганлыгын әйтеп китәргә кирәк» (1914, 71 сан).

Шагыйрьнең әсәрләрен аерым җыентыклар итеп басып чыгаруга беренче булып «Мәгариф» көтепханәсе керешә. 1912 елда көтепханә хуҗалары бу эшне тулысынча үз кулларына алалар, Тукай әсәрләрен ел саен зур тиражлар белән чыгарып торалар[2]. Ләкин шагыйрь истәлеген мәңгеләштерү хакындагы вәгъдәләр тиешенчә үтәлми. «Ялт-йолт» 1915 елда әрни-әрни яза: шагыйрьнең «кабере тапталып беткән. Нә таш, нә башка нәрсә — Тукаевның кабере икәнен күрсәтеп тора торган бер галәмәт тә юк... Оят, оят!» (88 сан). 1916 елгы юбилей санында да журнал шагыйрь каберенә өч ел буена «өч сумлык бер таш та куйдыра алмаган» китапчыларга зур үпкә белдерә, аларны «Тукай рухына хыянәт итүчеләр» дип атый (109 сан).

Журнал Тукай иҗатын пропагандалауга хезмәт итә торган чараларны хуплый, бу эшкә комачаулык итүче реакционерларны кискен гаепләп чыга. Әйтик, Хөсәения (Оренбург) мәдрәсәсенең алдынгы шәкертләре «Тукай көне» үткәрергә хәзерләнәләр. Ләкин вакыт җиткәч, идарә рөхсәт итми. Шулай да шәкертләр чигенмиләр. Эш җитди конфликтка барып җитә. Бу эшне башлап йөрүчеләрне классларга, мәчет бүлмәләренә ябып куялар. «Ялт-йолт» «сәяси тәс алуыннан» курыккан мәдрәсә җитәкчеләрен хурлык баганасына кадаклый.

Гомумән, туган көненнән соңгы саннарына кадәр «Ялт-йолт» татар әдәбияты тарихында яңа сәхифә ачкан, югары идеалларга хезмәт иткән, халыкчанлык һәм реализм өчен ялкынлы көрәш алып барган шагыйребез Тукай традицияләренең яшәүчән көчен күрә, аларның ишәячәгенә өмет белдерә. «Бер вакытлар дөньябызга чын көрәшчеләр чыгып, милли тарихта намың алтын белән язылыр...» яисә «аның язган нәрсәләре бу көн никадәр кирәк булса, моннан ничә гасырлар соң да шулай ук кирәкле булачаклардыр...» кебек сүзләргә аның сәхифәләрендә урын түрдән бирелә. Тукай иҗаты һәм татар халкының якты, бәхетле киләчәгенә ышаныч белән сугарылган шундый юллар безнең көннәрдә, татар әдәбияты күп милләтле бердәм совет әдәбияты гаиләсендә гөрләп чәчәк аткан көннәрдә, аеруча урынлы яңгырый.

---

[1] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 30 бит.

[2] 1921 елга кадәр «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан Тукай әсәрләренең 50 дән артык басмасы чыгарыла. Тукай үлгәндә «Мәгариф» нәшриятында аның 500 сумнан артык акчасы кала. Шагыйрь бу акчага бер зирәк баланы мәктәптә тәрбияләргә васыять әйтә («Казан утлары», 1966, № 4, 139 бит).

**Флүн Мусин**

# ХӘЗЕРГЕ АВЫЛ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

*Күзәтүләр һәм уйланулар*

Авыл элек-электән үзенә әдипләрнең даими игътибарын җәлеп итеп килә. Фән-техника революциясе заманы булган безнең дәвер дә авылны әдәбиятта күрсәтүгә мәгълүм йогынты ясый. Бер яктан, бу чынбарлык төрле яклабрак һәм төрле-төрле аспектларда карала башлады. Икенче яктан, хәзерге авылга фән-техника революциясе актуальлек биргән проблемаларны үз эченә алган бер дөнья итеп карау көчәйде. Биредә шундый мәсьәләләрнең берничәсенә тукталасы килә.

Билгеле булганча, фән-техника прогрессы илебез халык хуҗалыгының тагын да зуррак темплар белән үсүенә китерде. Бу хәл хәзерге производство, экономика белән идарә итүне бермә-бер катлауландыра һәм җитәкчелек итү системасын камилләштерүне заманның иң мөһим мәсьәләләреннән берсе итеп көн тәртибенә куя. Табигый, бу мәсьәләдән әдәбият та читтә кала алмый. Әмма язучыларны мәсьәләнең күбрәк кеше язмышы белән бәйләнештәге ягы кызыксындыра. Икенче төрле әйткәндә, соңгы вакытта совет әдәбиятларында хәзерге хуҗалык җитәкчесен сурәтләүгә игътибар бермә-бер артты. Бу мәсьәлә белән хәзерге тәнкыйть тә якыннан кызыксына. Аның тирәсендә матбугат битләрендә әледән-әле бәхәсләр кабынып тора.

70 нче еллар татар прозасында еш кына хәзерге колхоз председателе шәхесенә дикъкать ителә. Бу шәхес күбрәк безнең көннәр әдәбиятында актуаль төс алган «эшлекле герой» мәсьәләсе яктылыгында карала. Мәгълүм ки, заманыбызның яңа герое итеп аңлатыла торган эшлекле шәхесне сурәтләгәндә әсәрләрдә аның эшлеклелек һәм кешелеклелек сыйфатларын нинди мөнәсәбәттә бирүгә игътибар артты. Бу мәсьәлә әсәрләрдә төрлечә яктыртыла. Моны хәзерге авылга багышланган әсәрләрнең үзәгенә куелган колхоз председателе образларын сурәтләүдә шактый ачык күрергә мөмкин.

Экономик яктан артта калган һәм нык аксаган колхозны өзеклектән чыгару һәм аякка бастыру өчен җибәрелгән утызмеңче Халикъ Саматовны Г. Ахунов «Чикләвек төше» повестенда күбрәк менә шушы төп эшен башкару дәвамында күрсәтә. Саматов чын мәгънәсендә эш кешесе булып алга баса. Үз хезмәтенә ул зур җаваплылык белән карый һәм «булсынга» эшли. Аның гадәттән тыш тырышлыгы белән колхоз тиз арада аякка баса. Бу яктан Саматов илленче еллар башындагы авыл прозасының нык ихтыярлы җитәкче геройларын хәтерләтә кебек. Әмма үзенең эш принциплары буенча ул әлеге җитәкчеләрдән шактый аерыла да. Саматов волюнтарист түгел, бәлки акыл белән, уйлап эш итә торган җитәкче. Авылга килү белән герой ныклап экономиканы өй-

рәнә башлый. Формализмның һәм коры энтузиазмның дошманы булган Саматов хуҗалыкны үстерүнең экономик яктан нигезләнгән һәм акланган принципларын алга сөрә. Бу юлда аңа күнегелгән карашлар һәм принциплар белән конфликтка керергә туры килә. Менә ул, бер яктан, колхоз экономикасын ныгыту, икенче яктан, туфракның уңдырышлылыгын күтәрү нияте белән җитен һәм күпьеллык үлән чәчәргә керешә. Ә бу вакытта үлән чәчү системасы кире кагылган була. Һәм бераздан өлкә газетасында Саматовны тәнкыйтьләп «Травопольный король» дигән мәкалә чыга. Районнан исә аны клевер җирләрен сөреп ташларга мәҗбүр итәләр. Моның нәтиҗәсе шул була: сөт тапшыру буенча районда беренче урынны алып килгән колхоз, «яшен сугып сындырган агач төсле, кинәт артка авып төшә». Ә менә җитен чәчү колхозга зур файда китерә. МТС техникасын колхозларга сату башлангач, бары Саматовның гына бу техниканы алырга мөмкинлеге булуы ачыклана. Кыскасы, Саматов безнең алга аек акыл белән һәм киләчәккә карап эш итә торган җитәкче булып баса. Моның белән Г. Ахунов яңа тип колхоз җитәкчесенең бүген генә дөньяга килмәвен, бәлки аның инде 50 нче еллар авылында ук формалашуын күрсәтә. Әмма бөтен игътибарын полемик рәвештә геройның хуҗалык эшчәнлегенә һәм эшлеклелек сыйфатларын ачуга туплап, автор аның шәхси тормышы белән азрак кызыксына.

Ә менә В. Нуруллинның «Күпер чыкканда» повестенда, киресенчә, Саматов кебек үк булдыклы председатель Өлфәт Хәкимовның шәхси тормышын күрсәтүгә басым ясала. Автор өчен иң мөһиме — геройның шәхси язмышы, конкретрак әйтсәк, аның «бер минутлык дуамаллык аркасында бер гомерлек фаҗига»гә дучар булуы. Сүз Хәкимовның үз гаебе белән җимерелгән гаилә тормышы турында бара. Бу вакыйга геройга бик нык тәэсир итә, аның күңеленә төзәлмәс яра сала.

Җитәкче геройны әхлакый яктан сынауга Б. Камаловның «Күңел кыңгыраулары» һәм «Ялыкмаслар» повестьларында да шактый игътибар бирелә. Әсәрләрнең үзәк геройлары — райкомол секретаре Инсаф Заманов белән райком секретаре Хафиз Кадергулов шулай ук мәхәббәт һәм семья мәсьәләләрендә уңышсызлыкка дучар булалар. Б. Камалов һәм В. Нуруллин повестьларында шәхси моментка игътибарны арттыру җитәкче геройны кеше буларак җанлырак һәм күңелгә ятышлырак итеп бирергә булыша.

Бу әсәрләрдә икенче бер уртак момент та бар. Сүз җитәкче геройның иҗтимагый һәм шәхси яшәешен контраст буяулар белән тасвирлау турында бара. Геройлар хезмәттә кыенлыкларны һәм каршылыкларны җиңә-җиңә яңа үрләргә күтәреләләр, шәхси тормышта исә адым саен уңышсызлыкка очрыйлар. Кыскасы, бирегә авторларга җитәкче герой тормышының иҗтимагый һәм шәхси өлкәләрен үзара органик бәйләнештә карау җитенкерәми.

Х. Хәйруллин («Канатлар талмасын» повесте) белән М. Хәбибуллин («Чоңгыллар» романы) хәзерге колхоз җитәкчесен сурәтләүгә башкачарак якын килләр. Алар икесе дә геройларының хезмәте һәм шәхси тормышы белән бердәй диярлек кызыксына. Шунлыктан бу әсәрләрнең үзәк геройлары — Рамай Вильданов һәм Талип Бикмуллин төрле уй-омтылыш һәм хисләр белән яшәүче шәхесләр булып гәүдәләнәләр. Дөрес, әле бу әсәрләрдә дә җитәкче геройның иҗтимагый һәм шәхси яшәеше беркадәр капма-каршы төсләрдә сурәтләнә. Колхоз хуҗалыгын үстерүдә бик җитди кыенлыкларны җиңеп, геройлар үз теләкләренә ирешәләр һәм рухи канәгатьләнү табалар. Ә менә мәхәббәттә, семья тормышында әле хәлләр башкачарак. Гомумән, безнең күп кенә әсәрләрне укыганда күңелдә: «Җитәкче геройга нормаль семья тормышы белән яшәргә язмаган микәнни?» дигән сорау туа. Бу яктан, минемчә, Ф. Хөснинең «Мәйдан» повестендагы председатель Сәлим Ахунҗанов кына үзен бәхетлерәк сизә ала. Башта, яңа колхозга килгәч, яшь сатучы хатын белән бераз буталып алса да, соңыннан ул бердәнбер яраткан кешесе үзенең хәләл җефете икәнен аңлый.

Мораль конфликтлардан тыш безнең авылга багышланган әсәрләрнең иҗтимагый конфликтлары да игътибарны җәлеп итә. Г. Ахунов һәм Х. Хәйруллин повестьларында үзәк конфликт алдынгы карашлы колхоз председателе белән тормыштан артта калган райком секретаре арасында туа. Әйтергә кирәк, бу безнең проза өчен яңа конфликт түгел. 60 нчы еллар башында аңа беренчеләрдән булып «Язгы авазлар» романында А. Расих мөрәҗәгать итте. Һәм ул вакытта мондый конфликт әдәбият өчен шактый

дәрәҗәдә ачыш иде. Ә инде «Язгы авазлар»дан соң ул, гәрчә авторлар аны беркадәр үзләренчә аңлатырга, кайбер психологик нюанслар белән төрлеләндерергә тырышсалар да, гомумән алганда, штампка әверелде. Икенче яктан, әдәби әсәрнең гомумиләштерү көченә ия булуын да искә алсак, әлеге конфликтны безнең көннәрдә күтәреп чыгу тормыш чынлыгын исәпкә алып бетермәү булып яңгырый.

М. Хәбибуллин исә «Чоңгыллар» романында хәзерге җитәкчеләрнең эш стильләрен ачканда новатор белән консерватор арасындагы әлеге традицион конфликттан баш тарта. Әсәр геройлары — колхоз җитәкчеләре дә, район җитәкчеләре дә авыл хуҗалыгында яңалык өчен актив көрәшүчеләр булып алга басалар. Мәсьәләгә мондый карашы белән М. Хәбибуллин хәзерге авылның рухын дөресрәк чагылдыра кебек. 70 нче еллар авылының яшәеш шартларын яхшы аңлап эш итү әсәрнең стиленә дә эз салган.

Әйтергә кирәк, биредә карала торган әсәрләр хикәяләү үзенчәлекләре ягыннан да бер-берсеннән шактый аерылалар. Һәм бу хәл авторларның үз алларына куйган максатлары яки шәхси стиль үзенчәлекләре белән генә түгел, бәлки тормыш материалының характеры белән дә бәйләнгән. Колхозларның экономик хәле авыр булган һәм артель хуҗалыгын аякка бастыру өчен киеренке көрәш барган заманнарны сурәтләгән әсәрләрдә (Г. Ахунов һәм В. Нуруллин повестьларында) хикәяләү дә киеренке һәм драматик рухта алып барыла. Биредә сүзнең аерым зат исеменнән алып барылуы да мәгълүм роль уйный. «Чикләвек төше»ндәге Рокыя һәм «Күпер чыкканда»дагы Өлфәт һич тә тормыш турында киңләп сөйләргә омтылмыйлар, бәлки күңелләренә аеруча нык кереп калган хәлләр һәм вакыйгаларга гына мөрәҗәгать итәләр. Бу хәл хикәяләүдә эмоциональлекнең көчәюенә китерә. Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестенда 60 нчы еллар авылында тормыш стабильләшә барган кебек, хикәяләү дә салмаклана төшә, аңарда мөстәкыйльлек һәм объективлык көчәя. Ә М. Хәбибуллин романында бу сыйфатлар тагын да көчлерәк чагыла. Автор артык контраст буяулардан, геройларның үзара мөнәсәбәтләрен кискен конфликтлар ярдәмендә ачудан баш тарта.

Фән-техника революциясе (алга таба, кыскартып, ФТР дип кулланыла — Ф. М.) йогынтысында авыл темасы соңгы вакытта әдипләрне тагын бер мәсьәләдә кызыксындыра башлады. Мәгълүм ки, хәзерге тормышның зур темплар белән шәһәрләшүенә китергән ФТР кеше яшәешенең борынгыдан килә торган табигый нигезләренә игътибарны арттырды. Бу нигезләрне әдипләр башлыча табигатьтә, халык тарихында, аның рухи мирасында һәм традицияләрендә күрәләр. Ә шушы нигезләрне үзендә саклаучы дөнья итеп әдәбиятта еш кына авыл карала. Тарихның иң авыр сынауларын намус белән үткән һәм яшәү өчен күп гасырлык көрәштә үзенең милли бөтенлеген саклап кала алган туган халкының рухи көч чыганакларын эзләп, Г. Бәширов «Туган ягым — яшел бишек» повестенда революциягә кадәрге татар авылының рухи яшәешенә, аның гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә мөрәҗәгать иткән иде.

Бүгенге авылны нигез мәгънәсендә карауга безнең әдәбиятта беренчеләрдән булып Ә. Еники алынды кебек. «Әйтелмәгән васыять» дигән күләмле хикәясендә ул ФТР заманы кешеләренең әнә шул нигез белән аерылгысыз бәйләнештә яшәргә тиешлекләренә басым ясады. Әсәрдә күбрәк авылның халык тарихы, аның рухи мирасы һәм традицияләрен үзендә саклаучы дөнья булуына игътибар ителде. Ә җитмеш алты яшьлек Акъәбине автор аның шәһәрләшкән балаларын шушы дөнья белән «бәйләгән бердәнбер җеп» итеп карый. Карчык үлсә, бу җепнең өзелү куркынычы бар. Язучыны менә шушы куркыныч борчый. Чөнки әлеге «тере җеп өзелү белән бергә туган үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак». Әмма моңа һич тә юл куярга ярамый. Акъәбинең шәһәрдә яшәүче балаларына әйтә алмый калган васыяте мондый сүзләр белән тәмамлана: «Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер менә шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде, сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!» Кыскасы, Ә. Еники бу әсәрдә безнең заман кешеләренең шушы нигез дөнья белән бәйләнешләре өзелмәскә тиешлеген, әгәр өзелсә, бу хәлнең бик күңелсез нәтиҗәләргә, зур рухи югалтуларга китерәчәген чагылдыра.

Гомумән, әдәбиятта авыл кешесенең шәһәр кешесенә әверелүе мәсьәләсенә игътибар артты. Әгәр эшчеләр темасын яктырткан әсәрләрдә бу процесс за... бызның зарури күренеше итеп бәяләнсә, хәзерге авылга багышланган әсәрләрдә исә ул башкачарак яңгыраш ала.

М. Мәһдиевнең «Каз канатлары» романындагы Мәтәли агай оныгы Хәбибрахман образында, мәсәлән, әлеге процессның шактый катлаулы күренеш булуы һәм тормышта төрле нәтиҗәләргә китерүе күрсәтелә. «Шәһәр кешесе, аның да интеллигенты» булырга теләп, Хәбибрахман шәһәргә китә һәм анда диссертация яклап, галим Хәбиб Фәһмиевичка әверелә. Әмма шәһәр интеллигенты дәрәҗәсенә герой зур рухи югалту, туган авылы белән элемтәсен өзү, нигезен корыту исәбенә ирешә. Дөрес, бу хәлгә Хәбиб һич тә үзен гаепле санамый. Әгәр сугышта әтисе үлеп калмаса, ул һич тә карт әнисен шәһәргә алып китмәс иде. Хәбибнең мондый фәлсәфәсендә күпмедер дөреслек бар, әлбәттә. Шулай да геройның үзен бөтенләй гаепсез санавы белән килешүе кыен. Хәбибнең туган нигезен корытуында аңа туган авылының киләчәге өчен җаваплылык хисе җитмәү дә зур гына роль уйный. Нәкъ менә шул җаваплылык хисе, Ленар белән Маратны, шәһәрдә яшәргә бөтен мөмкинлекләре булса да, туган авылларына кайтара.

М. Мәһдиев романында геройның туган авылыннан аерылуына сугыш гаепле итеп күрсәтелсә, Х. Камаловның «Аэропортта» дигән шигырендә исә төп гаеп хәзерге шәһәр өстенә ташлана. Чөнки бер карт белән карчыкның улларын шәһәр укытам дип алган да:

**Өйрәтеп, кеше итеп**
**Үзендә калдырган.**
**Җибәрми авылга,**
**Кайтармый төп йортка.**

һәм карт шәһәргә болай дип ялвара:

**Бир, шәһәр, улымны!!**
**Нигезем бетә бит,**
**Бир минем кулымны!!**
**Буыннан-буынга**
**Килгән ул бишегем**
**Җуелыр мәңгегә,**
**Бетәр бит нишелеп!!**

Бу шигырьнең идеясен кырт кисеп кенә яхшы яки яман дип әйтеп булмый. Бер яктан, авылдан яшьләрнең күпләп китүләренә шагыйрьнең тирән борчылуы сизелә, һәм мондый борчылуга реаль җирлек тә бар. Яшьләрнең күпләп шәһәргә, производствога китүләре авылга һәм экономик, һәм рухи зыян китерә. Икенче яктан исә, Х. Камалов бу шигырендә чал бер хакыйкатьне искә алып бетерми кебек. Сүз авылның элек-электән шәһәр өчен эшче көч чыганагы булып торуы турында бара. Бу процессны бүген генә туктатып булмый торгандыр, күрәсең. Әмма бер хакыйкать ачык: авылның эшче көчләрен шәһәргә бирүгә хәзер бик уйлап, аек исәп белән, бу дөньяның үз ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен кат-кат үлчәп, искә алып кына килергә кирәк.

И. Юзеевның «Карурман» поэмасында исә замандашның туган нигезгә якынлыгы һәм җаны-тәне белән бирелгәнлеге күрсәтелә. Әсәрнең лирик герое — тавыш тизлегендәге самолетларда очучы егет башта «җир дә башка хәзер, җыр да башка» дип, үткәннән килә торган күп кенә нәрсәдән баш тартырга тели. Әмма бераздан аны күңеленең ниндәндер канәгать булмавы борчый башлый. Һәм менә шушы күңел тынычсызлыгы, рухи канәгатьсезлек аны туган авылына кайтара. Шунда мәсьәлә ачыклана. Аңа туган җир — «озын салмак көйләр, ат кешнәве, кошлар сайравы» җитмәгән икән. Ул аларның барысын да бабасы васыять итеп калдырган карурманда таба. Карурман поэмада табигатьне, халык тарихын һәм аның күп гасырлык рухи мирасын үзендә туплаган дөнья булып, нигез булып гәүдәләнә. Дөньяда иң гуманлы җәмгыять булган безнең җәмгыятьтә табигать саклау мәсьәләсенә гаять зур әһәмият бирелә, табигатьне саклау максатында дәүләт күләмендә җитди чаралар күрелә. Әмма бу чаралар тиешле нәтиҗә бирсен өчен безгә кешеләрдә табигатькә дөрес караш тәрбияләргә,

аның тормыштагы ролен һәм әһәмиятен тирәнтен төшендерергә кирәк. Бу бурычны хәл итүдә әдәбият өстенә чиксез зур эш йөкләнелә.

Г. Бәширов «Җидегән чишмә» романында бу мәсьәләне яктыртып ике моментка басым ясый. Бер яктан, әдип табигатьнең аерым шәхескә һәм бөтен халыкка кирәклеге турында сүз алып бара. Мәсәлән, Урал тауларына яшьтәш булган Җидегән чишмәне тасвирлаганда язучы аны күп гасырлык тарихның җанлы шаһите итеп карый. Бу чишмә — «халыкның картаймас юлдашы, юанычы, тормышының матур бизәге. Шундый да газиз ул, әгәр бу чишмә булмаса, болыннарны сугарып, якын-тирәне ямьләндереп тормаса, Ык буена нидер җитмәс, халык тормышының кай җиредер китек булыр иде». Чишмә җыр булып, шигъри аһәң булып халык тормышына үрелеп аккан, гасырлар буе кешеләргә дару-дәрман булып килгән, «сырхауларны дәвалаган, арыганнарга ял булган, моңлыларны юаткан». Алтынбикә тугае, Ык елгасы турында сөйләгәндә дә автор аларның менә шушы вазифасына басым ясый.

Табигатьне кеше яшәешенең рухи чыганагы итеп карау белән бергә, Г. Бәширов аның мөһим экономик фактор да булуын күрсәтә. Әйтик, урманнарны күпләп кисү, әрәмәлекләрне бетерү җирдә дымны киметә, туфрак эрозиясен көчәйтә.

Икенче яктан, язучы табигатькә җавапсыз карау һәм аның бөтенлеген җимерүнең бик зур югалтуларга китерүен ача. Беренче карашка Алтынбикә болынын сөреп ташлау гадәти күренеш кебек. Чөнки андый хәлләр чынлыкта бик күп булды. Романның табигатькә битараф геройларына ул шулай тоела да. Ә менә автор безне бу нәрсәләргә башкача, башка күз белән карарга мәҗбүр итә. Һәм без бу матур болынны сөреп ташлау зур югалтуларга, кайтарып ала алмаслык югалтуларга китергәнен күрәбез. Сөрелгән болында күп кенә үсемлекләр харап булган, кошлар юкка чыкканнар. Алай гына да түгел, бу болында башка бер җирдә булмаган бик борынгы бер үлән үскән. Язучы аны «моннан әллә ничә мең еллар элек безнең әби-бабаларыбызның шалашлары яисә землянкалары янында да үсеп утырган, аларның күңелләрен хушландырган, хәтта дару булып хезмәт иткән» үлән дип атый. Һәм бу үлән юкка чыгу әсәрдә безнең замандашларны ерак буыннар белән бәйләп торган бер җеп өзелү булып яңгырый.

«Җидегән чишмә»дә тасвирланган гыйбрәтле күренешләрнең тагын берсенә игътибар итеп узыйк. Химикатлар белән эшкәртелгән орлыкны аннан-моннан гына чәчү аркасында, аны чүпләгән кошлар агуланып һәлак булалар. Бу күренешне бәяләүгә дә Г. Бәширов художник буларак килә, аның рухи нәтиҗәсен ача. Ул тургай образына мөрәҗәгать итә. Бу җырчы кошның агуланган орлык ашап һәлак булуының нәрсәгә китерүен әдип карт умартачы Минһаҗ һәм колхозчы егет Гайнанның уй-кичерешләре аша чагылдыра. Минһаҗ карт тургай җырына «гомере буе гадәтләнеп беткән, ул иртән кояш чыгуы, кичен ай калкуы кебек үк тормышның җанга сеңгән табигый бер бизәгенә әверелгән иде.» Ә хәзер, «табигатьнең шушындый яфрак ярырга, чәчәк атарга, дәртләнеп яңарырга, үрчергә торган чагында» тургай җырын ишетмәү геройны шомга сала. Бала чактан ук «түземсезләнеп, юксынып көтелә торган, күктән көмеш кыңгырау чыңы булып агыла торган тургай җырын» бу язда ишетмәгәч, Гайнан да уйга кала. Чөнки «язның иң шау-шулы, иң җанлы көннәре булуга карамастан», тирә-юньне «зират өстендәге кебек шомлы тынлык баскан. Унтугыз яшенә җитеп, Гайнанның беркайчан да яз көне мондый җан өшеткеч хәсрәтле тынлыкка тарыганы юк иде әле».

Тургай җырында («Юл өстендә тургай» поэмасы) шагыйрь Р. Мингалимов тагын да зуррак мәгънә, рухи көч таба. Ул кеше йөрәген яшәртә, борчуларны җуя, өметләрне яңарта. Шундый зур көчкә ия булган бу кош моңына гөл тартыла, көн тартыла.

**Көй артыннан тал сузыла,**
**Үлән күккә үрелә.**
**Таш, үрелеп көйгә таба,**
**Йортларга әверелә...**
**Кынысында кылычы бар**
**Ир тартыла тургайга.**
**Уйламагыз тартылмый дип,**
**Җир тартыла тургайга.**

Әлеге тема уңаена Х. Туфанның «Сандугачлар эзлиләр каенны» дип исемләнгән шигыре дә аерым игътибарга лаек. Ул шигырьдә каен замандашларның рухи культу-

рәсын, әхлакый үсешен күрсәтә торган фактор итеп карала. Бик әдәпле, тәрбияле булып күренгән кешеләргә ул:

**Болар — яшәү дусы.**
**Алдынгылар болар, аңлылар.**
**Җырларында минем исемне дә**
**Ничә тапкыр телгә алдылар,**

— дип ышанып караган. Әмма югары белемле шул кешеләр, «әле генә мена унынчыдан, имтиханнан чыккан» яшь кызны хәтерләткән бу гүзәл агачны кисеп, тураклап ташлыйлар.

Безнең карашка, бу шигырьдә ФТР заманының күңелне борчый торган бер күренеше ачык гәүдәләнә. Фән-техника прогрессы заманы кешенең профессиональ яктан үсүен тизләштерә, ә аның рухи үсеше исә кайчак тоткарлана яки акрынрак бара. Безнең язучылар исә шундый күңелсез нәтиҗәгә китергән сәбәпләрнең берсе дип яшьләрнең табигатькә ихтирамы җитмәү һәм аны аңлый, ярата белмәүләрен саный.

Соңгы вакытта табигатькә туристларча, бер минутлык ләззәт ноктасыннан гына чыгып карауга каршы көрәш актуаль төс алды, браконьерлык мәсьәләсенә игътибар шактый артты. Әдипләр тормышта киң таралган бу күренешнең зарарын сәнгатьчә тирәнрәк ачарга, аңа зур социаль-әхлакый яңгыраш бирергә тырышалар. Хәзерге күп милләтле совет әдәбиятының бу өлкәдәге иң зур уңышларыннан берсен, һичшиксез, Ч. Айтматовның «Ак пароход» повесте тәшкил итә. Гадәти браконьерлык күренешенә — маралны үтерүгә кыргыз халкының ничек килеп чыгуы турында сөйләүче борынгы Ана болан легендасы аша карап, әдип мәсьәләгә гаять киң идея-фәлсәфи яңгыраш бирә. Маралны үтерү әсәрдә табигатькә генә түгел, бәлки халыкның күп гасырлык үткәненә, рухи мирасына да җинаятьчел төстә кул сузу булып, гомумән, безнең заманның иң кешелексез һәм иң мәрхәмәтсез күренешләреннән берсе булып гәүдәләнә. В. Астафьевның «Балык патша» һәм М. Әмирнең «Балыкчы ялганнары» повестьларында да браконьерлык теге яки бу дәрәҗәдә табигатькә колонизаторларча карау дип бәяләнә.

Хәзерге авылга багышланган әсәрләребезгә гомум бер күз ташласак, аларда авылның өлкән буынына игътибар көчле булуын да күрербез. Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ендә — Акъәби белән «әҗәлгә дә күптән кул селтәгән, елан таптаучы йөз яшәр» Миңлебай карт, Г. Бәшировның «Җидегән чишмә»сендәге Минһаҗ абзый, Ә. Баяновның «Төлке тоту кыен түгел»ендәге Тата, И. Юзеевның «Карурман»ындагы авыл карты яки М. Мәһдиевнең «Каз канаты»ндагы бер төркем карт һәм карчыклар шул хакта сөйли. Бу хәл бер безнең әдәбиятка гына түгел, башка әдәбиятларга да хас икән. Рус әдәбиятында бу мәсьәләгә игътибар зур булуның сәбәпләре турында язучы Ф. Абрамов кызыклы фикер йөртә. Хәзерге авылда төп фигура булып яшь механизатор торуын белә торып, күп кенә рус язучылары ни өчен соң өлкән буын вәкилләре белән күбрәк кызыксыналар? Ф. Абрамов үзалдына шушы сорауны куя да, аңа болай дип җавап бирә: «Әдәбиятта карт һәм өлкән буын кешеләре турында зур сөйләшү алып бару аларның рухи тәҗрибәсен, иң авыр сынау елларында да Россияне һәлакәттән саклап калырга булышкан әхлакый көчләрен аңларга һәм сакларга омтылу белән бәйләнгән.»[1] Ф. Абрамов рус язучыларын өлкән буын авыл кешеләренең чиксез фидакарьлеге, намуслылыгы, хезмәткә, җиргә һәм гомумән тереклеккә тирән мәхәббәте аеруча кызыксындыруын белдерә, өлкән буын авыл кешеләренең шул сыйфатлары белән хәзерге яшьләргә үрнәк булып торуларын әйтә.

Бу фикерләр байтак дәрәҗәдә безнең әдәбиятка да карый. Чөнки безнең әсәрләрдә дә өлкән буын авыл кешеләренең шушындый сыйфатларын ачуга дикъкать ителә. Мәсәлән, Ф. Хөснинең «Гыйльмениса» повесте героинясы яки Ә. Баяновның «Төлке тоту кыен түгел» повестендагы Тата, тарихның бик катлаулы һәм киеренке чорларында яшәп, авыл йөген сызланмыйча үз җилкәләрендә күтәргән, бернинди авырлыклардан да куркып калмаган көчле рухлы шәхесләр булып гәүдәләнәләр. Шул ук вакытта Ф. Хөсни Гыйльмениса карчыкны тирән хөрмәткә лаеклы ана итеп тә күрсәтә. Бик иртә тол калып, күп санлы балаларын «бер ялгызы, кешегә орчык эрләп,

---

[1] «Литературная газета», 30 июнь, 1976 ел.

өзен сугып, үзе киенмичә киендереп, тамагын, өстен-башын карап, укытып, канаткаурый куеп дөньяга очырган» Гыйльменисаны әдип үрнәк итеп куя.

Т. Миңнуллин исә «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасында туксан бер яшьлек авыл карты Әлмәндәрнең гаҗәп тормыш сөючән, яшәүчән һәм оптимист рухлы шәхес булуын күрсәтүгә басым ясый. Үз гомерендә ул күпне күргән, күпне кичергән. Газраил да аны инде өч мәртәбә теге дөньяга алып китәргә дип килгән булган. Әмма берсендә дә теләгенә ирешә алмаган. Чөнки тормышка гашыйк Әлмәндәр һәрвакыт үлемне җиңә алган. Бөтен гомере эштә, хезмәттә үткән бу гади авыл карты зур идеаллар, үй-омтылышлар белән яшәгән. Үләр алдыннан газраил аның ирешә алмый калган иң зур хыялы турында сорагач, Әлмәндәр бу хыялының бөтен дөньяда тыныч һәм бәхетле тормыш төзүдән гыйбарәт булуын әйтә.

Шул рәвешчә, язучыларыбыз хәзерге авылны сурәтләүдә кызыклы гына эзләнүләр алып баралар. Алар бүгенге авылга торган саен якынрак килергә, аның актуаль мәсьәләләрен күтәрергә омтылалар. Шуның белән бергә, бу өлкәдә алар алдында әле җитди бурычлар һәм зур эшләр торуын да әйтергә кирәк. Бу уңайдан иң элек язучыларыбызның бүгенге авыл белән бәйләнешләре мәсьәләсенә игътибар итәр идек. Беренче карашка, күпчелек вәкилләре авылдан чыккан әдәбият өчен бу нәрсә проблема булып торырга тиеш тә түгел кебек. Чынлыкта исә мондый проблема бар. Эш монда иң элек әдәбиятның тормыш белән бәйләнеше мәсьәләсен ничек аңлауда. Кайчак без бу мәсьәләне гадиләштеребрәк аңлыйбыз түгелме икән?..

Без, иң беренче чиратта, язучыларыбызның хәзерге авыл белән шәхси бәйләнышларын ныгыту турында уйларга тиешбез. Чөнки бүгенге авылны әдәби атналыкларда яки укучылар конференцияләрендә генә катнашып аңлап бетерү мөмкин түгел. Эшчеләр яки галимнәр турында җитди әсәр тудыру өчен аларның тормышын һәм хезмәтен ныклап өйрәнү кирәк булган кебек, хәзерге авылны сурәтләргә алынганда да шундый ук эш сорала. Бу чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерү өчен яңадан-яңа ачкычлар эзләргә кирәк булуы да бәхәссез. Чөнки хәзерге авыл күзгә күренеп үзгәрә. Бүгенге колхоз хуҗалыгы күп кенә яклары белән промышленность производствосын хәтерләтә. Бу хәл, аерым алганда, колхоз җитәкчесенең эш стилендә зур гына үзгәрешләр тудырды. Әгәр элегрәк ул башлыча экономик кыенлыклар белән очрашса һәм шуларны җиңеп чыгу өчен көрәшсә, хәзер аңа күбрәк рухи-әхлакый характердагы кыенлыклар һәм мәсьәләләр белән эш итәргә туры килә. Бүгенге көндә аңардан аеруча кешеләр белән эшли белү осталыгы сорала. Әмма бүгенге күп тармаклы колхоз производствосы белән җитәкчелек итә торган председатель безнең әдәбиятта тулы гәүдәләнеш тапмады әле. Бу юнәлештә хәзергә башлангыч адымнар гына ясала. Аннан соң әдәбият инде тормышта булганны гына түгел, бәлки булырга тиешлене дә күрсәтергә, ягъни алга карап, перспективаны да ачык күзаллап эш итәргә тиеш бит.

Әдәбият алдында торган тагын да зуррак бурычларның берсе — укучыда авылга, аның кешеләренә һәм хезмәтенә ихтирам хисе тәрбияләү. Моның өчен барыннан да элек авылның бөтен җәмгыять һәм аерым шәхес өчен нигез дөнья булуын, игенче хезмәтенең олы мәгънәсен һәм шигърияттен тирәнрәк ачарга кирәк. Бу мәсьәләгә игътибар итүебезнең тагын бер сәбәбе шунда: соңгы вакытта безнең әсәрләрдә гомумән хезмәт поэзиясе, романтикасы җитәрлек чагылмый башлады. Мисал өчен, Г. Бәшировның «Намус» романындагы кебек, үз хезмәтеннән зур тәм табып, мавыгып һәм рухланып эшләгән геройлар бик күренми хәзер. Биредә, күрәсең, фән-техника прогрессының игенче хезмәтенә зур йогынты ясавы да билгеле бер роль уйный-дыр. Дөрестән дә, фән-техника казанышларына корылган хәзерге авыл хезмәтенең романтикасын, поэзиясен ачу бик кыенлашты. Шул уңайдан күренекле немец марксист-философы Э. Ионның кызыклы бер фикере хәтергә килә. Ул болай ди: «Хезмәтнең примитив формалары, фән-техника революциясе заманында алга киткән формалары белән чагыштырганда, сәнгатьчә җиңелрәк үзләштерелә. XIX йөз әдибе кырда эшләүче уракчыны чагыштырмача җиңелрәк сурәтли ала иде. Ә менә хәзер үзәк идарә пунктыннан 20 комбайн белән идарә итә торган диспетчер хезмәтен ничек бирергә?»[1]

Биредә тагын шундый бер мәсьәлә үзенә игътибарны таләп итә. Элегрәк авыл кешесе җир белән турыдан-туры мөнәсәбәттә була иде. Безнең көннәрдә исә җир белән

---

[1] Э. Ион. Проблемы культуры и культурная деятельность. М., 1969, 346 бит.

игенче арасына фән һәм техника килеп керде. Бүгенге авылда инде традицион игенчене табуы кыен. Аның эшен күп төрле техника белән идарә итә торган механизаторлар башкара. Аларга хәзер махсус белем алырга, техниканы үзләштерергә, кыскасы, күбрәк баш белән эш итәргә туры килә.

Фән-техника авылда торган саен зуррак роль уйнавы, бик әһәмиятле яңалыклар алып килүе белән бергә, кайчак негатив күренешләр дә тудыра. Әйтик, кайбер авыл кешеләренә, бигрәк тә яшьләргә, элекке крестьянга хас булган җиргә тирән хөрмәт һәм мәхәббәт җитенкерәми, алар җиргә һәм үз эшләренә ничектер ваемсызрак карый башлыйлар. Кыскасы, бүгенге авыл кешесенең җиргә һәм игенче хезмәтенә мөнәсәбәте шактый катлаулы мәсьәлә һәм ул язучыларның җитди игътибарын көтә.

Авылга багышланган әдәбиятның сәнгатьчә сыйфаты да һәр вакыттагыча игътибарны сорый. Әдипләр **нәрсә** турында язу белән **ничек** язу хакында бердәй кайгыртырга тиешләр. Кайчак шулай була: автор кызыклы гына мәсьәләләр күтәрә, әмма алар әсәрдә тиешле идея-эстетик яңгыраш ала алмыйлар. Мисалга табигатьне саклау мәсьәләсен генә алыйк. Бөтен совет әдәбиятын якыннан кызыксындырган бу мәсьәлә татар язучыларының да игътибарын торган саен ныграк җәлеп итә. Аларның бу өлкәдә кызыклы гына эзләнүләре һәм табышлары да бар. Гомумән алганда исә табигатьне саклау идеясенең безнең әдәбиятта әле бөтенсоюз укучысының дикъкатен җәлеп итәрлек дәрәҗәдә яңгыраганы юк. Бу кимчелек бигрәк тә прозага карый. Прозаикларыбызның бу теманы яктыртуда Ч. Айтматовның «Ак пароход», В. Астафьевның «Балык патша» повестьлары яки Б. Васильевның «Аккошларга атмагыз» романы кебек уңышларга ирешә алганнары юк әле. Эш монда үз фикереңне сәнгатьчә гәүдәләндерү өчен үтемле әдәби чаралар таба алмауга да, аны бары сөйләп бирү белән генә чикләнүгә дә кайтып кала. Искә алынган әсәрләр исә авторларның нәкъ менә мәсьәләгә художникларча караулары, образлы фикер йөртүләре белән аерылып торалар. Инде әйтелгәнчә, Ч. Айтматов әсәр идеясен ачу өчен мифка мөрәҗәгать итә һәм Ана болан легендасы ярдәмендә маралны үтерүнең безнең заманның аеруча кешелексез һәм җинаятьчел күренеше булуын ача. В. Астафьев повесте белән Б. Васильев романында да балык патша һәм аккош образлары зур идея-фәлсәфи яңгырашка ия булып торалар һәм автор фикерен зур көч белән ачарга булышалар.

Бу әсәрләрдә безнең язучылар өчен тагын бер гыйбрәтле момент бар. Эш шунда ки, безнең әсәрләрдә кайвакыт табигатьне сакларга чакыру төп максатка һәм үзмаксатка әйләнә. Ч. Айтматов, В. Астафьев һәм Б. Васильев әсәрләрендә исә табигатьне саклау өчен көрәш кеше өчен, аның кешелеклелеге өчен көрәш булып та алга баса. Һәм бу бик табигый хәл. Чөнки табигатькә мөнәсәбәт фән-техника революциясе заманы кешесенең мораль-политик йөзен, тормышта үз-үзен тотышын билгеле торган мөһим факторларның берсенә әверелде. Шул сәбәпле, табигать һәм кеше әдәбиятта үзара органик бәйләнештә каралырга тиешләр.

Кыскасы, хәзерге авылның фән-техника революциясе йогынтысында күзгә күренеп үзгәрә, катлаулана барган тормышына тирәнрәк үтеп керү, аның яңа актуаль мәсьәләләрен кыюрак күтәрү һәм зур идея-эстетик һәм фәлсәфи көч белән чагылдыру бу дөнья белән элек-электән якыннан кызыксынып килгән әдәбиятыбызның мөһим бурычларыннан берсе булып кала.

# ТАРИХЫБЫЗНЫҢ ЯҢА СӘХИФӘСЕ

Язучы Вакыйф Нуруллин әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Аның «Шинельсез солдатлар», «Күпер чыкканда», «Әгәр син булмасаң...» исемле повестьлары укучыларыбыз тарафыннан яратып кабул ителделәр. Әлеге әсәрләр вакытында әдәби тәнкыйть тарафыннан да уңай бәяләнде.

В. Нуруллин иҗаты бүген дә үсештә. Язучы эзләнә, таба. Нәтиҗәсе күз алдыбызда. Ул — «Яшьнәп үткән яшьлек» повесте. Әсәр Бөек Октябрьның 60 еллыгы уңае белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты.

«Яшьнәп үткән яшьлек» повестеның нигезенә дәһшәтле 1918—1919 еллардагы сыйнфый көрәш вакыйгалары салынган. Революциянең язмышы хәл ителгән еллар... Көрәшнең бер ягында коммунистлар һәм эшче отрядлары, авыл ярлылары торса, аларга баштанаяк коралланган акгвардиячеләр, авыл кулаклары һәм аларның ярченнәре каршы куела.

Әсәрнең төп геройлары (аларның байтагы реаль тормыштан алынган тарихи шәхесләр) революцияне саклап калу өчен барган көрәшкә үзләренең гомерләрен багышлаучылар. Өяз башкарма комитеты председателе Емельян Петрович Колегов, өяз ревком председателе Олег Николаевич Шапошников, Миңнулла кебек коммунистлар, легендар Василий Константинович Блюхер, Владимир Мартынович Азин, Камил Якуп әнә шул көрәшнең каһарманнары. Ак офицер Кошкарев, авыл советы председателе булып алган корткыч Шишков, Совет органнарына оялаган Соколов, милләтче Хәйрулла Хәйретдинов, ат карагы Чегән Гата, сатлык җан Михайлов һәм аларның ярченнәре исә бөтен көчләре белән совет властен юк итәргә, иске җәмгыятьне кире кайтарырга тырышучылар.

Гражданнар сугышы сыйнфый көрәшнең иң киеренке, иң югары формасы. Бу көрәштән бер генә сыйнфый катлау да читтә кала алмый. Язучы В. Нуруллин «Яшьнәп үткән яшьлек» повестенда ярлы катлаудан чыккан көрәшчеләрне үзәккә куя. Әсәрнең төп герое Миңнулла Гайсин революция өчен барган көрәшнең иң алгы сафында. Аңа әле нибары унсигез яшь. Ләкин Миңнулла, яшь булуына да карамастан, тормышның ачысын-төчесен татып өлгергән, чын мәгънәсендә җитлеккән көрәшче-коммунист. Миңнулла Гайсин кызылгвардиячеләр отряды командиры, өяз башкарма комитеты председателе урынбасары, гражданнар сугышы башлангач, данлыклы Азин дивизиясендә батальон командиры буларак та тасвирлана. Аның өчен революция — илнең киләчәге, бөтен фаҗигаләрдән котылу юлы, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерергә мөмкинлек бирә торган бердәнбер чара. Миңнулла нинди генә шартларда калмасын, бәхетле тормыш турында уйлаудан туктамый, үзенең матур киләчәк өчен көрәшүен изге эш итеп саный. Шуңа горурлана. Ак офицер Кошкарев үзе өметләнгән «якты киләчәк» турында сүз башлагач, Миңнулла «мин... үзем ышанган коммунистик киләчәкне күздә тотып» сөйләшәм, ди.

Әсәрдә сурәтләнгән һәр вакыйгага Миңнулла ярсып, давылланып килеп керә. Аңардан яшьлек дәрте, сафлык, матурлык бөркелә. Повестьта Миңнулла белән Зәйнәпнең бер-берсенә булган эчкерсез мәхәббәтләре дә үзенә генә хас серле, мавыктыргыч төс ала. Кызганычка каршы, язучы Зәйнәп турында озаклап сөйләүне кирәк тапмый, аның халыкны агарту өчен тырышып йөрүен әйтү белән генә чикләнә.

В. Нуруллин повесте гади халык вәкилләренең кулга мылтык алып контрреволюционерларга каршы көрәше Бөек Октябрь нәтиҗәсендә яуланган социалистик һәм демократик казанышларны саклауда нинди хәлиткеч әһәмияткә ия булуын бөтен тулылыгы белән аңларга ярдәм итә. Язучы бу хакыйкатьне сәнгать чаралары ярдәмендә тирән һәм ышандырырлык итеп күрсәтә алган. Бу уңайдан аеруча Сафиул-

ла агай образы, аның язмышы гыйбрәтле. Укучы аның белән гадәти булмаган шартларда очраша. Сафиулла агай, кулына ау мылтыгы тоткан килеш, элеккеге Сәйфи бай йортының (революциядән соң ул ярлылар комитеты карамагына тапшырыла) болдырында басып тора. Шунда алар Миңнулла белән сөйләшеп киталәр. Бактың исә, әле шушы көннәрдә генә Сәйфи бай малае Шакир «үзе белән тугыз-унлап солдат ияртеп кайткан» да әлеге йортта типтереп ята икән... Сафиулла агай күзе тонган Шакирдан качырып кызын күрше авылга илтеп куйгач, бай малае аның кулына корылмаган мылтык тоттырып, аягын чылбыр белән бәйләп (дөрес, укучы бу урында ясалмалылыкны тиз сизеп ала, Миңнулла Сафиулла агайны танып алу белән аның аягындагы чылбырны күреп алырга һәм сүзне нәкъ әнә шуннан башларга тиеш иде) куйган.

Язучы үз геройларын үсештә, хәрәкәттә сурәтли. Бу Сафиулла агай образын сурәтләүдә дә күренә. Моңа кадәр үз шәхси тормышын кайгыртучы булып кына күз алдына килгән Сафиулла агай әсәр барышында бөтенләй икенче ягы белән ачылып китә. Ул кызын бай малаена бирергә риза булмагач, Шакир: «Әгәр мин унга кадәр санаганчы кызыгызның кайда икәнен әйтмәсәгез — өегезгә ут төртәчәкмен», — дип кычкыра. Кешелеклеген югалткан «Шакир шырпы кабызып түбә саламына үрелгәч» Сафиулла агай үз йортының януыннан бигрәк, халык турында уйлый. «Акылыңа кил, малай актыгы, харап итмә авылны», — ди ул. Үз өен кайгыртудан бигрәк, кешеләр өчен борчылу аны хәлиткеч адым ясарга этәрә. Сафиулла агай «Шакир җәһилне» буып үтерә...

Повестьта революция дошманнарын сурәтләүгә дә зур урын бирелгән. Мулла малае, контрреволюционер, милләтче Хәйрулла Хәйретдинов образы язучының уңышы дияргә тулы хакыбыз бар. «Милләтне яклаган булып, дошман сүзен» сөйләп йөрүче бу бәндә, әсәр барышында төрле кыяфәтләргә кереп өлгерә. Беренче очрашуда ул «милли шура съезды карарларын гамәлгә ашыру артыннан» йөрүче булса, икенче очракта исә «аклар агенты» булып күз алдына баса һәм хәтта үзен коммунистлар партиясе члены дип тә таныптырга омтыла. Тик ни генә булмасын, ул хакыйкать алдында көчсез булып кала, җиңелә. Хәйрулланың үлеме — революция дошманнарының җиңелә баруын раслаучы мисал. Бер кесәсендә «Колчак армиясе офицеры кенәгәсе», икенчесендә «коммунистлар партиясе члены билеты» йөрткән мулла малае яңа тормыш төзүче көрәшчеләр тарафыннан тарих чүплегенә ташлана.

«Яшьнәп үткән яшьлек» повесте сюжет, композиция төзелеше ягыннан да үзенчәлекле әсәр. Ул революция дошманнарының тантана итүе белән башланып китә. Повесть азагында исә җиңү революция каһарманнары ягына күчә. Хәер, әсәр тукымасының болай төзелүе әдәбият өчен әллә ни яңалык түгел. Аның матур үрнәкләрен К. Тренев «Любовь Яровая», А. Серафимович «Тимер ташкын» әсәрләрендә биргәннәр иде инде. Язучы В. Нуруллин исә бу алымнан үзенчә файдалана.

«Яшьнәп үткән яшьлек» повестенда, мәсәлән, Миңнулла Гайсин әсәр башында акгвардиячеләргә әсир төшә, озак кына алар кул астында интегә. Геройны бу хәлгә куеп сурәтләү язучыга образның ныклы характерлы булуын, аның революцион эшкә чын күңелдән бирелгәнлеген ачарга мөмкинлек бирә. Җәзалаулар, янаулар, куркытулар геройның характерын сындырмый, киресенчә, ул тагын да ныгый, формалаша төшә.

«Яшьнәп үткән яшьлек» повестеның тагын бер күркәм ягы — аның документаль характерда булуында. Бу — архивларда эзләнү, Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы тарихына караган бик күп материалларны туплау, өйрәнү нәтиҗәсе.

Дөрес, язучы болардан җитәрлек файдаланган дип әйтеп булмый. Язучы әсәрдә 1918—1919 елларга бәйле тарихи телеграммалардан, төрле приказлардан, хәрби донесениеләрдән киң файдаланган булса, әсәрнең документаль булуы тагын да тирәнәя төшәр иде.

Повесть башка кимчелекләрдән дә азат түгел әле. Язучы, мәсәлән, Миңнулла турында сөйләү белән артык мавыгып китә һәм кайбер геройларына игътибар биреп җиткерми. Мисалга Миңнулланың олаучысы Заһит абзыйны гына алыйк. Ул татар крестьянының типик бер вәкиле. Һәм бердәнбер байлыгы булган арык аты өчен барысын да эшләргә әзер, тик атыннан гына аермасыннар. Шуның аркасында Заһит абзый Миңнулла белән бергә акгвардиячеләр кулына эләгә. Шактый кыен хәлләргә очрый. Бу кадәресен язучы җентекләп сөйли. Ләкин Миңнулладан

аерылгач ул нишли? Заһит абзыйның аннан соңгы язмышы укучыга табышмак булып кала. Шушы ук кимчелек Миңнулланың абыйсы Зәйнулла образын сурәтләүдә дә кабатлана.

Язучы Миңнулланың инанган көрәшче — коммунист булып җитешүен җентекләп сөйләп торуны да кирәк тапмый. Алар әсәрдә информацион төстә генә әйтелеп узыла. Бу үз чиратында геройның нинди җирлектә үсеп җитүен, чыныгуын тулысынча күз алдына китерергә комачаулык итә, әсәрнең ышандыру көчен киметә.

Персонажлар теле дә бәхәсле, минемчә. Чөнки әсәр геройларының барысы да диярлек бүгенге татар телебездә сөйләшә. Алар теленнән шул заман сулышы, революцион рух сизелми диярлек.

«Яшьнәп үткән яшьлек» — киләчәккә, яшәүгә, яшьлеккә мәхәббәт белән сугарылган, оптимистик рухта язылган әсәр. Повестьта сурәтләнгән Миңнулла, Зәйнәп, Сафиулла, Касыйм һәм башка бик күпләр революцияне яклау юлында бер сафка басып зур җиңү яулыйлар.

Әсәр «Яшьнәп үткән яшьлек» дип аталган. Бу турыдан-туры Миңнулла яшьлеге турында сөйли кебек. Миңнуллалар узган юл давыллы, данлыклы. Алар яшьлеге чын мәгънәсендә яшьнәп үткән яшьлек, алар тормышы яшьләргә үрнәк булырлык. Язучы Вакыйф Нуруллин укучыларны әнә шуңа ышандыра. Әсәрнең ышандыру көче нык һәм нигезле.

**РАФИС ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.**

# ӘДӘБИЯТНЫҢ ЯШӘҮ КӨЧЕ ТУРЫНДА

Флорид Әгъзәмов исеме матбугат битләрендә еш күренә. Әдәби-публицистик мәкаләләре бүгенге әдәбият һәм журналистиканың өлгергән проблемаларына багышланган булыр, тәнкыйть чыгышларында һәм рецензияләрендә вакыйга булырлык әсәрләр һәм китаплар турында фикер йөртер...

Менә, ниһаять, бу авторның кайбер мәкаләләрен һәм рецензияләрен үз эченә алган аерым җыентык[1] дөнья күрде. Ул тематик принциптан чыгып төзелгән. Тәнкыйтьче моңарчы барлык язганнарын бергә туплап укучыга бирү максатын куймаган (гәрчә монысы да бик табигый һәм файдалы булыр иде), ә зур әһәмияткә ия берничә проблемага багышланган хезмәткә генә тукталган. Алар совет әдәбиятының һәм сәнгатенең нигез принципларын яктырталар. Үзәктә әдәбият һәм әдәби тәнкыйтьнең партиялелеге һәм халыкчанлыгы кебек, художество иҗатының алга үсешен тәэмин итә торган проблемалар, милли үзенчәлек һәм интернационализмның, идеялелек һәм сәнгатьчәлекнең диалектик берлеге кебек мәсьәләләр ята.

Берәү өчен дә яңалык түгел: татар әдәбияты фәненә һәм әдәби тәнкыйтенә бүгенге көндә нәкъ менә теоретик эзләнүләргә һәм гомумиләштерүләргә байлык җитенкерәми. Сәләтле галимнәребез һәм тәнкыйтьчеләребез бар, аерым уңышларыбыз да юк түгел. Ләкин үзәк теоретик мәсьәләләр буенча без әлегә бөтенсоюз әдәби-теоретик фикереннән калышыбрак барабыз. Шуңа күрә дә әдәбиятның төп идеологик, философик һәм методологик принципларына кагылышлы хезмәтләрнең барлыкка килүен һәр яктан хуплап каршы алырга кирәк.

Дөрес, бу җыентыгы белән Ф. Әгъзәмов әллә ниткән яңа теоретик ачышлар ясаган дисәк, хакыйкатьтән читләшкән булыр идек. Аның хезмәтләре, аерым алганда, бу китапка кертелгәннәре — марксизм-ленинизмның әдәбият һәм сәнгать турындагы өйрәтмәләрен татар әдәбиятына карата файдалану һәм куллану турында. Аларда аерым положениеләрне конкрет әдәби иҗат фактлары мисалында аңлатып бирү бар. Тулаем алганда, җыентык шул яктан әһәмиятле һәм кирәкле.

Автор әдәбиятның нигез ташларын тәшкил иткән принциплар — партиялелек һәм халыкчанлыкны аңлауның төп юллары турында сөйли. Болар турында һәм әдәбиятның сыйнфыйлыгы, иҗат ирегә һәм язучының, гомумән, иҗатчының җаваплылыгы мәсьәләләрен бәян иткәндә, ул, әлбәттә, Ленин тәгълиматына, аерым алганда, аның

---

[1] Флорид Әгъзәмов. Яшәү көче (әдәби-публицистик мәкаләләр). Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел, 120 бит.

«Партия оешмасы һәм партияле әдәбият» исемле хезмәтенә таяна. Бөек юлбашчының бу әсәре язылуга менә инде җиде дистәдән артык ел үтеп китте, ә аның актуальлеге, фәнни һәм практик кыйммәте кимеми генә түгел, торган саен арта бара. Кат-кат укыган һәм өйрәнгән саен андагы фикер тирәнлегенең яңа катламнары ачыла. Китапны ачып җибәргән «Нигез ташы» дип аталган мәкаләсендә Ф. Әгъзәмов әдәбиятның коммунистик партиялелеге принцибын менә шул даһи хезмәткә таянып аңлата. Әдәбият һәм сәнгатьнең партиялелеге мәсьәләсе үзенең асыл мәгънәсен һичкайчан җуймады һәм җуймаячак. Бу принципның бүгенге художество практикасында ни дәрәҗәдә мөһим роль уйнавын татар совет әдәбияты мисалында да ачык күрергә мөмкин. Партиялелек төгълиматындагы объектив һәм субъектив моментларны тирән итеп, диалектик берлегендә төшенү, аларны һичбер вакыт хәтердән чыгармау әдәби процессның дөрес юлдан һәм тиешле темплар белән үсүенә ярдәм итә.

Монда авторның бер мәсьәләгә ныклы игътибар итүенә аерым тукталып, аңар басым ясап үтәргә кирәк. Ул да булса — әдәбият һәм сәнгать үсеше өчен партия политикасының ни кадәрле зарури булуын аңлату. Иҗат өлкәсендә дә партия билгеләгән юл тормышның объектив закончалыкларын фәнни өйрәнеп, шуларга таянып эшләнә, ди автор. Шуңа күрә дә партиянең күрсәтмәләре, әдәбият һәм сәнгать буенча кабул иткән карарлары һәм башка документлары үзләренең тормышчан нигезләре белән, практик әһәмиятләре белән аерылып торалар.

Җыентыкка кертелгән мәкаләләрнең башкаларында да язучылар һәм башка сәнгатькярләр иҗатының төп мәсьәләләре игътибар үзәгендә тора. Мәсәлән, «Иҗат ирege һәм җаваплылык» дип аталган мәкаләнең исеме үк шул турыда сөйли. Монда сүз художникның үз иҗатын аңлау принциплары, иҗат ирege һәм гражданлык бурычы кебек төшенчәләрнең үзара тыгыз мөнәсәбәте турында бара.

«Дуслыкны байрак итеп» дип исемләнгән мәкалә теманы төрле яклап ачуы белән, үзендә җирле материалның киң һәм урынлы файдаланылуы белән матур тәэсир калдыра. Монда тәнкыйтьченең игътибар үзәгендә — әдәбиятта дуслык темасы, аны өйрәнү һәм чагылдыруда ирешелгән уңышлар һәм аерым кимчелекләр. Төп положенияләрне раслау өчен автор совет әдәбияты фәне ирешкән казанышлар белән беррә, үз әдәбиятыбыз мисалларыннан да, аның күренекле вәкилләре, әйтик, Г. Ибраһимов кебек какшамас авторитетларның карашлары һәм фикерләреннән дә киң файдалана. Тема төрле яклап, тәфсилле ачыла. Мәсьәләне киң алып, төрле аспектларында карау нәтиҗәсендә бу өлкәдә татар әдәбияты фәнендә әлегә җитешмәгән яисә йомшаграк хәлдә торган урыннарга да игътибар юнәлтелә. Мәсәлән, әдәби багланышларны комплекслы өйрәнү турындагы, әдәбиятта җанландырылган башка милләт вәкилләре образларын халыклар дуслыгы проблемасы яктылыгында өйрәнү ихтыяҗы хакындагы теләк һәм тәнкыйть фикерләре, һичшиксез, дөрес, урынлы һәм актуаль.

Шулай да, авторның төп положениеләре һәм фикерләре белән килешкән хәлдә дә, бер нәрсәгә аерым тукталып үтәсе килә. Интернационализмга каршы эш йөрткән Г. Исхакый, Ф. Туктаров, С. Максуди кебек буржуаз милләтчеләр монда урынлы тәнкыйтьләнә. Шулай ук милли культура мәсьәләләрендә суллык ялгышлары ясаган умырткасыз «марксист» С. Атнагулов кебекләрнең карашлары да дөрес ачыла (64 бит). Ләкин шулар янына ук бер таккага Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим кебек, татар әдәбияты фәненә һәм тарихына мөһим өлеш керткән галим һәм язучыларны да бастыруны, йомшак кына итеп әйткәндә, кызулык күрсәтү дип карарга кирәк. Әйе, бу ике галим марксизмга килүдә каршылыклы юл үттеләр, аларның ялгышларына да күз йомарга кирәкми. Ләкин аларны бер селтәнү белән юкка чыгарып атуны да мәсьәләне фәнни карау, аңар объектив якын килү дип әйтеп булмас. Ф. Әгъзәмов язганча, аларны шулай тулаем дуслыкка каршы позициягә бастырып булырмы икән? Ул очракта бу авторларның татар әдәбиятын рус телендә дә пропагандалауларын ничек аңлатырга?! Бигрәк тә Г. Гобәйдуллинның әзербәйҗан, үзбәк һ. б. халыклар тарихын өйрәнүгә керткән өлешен кая куябыз? Мәсьәләне бөтен каршылыгында, бөтен буена алып өйрәнмичә торып, тарихи шәхесләргә әндый ярлыклар ябыштырудан,— ә инде тискәре мөһер сугудан бигрәк тә,— сак булырга кирәк. Тарихи шәхесләрнең, үткәндәге галим һәм язучыларның эшчәнлеген бөтен тулылыгында һәм тарихи перспективасында алып караганда гына аларның

иҗатына объектив бәя бирергә мөмкин. Мәсәлән, Г. Ибраһимов исемендәге институтта Г. Гобәйдуллинның тууына 90 ел тулуга багышлап 1977 елның декабрендә уздырылган фәнни киңәшмә бу галим һәм язучының әдәбиятыбыз һәм тарихыбызга кертеш өлешен бәяләүдә билгеле бер адым булды. Безгә калса, Г. Гобәйдуллин халыклар дуслыгы мәсьәләсе уңаеннан андый тискәре бәяне күтәреп йөрергә һич кенә дә тиеш түгел.

Шулай ук авторның татар әдәбиятына Шәрык әдәбиятларының йогынтысы хакындагы хезмәтләр бары тик соңгы вакытларда гына күренә башлады дигән фикере дә (55 бит) бәхәс уята. Кыскасы, Ф. Әгъзәмов үзенең бөтен чыгышларында, барлык хезмәтләрендә культура мирасына карата сак һәм игътибарлы мөнәсәбәт кирәклеген яклап та, югарыда әйтелгән аерым мисалларда хаталык күрсәткән.

Ләкин, куанычка каршы, мондый кимчелекләр сүз бара торган китапта башка очрамый.

Ф. Әгъзәмов каләменең көчен һәм мөмкинлекләрен күрсәтү ягыннан җыентыктагы «Әдәби тәнкыйть һәм вакытлы матбугат» дип аталган мәкалә аеруча характерлы. Бирегә инде автор чын мәгънәсендә үз стихиясендә: яхшы һәм тәҗрибәле журналист буларак та, нечкә зәвыклы тәнкыйтьче буларак та ул белеп, материалдан иркен файдаланып яза. Монда аның күзәтүләре үткен, гомумиләштерүләре ышандырырлык. Әдәби тәнкыйтьне һәм гомумән художество иҗатын үстерүдә вакытлы матбугатның тоткан урынын автор тулы ача. «Җәмәгатьчелек фикерен гәүдәләндерүче һәм формалаштыручы, аның аңына йогынты ясаучы буларак матбугат иҗтимагый тормышның барлык сфераларын, шул җөмләдән художество культурасы өлкәсен идарә итүгә дә актив катнаша» (80 бит). Бусы — авторның төп темасы. Шуны ул Татарстан матбугаты һәм әдәбияты мисалында раслый. Әдәби тәнкыйтьнең кайсы тармаклары һәм формалары нинди хәлдә тора, аларның үзенчәлеге, алар алдындагы бурычлар, җиңеп үтәсе кыенлыклар һ. б. — бу мәсьәләләр дәлилле дә, кызыклы да ачыла. Шуңа күрә дә авторның бүгенге әдәби тәнкыйтебездә урын алган кимчелекләрне конкрет тотып күрсәтүе бик тә ышандырырлык яңгырый.

Тәнкыйтьченең иҗади анализдагы көче «Заман сулышын тоеп» һәм «Тормышчанмы?» исемле рецензияләрендә дә әйбәт чагыла. Беренчесе — Хәсән Хәйринең «Иҗат чишмәләре» дигән, икенчесе — Фарваз Миңнуллинның «Якты юллар» дип аталган мәкаләләр җыентыклары турында. Боларда югарыда исемнәре аталган авторларның үзенчәлекләре, алар ирешкән казанышлар ачык һәм аңлаешлы итеп күрсәтелә.

Ниһаять, җыентыкның уңышлы якларыннан дип автор теленең шактый төзек, аңлаешлы һәм гади булуын әйтеп китәргә кирәк. Ф. Әгъзәмов шактый катлаулы төшенчәләр, специфик мәсьәләләр турында сүз йөртә, әмма аларны укучыларга җиңел барып җитәрлек итеп яза белә. Монда, әлбәттә, нәшрият редакторы Яхъя Халитовның да роле зур. Әмма тулаем әйбәт язылган һәм яхшы редакцияләнгән бу хезмәттә дә әле кайбер чатак һәм авыр аңлаешлы җөмләләр очраштыргалый. Берике мисал: «Нәтиҗәдә әсәр колачлырак, реалистиграк, тормышчанрак булып әверелә, чөнки анда аңлы рәвештә (?) татар тормышында гаять зур роль уйнаган шул чорның йөзен билгеләүче тенденцияләр һәм закончалыклар сәнгатьчә чагылыш таба» (17 бит). «Тәнкыйтьченең Г. Әпсәләмов иҗатын тикшергән мәкаләләре аеруча игътибарга лаек. Ул арада (?) әдәбиятыбызда иң актив эшләп килүче әдипнең иҗат принципларын һәм алымнарын, ул алып килгән яңалыкны, аның индивидуаль йөзен әйбәт ачып бирә» (104 бит).

Дөрес, мондый җөмләләр китапта бик аз. Һәм язу теле төзек, грамоталы булган Ф. Әгъзәмовның тәҗрибәле редактор Я. Халитов редакцияләгән китабы уңае белән бу турыда аерым тукталмаска да мөмкин иде. Ләкин минем рецензия кысаларын беркадәр киңәйтәсем килде. Без еш кына нәшрият хезмәткәрләренең, аерым алганда редакторларның, гаять авыр һәм җаваплы вазифасын күреп һәм укучыга да күрсәтеп бирә белмибез. Чыннан да, алар бик файдалы һәм еш кына четерекле эш башкаралар. Югарыдагы ике мисал гына да шуны күрсәтсә кирәк. Китапның матур булып, әйбәт булып чыгуына җаваплы кешеләр шактый. Мәсәлән, сүз алып барыла торган китап тышкы кыяфәте һәм формасы белән уңай тәэсир калдыра. Димәк, рәссам З. Хөсәенов төп максатына ирешкән, редактор да аның алдына тиешле зәвык белән таләп куя белгән. Ә менә китапның техник яктан редакцияләнүендә эш ахырына кадәр җиткерелмәгән. Сүз китапның икенче өлешен—«Әдәби тән-

кыйтьнең кайбер принциплары» дигән бүлекне аерып кую турында бара. Хәзергә, хәрефләрнең зурлыгы һәм формасы дөрес сайланмау аркасында булса кирәк, бүлеиеш аңлаешсыз, ачык түгел. Хәлбуки, авторның теләк-фикере һәм планы буенча ул бик оригиналь һәм урынлы булырга тиеш иде. Гәрчә китап аерым мәкаләләр һәм рецензияләрдән торса да, аларның эчке берлеге, эчке мәгънәви бәйләнеше бар һәм техник редактор шуны укучыга аңлаешлы итеп җиткерергә җаваплы иде.

Кабатлап әйтәм, мондый чатаклыклар гомумән китапның уңай йогынтысын юкка чыгара ала торган түгелләр. Ләкин аларга игътибар итәргә кирәк, ә без еш кына нәшрият хезмәткәрләренең бу эшләрен бәяләп җиткермибез. Хәлбуки, бу табигый түгел, дөрес түгел.

Тулаем алганда исә бер сүз: автор Ф. Әгъзәмов һәм нәшрият укучыга кирәкле һәм файдалы китап бүләк иттеләр.

**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# БЕРДӘМ ГАИЛӘДӘ

Илебезнең яңа Төп Законы — СССР Конституциясе кабул ителү һәр совет кешесендә зур горурлык хисе, рухи күтәренкелек һәм илһам тудырды.

Бу олы документта җәмгыятебез строе, политик нигезләре, дәүләт һәм шәхес кебек мәсьәләләр киң яктыртылу белән бергә, СССРның милли-дәүләт төзелешенә, шул җөмләдән милләтләр үсешенә дә, зур әһәмият бирелә. Милләтләрнең тигез хокуклылыгы, һәрьяклап үсү, чәчәк ату һәм үзара якынаю процесслары марксизм-ленинизм тәгълиматы нигезендә аңлатылып, бу процессларның яңа тарихи шартларда үсеше күрсәтелә. «Барлык милләт һәм халыклар хезмәт ияләренең сугышчан союзы өчен көрәшеп, партия, В. И. Ленин һәр вакыт милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын, аларның тулы һәм чыннан да тигез хокуклы булуларын яклады,— диде иптәш Л. И. Брежнев, — һәм Октябрьның җиңүе бер үк вакытта милли азатлык өчен көрәштәге җиңү дә булды».

Милли мәсьәлә һәр вакыт партиябезнең игътибар үзәгендә булды. Шунлыктан бездә милли мәсьәләгә кагылышлы фәнни хезмәтләрнең әледән-әле дөньяга чыгып торуы бик табигый. Бу җәһәттән Казан дәүләт университеты доценты Риф Галәветдинович Хәйретдинов монографиясе[1] дә игътибарга лаек. 1917—1920 елларда Идел һәм Урал буенда милли мәсьәләне хәл итү өлкәсендә ленинчыл программаны тормышка ашыруда партиябез башкарган гаять зур эшкә төпле анализ ясала әлеге хезмәттә. Аның марксистик-ленинчыл методология, В. И. Ленин хезмәтләре, партия һәм хөкүмәтебез карарлары, күрсәтмәләре нигезендә язылуын да ассызыклап әйтергә кирәк.

Автор бу өлкәдә инде байтак еллардан бирле уңышлы гына эшләп килә. Әлеге хезмәтендә дә ул Мәскәү, Ленинград, Казан, Уфа, Оренбург, Пермь, Ульяновск, Куйбышев, Саратов, Астрахань партия һәм дәүләт архивларыннан табылган бай фактик материалга таянып эш итә. КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институтының Партия Үзәк архивыннан алынган материалларның исә әһәмияте аеруча зур. Аларда ленинчыл милли программаны тормышка ашыруда, РКП(б)ның милли секцияләрен төзүдә һәм аларның эшен җайга салуда партиябез күргән чаралар яктыртыла. Риф Хәйретдинов шул чорда чыгып килгән көндәлек матбугат материалларына мөрәҗәгать итә, аларга фәнни күзлектән чыгып бәя бирә.

Автор бу өлкәдә эшләүче башка галимнәрнең хезмәтләренә дә җитди һәм тирән анализ ясый, аларның уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтә, тарихчылар игътибарыннан читтә калган байтак моментларны ачыклый. Болар бөтенесе Р. Г. Хәйретдиновның милли мәсьәләне тирән үзләштерүен һәм тарих фәненең бу өлкәсендә киң колачлы белгеч булуын раслый.

Китап күләме белән шактый зур. Анда халыклар дуслыгының тарихи нигезе, Идел һәм Урал буе хезмәт ияләрен интернациональ яктан туплау, хаким сыйныфларны бәреп төшерү өчен көрәшкә тарту өлкәсендә большевиклар башкарган эш тәфсилләп яктыртыла. Революция җиңгәннән соң Коммунистлар партиясенең бу регионда

[1] Р. Г. Хайрутдинов. Осуществление Коммунистической партией ленинской программы по национальному вопросу в 1917—1920 гг. Издательство КГУ, 1976.

ленинчыл милли политиканы нинди юллар һәм чаралар белән тормышка ашыруы күрсәтелә, партия һәм дәүләт төзелеше мәсьәләләренә киң урын бирелә. Шулай ук автор гражданнар сугышы елларында милли хәрби частьлар төзүне, аларда партия оешмалары алып барган күп кырлы эшне, хәрби һәм политик кадрлар әзерләү мәсьәләсен җентекләп тасвирлый, хуҗалык һәм культура төзелешенә зур игътибар бирә.

Большевиклар партиясе революциягә кадәр үк милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы, аларның рухи һәм социаль-политик тигезлеге өчен көрәшеп, революциядән соң ленинчыл милли программаны киң колач белән тормышка ашыру эшенә тотынды. Бу җәһәттән социалистик революция җиңеп чыкканнан соң ук В. И. Ленин күрсәтмәләре нигезендә һәм аның турыдан-туры катнашы белән Эчке Россия мөселманнары эше буенча комиссариат һәм чуваш, мари, удмурт, мордва бүлекләре төзелүен әйтергә кирәк. Барлык милләт һәм халыклар хезмәт ияләренең тигез хокуклылыгы, Совет властеның тәүге актларыннан берсендә үк, («Россия халыкларының хокуклар декларациясе»ндә) закон тәртибендә беркетелде.

Халык Комиссарлары Советының «Россиянең һәм Көнчыгышның барлык мөселман хезмәт ияләренә» 1917 ел, 20 ноябрь мөрәҗәгате хезмәт халкын Совет власте тирәсенә туплауда, аларның милли тигез хокуклылыкны аңлауларында аеруча зур роль уйнады. Милләтләр халык комиссариаты каршында В. И. Ленин инициативасы белән комиссариатлар төзелү аеруча уңай нәтиҗәләр бирде. Мәсәлән, автор 1918 елның январь аенда Үзәк мөселман комиссариаты төзелүгә махсус тукталып, аның эшчәнлегенең тулы картинасын сурәтли. Шул үк вакытта урыннарда милли комиссариатларның бүлекләре дә төзелә, аларда коммунистлар хезмәт ияләрен политик яктан тәрбияләүдә гаять зур эш алып баралар. Югарыда әйтелгән фикерне раслау өчен Саратов шәһәрендә Б. Юскаев җитәкчелегендәге мөселман большевистик группасы эшчәнлеген мисал итеп китерергә мөмкин.

Р. Г. Хәйретдинов китабын күздән кичергәндә РКП(б)ның милли секцияләренә дә аерым тукталып үтәсе килә. Автор татар мөселман социалистлары комитеты һәм чувашлардагы сул социалистлар комитеты эшенә дөрес позициядә торып бәя бирә. Милли коммунистик партияләр төзүнең ялгыш юлга этәрү мөмкинлеген билгеләп, автор ул чорда аерым милли секцияләр оештыруның максатка туры килүен ассызыклап уза. 1918 ел ахырында, мәсәлән, большевиклар партиясенең Казан губерна комитеты каршында РКП(б)ның мөселман (татар), чуваш, мари, удмурт, латыш секцияләре оештырыла. Әйтергә кирәк, Уфа, Оренбург, Самара, Сембер, Саратов, Астрахань, Пермь һ. б. губерналарда да шундый секцияләр төзелеп, алар хезмәт ияләре арасында марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалауда, бөек Ленин партиясе тирәсенә туплауда, яңа социалистик җәмгыять кору өчен көрәштә хәлиткеч роль уйнадылар. Аларның тирән йогынтысы астында большевиклар партиясе сафына керүчеләр саны сизелерлек арта. Әйтик, революциягә кадәр марилар арасында нибары өч партия члены булса, 1920 елның октябрена инде бу сан 605 кешегә җитә.

Автор элекке патша Россиясендә изелүгә дучар булган милләт һәм халыкларның революциядән соңгы язмышын күрсәтүгә дә игътибар бирә. Бу мәсьәлә бүген дә үзенең актуальлеген югалтмый. Милли мәсьәләнең илебездә әнә шулай уңай хәл ителүе исә капитализм илләре, шулай ук милли азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшүче Азия, Африка һәм Латин Америкасы халыкларына үрнәк булып хезмәт итә.

Идел һәм Урал буе халыкларының дәүләт төзелеше мәсьәләсе илебез өчен иң авыр һәм киеренке вакытта, гражданнар сугышы һәм чит ил интервентларына каршы көрәш чорында хәл ителде. Мәгълүм булганча, Идел һәм Урал буе ике тапкыр дошман чолганышында калып, яшь Совет республикасының язмышы хәл ителгән көрәш учагы булды. Шундый җаваплы һәм киеренке бер чорда җирле хезмәт ияләренең иң зур күпчелеге Совет властен яклап чыга, революция казанышларын саклап калу өчен кулына корал ала, милли хәрби частьларга кушыла. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе күренекле большевиклар М. Вахитов, һ. Маликов, К. Якуб, А. Алмаев һ. б. җитәкчелегендә хезмәт халкын эчке һәм тышкы реакциягә каршы көрәшкә туплауда гаять зур эш алып бара. Кызыл Армиянең милли частьларын оештыруга турыдан-туры РКП(б) Үзәк Комитеты җитәкчелек итә. Аерым алганда, Мәскәүдә ике татар-башкорт батальоны, Казанда Беренче мөселман социалистик полкы, Ас-

траханьда татар полкы, Уфа, Чиләбе, Сызраньда сигез татар-башкорт батальоны, Пермьда татар Урал кызыл коммунистлар батальоны, Аерым удар татар батальоны, Богырыслан аерым ирекле удар татар батальоны, Казанда Беренче татар җиңел артиллерия дивизиясе, Запастагы татар батальоны, Беренче һәм Икенче татар бригадалары оештырыла. Бу исемлеккә шулай ук башкорт полкларын, кавалерия частьларын, чуваш, мари хәрби отрядларын да өстәсәк, Идел һәм Урал буенда Кызыл Армиянең нинди зур көчләре туплануын күрү кыен булмас. Әлеге фактлар изелгән милләт һәм халык вәкилләренең Совет властен кулларына корал тотып яклаулары һәм ленинчыл милли программаны тормышка ашыруга гаять зур өлеш кертүләрен ачыктан-ачык раслап тора. Болар бөтенесе буржуаз тарихчыларның, янәсе рус булмаган халыклар Совет дәүләтен яклап чыкмадылар, көрәштән читтә тордылар, дигән ялган уйдырмаларын тулысынча фаш итә.

Автор хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, Коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасы әнә шундый катлаулы шартларда тормышка ашырылды, авыр сынау елларында төрле милләт һәм халыклар хезмәт ияләренең интернациональ дуслыгы ныгыды.

Шунысы аеруча куанычлы, Р. Хәйретдинов конкрет мисаллар ярдәмендә Идел һәм Урал буенда автономияле республикалар, өлкәләр төзелү эшен, аның катлаулы һәм үзенчәлекле якларын, бу өлкәдә Коммунистлар партиясе үткәргән дөрес политик линияне ышандырырлык итеп күрсәтә алган.

Әлеге хезмәттә халык бәхете өчен көрәшкән бик күп кешеләрнең исемнәре беренче тапкыр телгә алына. Чыннан да, Бөек Октябрь социалистик революциясендә һәм гражданнар сугышында актив катнашкан батырларны эзләп табу, аларның тормыш һәм көрәш юлын яктырту, бүгенге яшь буынны алар үрнәгендә тәрбияләү — һәркемнең изге бурычы. Мәсәлән, исемнәре аз билгеле булган Хафиз Сәйфи, Шакир Измайлов, Саттар Еникеев, Хөсәен Тарпищев, Сәйфи Усманов, Ибраһим Ганиев, Хөсәен Кумачков, Әхмәт Умеров, Сәгъдия Булатова, Каюм Гобәйдуллин, Билал Ишкенин, Сәнә Сафиуллина кебек революция каһарманнары белән танышу бүгенге укучы өчен файдалы һәм кызыклы да булырга тиеш.

Бер үк вакытта Р. Г. Хәйретдинов, яңа материалларга таянып, Астраханьнан Урта Иделгә кадәр сузылган гаять зур территориядә культура-агарту эшенең куелышына тирән анализ ясый, бу өлкәдә Коммунистлар партиясе башкарган олы хезмәтне тарихчы буларак күздән үткәрә. Авторның мәгариф, матбугат, музыка, сынлы сәнгать һәм театр өлкәсенә караган материаллары аеруча кызыксыну уята. Яңа мәктәпләр ачу, укый-яза белмәүчелекне бетерү, элек изелүгә дучар булган халыкларның культура дәрәҗәсен тиз арада күтәрү, милли укытучы кадрлар өчен көрәш бу чорда бигрәк тә зур әһәмияткә ия була.

Китапта милли сәнгать эшлеклеләре арасында партия йогынтысын көчәйтү һәм яшь партия кадрлары тәрбияләү мәсьәләсен өйрәнүгә дә зур урын бирелгән. Автор бу җаваплы һәм катлаулы эшнең барышын киң планда сурәтли. Революциядән соң театр труппаларының эшчәнлеген яңача үзгәртеп кору, аларның репертуарын яңа эчтәлек белән баету, заман рухына җавап бирә алырлык сәхнә әсәрләре иҗат итү бездә, нигездә, хәл ителде дигән нәтиҗә ясала хезмәттә.

1903 елда Мәскәү консерваториясен уңышлы тәмамлаганнан соң, Саратов консерваториясендә эшләп, татар-башкорт көйләре турында фәнни хезмәтләр бастырып чыгарган музыка белгече профессор Мансур Солтанов хакындагы яңа материаллар да зур кызыксыну уята.

Инде Риф Хәйретдинов хезмәтенең кайбер кимчелекләрен дә күрсәтеп узыйк. Автор Идел һәм Урал буе территориясендә милли мәсьәләнең хәл ителүен яктыртса да, ни өчендер Калмык автономияле өлкәсе турында эндәшмичә узган. Бу уңайдан 1920 елда Калмык автономияле өлкәсе оештырылуы турында кабул ителгән декретны искә төшерергә мөмкин. Автор милли мәсьәләнең хәл ителүен яктырту белән бергәттән, милли өлкә һәм республикаларның экономик үсешенә дә игътибар иткән булса, мөгаен, китап тагын да отар иде.

Р. Г. Хәйретдинов китабы, Идел һәм Урал буе халыкларының революциядән соңгы тарихын өйрәнүдә мөһим хезмәт буларак, һичшиксез, укучылар тарафыннан җылы каршы алыныр дип ышанасы килә.

**Марат МӨЛЕКОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ШЕРШЕЛЬ КӨНДӘЛЕГЕ

Бу язманың авторы Александр Михеев — Казан кешесе. Мәскәү чит телләр институтын тәмамлап, ул Алжирда эшли. Якташыбыз көндәлек алып бара икән. Укучыларыбыз игътибарына шул көндәлектән бер өзек тәкъдим итәбез.

Без Алжир Халык Демократиясе Республикасына очабыз. Без дигәнем — Мәскәү һәм Ленинградтан, Новосибирск һәм Казаннан, Курск һәм Әстерханнан төрле хезмәт ияләре: геологлар, врачлар, нефтьчеләр һәм башка һөнәр белгечләре — алжирлыларга ярдәм итү теләге белән ерак юлга чыккан совет кешеләре...

Белградта һәм Будапештта кыска гына вакытта тукталышлардан соң Алжир шәһәренә юнәләбез. Мөлаем стюардесса барыбызга да француз һәм гарәп телләрендә сораулар язылган бланк кәгазе өләшеп чыкты да аны тутырырга кушты. Без, хезмәттәшем белән икәүләп, җавапларны гарәп телендә яздык, чөнки республика хөкүмәтенең илне гарәпләштерүгә табан юнәлеш алганлыгын белә идек.

Менә безнең самолет Дар-Эль-Байда аэропортына килеп тә төште. Таможня күзәтчеләре тикшерүен узабыз: паспортларыбызны һәм гарәп телендә тутырылган илгә керү турындагы бланк кәгазьләрен тапшырабыз. Әмма дежурный аларны безгә кире кайтарып бирә һәм француз телендә язарга куша. Без киреләнәбез, гарәпчә тутырылган документның да шул ук көчкә ия булуын расларга тырышабыз. Шулай тарткалаша торгач, дежурныйның гарәпчә белмәве ачыклана. Безнең үҗәтлекне җиңә алмагач, ул бланк кәгазьләрен үзе французча тутырырга мәҗбүр була.

Бу мәшәкатьләрдән котылып, залга кергәч тә карашларыбыз стенд-әлифбага төшә. Анда гарәп әлифбасының беренче өч хәрефе: «әлиф», «би», «ти» язылган. Француз һәм гарәп телләрендә язылган белдерүләр, белешмәләр күзгә ташлана.

Әйберләребезне әйләнмә конвейердан алабыз. Безгә ярдәмгә носильщик килеп өлгерә. Исәнләшәбез. Гарәпчә сөйләшүебезне ишетеп, ул елмая, һәм кайдан икәнлегебезне сорагач, чемоданнарыбызга ниндидер значок беркетеп, аларны залдан чыгарышып куя.

Менә без аэропорт каршындагы мәйданда басып торабыз. Без борынгы Алжир җирендә, азат дәүләт территориясендә. Хәтердә шундый саннар яңара: халкы — 17 миллион, бәйсезлек яулап алган елы — 1962, шул ук елда СССР белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырыла.

Берничә сәгатьтән инде без Урта диңгез буендагы Шершель исемле кечкенә генә шәһәрдә идек. Биредә безгә берничә ай дәвамында булырга туры киләчәк.

Алжир Мәгъриπнең башка илләреннән борынгы һәйкәлләр күплеге белән аерылып тора. Һәр шәһәрдә, авылда кешеләрне әлегәчә дулкынландыра торган борынгы финикия, рим, ислам цивилизациясе эзләре сакланган. Беркөнне шәһәр белән танышып йөргәндә аның тирәсендә рим хәрабәләренең музейларда күрелгән фоторәсемнәренә охшаган бер йорт игътибарыбызны җәлеп итте. Төпченебрәк карагач, феллахның (Алжир крестьянының) җимерелгән тарихи һәйкәлнең таза стенасын каралты кору өчен файдаланганлыгын күреп гаҗәпләндек.

Без Шершельдә яшәгән көннәрдә шәһәрнең үзәгендә рим чорына кадәрге заманнан сакланып килгән каберлек ачылды, мәрмәр колонналар, сыннар, балчык җиһазлар табылды. Белгечләр әйтүенә караганда, бу табылдыклар турында Алжир тарихына яңа битләр язылачак.

Таминраст шәһәрендә тагын бер кызыклы табылдык турында сөйләделәр. Борын-борын заманнарда бу якларга үзенең бердән-бер хезмәтчесе белән Тахоян исемле бөек һәм зирәк хатын килеп чыккан. Җирле кешеләр бу ике хатынны башта бик өнәп бетермәгәннәр, ләкин Тахоянның зирәклегенә һәм киң күңелле кеше булуына ышангач, аны үз иткәннәр. Тахоян биредә кияүгә чыккан һәм бер кыз бала дөньяга китергән. Еллар үтеп картайгач, гомеренең соңгы көннәре җитүен сизенгәч, Тахоян үз янына якыннарын җыеп алган да үзен күмеш беләзекләр кидереп җирләргә васыять иткән. Ул беләзекләр аны теге дөньяда хәвеф-хәтәрдән сакларга тиеш булган.

Тахоянны шулай җирләгәннәр дә. Халык аны озак вакытлар сагынып сөйләгән, аның игелекле эшләре турында риваять буыннан-буынга күчеп килгән. 1925 елда шушы риваятьне бирегә килеп чыккан бер америкалы археолог ишеткән һәм гарәп җирләрендә хакимлек итүче француз властьларыннан Таминраст шәһәре тирәсендә кызу эшләре алып барырга рөхсәт алган... һәм Тахоянның каберен тапкан. Табылдыкларны тикшергәч, галим бу риваятьтә сөйләнгән хәлләрнең безнең эраның 225—307 елларына караганлыгын ачыклаган.

Мөлкәтле һәм борынгы Алжир җире үткән гасырлар һәм төрле цивилизацияләрнең үзенчәлекләрен үзендә сеңдерә һәм саклый килгән. Көннәрдән бер көнне без бер парикмахер белән таныштык. Ул безгә алжир сакал кыручыларының кызыклы тарихын сөйләде. Алжирда гомер-гомергә чәчтарашларга эш бетеп тормаган. Чөнки элек-электән өлкән яшьтәге ирләр чәчләрен төптән үк кырдырып йөрткәннәр. Ә бала-чаганың һәм яшьләрнең түбәсендә генә бер кисәк озын чәч калдырыла торган булган. Көньяк Алжирда исә кызларның да чәчен ялмап алдырганнар. Чисталык өчен шулай эшләнгән. Бу гадәт урыны-урыны белән хәзерге көнгә кадәр сакланып килә.

Алжир чәчтарашы — шактый үзенчәлекле фигура. Ул, үзенең төп бурычын үтәү белән бергә, яшьләрне кавыштыручы ролен дә уйный, ягъни яучы була, кирәк икән, кан җибәрә дә белә, малайларны сөннәткә утырту эшләрен башкара, авырулардан дәвалаучы булып санала. Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, пеләшлектән дәваланучыларны чәчтараш бик үк кызганып тормый икән. Ул «авыручы»ның баш тирәсенә үткен пәке белән бик күп яралар ясый, шул яраларны кызыл сарымсак белән ышкый, анлары төрле үләннәрдән ясалган дәвалар тәкъдим итә.

Алжирда бүгенге чәчтараш — сөйләшергә яратучы, барысын да белүче, хөрмәтле кеше. Кайбер гаиләләрдә баланың беренче мәртәбә чәчен кырдыру гадәте бүгенге көнгә кадәр сакланып килә. Бу тантанага чәчтараш чакырыла, ул эшен башкарганда өйдәге хатын-кызлар шатлыклы авазлар чыгарып торалар.

Эшен бетергәч, гаилә чәчтарашны бүләкли: хезмәт хакын икеләтә түли һәм тәмле ризыклар бирә.

Кыз белән егет ярәшү чәчтараштан башка була алмый дип санала, егет һәм кыз турында аңардан сорашалар, чөнки ул бик күп гаиләләрнең серләрен белеп тора. Кайчакларда, чәчтарашның «озын телле булуы аркасында», гаиләләр арасында гаугалар да чыккалый икән. Шулай да ул — хөрмәтле кеше һәм бер генә тантана да аңардан башка узмый. Эштән буш вакытларында чәчтарашны клубта күрергә мөмкин: ул анда музыка белән шөгыльләнә, җырлый, шигырьләр сөйли, хикәяләр бәян итә... Халыкның атказанган бик күп җырчылары шундый чәчтарашлардан чыкканнар.

Француз колонизаторлары Алжир җирендә йөз утыз ике ел буена хуҗалык иткәннәр. Гасыр ярым диярлек вакыт... Шул арада француз рухында тәрбияләнгән яңа буын үсеп өлгергән. Алжирлыларны үз телләрен, үз культураларын, үз гореф-гадәтләрен оныттырыр өчен, басып алучылар барысын да эшләгәннәр. Бу хакта безгә китаплар белән сату итүче алжир карты сөйләде. Ул укытучының балаларны үз телендә сөйләшкән өчен генә кыйнаган заманнарны искә алды.

Бу хакта гарәп телен белми торып гарәп милләте кешесе булып булмаганны аңлаган алжирлылар сөйли. Республика президенты Хуари Бумедьен һәм аның хөкүмәте илне гарәпләштерү, илнең иҗтимагый тормышында француз теле хакимлеген бетерә бару юлын тота. Милли азатлык фронты газетасы «Әл-Мөҗәһит» гарәпләштерү эшенең мөһимлеген ассызыклап: «Гарәпләштерү мәсьәләсе — партия һәм гарәпләштерүне үткәрү комитеты эше генә түгел, бу барыннан да элек, безнең шәхесебезгә, безнең цивилизациябезгә, безнең тарихыбызга караган милли мәсьәлә»,— дип яза.

Алжирга килгәч, без илне гарәпләштерү эшенең никадәр мөһим эш булуына төшендек. Баштарак алжирлыларның французча язмаларны тырыша-тырыша бетереп, аларны гарәпчә язмалар белән алыштыруларын күреп гаҗәпләнгән булсак, торабара мондый хәлләр гадәти булып күренә башлады. Бер кибеттә гарәп әдәбиятының гүзәл һәйкәле «Мең дә бер кичә» китабын сатып алганда, чал чәчле алжир картыннан алжирлыларның үз телләрен белмәүләренең сәбәпләрен ишеттек. Аның кибетенә вывеска гарәпчә язылган. Французча сүзләр өстенә язылганы сизелеп тора. «Беләсезме,— дип аңлатты ул бу хәлне,— без чит телләргә каршы түгелбез, әмма аларны белү гарәп телен кимсетү исәбенә бармасын иде. Советлар Союзында безнең телне белүләрен күреп торуы миңа рәхәт. Сезнең кешеләр миннән еш кына китаплар алалар. Хәзер инде алжирлылар да үз телләрендә китаплар укый башлады». Шулай сөйләшеп торганда кибеткә бер малай килеп керде. «Бу — минем төпчегем,— дип таныштырды сатучы,— аның гарәпчә белемен тикшереп карагыз әле. Әхмәт, укып күрсәт абыйларыңа». Малай китапны ачып тырыша-тырыша берничә җөмлә укып күрсәтә алды. Без соклану белдереп, тел шартлаттык һәм җитди рәвештә малайның гарәпчә белүен расладык. Бу хәлдән картның күңеле булды һәм ул, кесәсеннән резин чәер алып, улына сузды. «Үземә туры килмәде, хет улларым үз телләрендә укый алсыннар»,— диде ул. Гарәпчә басылган һинд халык әкиятләрен дә алып, без саубуллаштык. Без әле ул карт янына тагынтагын киләчәкбез һәм һәр очрашуыбызны ул үзенең туган әдәби теле буенча дәресләр алу өчен файдаланачак. Бу хәл бик күп урыннарда безнең — совет кешеләренең алжирлыларны гарәп теленә өйрәтүчеләр сыйфатында йөрүебез, үзебезгә дә гаҗәп тоела иде. Гарәп басмалары кибетенә бер килүебездә кибетче: «Советлар Союзында әллә барыгыз да безнең телне беләме?» — дип сорады. «Барыбыз да булмаса да, күпләр белә»,— дип җавап бирдек. Танышлыгыбыз арткан саен, аның совет иленнән килгән кешеләргә хөрмәте зурая барды. Кайда гына булмасын, алжирлылар безнең гарәпчә сөйләшүебезне бирелеп тыңлыйлар һәм, гарәп телен өйрәнер өчен шактый авыр тел дип санаганлыктан, безгә сокланып карыйлар иде.

Алжирда гарәпләштерү процессы дәвам иттерелә. Анда бу эшне яклаучылар да күп, аның дошманнары да җитәрлек. Алжир интеллигенциясенең күпчелеге илне гарәпләштерү процессын тирәнәйтә бару ягында. Бу мәсьәләгә республика президенты Хуари Бумедьен үзе зур әһәмият бирә. Һичшиксез, киләчәк — гарәп теле ягында, прогресс ягында.

Быел алжир халкы азатлык революциясенең егерме алты еллыгын билгеләп үтә. Революция көнен Алжир социализмга йөз тотып үсештә, революцион үзгәрешләрне ныгыта һәм тирәнәйтә бару юнәлешендә күзгә күренерлек уңышлар белән билгеләп үтә. Илдә Конституция кабул ителде, Милли Халык Җыелышына сайлаулар үткәрелде. Бөтен халык ихтирамын казанган президент Хуари Бумедьен, үз иленең киләчәк язмышы белән горурланып: «Бүген мәктәптә кем укый? — Алжирлы. Кем укыта? — Алжирлы. Үз илен дөрес юлдан кем алып бара? — Алжирлы»,— ди.

**А. МИХЕЕВ.**

# ӘБЕЛФӘРӘҖНЕҢ «КЫЗЫКЛЫ ВАКЫЙГАЛАР КИТАБЫ»ННАН

*Сүриянең атаклы язучысы Әбелфәрәҗ (бу аның әдәби псевдонимы) — Григорий Иоанн Бар-Эбрей 1226 елны Төркиянең Малатья шәһәрендә христиан динендәге сүрияле врач гаиләсендә туган. Антиохия һәм Триполиста медицинага һәм риторикага өйрәнгән. Егерме яшендә епископ итеп билгеләнгән. Медицина, астрономия, философия, теософия һәм риторика буенча күп санлы хезмәтләр язган. Философиядә Әбу Гали Сина карашларын үткәргән Әбелфәрәҗнең әдәби мирасы бик зур. Шуларның берсе — «Кызыклы вакыйгалар китабы». Бу әсәрендә ул кешедә булган кимчелекләрне — комсызлык, көнчелек, куркаклык, ахмаклык, саранлык, наданлык һ. б. бик күп нәрсәләрне нык камчылый. Ул шулай ук берничә поэма, бик күп шигырьләр, эпиграммалар, сүрия теле грамматикасы, гомуми тарих һәм 816 биттән торган аңлатмалы сүзлекнең авторы. Аның бик күп әсәрләре Европа һәм Көнчыгыш телләренә тәрҗемә ителгән. Әбелфәрәҗ 1286 елда алтмыш яшендә Көнбатыш Әзербәйҗанның Марага шәһәрендә вафат булган.*

## Кемгә ничек?

Бер вакыт Сократ бер бай белән юлга чыккан. Юлда алар бу җирдә юлбасарлар бандасы эш иткәнен ишеткәннәр.

— Аһ, минем кем икәнемне белсәләр — эш начар! — дигән бай.

— Аһ, минем кем икәнемне белмәсәләр — эшләре начар, — дип куйган философ.

## Урыннарын алыштырыгыз!

Бер шәһәрдән узып барганда бер философ шәһәрдәге врачның надан, ә гаскәр башлыгының булдыксыз икәнлеген белгән. Шуннан соң ул шәһәр халкына мондый киңәш бирә икән:

— Иң яхшысы — сез аларның урыннарын алыштырыгыз. Гаскәр башына врачны куегыз — кеше үтерүдә аның тәҗрибәсе зур. Ә врач исә гаскәр башлыгы булсын — кешене үтерүдә ул үтә саклык белән эш итә.

## Ялганчы һәм ахмак

Бер хәким болай дигән:

— Әгәр дә берәү байлыкны яратмыйм дисә һәм шул фикерен исбат итмәсә, минемчә, ул ялганчы була. Ә инде шул сүзләренең раслыгын исбат итсә, минемчә, ул — һичшиксез, ахмак.

## Кем нәрсәгә мохтаҗ?

Әсфәндияр хәким әйткән:

— Иң күндәм ат та чыбыркыга мохтаҗ, иң тыйнак хатын да иргә мохтаҗ, иң акыллы ир дә бүтәннәрнең киңәшенә мохтаҗ.

## Сүзсез аңлату

Кейкобад дигән патша үлгәч, бер хәким болай дигән:

— Кичә ул бик күп сөйләгән иде, ә бүген бер сүз әйтмәсә дә бик күп нәрсәне аңлата...

## Дүрт сыйфат

Бер хәким болай дигән:

— Аракы аны һәр эчүчегә дүрт сыйфат бирә: башта ул тутый кошка охшый — бик эреләнеп, салмак кына басып, кәпәренеп йөри. Аннары, маймылга охшап, теләсә кем белән шаяра-уйный башлый. Аннан соң, арысланга охшап, көченә һәм сәләтенә ышанып, тәкәбберләнә. Иң ахырда, дуңгызга охшап, пычракта ауный.

## Күп сөйләү

Бер акыл иясе болай дигән:

— Күп сөйләүдән саклана күрегез. Чөнки ул абынып егылырлык ташлар белән тулган киң сахрага охшый.

## Иң уңай вакыт

Бер врачтан:

— Ашар өчен иң уңай вакыт кайчан?— дип сораганнар.

Ул болай дип җавап биргән:

— Ашарына бар кеше карыны ачкач ашасын, ә ашарына юк кеше ашарга тапкач ашасын!

## Түләүле яктылык

Өч саран, бер бүлмә алып, шунда яшәргә булганнар. Лампага сала торган майны өчесенең дә акчасына алалар икән. Бер көнне берсенең май алырга бирерлек акчасы булмаган. Калган икесе, лампа яктысыннан бушлай файдаланмасын дип, тегенең күзләрен чүпрәк белән бәйләп, үзләре ут сүндереп йокларга ятканда гына чүпрәкне чишә торган булганнар.

## Тирләтү чарасы

Бер саран бик каты чирләгән, ләкин кризис көне килеп җиткәч тә тирли алмый ята икән. Хезмәтчеләре бу турыда врачка хәбәр иткәннәр. Врач аларга мондый киңәш биргән:

— Сез аның күз алдында ул үзе генә ашый торган кыйбатлы берәр нәрсәне ашый башлагыз. Хуҗагыз шундук тиргә батар!

## Саранның монологы

Бер саранның бер тәңкәсе идәнгә төшеп киткән. Шундук ул аны алган да, башта акчаны үбеп, учына салып сыйпаган да болай дигән:

— Син минем әтием дә, әнием дә, туганым һәм дустым да. Син күпме шәһәрләрдә булдың, күпме диңгезләр кичтең, күпме байларны хәерчелеккә калдырдың, күпме ярлыларны баеттың, күпме чибәрләрне аздырдың, күпме кызларны боздың!

Аннары, тәңкәне кесәсенә салып, болай дигән:

— Хәзер инде беркайчан да чыга алмаслык урынга кереп ят. Моннан ары беркемнең дә тынычлыгын боза алмассың!

## Начар гадәт

Бик саран берәүнең малае, әтисе икмәк биргәч, башта аны тәрәзә төбенә куеп тота да шуннан соң гына ашый икән. Әтисе нигә алай итүен сорагач, малай болай дигән:

— Өйнең аскы катындагы кухнядан безнең тәрәзәгә аш исе күтәрелә. Мин икмәкне шул исне сеңдерер өчен тәрәзә төбенә куеп тотканнан соң гына ашыйм.

Әтисе аңарга бик каты сугып җибәргән дә болай дигән:

— Ах, азгын малай! Кече яшеңнән коры икмәк ашамаска өйрәнәсең бит!

## Ризыгы гына булсын...

Бер актердан күршесе кашык сорап кергән. Актер аңарга болай ди икән:

— Мин әле генә ашарлык берәр нәрсәбез булсын иде дип теләп утыра идем. Әгәр булса, кашыксыз гына, кул белән дә ашар идем.

## Уңдырышлы хатын

Бер мәзәкчедән ничә баласы бар икәнен сорагач, болай дигән ул:

— Валлаһи дип әйтәм, хатыным тудырган балаларымның саны аның белән үткәргән төннәремнән күбрәк!

## Аванс тәртибендә

Нинди дер җинаять эшләүдә гаепләп явыз җаннар ясаган яла буенча бер судья мәзәкчегә илле камчы суктырган. Соңыннан аның гаепсезгә җәза алганлыгы мәгълүм булгач, судья аңарга:

— Мин бит сиңа җәзаны ялгыш биргәнмен,— дигән.

— Зур бәла түгел!— дигән мәзәкче.— Син мине суктырганың турында берәр җиргә теркәп куй. Мин чыннан да берәр җинаять эшләсәм, биргән җәзаңны исәпкә алып, мине бүтән суктырмассың!

## Кем үлгән?

Шундый бер вакыйганы сөйлиләр: бер дивана бик якын танышының үлгәнлеген ишеткәч, аның абыйсын очратып:

— Әйт әле, кайсыгыз үлде — синме, энеңме?— дип сораган.

## Катнашым юк!

Берәүнең малае туган. Күршеләре кереп котлый башлагач, ул аларга:

— Бу бит алла белән сезнең эшегез, бирердә минем бернинди катнашым юк! — дигән.

## Тиле белән ишәк

Бер тиле кеше атланып барганда аның ишәге кинәт туктаган да кузгалмый тора башлаган. Тиле кеше шунда аңарга кич белән ашарга бирмәячәген әйтеп ант иткән. Ә кичен, өйгә кайткач, хезмәтчесенә болай дигән:

— Бар әнә ишәккә арпа үлчәп бир. Ләкин, зинһар, мин кушканны әйтә күрмә. Югыйсә, ишәгем миннән бөтенләй курыкмый башлар.

## Кайчан үлгән?

Бер тилемсә кеше болай дигән:

— Минем әти Иерусалимда ике тапкыр булган, шунда үлгән һәм шунда күмелгән. Тик кайсы баруында үлгәнен генә белмим — беренче баруындамы, икенчесендәме?!

## Беркатлылык

Беркатлы берәүнең бөркете югалган. Ул, шәһәр башлыгына мөрәҗәгать итеп, бөркетен тотканчы шәһәрнең капкаларын бикләп торуын үтенгән.

## Бераз ял итсен

Бер тиленең дуслары аның ияреп сорап торганнар.

— Гаеп итмәгез,— дигән ул аларга,— үзем әле генә шул ияръдән төштем. Берәр сәгать сабыр итегез инде. Ияр ял итеп алсын!

## Әгәр ышанмасаң...

Берәү аллага болай дип ялвара икән:

— Я раббым, миңа биш мең көмеш бир. Шуның бер меңен сәдака итеп хәерчеләргә өләшергә сүз бирәм. Әгәр сүземә ышанмыйсың икән, миңа дүрт меңен бир дә, калганын хәерчеләргә үз кулың белән өләш.

## Ул әле сине белми...

Бер малай тәрәзәдән башын тыккан икән дә, боз ява башлап, башына бер боз кисәге килеп төшкән. Малай, аны кемдер сукты дип белеп, башын авырттыручыны кычкырып тиргәгән. Моның өчен әтисе аны кыйнаган да, тәрәзәдән башын тыгып, күккә карап әйткән:

— Я ходай! Бу сүзләре өчен син аңа ачуланма инде. Ул сине белми бит әле!

## Тиленең төше

Бер тиле әйткән:

— Бүген төнлә мин бер төш күрдем, шуның яртысы дөрес, яртысы ялган төш булып чыкты.

Нинди төш күргәнен сорагач, ул болай дигән:

— Төшемдә бик матур бер яшь кыз кочагында ята идем. Уянып китсәм — ул шактый карт бер хатын булып чыкты...

## Кушканны төгәл үтәү

Берәү базарда кыздырган ит ашап утыра икән. Үтеп баручы берәү аңарга:

— Үзең ашый торган нәрсәнең беразын миңа бир әле. Шул ризыкны синең белән уртаклашасым килә,— дигән.

— Ит үземнеке түгел шул,— дигән тилемсә.— Аны миңа бер бай үз урынына ашарга кушып биргән иде. Аның әмерен бозарга куркам.

## Алайса, күрсәт!

Бер диванага берәү:

— Нишләп монда әрәм булып торасың? Әллә белмисеңме — әнә тегендә бер бай диваналарга икешәр тәңкә өләшә,— дигән.

Дивана аңарга:

— Әгәр сүзең чын булса, үзең алган ике тәңкәне күрсәт миңа,— дигән.

## Җәлләгән

Берәүнең өенә карак кергән. Ләкин, күпме актарса да, каләм белән карадан башка әйбер таба алмагач, мондый язу калдырып чыгып киткән:

— Мин сезне бик җәллим — шундый мохтаҗлыкта яшисез, шул хәтле ярлы тормыш кичерәсез икән!

**ӘХМӘТ ИСХАК** тәрҗемәләре.

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

## Рәшит Гарипов

### Сер бирмәү



Бервакытта да сер бирми дип ишеткәнем бар иде Гайникамал әби турында. Моны аның әйбәт сыйфаты итеп сөйлиләр идеме, әллә башка яктанмы — бүгенге көнгә кадәр төшенә алганым юк һәм аңа омтылганым да булмады.

Әмма бер көнне үзе белән кételмәгән хәл килеп чыкты.

Кешелеккә дигән күлмәкләрен киеп, матур яулыкларын катлы-катлы япкан Гайникамал әби берәрсенә кунакка бара иде булса кирәк. Хәер, безгә анысы мөһим дә түгел. Менә аның, кулындагы таягына ныклап ябышкан килеш, кинәт туктап калуы игътибарны ирексездән җәлеп итте. Бөгелгән уңайдан тын да алмый катып калды ул. Ярдәм итәргә ашыктым.

— Ни булды, әби, нишләргә кирәк? — дип сырпаланам үзем.

Ләкин хәле җавап бирерлек түгел иде, күрәсең.

Тегендә-монда йөгермәкче булып карыйм. Әби уң кулының имән бармагы белән мине тавыш-тынсыз гына чакырып алды. Шунда аның хәле киткәнлегенә тагын бер кат ышандым. Минем соравыма көчхәл белән җавап бирде:

— Туктап уйлап тордым әле, улым. Дөньясы матур, каһәр. Синең кебек егетләр озатып куйса, әллә кая барып җитәрлегем бар шикелле.

### Биш тиен акча

Гыйззениса әби инде йөзгә җитеп килә. Уллары, кызлары, кияүләре, киленнәре бар аның. Түр башында аяк бөкләп кенә утырса да, беркем гаеп итмәс иде үзен.

Юк, Гыйззениса әби иртүк торып каз-тавык ашата, өйне җыештыра, кичен көтү каршылый әле.

Ә көндезләрен ул чишмә янына төшеп утырырга ярата. Күңел нечкәргән чакларда телдә сүз тормас була бит. Бер көнне шул чишмә янында безгә — каз, бозау көтүче бер төркем үсмерләргә, әби кайбер серләрен дә чишеп куйды.

— Шакирҗан бабагызның яшь, минем кыз чагым иде,— диде ул, күзләрен бер ноктага төбәп. Бераз кеткелдәп куйгач, сүзен дәвам итте: — Кичен мин суга килгәндә, менә шушы сукмакта көтеп то-

рыр иде. Кыюсыз иде үзе. Шуның өчен башта якын итә алмый да йөрдем. Бер көнне ул мина:

— Матур кыз, минем белән йөрсәң, дәү биш тиен акча бирәм, дип әйтеп ташлады. Ул чакта бер тиен дә зур акча иде... Мин ялындырырга теләгәч, кичке караңгыда тәрәзәбезгә таяк белән шакып:

— Гыйззениса, китер биш тиен акчаны, барыбер минем белән йөрмисең, — дип, әниләр алдында кызарта язды.

Шулай да без аның белән матур яшәдек...

## Бер поездда

Бер минуттан китәргә тиешле Васильево поезды турында ишеткәч, вокзалдагы халык ашыга, кабалана башлады. Без дә бер әйбәт кенә вагонда әлегә буш калган урыннарга барып утырдык. Шул чагында ишектән өстенә зәңгәргә ак чәчәкләр төшкән күлмәкле, башына шәльяулыгы бөркәнгән бер әби күренде. Уң кулында кызыл төенчек, икенчесендә — мендәр тутырып бәйләнгән сыман йомшак капчык иде аның. Сизелеп тора, әби кеше авылдан, ә үзе каядыр кунакка бара. Аның артыннан ук тагын бер тернәк кенә, ягымлы гына әби күренде. Алар, буш урын эзләп, бер-бер артлы безнең янга таба килә башладылар. Буш урыннар инде беткән иде.

Каршыбызда гына озын чәчле бер егет белән малайлардан аергысыз бер кыз бик нык берегешеп, яратышып утыралар иде. Әби кешеләр нәкъ алар янында туктап калдылар. Вагондагылардан берәү:

— Әй, сез, яшьләр, олы кешеләргә урын бирегез, — дип әйтеп куйды.

— Юк, юк, утырсыннар, яшьләр ич алар, — дип каршы төште әбиләрнең алдан килгәне.

— Курыкма, кордаш, — диде аларның икенчесе, — болар, ялынып сорасаң да, тиз генә урын бирә торганнардан түгел.

Ниһаять, кайгырта торгач, әбиләргә урын табып бирдек. Поезд да кузгалып китте.

— Кордаш, син дә кунакка барасың, ахрысы, — диде икенче әби, төенчекләрен җайлап урнаштырып бетергәч.

— Кай яклардан?

Беренче әби төенчеге турында бик кайгырта иде. Ул аңа һич кенә дә җайлы урын таба алмый азапланды. Идәнгә дә, тезенә дә куеп карады, ахырдан, берәү киштәгә иплән куйгач кына тынычлап калды.

— Әйе, кордаш, — диде ул аннары икенче әбигә борылып. — Нәрсә дип әйткән идең әле? Хәтерем бик начар.

Икенче әби аңа шул ук сорауларны кабатлады.

— Кызым янына барам, кордаш, кызым янына. Васильевода киявем белән бик әйбәт, бай торалар. Күчтәнәчләр алып, карап, хәлләрен белеп кайтыйм дидем.

Ягымлы әби уйланып торгандай итте. Аннары, ко**я**штай балкып, күршесенә борылды.

— Кара әле, кордаш, — диде ул, аңа мөрәҗәгать итеп.

Ләкин беренче әби, аның сүзен бүлдереп, үзе сорау бирде:

— Үзеңнең кая барышың соң, кордаш, болай бәйрәмчә киенеп?

— Мин улым янына, Арчага барышым. Бу улым бик уңган булып чыкты. Тормышлары әйбәт, өйләре зур, ул мунчалары, машиналары дисеңме...

Беренче әби аны бүлдереп әйтеп куйды:

— И кордаш, нинди рәхәт заманнарда яшибез, бер үк поездда икебез ике якка барабыз икән ич.

## Җөмләләр

Кешене төн һәм күңел гимнастикалары камилләштерә.

Ясалма матурлык — шыксызлыкның бер төре.

— Минем бу серем бүсеремә әйләнмәс,— дип, син үлгәч кенә мактан.

Һәр кыз бала һәр егеттән саф була. Ир-егетләр кыз баладан сак була.

Бәхетсез булырга теләсәң, үзеңне генә ярат.

Иҗади хезмәт һәр вакыт батырлыкны таләп итә.

— Кечкенә генә хаталарымны беркем дә сизмәс әле, — дидеңме, алар тау хәтле зураеп китеп, күңелеңне изә дә башлыйлар.

Яхшы күренергә тырышу белән яхшы булырга тырышуның аермасы — җир белән күк аермасы.

Мещаннар догасы: «Минем синдә эшем юк, синең миндә эшең юк. Амин!»

И. Туктар.

# НУР ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНГА 50 ЯШЬ



Илленче еллар башында татар әдәбиятына зур төркем яшьләр килеп керде. Бүген безнең урта буын дип йөртелә торган прозаикларыбыз, шагыйрь һәм драматургларыбыз иде алар. Менә шулар арасында тәнкыйть һәм әдәбият белеме белән шөгыльләнә башлаган яшьләр дә бар иде. Вакыт үтә торды, алар олыгая төштеләр, араларыннан фән кандидатлары, докторлары үсеп чыкты. Алар югары уку йортларында, төрле гыйльми учреждениеләрдә фәнни-педагогик эш алып баралар, үзләренең хезмәтләре белән әдәби процесска актив катнашалар.

Нур Гыйззәтуллин — шул буынның бер вәкиле.

Минзәлә педагогия училищесын һәм Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлагач, ул берара укытучы булып эшли һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага кабул ителә. Аның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге беренче чыгышлары да аспирантурада уку чорына туры килә. «Совет әдәбияты» журналында, газеталарда мәкаләләре басылып чыга башлый. 1953 елда ул, диссертациясен уңышлы яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1956—1957 нче елларда аның бер-бер артлы татар һәм рус телләрендә күренекле татар совет язучысы Кави Нәҗминең тормыш һәм иҗат юлы турындагы китаплары дөнья күрә. Тагын бер елдан «Әдәбият белеме сүзлеге» чыга. Төзүчесе Н. Гыйззәтуллин булган бу хезмәт бүгенгә кадәр татар телендә әдәби терминнарны мисаллар белән аңлатып биргән бердәнбер кулланма булып кала бирә. Бик кыска вакыт — нибары ике ел эчендә (1958—1960) ул язучы Сәрвәр Әдһәмова белән берлектә Кави Нәҗминең дүрт томлык әсәрләрен җыйнап чыгара. Сүз башы, фәнни искәрмәләр язу, язучы әсәрләренең шактый тулы библиографиясен төзү дә аның тарафыннан башкарыла. Егерме сигез яшендә ул СССР Язучылар союзына кабул ителә.

Нур Гыйззәтуллинның бөтен эшчәнлеге СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты белән бәйләнгән. Институтның башка әдәбият галимнәре белән бергә ул «Татар совет әдәбияты тарихы. Очерклар» (1960), «История татарской советской литературы» (Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1965) дигән зур фәнни хезмәтләрне язуда катнаша. СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты тарафыннан чыгарылган алты томлы «История советской многонациональной литературы» дигән капиталь хезмәтнең II һәм IV томнарында (1972) аның утызынчы һәм сугыштан соңгы еллардагы татар прозасы турындагы бүлекләре басыла. Республика һәм үзәк матбугатта уңай бәя алган бу хезмәтләрдә Нур Гыйззәтуллин татар совет прозасының бай тарихын, әдәби процессның катлаулы күренешләрен күп санлы фактик материаллар нигезендә шактый тулы һәм киң итеп ача алды.

Тәнкыйтьче төрле елларда «Социалистик Татарстан» газетасында Ф. Хөсни, А. Шамов, Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Р. Төхфәтуллин, Ш. Рәкыйпов һ. б. иҗаты турында мәкаләләр-рецензияләр чыгарды, Җ. Тәрҗеманов һәм Л. Ихсанова китапларына сүз башлары язды. Татар совет әдәбиятының аерым проблемаларына багышланган «Яңа герой эзләгәндә» («Казан утлары», 1973), Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты темасына багышланган «Халык батырлыгы һәм әдәбият», «Ераклашкан саен» («Социалистик Татарстан»), «Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы темасы» («Татарстан коммунисты», 1975) һ. б. хезмәтләр дә аның иҗатында әһәмиятле урын алып торалар.

Нур Гыйззәтуллин җәмәгать эшләренә актив катнашып килә: төрле елларда институтның партбюро секретаре итеп сайлана, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында «Белем» җәмгыяте оешмасының председателе булып эшли, Казан шәһәренең Совет район халык судында сигез ел халык утырышчысы була, институтта марксизм-ленинизм эстетикасы буенча теоретик семинар алып бара, халык алдында лекцияләр белән чыгыш ясый һ. б.

Хәзер Нур Гыйззәтуллин Г. Ибраһимов исемендәге институт тарафыннан матбугатка әзерләнә торган алты томлы «Татар әдәбияты тарихы»н язуда катнаша. Татар әдәбиятын иң борынгы чорлардан алып бүгенге көннәргә кадәр колачлаган бу хезмәтнең төрле томнары өчен аның тарафыннан XX йөз башындагы татар прозасы, егерменче-утызынчы еллар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы чорлардагы әдәби хәрәкәт һәм проза жанры турында бүлекләр, аерым язучыларның иҗат портретлары язылды.

Шактый эшләнгән. Ә киләчәктә әле тагын да күбрәк һәм нәтиҗәлерәк эшләргә, җиңне ныграк сызганып эзләнергә, әдәбиятыбыз тарихына тагын да тирәнрәк керeп, хәзерге әдәби процесска активрак катнашырга кирәк. Татар совет прозасының актуаль мәсьәләләренә багышланган зур хезмәт тә тиздән тәмамланыр дип ышанасы килә. Шул уңай белән каләмдәш дуслары тәнкыйтьчегә сәламәтлек һәм яңа иҗади уңышлар тели.

# РӘШИТ ВАҺАПОВ

(1908—1962)

Рәшит Ваһаповның артистлык эшчәнлеге Ватаныбыз зур сынаулар кичергән вакытта башлана.

Ватан сугышының иң авыр чоры. Республикабыз авылларында концертлар бирeп йөргән Рәшит Ваһапов халык күңелен тиз яулап алган талантлы артист булып кына түгел, ә чын патриот, олы җанлы гражданин булып та танылa. Концертлардан бушаган арада ул колхозчылар белән бергә эшли, печән чабарга, иген җыярга чыга. Ә кичләрен колхозчылар аның җырлавын онытылып тыңлыйлар...

Ул озын көйләрне җырлаучы буларак танылган көчле тавышлы, киң сулышлы җырчы иде. Чөнки ул көйләр импровизациягә зур мөмкинлек бирәләр, алар Иделдәй киң агылалар. Аларга үзеннән бизәкләр, бормалар өстәргә була. Бу җырлар эчтәлекләре белән дә кыйммәт була.

Рәшит Ваһапов — авыл егете.

Ул 1908 елның 7 маенда хәзерге Горький өлкәсе Кызыл Октябрь районы Яңа Актук авылында туа. Горький шәһәрендә татар педагогия техникумын тәмамлаганнан соң үз районы мәктәпләрендә укыта. Аннан Мәскәүдә метро төзүче татар эшчеләрен яңалиф белән укырга, язарга өйрәтә. Мәскәү музыка техникумында укый һәм 1940 елда Казанга килә. Гомеренең соңгы көненә кадәр ул музыка сәнгатенә эшләп, халык мәхәббәтен казана, Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемгә лаек була.

Коммунист, интернациональ рухлы Рәшит Ваһапов тугандаш республика халыкларын татар музыкаль культурасы белән таныштыруда, төрле милләт сәнгать осталары белән иҗади аралашуда да тирән эз калдырган сәнгать остасы.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КУЛЬТУРА РАБОТНИКЛАРЫ СЪЕЗДЫ

20 мартта Казанда культура работникларының V республика съезды булды. М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры залына клуб учреждениеләре, китапханәләр, музейлар, парклар, кинотеатрлар работниклары, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре җыелды.

КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү өлкәсендә республика культура работникларының бурычлары турында ТАССР культура министры **И. Н. Алиев** сөйләде. РСФСР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе дәүләт комитеты председателе **Н. В. Свиридов**, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре **М. Ф. Вәлиев** һәм башка иптәшләр чыгыш ясады.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре **Ф. Ә. Табеев**, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе **С. Г. Батыев**, ТАССР Министрлар Советы Председателе **Г. И. Усманов**, профсоюзларның Татарстан өлкә советы председателе **С. Г. Сафин**, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары **М. Х. Хәсәнов**, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре **М. М. Мусин** һәм **Ә. С. Миндубаев** катнаштылар.

Съезд Татарстанның барлык культура работникларына мөрәҗәгать кабул итте.

## ИҖАДИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстан художникларының 1977 иҗат елы йомгакларына багышланган җыелышында доклад белән ТАССР Художниклар союзы правлениесе председателе **Ә. И. Тумашев** чыкты.

РСФСР художество фондының Татарстан бүлеге директоры **Е. А. Макаров** художество фондының 1977 елгы эшенә һәм алда торган бурычларга тукталды. Шулай ук Татарстан Художниклар союзының художество советы председателе **Е. А. Симбирин** отчеты тыңланды, ТАССР Художниклар союзы каршында эшләүче иҗат секцияләре җитәкчеләре, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләренең художество участоклары җитәкчеләре һ. б. лар сөйләде.

Иҗади ел йомгаклары җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире **М. М. Мусин** чыгыш ясады.

*
* *

Казан кинохроника студиясенең 1977 ел йомгакларына багышланган иҗат конференциясе дә март аенда булып узды.

«1977 иҗат елы йомгаклары һәм КПСС Үзәк Комитетының декабрь Пленумы карарлары яктылыгында студия алдына куелган бурычлар турында» Казан кинохроника студиясенең баш редакторы **Р. И. Копосов** сөйләде.

Конференциядә Үзәк документаль фильмнар студиясе кинорежиссеры, Дәүләт премияләре лауреаты, РСФСРның халык артисты **Л. М. Кристи**, РСФСР Госкино производствосы баш идарәсе начальнигы **Ю. В. Симаранов**, КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире **М. М. Мусин** иптәшләр чыгыш ясады.

Иҗат конференциясендә шулай ук КПССның Чувашия өлкә комитетының культура бүлеге мөдире О. И. Галля, КПССның Мордовия өлкә комитетының пропаганда бүлеге инструкторы В. И. Петров, СССР Кинематографистлар союзының Идел буе бүлеге секретаре М. А. Скворцов, ТАССР Министрлар Советының кинофикация идарәсе начальнигы В. Н. Макаров, Куйбышев һәм Саратов кинохроника студияләре иҗат работниклары, Мари АССР, Татарстан телевидениеләре һәм кинопрокатлары работниклары, иҗат союзлары вәкилләре, кино сөючеләр, Казан театрлары артистлары һәм башкалар катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Язучыларның ачык партия җыелышында шагыйрь һәм прозаик Гәрәй Рәхимнең иҗат отчеты тыңланды. Аның иҗаты турында Г. Шәрәфи, Ш. Галиев, Г. Ахунов, Р. Гатауллин, С. Хәким, М. Вәлиев иптәшләр чыгыш ясады. Г. Рәхимнең «Моңнарым» дигән шигырьләр җыентыгын һәм «Көннәр язга авышкач» исемле повестен республика комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясенә тәкъдим итәргә дигән фикер әйтелде.

## ГАЗЕТА ТАНТАНАСЫ

КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм ТАССР Министрлар Советы органы Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы «Социалистик Татарстан» газетасы хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү һәм алар-

ны хуҗалык һәм культура төзелеше бурычларын үтәүгә туплау өлкәсендәге нәтиҗәле эше өчен РСФСР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

Пресса йортының конференц-залында журналистларның бүләкне тапшыруга багышланган тантаналы җыелышы үткәрелде. Анда республика газеталары һәм журналлары, телевидение, радио, нәшриятлар работниклары, полиграфистлар һәм матбугат таратучылар, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашты.

КПСС өлкә комитеты секретаре **М. Ф. Вәлиев** КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе коллективын РСФСР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнүе уңаеннан кайнар котлады һәм югары бүләкне тапшырды. М. Ф. Вәлиев журналистларга, редакциянең барлык работникларына хезмәт җиңүләрен коммунистик тәрбияләүдә яңа иҗат уңышлары теләде.

«Социалистик Татарстан» газетасының 60 еллыгы турында газета редакторы **Ш. Х. Хамматов** сөйләде.

## ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ФИКЕР АЛЫША

28 мартта тәнкыйтьчеләр секциясенең киңәйтелгән утырышы булды. Анда тәнкыйтьчеләр, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре, язучылар, «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре катнашты.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карары яктылыгында бездә бүгенге әдәби тәнкыйть эшенең торышы, аның үсеш проблемалары, тәнкыйтьче кадрларны тәрбияләү хакында Ф. Мусин, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Г. Ахунов, Х. Сарьян, Р. Мостафин, Д. Вәлиев, Н. Гыйззәтуллин, Г. Рәхим, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Ш. Маннапов һәм башкалар фикер уртаклаштылар.

## «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» БАСМАГА ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ

СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советы утырышында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» («Йосыф кыйссасы») поэмасы матбугатта басып чыгаруга тәкъдим ителде.

Китапның күләме 40 басма табактан арта.

Кереш мәкаләне институтның өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Фазыл Фасеев язган.

Поэма тексты транскрипциядә басыла, шулай ук поэманың хәзерге әдәби телебезгә мәгънәви-поэтик тәрҗемәсе һәм русчага юлга-юл тәрҗемәсе бирелә. Русчага тәрҗемәне шагыйрь Әхмәт Исхак ясаган.

Китап художник Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәре белән бизәлгән.

* * *

Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты Татарстан Язучылар союзы белән берлектә «Хәзерге татар матур әдәбиятының теле һәм стиле» дигән темага конференция үткәрде. Докладларны Г. Ахунов, И. Бәширова, С. Ибраһимов, Ф. Сафиуллина, В. Хаков, Х. Курбатов иптәшләр ясады. Фикер алышуларда Ф. Хәсни, Х. Сарьян катнашты.

## ДУСЛЫК ҖЕПЛӘРЕ

Кыргызстан вакытлы матбугаты Әхмәт Фәйзинең тууына 75 ел тулуны зурлап билгеләп үтте. «Ленинский путь» газетасында Ош дәүләт педагогия институтында шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлына багышлап үткәрелгән кичә турында языла: әлеге кичәдә Әхмәт Фәйзи иҗаты үрнәгендә шигърият, иҗат һәм интернациональ дуслык турында җитди сөйләшү булды, шагыйрьнең әсәрләре русча, кыргызча, татарча яңгырады диелә.

Кыргыз шагыйрьләре Эрмамат Османов, Усман Темур, Атакул Жакыпов тәрҗемәсендә Ә. Фәйзи шигырьләре «Ильич нуру», «Колхоз хакыйкате», «Кыргызстан мәдәнияте» газеталарында басылып чыккан.

* * *

Башкортстан АССР Ярмәкәй районы Рәтәмак авылы клубында шул авылда туып үскән язучы Мәсгут Шәрифуллинның тууына 50 ел тулу уңаеннан әдәби кичә уздырылган. Авылдашлары язучының әсәрләре турында фикер алышканнар, истәлекләр сөйләгәннәр.

* * *

Гамзат Цадаса исемендәге авар дәүләт музыкаль драма театры сәхнәсендә Хәй Вахитның «Күк капусы ачылса» дигән комедиясе буенча эшләнгән спектакль куелды. Спектакльне сәхнәгә режиссер З. Хиясов әзерләгән. Музыканы Дагыстанның яшь композиторы Ә. Әскәрханов язган.

«Күк капусы ачылса» спектакле шулай ук Алим-Паши Салаватов исемендәге кумык музыкаль драма сәхнәсендә дә уңыш белән бара. Бу театр Х. Вахит иҗатына моннан элек тә мөрәҗәгать итеп, аның «Чит кеше гаебе» («Туй алдыннан») исемле драмасы буенча эшләнгән спектакльне күрсәткән иде.

* * *

Пермь шәһәрендә һәм өлкәсендә татар музыкасы кичәләре булып узды. Концертның беренче бүлеге ТАССРның халык артисткасы, композитор Сара Садыйкова иҗатына багышланган иде. Бу — җыр сөючеләр күңеленә аеруча хуш килде, алар композитор С. Садыйкованы сәхнәгә кат-кат чакырдылар.

Программаның икенче бүлегендә РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Ф. Насретдинов, ТАССРның халык артисткасы Р. Билалова, ТАССРның атказанган артисткасы Х. Гыйниятова, яшь артистлар Р. Сәхәбиев, З. Сәхәбиева, шагыйрь М. Хөсәен чыгыш ясады.

*
* *

Мәскәүдә җыр һәм бию ансамбльләре һәм халык бию ансамбльләренең Бөтенроссия смотры булды. Татар дәүләт филармониясе ансамбле (баш хормейстер Л. Кустобаева, баш балетмейстер Р. Гарипова) смотрда зур уңыш казанды. СССРның халык артисты И. Моисеев җитәкчелегендәге жюри аңа икенче урынны бирде.

Смотрда катнашучыларның П. И. Чайковский исемендәге залда булган йомгаклау концертында безнең артистларга Россиянең иң яхшы коллективлары чыгышларын төгәлләү хокукы бирелде. Алар «Казан кунаклары» дигән биюле күренеш күрсәттеләр, ТАССРның атказанган артисткасы Н. Василова татар халык җыры «Кәккүк»не башкарды.

*
* *

Оренбург шәһәренең Х. Ямашев исемендәге татар китапханәсендә Ибраһим Нуруллинның «Гүзәл кешеләр тормышы» сериясендә чыккан «Тукай» исемле китабы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Март аенда Ибраһим Нуруллин Васильево санаториенда, профсоюзларның Хезмәт сараенда «Тукай» китабын укучылар белән очрашты, аларның шул китап турындагы сорауларына җавап бирде.

*
* *

РСФСР Язучылар союзының «Волга» журналы бүләге Мәҗит Рафиковка «Сыртқы мәктәп» дигән әсәре өчен бирелде. Язучының Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган бу әсәре журналның юбилей санында — 1977 елның ноябрь санында басылган иде.

*
* *

Норвегия радиосы татар музыкасына багышланган махсус тапшыру яңгыратты. Норвегия радио тыңлаучылары И. Шакиров, Ә. Афзалова, Т. Якупов башкаруында татар халык җырлары белән таныштылар, Татарстан һәм татар культурасы хакында мәгълүмат алды. Тапшыру уңае белән «Адрессеависен», «Афтенпостен» газеталарында материаллар басылып чыкты.

Радиотапшыруны һәм матбугаттагы мәкаләләрне күптән түгел Казанга килеп киткән Норвегия язучысы Елена Краг әзерләгән. Хәзер ул Норвегия укучыларын Г. Тукай, Г. Ибраһимов иҗатлары белән таныштырырга җыена.

## ОЧРАШУЛАР, КИЧӘЛӘР

Татарстан мех берләшмәсе большевикреволюционер Хөсәен Ямашев исемен йөртә. Аның хөрмәтенә коллектив «Атказанган ямашчы» дигән мактаулы исем булдырды.

Хөсәен Ямашев турындагы китаплар авторы Атилла Расих мехчылар янында еш була, аларны үзенең иҗат планнары белән таныштыра, коллективның тормышы белән кызыксынып яши. А. Расих, социалистик ярышта җиңеп, «Атказанган ямашчы» исеменә лаек булган эшче комсомолкалар Г. Галиуллина белән С. Гыйниятуллинаны кайнар котлады.

*
* *

Прозаик Мөхәммәт Мәһдиев Кукмара районының «Коммунизмга» колхозы хезмәтчелләре һәм Зур Сәрдек урта мәктәбенең өлкән класс укучылары белән очрашты. Ул үзенең «Кырык беренче ел балалары», «Фронтовиклар» дигән әсәрләренә карата китап укучыларның фикерләрен тыңлады һәм аларның сорауларына җавап бирде.

*
* *

Казанның сәүдә работниклары клубында шигырь һәм җыр кичәсе уздырылды. Кичәдә шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов, Татарстанның атказанган артистлары Хәдичә Гыйниятова, Нәфисә Василова, җырчылар Зилә Сөнгатуллина, Риф Гатауллин чыгыш ясады.

## Ф. СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ ТУГАН АВЫЛДА

Шушы елның 22 мартында җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм журналист, тәнкыйтьче һәм публицист Фатих Сәйфи-Казанлының тууына 90 ел тулды. Шул уңай белән бер төркем язучылар әдипнең туган якларында булып, Әлки районының күп кенә колхозларында һәм совхозларында хезмәт ияләре белән очраштылар. Ф. Сәйфи-Казанлының туган авылы Карамалыда узган кичә ачуча тантаналы һәм истәлекле булды. Анда КПСС райкомы секретаре Ә. К. Садриев, «Мир» совхозы директоры Д. Х. Насыйбуллин һәм башка иптәшләр катнашты.

Кичәдә әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында сүз белән «Казан утлары» журналының тәнкыйть бүлеге мөдире Ринат Мөхәммәдиев чыкты. Өлкән әдип Нәби Дәүли, язучы Мәдинә Маликова, шагыйрьләрдән Рәшит Гәрәй һәм Әхмәт Рәшитов үзләренең әсәрләреннән өзекләр һәм шигырьләр укыдылар.

## ШӘРЫК ТЕЛЛӘРЕ БЕЛГЕЧЛӘРЕНЕҢ ХАЛЫКАРА СИМПОЗИУМЫ

Мәскәү шәһәрендә социалистик илләрнең шәрык телләре белгечләре «Шәрык тел белемесенең теоретик проблемалары» дигән

темага симпозиум үткәрделәр. Утырышларда шәрык телләрен өйрәнүнең актуаль мәсьәләләренә багышланган йөз иллеләп доклад тыңланды. «СССРда тюркологик тикшеренүләрнең торышы һәм бурычлары» дигән темага академик А. Н. Кононов доклад ясады. Фикер алышуда күренекле тюркологлардан Рона-таш (Венгрия Халык Республикасы), А. Дубинский һәм В. Зайончковский (Польша Халык Республикасы), Г. Камбалсуран (Монголия Халык Республикасы), Э. Р. Тенишев, И. Ф. Вардуль (Мәскәү), М. С. Джикия (Тбилиси), С. Кудайбергенов (Фрунзе), В. И. Цинциус (Ленинград) һәм башка галимнәр катнашты.

Казаннан филология фәннәре докторы, профессор М. З. Зәкиев «Идел буе төрки халыклары этногенезы», филология фәннәре кандидаты Ф. А. Ганиев «Төрки телләрнең аналитик формологиясе: бурычлар һәм проблемалар» дигән темаларга чыгыш ясадылар. Профессор М. З. Зәкиев үзенең докладында Идел буе төрки халыкларының килеп чыгышы проблемасына багышланган хезмәтләргә тукталып, бу мәсьәләнең катлаулылыгына, самодержавие чорында бозып аңлатылуына басым ясады, хәзерге татар теленең барлыкка килүе мәсьәләсендә үз фикер һәм карашлары белән уртаклашты.

Симпозиум социалистик илләр галимнәренең шәрыкне өйрәнүдә киң колач белән бердәм рәвештә хәрәкәт итүләрен күрсәтте. Социалистик илләр шәрык телләре белгечләренең икенче симпозиумын 1980 елда Варшавада үткәрергә карар ителде.

## АРХЕОГРАФЛАР ТАБЫШЫ

Казан университеты Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең борынгы кулъязмалар бүлегенә XVI гасырда яшәгән татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» һәм «Төхфәи мәрдән» поэмаларының тагын бер кыйммәтле кулъязма нөсхәсе тапшырылды. Археографлар аларны Пермь өлкәсендә табып алганнар. Китапханә хезмәткәрләре, университет галимнәре һәм студентлары соңгы елларда гына Идел, Урал буе, Себер, Оренбург, Рязань һәм башка өлкәләрдәге авылларда йөреп, төрки-татар, гарәп, фарсы телләрендә язылган ике меңгә якын иске кулъязма алып кайттылар.

Касыйм шәһәрендә яшәүче укытучы Ф. Бәширова университет китапханәсенә XIV—XVIII гасырларга караган күп санлы кулъязма китаплар бүләк итте.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210